# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Гөлүсә БАТТАЛОВА. Айсыз авыл. *Поэма.* ....3
Зөлфәт ХӘКИМ. Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?.. *Роман.* ....8
Рашат НИЗАМИ. Күтәрелдек без дә түбәннән. *Шигырьләр.* ....65
Асия ЮНЫСОВА. Мәк чәчәге. *Бәян.* ....69
Сирень ЯКУПОВА. Күңел галәмендә һич тынгы юк... *Шигырьләр.* ....108
Солтан ШӘМСИ. Әшрәф баба хөҗрәсендә. *Хикәя.* ....112
Әлфия СИТДЫЙКОВА. Мин кыяда басып торам... *Шигырьләр.* ....125

ЯҢА ИСЕМНӘР

Илфак ХАФИЗОВ. Хикәяләр. ....129

«МӘЙДАН – БАТЫРЛАР ӨЧЕН!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Батыр асты. *Хикәя.* ....137

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Әзрәт АКБАЕВ. Белгәнемне язам манып канга...
*Шигырьләр.* (Зөлфәт ХӘКИМ тәрҗемәләре) ....147

ЮБИЛЕЙЛАР

«Дин белән фән тора...» *(Харис хәзрәт САЛИХҖАНга – 95 яшь).*
*Әңгәмәдәш – Ландыш ӘБҮДӘРОВА* ....150
Рафис КОРБАН. Картаюны белмәс картлач. *(Рифат СВЕРИГИНга – 90 яшь).* ....153
*Милләттәшебез:* Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Татар фәне – Кыргызстанда. ....159
*Замандашыбыз:* Ландыш НӘСЫЙХОВА. Бердәмлекне көч итүче ханым. ....163

КИТАП КҮЗӘТҮ

Рәҗәп БӘДРЕТДИНОВ. Хатирәләрне барлаганда *(әдәбият галиме Хатыйп Миңнегуловның «Озын гомерем хатирәләре» (икенче кисәк) исемле китабы чыгуы уңаеннан).* ....166
*Хәтер:* Ренат ХАРИС. Урманче һәм Такташ. Истәлек. ....172

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. XVI гасырның икенче яртысы – XVIII йөзнең уртасында Идел-Урал төбәгендә ислам дине. ....175

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

«Кайда сез, ирләр?» дигән иде... (*Рөстәм Мингалимнең тууына – 85 ел*). ....184
Олпат мөхәррирләр затыннан. *(Наис Гамбәрнең тууына – 75 ел). Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....185
*Печән базары:* Халисә МӨДӘРРИСОВА. Сайлау. Юмористик хикәя. ....186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 8 (1198) 2022*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 27.07.2022, график буенча 27.07.2022, басылып чыгу вакыты 01.08.2022
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-2280. Тираж 7594.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2022 ел



Гөлүсә
Батталова

# АЙСЫЗ АВЫЛ

ПОЭМА

*XX йөздә Октябрь инкыйлабы тудырган давыллы елларда нахакка гаепләнеп, тереләй күмелгән Әсхапҗамал һәм Хисмәтулла Садыйковларның, ил буенча нәкъ шундый ачы тәкъдиргә дучар булган йөзәрләгән-меңәрләгән корбаннарның рухына багышлыйм.*

**1**

Каргышмы бу?
Күкләр, әйтегезче!
Бәддогамы дәвер чатында?
Тәүбә-фәлән кабул ителмәслек
Кыямәтме әллә якында?

Күзләр эзли таянырлык нокта,
Күкрәк читлегендә җан уйный.
Азан?..
Хәтер төпкелләре такыр...
Биш вакытка бүген җил улый.

Җаһил чор да түгел.
Күптән үткән...
Иман да бар...
Төсле...
Тирәндә...
Нинди уйлар кереп чыгадыр ла
Чабатаны түргә элгәндә?

Авыл күге – ятим.
Үксез бу җир.
Манарасыз.
Гамьсез.
Хәтерсез.
Тәкбир әйтеп, гает таңын көткән,
Сукбай кебек картлар, кадерсез.

---

Гөлүсә БАТТАЛОВА (1982) – *шагыйрә; «Бер йотым бәхет», «Кесә тулы – давыл!» исемле китаплар авторы. Әтнәдә яши.*

Айсыз авыл.
Инде гасыр җөе
Урагандыр агач үзәген.
Кемнәр белсен хәзер – шушы җирдә
Нахак сүзнең гомер өзгәнен.

Кемнәр белсен?
Бары ялгыз кабер
Юл читендә кала үткәндә.
Кем ваемлар, заманына күрә
Йөрәгендә йозак йөрткәндә?

**2**

Хәзрәт корбан чалды.
Яңа туган сабыена атап.
Таң белән.
Авыз итәр барча авылдашы,
Өлеш чыгар бүген табыннан.

Бер сөенеч булыр.
Юкса, күңел
Сулык-сулык килә чарасыз.
Кыямәтен көтә бәхетсезләр,
Бу дөньяда калып җәзасыз.

Манарасы ауды.
Аллаһ йорты
Сүзсез генә, тып-тын елады.
Айсыз калган авыл көчекләре
Кара төндә шомлы улады.

Бәргәләнде йөрәк.
Авылдашлар
Күзендә ул аңлау эзләде.
Бәгырьләрне бәйләп торган кыллар
Өзелделәр шартлап.
Түзмәде...

Корбан чалды хәзрәт.
Гакыйкага.
Бер Аллаһка аны багышлап.
Дәва булмас микән хәсрәтеннән?
Дәва булмас микән сагыштан?

Шулчак шыгырдады җил капкасы –
Бусагада – Кызыл Әтүтән*.
Нишләп йөри?
Юкса, соңгы сүзләр
Айсыз калган чакта әйтелгән!

Кунак шундук корбан канын сизде,
Әсәренде төмсә карашы.

* Әтүтән – адъютант. Биредә аллегорик исем рәвешендә бирелә.

Сер бирмәде үзе.
Тик шулай да
Сатты аны чырай карасы.

– Колхозга кер!
Аллаң ярдәм итмәс,
Власть безнеке хәзер, яшибез!
Агу чәчмә намаз-нияз диеп,
Себер китәр, юкса, башыгыз!

Дәшми түзде хәзрәт.
Тешен кысты,
Бисмилласын эчтән пышылдап.
Ут ялмады җанын, ялкын алды,
Тыныч булып калды тышыннан.

– Ник дәшмисең? Әй, син, Алла колы,
Табармын мин сиңа авызлык!

...Күк күкрәде. Яшен ярып үтте.
Җирдә хаким булды явызлык.

Каһкаһәләп көлде, төкеренде,
Елтырады күзләр биешеп.
Сабырлыгын йодрыгына кыскан
Хәзрәт җаны килде бөрешеп.

– Авызлыгын, шиксез, табарсыз да,
Манараны җәһәт кисәрсез.
Сорау көне килгәч, җәһәннәмнең
Кызуына ничек түзәрсез?

Язмасын ла берүк газиз Раббым
Тезләнергә кяфер алдына!

– Мәчет корты, колагыңа киртлә:
Дөнья хәзер миңа табына!

Буйсынмасаң, сүзем кыска булыр:
Ходаем дип күпме селкенмә,
Язмышыңа балта чапсам әгәр,
Аллам ташлады дип үкенмә!

...Җил капкасы ыңгырашып калды,
Гамьле таңның яме җуелды.
Күк йөзенә түгел, баш очына
Шом сугарган болыт җыелды.

**3**

Кан кайнады Кызыл Әтүтәннең,
Сулыш авырайды ачудан.
Искәрми дә калды, шул арада
Ызбасында ишек ачылган.

Тыны капкан колхоз көтүчесе:
– Харап булдык! Бер баш мал җитми!
Югалдымы, бурлар эшеме соң?
Безнең генә моңа теш үтми.

Уй йөгерде кинәт Әтүтәннең
Мәкер тулган кызыл башына.
Хөсет катыш көлемсерәү белән
Ятьмә үреп салды каршына.

– Корбан чалдым дисең инде, хәсрәт!
Атаң малы диеп белдеңме?
Җәһәннәмең белән куркытасың –
Мин әзерлим сиңа үлемне!

Әйдә, ялын, Аллам, гомер бир дип!
Әйдә, үкер хәзер бүредәй!
Син суфыйны атып егу бик аз,
Күмү кирәк җиргә!
Тереләй!

**4**

Чирү-чирү шайтан туй ясады –
Җан кыелды җирдә төн ката.
Авыл телсез булды.
Авыл – сукыр...
Тып-тын гына әнә таң ата...

Күңелләргә кереп курку поскан,
Усалныкы яңа замана.
Башны иеп, бер карусыз яшә –
Анысы да килер таманга!

Бу яшәүне яшәү диеп булса!
Җан асраудыр, бәлки, дөресе?
Кемнәргәдер – казан төбен кыру,
Ә кемгәдер – ашның өресе.

Ә колакта...
Түгел!
Бәгырьләрдә
Яңгырап торыр соңгы сүзләре:
– Айсыз тилмерегез!..
Туфрак күмде
Чиксезлеккә баккан күзләрне...

...Тәүлек узгач, басу капкасыннан
Ир-ат керер бәрән җитәкләп:

– Безнең авыл көтүенә килеп
Кушылды бу! – дияр әйдәкләп, –
Сезнең колхоз малы түгел микән?
Адашкан ул, йөри каңгырап.

Авыл айныганда – вакыт үткән...
Кайтавазы калды яңгырап...

**5**

Айсыз тилмерегез...
Ниләр уйлап,
Җан әрнүе чыккан өзелеп?
Үз кардәшен гүргә керткәннәрнең
Кысыбрак тот, тәкъдир, тезгенен!

Пәйгамбәрләр алышынып торган
Кавемнәрдән ниләр көтәсе?
Сатлык иманыңны түш кесәңдә
Югалтмыйча ничек йөртәсе?

Айсыз авыл.
Җилеп үткән дәвер
Үзгәртмәгән таныш сурәтне.
Хәтер саумы?
Тарих нигә дәшми?
Гамьсез тынлык өзә үзәкне.

Ялгыз кабер күптән телсез инде...
Җил искәндә, кура сызгыра.
Такыр юлда
Киткәннәрнең эзен
Тузан куып, вакыт туздыра.

Айсыз авыл.
Манарасыз авыл.
Ни бар тагын котны алырлык?
Кыйбла югалганга гасыр инде –
Иңнәр чыдаталмас авырлык.

Шом куера вакыт үткән саен:
Гөнаһларның арта дәһшәте.
Нуры качкан меңнәр яши бүген
Салып ташлап иман бишмәтен.

Айсыз авыл – берәү.
Айсыз җаннар
Әрдәнәләп өеп куярлык!
Әҗәленә чаклы кемнәр күрер
Җирдә үксезлеген, уянып.

Бәддогамы?
Алда ниләр язган?
Ниләр җуеп, ниләр табасы?
Телдә – дога.
(Бәлки, тәүбә?)
Күкләр
Айсыз язмышлардан аясын...

Зөлфәт
Хәким

# БЕР СӘГАТЬТӘ НИЧӘ МИЗГЕЛ БАР?..

РОМАН

**18**

Уянганда таң беленеп килә иде инде. Самат сикереп торды да пистолетын капшап карады. Ортвин үз сәкесендә аңа елмаеп карап утыра иде. Ник елмая әсир? Нәрсә булган? Ул бит Саматны үтерә ала иде.

– Wasser... (Су) – диде Ортвин, өстәлдәге чәйнеккә ымлап. – Ich habe dir Wasser gebracht (Мин сиңа су алып килдем). – Ул бер кружкага су салып өстәлгә куйды, икенчесен Саматның үзенә сузды. – Himbeeren gesammelt. Iss, bitte (Кура җиләге җыелган. Рәхим итеп, аша).

Самат шаккатты – ул йоклап ятканда, Ортвин, чыгып, чишмә буенда ишле булып үскән кура җиләге җыйган һәм су алып кергән иде. Саф һавалы урманда яхшы йоклаганнан соң күренеп тора, Ортвинга хәл кергән, йөзе шат, елмая иде.

Самат кружкадагы кура җиләгенә карап елмайды. Кура җиләге... Светаның фамилиясе – Малинина... Света үзе дә кура җиләге кебек шул.

– Рәхмәт, – диде Самат, бер атна эчендә, ниһаять, әсиргә карата тавышына кырыслык кертмичә.

Җитлегеп пешкән кура җиләге бик татлы, чишмә суы да искиткеч тәмле иде.

Тышта коеп яңгыр ява башлады. Сәгать әле иртәнге дүрт кенә, бераз көтәргә кирәк, туктамасмы, дип уйлады Самат.

Нинди татлы йокы булды бүген! Ул бит Светаны төшендә күрде! Уянмаска иде, озаграк дәвам итсен иде ул төш. Аның өчен бөтен нәрсә үзгәрде. Сугыш юк, дөнья тынлык алган, Света да еракта түгел, кайдадыр шушы тирәдә генә шикелле иде.

Самат аңлатып булмаслык рәхәтлек тойды. Хәзер инде аның каршысында әсир түгел, Ортвин Мейер атлы гап-гади кеше елмаеп утыра иде. Саматны илһам көче Җирдән югарырак күтәрде, бу мизгелләрдә ул үзен барысыннан да, бөтен нәрсәдән дә югарырак вә өстенрәк хис итте. Аның бәһасез зур байлыгы бар бит хәзер – Света һәм аның белән бергә кичергән өч көн, өч төн!

*Ахыры. Башы узган санда*

Ул Ортвинга, ишарәләп, тәрәзә яныннан түрдәге сәкегә күчеп утырырга кушты. Аннары саклык белән, кадерләп кенә, янчыктан Света биргән блокнот белән каләмне алды. Блокнот тышлыгының эчке ягында Самат эре хәрефләр белән үзенең тулы исемен һәм бала чактан ук Казандагы яшьтәшләре тарафыннан тагылган «Чукмар» кушаматын язып куйды, чөнки кушаматы үзенә ошый, хәтта аның белән горурлана да иде: «Гарипов Самат («Чукмар») Габделхәй улы. 1924 елны туган.»

Шуннан соң, сәкегә кырын ятып, тәрәзәдән саран гына төшкән яктылыкта шигырь яза башлады.

Икәү генә калдык бу дөньяда
Бүген Вакыт бармы, юкмы ул?
Булса, бер сәгатьтә ничә мизгел,
Безнең мәхәббәттә күпме ул?

Яу кырында әҗәл очраса да,
Минем җанда калыр сөйгән яр,
Сине искә алып сөяр өчен,
Мизгелләрем минем һәрчак бар.

Йөзеп чыксам афәт дәрьясыннан,
Батырмаса кайгы-диңгезләр,
Савыктыра алыр мең ярадан
Сине искә алган мизгелләр.

Бәһасе дә юк бит мизгелләрнең,
Күпме тора синең сулышың?..
Мәхәббәтнең изге җанын кыю
Хәлләреннән килмәс сугышның.

Кадалса да пуля күкрәгемә,
Тәнем ятса яуның кырында,
Мәхәббәтнең сайрар кошы булып,
Җаным очар синең янында.

Мәңгелеккә дәгъва кыла ала
Безнең бергә булган минутлар.
Бер сәгатьнең күпме мәле була,
Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?..

Саматның әле моңарчы шигырьне болай тиз язганы юк иде. Ул, баш астына кулларын куеп, сәкегә чалкан яткач, Ортвин, торып, әкрен генә өстәл янына килде һәм ачык блокнотка күз салды.

– Sind das Gedichte? (Шигырьме?) – диде ул һәм, гаҗәпләнеп, Саматка карады.

– Аңламадым? – диде Самат, гәүдәсен калкытып.

– Sind das Gedicht die du Svetlana gewidmet hast? (Син бу шигырьне Светага багышлап яздыңмы?)

Самат Ортвин әйткәннән «Светлана» сүзен генә аңлады һәм аны нәрсә кызыксындырганына төшенде.

– Әйе, Светага багышлап, шигырь яздым, – диде Самат һәм беренче тапкыр әсиргә елмаеп карады.

– Svetlana ist ein sehr schones, gutes Madchen (Светлана бик матур, әйбәт кыз), – диде Ортвин.

Самат аның бу сүзләрен аңлады.

– Әйе, ул искиткеч гүзәл кыз, – диде Самат моңсу тавыш белән.

Ортвин, башын чак кына иеп, үз телендә ниндидер шигъри юллар әйтте һәм соңыннан:

– Iohann Wolfgang Goethe (Иоганн Вольфганг Гёте), – дип, түрдәге сәкегә барып ятты.

– Гётене ишеткәнем бар, – диде Самат. – Белүем буенча, бөек кешеләрегез шактый сезнең. Шундый шагыйрьләрегез була торып, нишләп сез дөньяны канга батырдыгыз?! Сез безгә афәт алып килдегез!

Ортвин Саматның кинәт ачуы кабарганны аңлап, капылт кына стенага борылып ятты.

Әмма Самат барыбер бу аерым бер алман кешесен инде дошман итми иде. Хәтта хәзер ул аңа юлдаш кебек тоела башлады. Бу әсир булмаса, Света белән очрашырга насыйп булыр идемени? Хәзер аның уенда, күз алдында гел Света гына. Сагына башларга да иртә бит әле аны, кичә генә бергә иде алар, менә-менә тагын очрашырлар кебек, ул кайдадыр якында гына шикелле, эндәшсәң, килеп җитәр сыман иде.

Ашыйсы килә башлады. Янчыкта Света биргән ипи белән алма бар лабаса!

Конвоир белән әсир ипи белән алманы тәмләп ашадылар. Самат өчен бу ризык кына түгел, зуррак нәрсә иде – Света үстергән, Света җыйган, Света юган алма бит бу. Ортвин исә Саматның яхшы мөгамәләсеннән бөтенләй җанланып китте һәм берничә тапкыр үз телендә:

– Sehr lecker, sehr lecker! (Бик тәмле, бик тәмле!) – дип кат-кат кабатлады.

Самат елмаеп куйгач, Ортвин тагын да кыюланыбрак китте:

– Bist du kein Russe? (Син рус түгел бугай?) – дип сорады ул.

– Найн, – диде Самат, сорауны аңлап. – Мин – татар! Их бин айн татар.

– Ich bin Deuscher (Ә мин алман кешесе), – диде Ортвин моңсу тавыш белән.

– Беләм. Күренеп тора. Кем икәнең чыраеңа язылган, – диде Самат коры гына.

– Woher kommst du? Wo wurde er geboren? (Син каян? Кайда тудың?)

– Нәрсә быр-быр киләсең? – диде Самат, аның ни әйткәнен аңламыйча.

– Ich komme aus Frankfurt am Main. Wo hast du vor dem Krieg gelebt? (Мин Франкфурт-на-Майне шәһәреннән. Син сугышка кадәр кайда яшәдең?)

Самат аңламагач, Ортвин башкачарак әйтергә булды: – Ich wohne in Frankfurt… Die Stadt Frankfurt. Und du? (Мин Франкфуртта яшәдем... Франкфурт каласы. Ә син?)

– Казан каласыннан мин, – диде Самат, ниһаять, аңлап. – Казан! Татарстан! Штадт Казан!

– Kasan... – дип үзалдына кабатлады Ортвин һәм: – Was arbeitest du vor dem Krieg? (Сугышка кадәр кем булып эшләдең?) – сорады.

Самат йөзен чытып, башын читкә борды, бу – аңламыйм дигәнне аңлатуы иде аның.

Ортвин уйчан кыяфәт белән:

– Ich bin ein Meister der Reparatur von Elektrogeraten. Mein Vater auch, – дип, әтисенең һәм үзенең электр җиһазларын төзәтүче осталар булып эшләүләрен әйтте.

Яңгыр чак кына сибәли, әмма иртәнге кебек көчле түгел иде. Хәзер үк кузгалып, Ортвинны тизрәк илтеп тапшырырга да аннан соң үз частен куып җитәргә, тизрәк дошманны оясына кадәр куарга, тар-мар итәргә кирәк. Тизрәк туктатырга кирәк бу сугышны! Тизрәк җиңәргә дошманны! Һәм тизрәк Света янына барырга кирәк!

– Геен, – диде Самат. – Яңгыр туктаганны көтеп тормыйбыз. Блокнот чалбар кесәсендә чыланыр инде, – дип куйды ул үзалдына. – Света биргән янчыкта да юешләнәчәк.

Блокнотны ул Ортвинның пинжәгенең эчке кесәсенә тыгып куярга булды.

– Яңгыр туктаганчы синең кесәңдә булсын, – диде Самат. – Верхнегорскида алырмын. – Һәм әсиргә блокнотны пинжәкнең куен кесәсенә тыгарга кирәк икәнне ишарәләп аңлатты.

Ортвин:

– Gut, – дип, блокнотны кесәгә тыгып куйды.

Инде чыгып китәбез дигәндә генә, алан буйлап берәүнең йөгереп килгәнен башта Ортвин күреп алды.

– Jemand flieht hierher (Монда таба кемдер йөгерә), – диде ул Саматка.

Самат, тәрәзәдән карап, урманчы Тимофейны танып алды. Артына карый-карый йөгереп килеп, ул өйгә томырылып керде һәм беравык сүзен әйтә алмыйча еш-еш сулап торды:

– Нимес дивизиясе... якында... – диде ул, ниһаять, ике кулын да күкрәгенә куеп, гүя йөрәге атылып чыгар дип куркып. – Урманның теге ягында... Елганы чыгарга җыенучы сәвит гаскәрләренә арттан китереп бәрергә җыеналар. Урап ук киләләр... Район үзәгенә хәзер үк барырга кирәк... Җитешсәгез инде... Өч йөзләп нимес әнә теге яктан килә, дивизиягә кушылыргадыр, – дип өстәде ул үзе килгән якка, урман эченә күрсәтеп. – Әсиреңне ташлап кач тизрәк! Нигә бу мәхлук сиңа? Кач! Сине үзеңне пленга алып тормаячаклар, атып үтерәчәкләр.

Тимофей бүтән бер сүз дә әйтмәде, чыгып китте һәм килгән якка түгел, олы юл тарафына йөгерде.

Ә Самат соңгарак калды – алан кырыннан сузылган юлда немец хәрбиләре күренде.

Юл урманчы өеннән ике йөз адым чамасы читтән уза, дошман колоннасы шуннан ашыга-ашыга үтеп бара иде. Урманчы әйткән өч йөзләп немец шушыдыр инде... Колонна бара да бара... Полк калдыкларыдыр, ахрысы...

Саматның үзәге куырылды. Менә моны ул бөтенләй көтмәгән иде. «Курыкмаска, каушамаска, югалып калмаска!» – дип, эчтән боерды ул үзенә.

Ортвин сораулы вә ялварулы караш белән Саматка карады. Ә Саматның башында бу мәлдә бер генә уй чыңлады – аның биш патроны бар – дүртесен дошманнарга атса, берсе – үзенә кала.

– Тс-с-с, – дип усал итеп ысылдады Самат һәм пистолетын чыгарды.

Бу «Кычкыра күрмә!» дигәнне аңлата иде.

Колонна кызу адымнар белән атлады, кайберләре бу ташландык йортка карап-карап үттеләр.

Ортвин дулкынланып калтырана башлады. Аның ватандашлары янәшә, әнә, алар үтеп баралар, нәкъ менә хәзер котылу мөмкинлеге бар. Самат пистолетны әсиргә төбәде. Ортвин аңлый – сугышып, Саматны җиңә алмаячак, ташлана калса, Самат аны үтерәчәк, ишетерләр дә килеп, үзен үтерерләр дип курка торганнардан түгел. Йорттан йөгереп чыккан сурәттә дә Самат аның артыннан атачак, шуңа күрә Ортвин әле генә шигырь язып яткан конвоирның күңелен ялынып-ялварып җибәтергә теләде.

– Samat! Lass mich gehen! – дип үтенде Ортвин. – Ich verrate dich nicht. Ich werde sagen, dass niemand im Haus ist und nichts. (Самат! Җибәр мине! Мин сине сатмам. Бу өйдә беркем дә, бернәрсә дә юк, диярмен).

Самат немецның ни әйткәнен тәгаен аңламаса да, аның ни теләгәненә төшенде.

– Найн! – диде Самат һәм пистолетын чак кына өскә күтәрде.

Алга таба нишләргә һәм бу хәл ни белән тәмамланасын Самат бу минутларда белми иде. Берүк Ортвин кычкыра башламасын, берүк чыгып йөгерергә талпынмасын.

Шулчак Саматның йөрәге жу итте – ике немец, колоннадан аерылып, читкә чыгып бастылар һәм, беркавым бу тарафка карап торганнан соң, әкрен генә йортка таба атладылар.

Ортвин белән Саматның күз карашлары очрашты.

– Ich gehe. Ich muss gehen. Das wird besser. Du und ich, (Мин чыгам. Миңа чыгарга кирәк. Шулай яхшырак булачак. Сиңа да, миңа да), – диде Ортвин, калтыравык тавыш белән Саматка караган килеш, ишеккә таба, бер-ике адым читкә атлады.

Самат бармагын курокка куйды, әмма бу мизгелләрдә Ортвинның чыгып китүенә ул каршы түгел иде инде.

Ортвин, Саматның пистолетыннан күзләрен алмыйча, курка-курка, артка таба чигенде, җилкәсе белән этеп, ишекне ачты һәм тышка чыгып, ике кулын да болгады.

Самат, ишек ачылганда күренмәс өчен, аркасы белән стенага «сеңде». Ул ишек ачык калыр дип курыккан иде, әмма Ортвин, үзе артыннан ишекне каты иттереп япты һәм Самат, стенага елышкан килеш, кырынлап, тәрәзәдән карап торды.

Ортвин аксый-аксый, ватандашларына таба атлады:

– Freunde! Bruder! Mein Name ist Ortwin Meyer. Ich bin Soldat in Deutscland. Ich bin fus russischer Gefangenschaft geflohen. Ich lebe! (Дуслар! Туганнар! Минем исемем Ортвин Мейер. Мин – Германия солдаты. Мин пленнан качып котылдым. Мин исән!)

Бетте баш! Хәзер ул монда кызылармеец бар дип әйтәчәк тә... Самат инде үзе өчен карар кабул итте – аны берничек тә әсир итә алмаячаклар, бирелмәячәк ул! Берүк пистолет кына хыянәт итмәсен, осечка гына була күрмәсен!

Ортвин колоннадан аерылган ике немецка нәрсәдер аңлатты. Берсе йортка таба ишарәләгәч («Нинди йорт, кемнеке, тагын кешеләр бармы?»

дип соравыдыр инде), Ортвин, кул селтәп, нәрсәдер җавап бирде. Шуннан соң өчесе дә, колоннага ияреп, китеп бардылар.

Самат тирән сулыш алды, әмма йөрәк барыбер өскәрәк менеп, өңер янында ярсып тибә һәм киеренкелектән бөтен тән тирләп, манма су булган иде.

Димәк, Ортвин аның турында әйтмәде. Ташландык йорт, анда беркем дә, бернәрсә дә юк, дигәндер. Ортвин кеше булып чыкты, фриц булса да... Ярар, Ортвин аны сатмады... Ә шулай да, берәрсе килеп, йортны тикшерергә теләсә?.. Саматка колоннада өч йөз түгел, өч йөз мең кешедер кебек тоелды.

Ниһаять, колоннаның койрыгы урман эченә кереп югалды.

Самат, күзләрен тәрәзәдән алмыйча, сәкегә утырды.

Котылдым бугай... Исән калдым бит. Инде харап булам дигәндә... Котылдым.

Самат алга таба нишләргә, бу полк турында кемгә ничек хәбәр итәргә, дип, баш ватты. Кинәт: «Нишләп һаман монда утырам соң мин?! Немецлар тагын килеп чыгарга мөмкин бит», – дигән уй аны урыныннан кузгатты.

Ул саклык белән генә йорттан чыгып, немец полкы киткән якка кача-поса юнәлде һәм юлдан ерак китмичә, агачлар арасыннан дошман колоннасын күзәтеп барды.

Әнә, немец полкы урман юлыннан бара. Бу юл, Березняк белән Верхнегорск арасындагы олы юлны кисеп, төньякка алып китә. Болар уңга – Верхнегорскига барырлармы, сулга – Березнякка китәрләрме? Ничек булса да, нишли ала инде ул?.. Барыбер Верхнегорскига болардан алдан барып җитешә алмаячак. Березнякка юнәлсәләр?.. Света качарга җитешер микән?.. Хәер, болар бик ашыгалар, Березнякта озак тоткарланмаслар, мөгаен.

Әмма немец колоннасы сулга да, уңга да китмәде, барган юл белән туп-туры төньяк тарафына юнәлде.

Ниһаять, Самат җиргә ятып хәл алды. Исән калды калуын, әмма приказны үти алмады бит ул. Аның каравы, Ортвин аны үзләренекенә белгертмәде, сатмады. Мөгаен, йортта кеше бармы дигәч, юк дигәндер, юкса, кереп, Саматны үтерерләр иде.

Шунысы аяныч – Ортвинның пинжәк кесәсендә Света биргән блокнот китте. Ә анда Светага багышланган шигырь һәм, иң мөһиме – аның Березняктагы адресы язылган иде.

**19**

Мюльхайм-ан-дер-Рур шәһәренә инде караңгы төшеп килә иде. Ә алар этиләре турында сөйләшеп туймадылар. Бу әңгәмә аларны һич кенә дә ялыктырмады, киресенчә, һәр икесе өчен яңа детальләре ачыкланган вакыйга тирәсендә алар тагын озын-озак итеп, әңгәмәне дәвам итәргә әзер иде.

Профессор Винфрид Мейер этисенеке кебек кыска төз борынлы, бәләкәй соры күзле, аның яртылаш пеләш башы чәче куе чакта да киң маңгайлы булган, йөзе төгәл пропорцияле булмаса да, озын гәүдәле бу докторның, гомумән алганда, кыяфәте бик затлы, акыллы һәм читтән үк олпат шәхес икәнлеге күзгә ташлана иде. Өстендәге кәчтүме дә, күренеп тора, кыйммәтле һәм профессор өчен махсус тегелгән шикелле иде.

Хәйдәргә дә әтисеннән күп нәрсә күчкән, аны да яшьрәк чакта казакъка охшатучылар була иде. Елмайганда, тач Самат инде, диләр иде туганнары. Хәзер инде олы яшьтә, чәчкә чал кергәч, картая төшкәч, аны әтисе белән чагыштыру мөмкин түгел, чөнки Самат бу яшькә кадәр яши алмады бит. Шулай да, Саматның фотосурәтен карап чагыштырсаң, чит кеше дә, һичшиксез, бу – Хәйдәрнең әтисе дияр иде.

Әйтерсең лә, еллар узганнан соң, Ортвин белән Самат тагын очрашканнар. Гүя алар 1944 елның августыннан 2014 ел августына менә шушы яшьләрендә килеп җиткәннәр дә, уллары Винфрид һәм Хәйдәр әверелеш-рәвешендә Германиянең шушы кечкенә шәһәрендә бер-берсен тапканнар.

– Әти, бер ай чамасы тылдагы госпитальдә ятканнан соң, янә фронтка үзенең частена кайткан, – диде Винфрид Мейер. – Сугыш тәмамланганда, ул американыларның оккупация зонасында була. Төрле тикшерүләрдән соң, аны азат итәләр. Сугыш беткәч, әти үз кәсебенә тотына, һөнәрханәсен торгыза. Кызганычка каршы, бабай исән булмый инде – шәһәрне бомбага тотканда һәлак булган. Әти табибә кызга өйләнә, 1950 елда беренче балалары туа – минем апам... Ул врач-педиатр. Мин 1955 елда тудым... Хатыным да «Шаритэ»дә, врач-маммолог булып хезмәт итә. Кызыбыз – мәктәптә укытучы булып эшли, улым музыкант, бик талантлы егет, үзе көйләр дә яза.

Хәйдәр дә әтисе турында хәтерендә калганнарын һәм үзенең тормышының кайбер әһәмиятле өлешләрен сөйләде.

Көтелмәгән яңалык һәм әйтеп бетергесез зур вакыйга булып килеп чыккан могҗизалы бу очрашуга икесе дә чиксез шат иде.

– Әти ул вакыйганы бәян иткәндә, миңа ун яшь кенә иде, – диде Хәйдәр. – Сагынып, якты сагыш белән сөйләгән иде ул. Сугыш вакытында миңа берничә бәхетле көн насыйп булды, дигәнен аермачык хәтерлим. Света дигән кызны искә ала иде ул, әмма мин, бала буларак, аларның мөнәсәбәтләрен аңларлык түгел идем әле.

– Минем әти дә алар турында тәфсилләп сөйли иде, – диде Винфрид. – Алар арасындагы мәхәббәтне сизеп, аңлап яткан ул. Әтиемнең качарга мөмкинлекләре булган... Теге авылның иске лапасында ятканда да, Иван Константиновичның операциясеннән соң да, урманда чакта да... Котылырга нияте дә булган аның. Әмма качмаган. Качып, кая барыр иде инде ул? Тагын тотсалар, шундук үтерүләре ихтимал. Смерштан курыкмаган – ул бит радист түгел, ә фәкать радио аппаратларын, элемтә корылмаларын төзекләндерүче булып хезмәт иткән. Диверсант түгел, гап-гади элемтәче булган ул. Сугышка кадәр бабай белән бергә Франфурт-на-Майне каласында радиоалгычлар рәтләүче булганнар, ә ул вакыт өчен андый һөнәр алдынгы профессия саналган, аларның үзләренең остаханәләре тирә-якта бик абруйлы санала иде. Смерш кулына эләккән очракта да, әтине үлем җәзасына хөкем итмәгән булырлар иде.

– Мин шуны уйлап куйдым әле... – диде Хәйдәр, бер ноктага текәлеп. – Дөньяда булган һәрбер нәрсә, һәрбер кеше каядыр югалып гаип булмыйдыр, без күрмәгән, аңламаган яссылыкта, без абайламый торган формаларда, шушы дөньяда яшәвен дәвам итәдер. Безнең бу очрашуыбыз, бәлки, 1944

елгы вакыйганың дәвамыдыр... Балаларыңның, онықларыңның язмышы да синең теге яки бу мизгелләрдә нинди карар кылуыңа, нинди адым ясавыңа бәйледер. – Хәйдәр профессорга карап елмайды. – Урманчының ташландык йортында әтиләребез дөрес карар кабул иткәннәр бит...

– Әлбәттә, – диде Винфрид. – Бәлки, аңлап түгелдер, интуиция белән сиземләп, үзләрен дөрес тотканнар дияр идем мин.

– Сугыш кагыйдәләре буенча, икесе дә трибуналга лаек булганнар инде алар, – диде Хәйдәр, көлемсерәп. – Кызылармеец Гарипов Самат – приказны үти алмаганы өчен, вермахт солдаты Ортвин Мейер – йортта дошман качып калганны әйтмәгәне өчен.

– Алар бер-берсен дошман итми башлаганнар инде. Мөнәсәбәтләр үзгәрү дә мизгелләр эчендә булырга мөмкин бит. Кеше бер халәттә бер мизгелдән артык тора алмый. Аның халәте гел хәрәкәттә, гел кыймылдап тора, шуңа күрә бер үк фикерне бер үк сүз белән әйтү дә башкачарак мәгънәгә ия була, бер үк сүзгә төрле вакытта төрлечә мәгънә салына. Чөнки кешенең халәте гел үзгәреп тора, гамәл кылу да төрле мизгелдә төрлечә булырга мөмкин.

– Безнең әтиләребез белән булган ул вакыйгада батырлык, геройлык, искитәрлек һәм тарихта язып калдырырлык нәрсә юк шикелле. Әмма ул вакыйгада бөек күренеш күрергә мөмкин – ике кешенең кеше булып кала алуларын. Ахыр чиктә, алар бер-берсен коткарганнар булып чыга бит. Еллар узгач та, һәрикесе якты вакыйга итеп саклаганнар бит ул вакыйганы. Тикмәгә түгел бит бу. Кеше хәтерендә синең якты хатирә булып саклануың – тарихта уйдырма каһарман булып язылуга караганда, югарырактыр, әһәмиятлерәктер.

**20**

Бер атна узгач, якшәмбе көнне Винфрид Мейер килеп, Хәйдәрне тагын шаккатырды – зур портфелендәге җыйнак кына күн папкадан саргаеп, таушалып беткән блокнот алды һәм:

– Моны әтием бик кадерле әйбер итеп саклады, – дип, Хәйдәргә бирде.

Хәйдәр блокнотны ачты – кайчандыр әтисе тарафыннан карандаш белән язылган сүзләр җентекләп, өстеннән кара белән кабатланган иде. Һәрбер сүзе аңлашырлык, тышлыкның эчке ягында «Гарипов Самат («Чукмар») Габделхәй улы» дип язылган, беренче ике биттә Саматның Светага багышланган шигыре, урта битләренең берсендә Светлананың Березняктагы адресы язылган иде.

Хәйдәр, тын да алмыйча, әтисе җитмеш ел элек язган шигырьне укыды.

– Сугыштан соң, әти блокноттагы һәрбер хәрефне карандаш өстеннән кара манып язып чыккан, – диде Винфрид. – Аннары шигырьне кәгазьләргә күчергән, машинкада бастырган. Әтинең һөнәрханәсе янында төрекләр кибет тотканнар, ул шулар белән аралаша торган булган. Кибет хуҗасының ерак туганы төрки телләр белгече икәнне белгәч, әти, аның белән элемтәгә кереп, шигырьне төрекчәгә, немесчәгә тәрҗемә иттергән.

– Рәхмәт яусын сезгә, рәхмәт яусын әтиегезгә, – диде Хәйдәр, күңеле тулып.

– Минем сюрпризым тагын бар әле, – диде Винфрид, серле елмаеп.

Винфрид портфеленнән ноутбук чыгарды, аны кабызып, флешка

тоташтыргач, палата эчендә беренче ноталардан ук күңелгә ятышлы искиткеч моңлы җыр яңгырады. Куе баритон тавышлы җырчы ир-егет бәрхетле тембр белән җанын-тәнен биреп җырлый, җыр да таң калырлык матур, оркестрның уйнавы да гаҗәп югары дәрәҗәдә иде.

– Минем улым музыкант, үзе көйләр дә яза, – диде Винфрид, җыр тәмамлангач. – Бу шигырьнең немесчә вариантына 2007 елда ул көй язды һәм җырны вокал буенча консерватория тәмамлаган дустына бирде. Бу җыр дискларда чыкты, аны радиодан, телевизордан төрле каналларда еш яңгыраттылар һәм хәзер дә ишетергә мөмкин. Башта улым, аккомпанементчы буларак, җырчыга берүзе пианинода уйнады, аннары, оркестр ярдәмендә шушы җыр белән алар Европада уздырылган өч конкурста лауреат дәрәҗәсенә ирештеләр. Ишеткәнегез юк идеме бу җырны?

– Юк, кызганычка каршы, – диде Хәйдәр, әле һаман җыр тәэсирендә калып. – Көе гомуммузыкаль стильдә, романс формасында язылган, һәр милләт кешесенә аңлаешлы итеп иҗат ителгән. Искиткеч романс килеп чыккан! Киләчәктә шигыре җыр булып яңгырар дигән уй әтинең хыялларында да булмагандыр. Шул афәтле заманнан бүгенге көнгә аваз салган кебек...

– Начар заманалар булмый, начар кешеләр була, – диде Винфрид Мейер. – Заман нәрсә ул? Фәкать Вакытның бер өлеше генә. Заман дип атаганыбыз мәңгелек өчен – мизгел генә бит ул. Кешеләр нишли, нинди гамәлләр кыла шул вакыт эчендә – менә шунысы мөһим бит киләчәк өчен. Син яшәгән заман һичничек тә җиңел була алмый инде ул. Йә элек булган ул рәхәт тормыш, йә алдагы елларда гына булырга мөмкин. Ә кеше барыбер яши, ярата, иҗат итә, өметләнә.

Винфрид Мейер флешканы, шул җыр кергән дүрт дискны Хәйдәргә тапшырды һәм җырны ноутбуктан телефонына да күчереп бирде.

– Киләчәкне алдан күрү мөмкинлеге булса, бәлки, сугышлар булмас иде, – дип куйды Хәйдәр, әле һаман профессор алып килгән бүләкнең чын икәненә тәгаен ышанып җитә алмыйча.

Винфрид, беравык уйга калып торганнан соң:

– Кешеләр барыбер сугышырлар иде, – диде. – Рус философы әйтмешли, кешедә, кешелек дөньясында аңлашылмый торган яман чыганак ята. Уңай шартлар булу белән, шул чыганактан вәхшилек калкып чыга. Бу – асылда, кешелекнең эчке дөньясының чагылышы, аның рухи халәтенең манифестациясе. Гафу ит, бу мисалым өчен – кешедә яман күзәнәкләр һәрвакыт бар, алар сәбәпне һәм уңай шартларны гына көтеп яталар. Барыбер рак чиренең ник барлыкка килүен хәтта без профессионаллар да әйтә алмыйбыз, белмибез, аңламыйбыз. Шулай ук нигә кешелек дөньясында яман чыганак бар, ник аңардан гел ялкынсыну чыгып тора, ник кешеләр бер-берсен үтерергә омтылалар – моны да беркем аңлата алмый. Аерым кешеләрнең сугыш вакытында мәрхәмәтле булып калулары – сәламәт күзәнәкләрнең исән булуына, аларның кешелек дөньясындагы яман күзәнәкләргә каршы көрәшүенә тиң.

Хәйдәр шактый вакыт дәшми торды.

Әйе, аларның әтиләре арасында дошманлык үзеннән-үзе юкка чыккан.

Үзара дошман булсалар, еллар узгач, мондый затлы җыр тумаган булыр иде. Нигә соң алайса миллионлаган кешеләрне үтерергә иде?! Ни хакына? Ни өчен?! Мәгънәсе нәрсәдә?! Бер-берсенә һич охшамаган ике милләт кешесе, төрле нәсел вәкилләре тарафыннан, еллар узгач, җыр туган һәм аны меңләгән-меңләгән кешеләр яратып тыңлый... Кызык бу дөнья һәм... сәер.

– Әти 2000 елда сиксән яшендә вафат булды, – диде Винфрид, Хәйдәрне уйларыннан арындырып. – Йоклаганда, йөрәге туктады. Безнең очрашуыбыз, әтиеңнең шигырен җыр итеп тыңлавың – болар синең халәтеңә уңай тәэсир итәрләр, дәвалануга өстәмә сихәт булыр дип ышанам.

– Әлбәттә, – диде Хәйдәр. – Сезнең белән очрашу мине яхшы мәгънәдә тетрәндерде, күңелгә мең шифалы, җылы дулкын керде. Киноларда гына була торган хәл бу.

– Киноларда да шул ук кешеләр тормышы инде.

– Сезнең белән очрашу – минем өчен гаҗәп зур шатлыклы вакыйга.

– Мин дә чиксез шат!

Алман профессоры татар галименең кулын каты иттереп кысты һәм, Хәйдәрнең тиз арада савыгуын теләп, саубуллашып, Берлинга кайтып китте.

Хәйдәрнең күңелен якты сагыш катыш кинәнү биләп алды. Иттифакый яңалыктан ул хәтта иләсләнеп китте һәм бик озак һичтуктамый палата буйлап, әрле-бирле йөрде. Әтиләре исән һәм бу вакыйгалар моннан җитмеш ел элек түгел, менә шушы заманда, бу көннәрдә генә булган сыман тоела башлады. Яшәеш бүгенге көннән генә түгел, киләчәктән һәм үткәннәрдән дә тора лабаса. Кешеләр яшәеше социологик төшенчә генә түгел, тарихи категория дә бит әле ул. Синең гомереңнең дә кешелек дөньясында, аның тарихында үз урыны бар. Күп еллар элек булган вакыйга да яңалык буларак кабул ителергә мөмкин. Кызык бит... Ничек инде яшәү кызык вә ләтафәткә ия булмасын! Яшәргә кирәк! Сәламәт чагым да бар иде бит минем... Сәламәт чакларым да – минеке, алар да минем гомеремнең өлеше ләбаса. Шул еллар белән элемтәне өзмәү зарур. Әгәр әтиләребез вакыйгасы илһамландыра ала икән, ә нишләп әле үземнең гомеремнең якты өлешләре миңа илһам бирмәскә тиеш?!

Шуның белән беррәттән, соңгы елларда борчыган сораулар Хәйдәрнең күңелендә тагын калыкты. Бер яктан авыр сораулар булса, икенче яктан бу халәтнең яхшы ягы да бар иде – алар Хәйдәрнең аңын үз диагнозына бәйле кара уйлардан башка проблемаларга юнәлтте.

Синең акылың, гомерең кемгә, нәрсәгә хезмәт итүен анык аңлау мәслихәт. Без, сугышта батырлыклар күрсәтеп, тыныч тормышта ат шикелле җигелеп эшләп, аннары һәр кылган гамәлләребез үзебезгә түгел, ә гомуми бер казнага, дөнья яшәешенең казанына салынып, кайнап торса, – безгә моның фәтвасы бармы соң?.. Татар шигырен немецчага тәрҗемә иткәннәренә сөенергәме, көенергәме?..

Туктале, әти Казанга кайткач, шигырен тәкъдим иткән очракта, берәр татар композиторы җыр язган булыр иде микән?..

Аерым алган кешенең гомере дә, кылган гамәлләре дә бу дөньяда үзеңнеке генә, халкыңныкы гына, авылыңныкы яки шәһәреңнеке генә, хәтта үз илеңнеке генә була алмыйдыр инде, күрәсең.

Татар кешесенең шигыренә җыр язганнар... Аны Европада яратып тыңлыйлар. Ә татарлар турында европалыларның күбесе белми дә, ишетми дә.

Миңа хәзер бу турыда уйларга кирәкме соң?..

Хәйдәр җырны кат-кат тыңлады.

Җанны иркәләгән якты нәгъмәдән күңел күтәрелде, хәл яхшырып китте. Шуның белән бергә, бүгенге сөйләшү, әтисе хакындагы яңа ачышлар берникадәр алҗытып та җибәрде. Якты хисләр дә, артык көчле булса, хәлне ала бит. Караңгы уйлар да ерак йөрмәгән, тагын башта кайнарга тотындылар.

Шулай инде, татар кешесе изтираб дулкыннарында тирбәлергә ярата, җан газабы булмаганнан да газаплана башлый бит ул. Кайвакыт читен булса гына рәхәт була татар кешесенә.

Күңелдә ике халәт капма-каршы килделәр. Бусарыну дулкынына икенче җылы вә көчле дулкын килеп бәрелде – өмет дулкыны.

Яман чир рәвешендә килеп төшкән сынауны коелып иңмичә үтәргә шартлар, мөмкинлекләр бар. Тагын биш ай дәвамында ул монда дәваланачак. Винфрид Мейер белән язмыш аны тикмәгә очраштырмады лабаса. Бәлки, моннан җитмеш ел элек аларның әтиләрен дә язмыш тикмәгә очраштырмагандыр?..

Винфрид Мейер дәвалау курсын үзем шәхсән катгый контрольдә тотачакмын, диде. Профессор Ян Шредер белән бергәлектә алар мине үлем кулына бирмәячәкләр.

Бу очрашудан соң Хәйдәр инде беренче көннәрдәге кебек төшенкелеккә бирелмәячәк, тереләчәгенә, савыгачагына аның өмете ныгыды, ышанычы артты.

Бүген ул, капма-каршылыклы уй-хисләр әсире булуга карамастан, ни гаҗәп, бик тиз йокыга китте.

**21**

Самат Верхнегорск ягыннан килгән машиналар каршына чыгып, кул болгады. Колонна туктагач, машиналарның берсеннән базык гәүдәле, әмма җитез хәрәкәтле майор төште һәм тирә-якны яңгыратып кычкырды:

– Монда кил!

Самат йөгереп барды һәм үзенең кем икәнен әйтте, нинди йомыш белән йөргәнен сөйләде. Майор аны игътибар белән тыңлагач, үткен күзләре белән Саматка текәлде.

– Нишләп тулы формадан түгел? – дип җикерде майор. – Коралың, документларың, пилоткаң кая? Әсир кая олакты? Рация кайда?

– Әсирне бандерачылар үтерделәр... – диде Самат. – Рацияне үзләренә алдылар...

– Ә сине нишләп исән калдырдылар? – диде майор, Саматка ышанмыйча.

– Мин качтым... Бу тирәгә адашып килеп чыктым....

Алдарга ниятләде Самат, шулай яхшырак булыр дип уйлады.

– Гаврилов дивизиясеннән дисеңме?

– Так точно!

– Полк командирың кем? Взвод командирың? – дип төпченде майор.

Самат барысына да дөрес җавап бирде.

– Без хәзер нәкъ сезнең часть урнашкан җиргә барабыз. Әйдә, утыр машинага, кем икәнеңне шунда ачыкларбыз.

Машина арбасына менгәнче, Самат урман аша үткән немец батальоны турында әйтергә кирәк дип тапты:

– Иптәш майор, әнә теге юлдан немецларның бер батальоны үтеп китте, полк калдыклары бугай.

Майор, кул селтәп:

– Без беләбез ул полк турында, – диде. – Алар кичү янында безгә тылдан бәрергә чамалаучы дивизиягә кушылырга телиләр. Әмма барып чыкмаячак, аларны безнең засада көтеп ята инде. Ә дивизияләре бүген-иртәгә чолганышта калачак.

Машина арбасында чиста киемле яшь солдатлар ике яклап тезелешеп утырганнар иде. «Әле дары исен иснәмәгән малайлар, ахрысы», дип уйлап куйды Самат.

Колонна Березняк аша үтә икән... Света күренмәсме? Майорга рациянең монда икәнлеген әйтәсе калды мәллә?.. Рацияне алган арада, бәлки, Света белән очрашырлар иде, әмма шундук кире уйлады – рация бандерачыларда һәм бу тирәгә адашып килеп чыктым дип әйтте бит инде ул. Ортвинны монда дәвалаганнарын, бергә Верхнегорскига киткәннәрен белсәләр, ул чагында инде трибуналдан котыла алмассың. Болай да әле алда ни көтәдер – белгән юк. Әсирдән колак каккан өчен, бәлки, әле хөкем итәрләр. Ни булса, шул!

Самат үрелеп-үрелеп карады, берән-сәрән кешеләр очрый, әмма Света күренмәде. Өйдә микән, бүлнисне җыештыра микән?..

Шәһәр инде артта калды, ә ул әле һаман Света күзгә чалынмасмы дип өметләнде. Янәшә утырган солдат аңа ниндидер сораулар бирде, ә Самат аны ишетмәде, аның күз алдында бары тик Света гына иде.

Ул үзен бу вәхши дөньядан читтә кебек хис итте. Гүя ике йөрәк таләбе буенча аерым дөнья барлыкка килгән һәм ул шунда качкан – анда сугыш юк, өстән бомбалар яумый, аста миналар шартламый, каршы яктан пулемёттан атмыйлар, елгалар кичәсе, урманнарда качып йөрисе юк. Яңа, уйдырма дөньяда фәкать очып йөрергә генә мөмкин иде.

Татлы уй-хыялларыннан арынгач та, ул әле илһамлы халәттә кала бирде. Сугыш дәвам итә... Дошман бирешергә теләми, әлегә көн саен үлем, кан, күз яше... Әмма Самат ышана – аңа пуля тимәячәк, аны снаряд кыйпылчыгы харап итмәячәк һәм беркем дә аны әсир итә алмаячак. Аңа һәлак булырга ярамый, әгәр бу сугышта аны үтерсәләр, сәмави рәвештә насыйп булган могҗизалы өч көн турында беркем белми калуы ихтимал лабаса. Ул өч көн эчендәге бәхетле мизгелләр аныкы гына, башкалар бу хакта берни белми, ә аның бу турыда кемгәдер сөйлисе, кем беләндер уртаклашасы килә һәм аның җаны бәхетнең дәвамын тирән игътизар белән эсти иде.

Андый бәхет кичергән яшь кешене үлем үзе белән алып китәргә җөрьәт итмәс, бөтенесе үлеп беткән сурәттә дә, ул барыбер исән калачак! Чөнки аның, сугыштан соң, Света янына барасы, аны үзе белән Казанга алып кайтасы бар. Кайгылар, михнәтләр күрер өчен генә тумыйдыр бит кеше. Бәхет тә өч көнлек кенә булырга тиеш түгелдер.

Ул тагын үзенең якты вә серле дөньясына чумып, язмыш арбасында Көнбатыш ягына баруын дәвам итте. Аның күзләрен йомып елмаеп баруына солдатлар сәерсенеп карадылар.

Ә Самат бәхетле, вәхшәтле чынбарлыкта рәхәт иде аңа. Алда ни буласын уйламады ул, киләчәк яман буласын күз алдына да китерергә теләмәде. Бүген ул исән, ул сулый, ул ярата, ул бәхетле, иртәгә дә, алга таба да һәм мәңге шулай булачак дип уйлады.

Кайчаннан бирле сугыш бара. Өч көн генә алар бергә булдылар. Өч көнне сәгатьләп, минутлап, секундлап санарга мөмкиндер. Ә мизгелләр белән?.. Туктале, сәгатьтә ничә мизгел соң?.. Санарлык түгел – бихисап. Ә өч көндә?.. Акылга сыймаслык!

Алар чиксез, алар мәңгелек!

**22**

1994 елда Ортвин Мейер, җитмеш дүрт яшьлек агай, Россиядән күчеп килгән Идел буе немецлары белән аралаша башлады. Ул кайчандыр Казакъстанга сөрелгән, СССР таркалгач, Германиягә килеп урнашкан бер гаилә белән якынлашып-дуслашып китте һәм аларның егерме биш яшьлек уллары Викторны үзенең һөнәрханәсенә эшкә алган иде.

Беркөнне Мейер әфәнде Викторга үтенеч белән мөрәҗәгать итте:

– Виктор, минем сиңа бер гозерем бар. Сине эш белән тәэмин итүче хуҗаң буларак түгел, дус итеп, якын итеп, алманча да, русча да яхшы сөйләшкәнеңә күрә, ярдәм итүеңне үтенәм.

– Хәлемнән килгәнчә тырышып карармын, Мейер әфәнде, – диде Виктор.

– Минем машина белән Украинага барып кайтыйк әле.

– Рәхәтләнеп барып кайтабыз, – дип, Виктор шундук ризалык бирде.

– Син миңа тәрҗемәче буларак кына түгел, шофёр буларак та кирәк булачаксың бит.

– Аңладым, Мейер әфәнде, – диде Виктор. – Мин әзер.

Күп тә үтмәде, Ортвин Мейернең затлы «Мерседес»ы Франктфурт-на-Майне каласыннан чыгып, элекке СССРның элекке республикасы Украинага юл алды.

Чикләрдә, таможняларда шактый вакыт чират торырга туры килсә дә, зур каршылыклар, киртәләр очрамады һәм җәй уртасының якты бер көнендә Украинаның Николаев өлкәсендәге Березняк шәһәренә Виктор, машина рулен нык тотып, Ортвин Мейерне алып килеп җитте.

Березнякта Саматның блокнотында язылган адрес буенча бардылар, әмма урам исеме шул ук калса да, анда инде, табигый ки, бөтен нәрсә үзгәргән, башка төрле йортлар тора, арада бик искеләре дә, яңалары да, әле генә төзелеп килгәннәре дә бар иде. Табигатькә якынрак булганга күрә, Березнякта баерак кешеләр йортлар сала башлаганнар, Светалар йорты урынында ике катлы кирпеч коттедж мәһабәт бина булып калкып тора һәм анда хәлле кеше яшәгәнен читтән үк чамаларлык иде.

Малинина Светлананың сиксәненче еллар азагында үзенең йорт-җирен Березнякның башкарма комитетында эшләүче Сидоренко фамилияле чиновникка сатканын мәгълүм кылдылар. Купшы коттеджны әлеге дә баягы Сидоренко дигән кеше төзегән булып чыкты.

Коттедж хуҗасы Германиядән килгән кунакларны игътибар белән тыңлап, хәзерге вакытта Верхнегорскида яшәүче Светлана Петровнаны табарга ярдәм итәргә үзе алынды һәм Ортвин Мейернең «Мерседес»ы

алдыннан Сидоренко үзенең «Ниссан Патрол» машинасы белән юлга кузгалды.

Егерме чакрым нәрсә инде ул мондый шәп машиналар өчен – ярты сәгатьтә барып та җиттеләр. Верхнегорск, район үзәге булса да, Березнякка караганда төссезрәк, хәтта шыксызрак дип әйтергә була иде.

Светлана Петровна биш катлы йортның икенче катында яши икән. Сидоренко ишек кыңгыравының төймәсенә баскач, эчке яктан:

– Кем бар анда? – дигән тонык тавыш ишетелде.

– Светлана апа! Светлана Петровна, бу – мин, Сидоренко, сездән йорт-җир алган кеше.

Ишек ачылды. Көтелмәгән кунаклар каршында халат өстеннән караңгы кызыл кофта кигән, башына кояш төсендәге яулык чөйгән якты, ачык йөзле, тирән сагышлы күзләрендәге нурын җуймаган олы яшьтәге апа ачты.

Зур чемодан, ике авыр сумка тоткан ят кешеләрне күреп, Светлана аптырап китте. Ул сораулы караш белән Сидоренкога төбәлде, теге исә тизрәк аңлатырга кереште:

– Светлана Петровна... Светлана апа, исәнмесез... Сезгә кунаклар...

Германиядән.

– Каян? – диде Светлана, кашларын җыерып.

– Германиядән.

– Исәнмесез, фрау Свейтлуана, – дип елмайды Ортвин, Светлананың күңеле булсын өчен русча әйтергә тырышып. – Ich bin... Мин Ортвин... Ортвин Мейер!

Виктор шундук ярдәмгә килде:

– Светлана Петровна, бу агай – Ортвин Мейер. Сугыш вакытында, 1944 елда сезнең здравпунктта өч көн яткан булган. Хәтерлисезме?

Светлананың йөзе тартылып китте.

– И Ходаем! Ортвин?! – диде ул, ишек яңагына сөялеп. – Хәтерлим. Нишләп хәтерләмәскә. Әсир... Радистмы?

– Радист, радист, – дип баш какты Ортвин, Светлананың хәтере яхшы булганга куанып.

Ә Светлана әле ышанып җитә алмады:

– Чын әйтәсезме?

– Ул сезне эзләп килде, – диде Виктор.

Һәм очрашуның башыннан азагына кадәр Виктор тәрҗемәче вазифасын бик оста итеп, җиренә җиткереп башкарды.

– Исәнмесез, Светлана! Ничек хәлләрегез? Ничек яшисез? Сез, әлбәттә, бераз үзгәргәнсез, әмма барыбер чибәр һәм мөлаем килеш калгансыз, – диде Ортвин тәрҗемәче аша.

Светлана, әлбәттә, бик нык каушады:

– Әсир... радист... Ортвин... Керегез. Узыгыз. И Ходаем! Бу ни хәл соң?..

Сидоренко:

– Мин кереп тормыйм. Сау булыгыз, Светлана Николаевна, – дип, алман кунакларының кулларын кысып хушлашты һәм китеп барды.

Тыйнак кына җиһазланган ике бүлмәле фатирда Ортвин Мейер җан җылылыгын тойды. Төз гәүдәле, чибәр Света, чынлап та, илле ел узганнан соң да гүзәллеген җуймаган иде. Яулык, нинди генә матур

булса да, бәс кунган чәчләрне бөтенләй каплап бетерә алмый, нурлы йөздәге җыерчыкларны да бернинди шатлыклы минутлар юкка чыгара алмый иде.

Тынгысыз Җир йөзендә инде күптән сагышлы һәм якты хатирәләргә әверелгән вакыйгада катнашкан ике кеше – вакытлыча әсир төшкән алман кешесе һәм аның ярасын бәйләгән, уколлар кадаган, үз бакчасында пешкән алмалар белән аны сыйлаган Света – илле ел узгач очраштылар.

Ортвин белән Викторны утыртыр алдыннан, Светлана кабалана-кабалана матур җәймә алып килеп, диванга җәйде. Аның кул хәрәкәтләре таныш вә якын иде Ортвинга. Онытырлыкмыни Светаның перевязка ясагандагы күз карашын, аны дошман итмәвен, укол кадаганда, җаваплылык тоеп, иреннәрен кысканын, хуш исле, тәмле кып-кызыл алмаларын?

– Сезгә ничә яшь соң? – диде Светлана Николаевна, кунаклар каршысына урындык куеп утыргач.

– Җитмеш дүрт, – диде Ортвин.

– Миңа җитмеш, – диде Светлана, сагышлы елмаеп.

Аның елмаюында михнәтле елларны узып, шушы яшькә җитү куанычы һәм кешеләр арасындагы табигый якынлыкка күңел кинәнүе бар иде. Бу очрашуның төштә түгел, өндә чынга ашканына тиз генә тәгаен ышанып җитәрлек тә түгел иде.

Киеренкелек, каушау тиз арада юкка чыкты. Светлана бүлмә уртасындагы түгәрәк өстәлгә ашыга-ашыга, чәй табыны әзерләгәндә, кунаклар сумкалардан бүләкләр, төрле күчтәнәчләр чыгардылар. Затлы сувенирлар, китаплар, матур бизәкле һәм кыйммәтле савыт-саба, төрле-төрле тәмле ризыклар – боларны Светлана кая куеп бетерергә белми аптырады.

Ортвин 1944 елның августында урманда булган хәлне һәм ничек котылганын, Саматның урманчы йортында калганын түкми-чәчми сөйләде.

Ортвинның кыяфәте дә Светлананы шаккатырды. Кайчандыр бөрешеп яткан әсир радист шушы микәнни?! Үзенә җитмеш дүрт яшь, ә өстендәге пөхтә киеме ыспай һәм яшьләрчәрәк иде. Дәһшәтле еллар аның зыялы кыяфәтендә дә эзләр калдырган, әмма затлы, олпат шәхес икәне төсенә чыккан, күз карашы чиста, тәмле ислемай исе аңкып тора үзеннән.

Светлана, елмаеп:

– Мин хәтерлим, сез аксый идегез... – дигәч, Ортвин, гаҗәпләнеп:

– Анысын да хәтерлисез икән, – диде. – Минем балтырымның сеңере тартылган булган. Тылдагы госпитальдә ятып чыкканда аксамый идем инде.

Светланага бик кадерле, якын кунак иде Ортвин Мейер. Чөнки бу алман кешесе дә бар иде теге көннәрдә. Самат белән Светаның бер-берсенә гашыйк булганнарына ул да шаһит булган иде бит.

– Сезнең үзара мөнәсәбәтләрегез миңа да ул вакытта берникадәр көч-куәт бирде, – диде Ортвин. – Сезнең мәхәббәтегез, яшәеш бәхетенең әверелеше булып, миңа да өмет, дәрт өстәгән иде.

– Мин сез киткәннән соң, Верхнегорскига барып, комендантта сезнең хакта сораштырдым, – диде Светлана чак кына дерелдек тавыш белән. – «Алар монда килмәделәр, күренмәделәр», – дигәч, әлләниләр уйлап бетердем.

– Сез Самат белән сугыштан соң очрашмадыгызмы? – дип кызыксынды Ортвин.

– Юк шул, очрашмадык, – диде Света сыкраулы тавыш белән. – Улым 1969 елда Казанга барып кайтты... Кызганычка каршы, Самат 1968 елда вафат булган. Безгә аның белән тагын очрашырга, күрешергә насыйп булмады.

Ортвинның кинәт сөмсере коелды. Кайчан да булса үзенең конвоирын – кырыс һәм игелекле, якты һәм батыр йөрәкле, дошман булса да, ахыр чиктә, дошман итмәгән кызылармеецны – очратып, күрешербез, сөйләшербез дип өметләнгән иде ул.

– Шулай итеп, улым да үз әтисен күрә алмый калды, – дип куйды Светлана, моңсу тавыш белән һәм Ортвинның күзләрендә сорау чагылганны күреп елмайды. – Әйе, Саматтан минем малай туды. 1945 елның җәй башында... Сабит исемле... Сабит Саматович. Аңа хәзер кырык тугыз яшь, алар Николаевта яшиләр.

Бу хәбәр Ортвинга бик җылы тәэсир итте, моны ишетеп, ул бик сөенде, аның хәтта күңеле тулып, күзләре дымланды.

Чәй эчкәннән соң, Светлана альбомын алып, кунакларга фоторәсемнәрен күрсәтте. Альбомны актарганда, Светлананың сугыштан соң ничек яшәве, ниләр кичергәне, тормышының нечкәлекләре кунакларга тирәнрәк ачылды.

Улы Сабит Харьковта институт тәмамлаган, бүгенге көндә зур преприятиедә генераль директорның урынбасары булып эшли икән. Казанга баргач, татар кызы белән танышып, аңа өйләнгәнен ишеткәч, Ортвин башын чайкап, соклануын белдерде.

Светлана оныкларының фотоларын күрсәтеп:

– Саматның ике улы – Сабир һәм Салих, – диде.

– И Ходаем! – дип шаккатты Ортвин. – Инде зурлардыр.

– Әйе, фоторәсемнәрен күрсәтермен. Сабир Тын океан флотында хезмәт итеп кайтты, озакламый инде өйләнергә җыена. Читтән торып, институтта укый, ниндидер бизнес белән шөгыльләнә. Салих институтта укый, өченче курста. Әниләре – киленем Зөлфия – Николаев каласының башкарма комитетында социаль мәсьәләләр бүлегендә эшли, аңарчы азык-төлек, кафе-рестораннар системасында иде.

– Исемнәре бер-берсенә бик охшаган, – дип көлемсерәде Ортвин. – Сабит, Сабир, Салих...

– Булсын. Миңа бик ошый, – дип, матур итеп елмайды Светлана. – Барысы да Самат дигән исемгә тартым. Төскә-биткә улым да, оныкларым да Саматка охшаганнар. Сабит дигән исемне үзем куштым. Кайсыдыр китапта укып, исемдә калган иде – анда «...татар егете Сабит..» дигән юллар бар иде. Матур исем. Ә оныкларга исемнәрне килен тапты, үзе татар булгач, озак эзләп торасы булмады. Ул Сабитны татарча сөйләшергә өйрәтте. Оныкларны да өйрәтә, әмма аларына авыррак керә. Шулай да азмы-күпме сөйләшә алалар.

Ортвин Сабитның бала чактан алып, бүгенге көнгә кадәр төшкән күпсанлы фотоларын зур кызыксыну белән карады һәм кат-кат шаккатуын белдерде:

– Сабит шулхәтле Саматка охшаган!

– Чын татар инде, – дип елмайды Светлана.

– Оныкларыгыз да бабаларына бик охшаган.

Светлана бөтенләй җанланып китте:

– Озакламый кунакка киләчәкләр, – диде ул шат вә горур тавыш белән. – Минем өчен бәйрәм була инде. Мине Николаевка үзләре янына күчеп китәргә өндиләр, ә минем моннан һич кенә дә китәсем килми. Киленнән дә уңдым югыйсә, бергә яшәве, бәлки, күңеллерәк тә булыр иде, әмма миңа барыбер туып-үскән Березнягым янәшә булу кирәк.

Онытканчы дип, Ортвин Сабитларның Николаев каласындагы адресларын, телефоннарын язып алды.

– Бу юлысы барып булмас инде, без бүген үк Германиягә кайтып китәргә планлаштырдык. Сез рөхсәт итсәгез, мин улыгыз Сабитка телефоннан шалтыратачакмын.

– Әлбәттә, шалтыратыгыз, – диде Светлана. – Рәхмәт сезгә, онытмаганыгыз өчен, шул кадәр ерак араны үтеп килеп, миңа шундый җылы сүзләр әйткәнегез өчен, күчтәнәчләрегез, бүләкләрегез өчен. Мин шулхәтле шат сезне күрүемә, мин чиксез шат сезнең исән-имин булуыгызга.

– Сезгә рәхмәт, Светлана! Олы йөрәкле, киң күңелле, алтын куллы булганыгыз өчен. Сез ясаган перевязкалардан соң, берничә көн эчендә ярам төзәлде бит минем. Сез ул вакытта сыйлаган алмалар кебек тәмле алмаларны минем бүтән беркайчан да ашаганым булмады.

1944 елның августындагы ул көннәрне икесе дә рәхәтләнеп искә төшерделәр. Һәр икесе үзе турында да озын-озак итеп сөйләде, сугыш тәмамланган вакыттагы хәлләрне, сугыштан соңгы тормышларын бер-берсенә бәян иттеләр. Һәм гомернең кайсы өлеше турында гына сүз чыкмасын, алар гел Саматны искә алдылар, Самат һәрвакыт алар белән, гел «аларда» иде.

– Әйбәт егет иде, – диде Ортвин, бер ноктага текәлеп. – Кыҗраганда да, аның кыяфәтеннән барыбер игелекле кеше икәне күренеп тора иде. Ул бит миңа бер тапкыр да сукмады. Тешләрен кысып кизәнә иде, әмма андый вакытта да сукмасын сизә идем, белә идем. Аңардан начарлык көтмәдем мин. Киресенчә, ул бит мине берничә тапкыр үлемнән коткарды. Кызганыч, иртә вафат булган... Кызганыч, кызганыч...

Ортвин кулъяулыгы белән күз яшен сөртте һәм Светланага елмайды:

– Миңа бит тагын бер сорау тынгылык бирми, фрау Светлана. Минем рациянең язмышы ничегрәк соң, белмисезме? Аңлавымча, Самат аны шушында, Березнякта яшереп калдырган иде бугай...

– Без аны Самат белән йортыбызның түбәсенә яшергән идек, – диде Светлана. – Рация турында, әнидән кала, башка беркемгә дә әйтмәдем. Аны алырга берәр көнне Самат үзе килеп чыгар дигән сәер өмет яшәде миндә. Ул рация ниндидер кадерле әйберемә әйләнде. 1969 елда, улым Саматның вафат икәнен белеп кайткач, мин аңа рацияне юк итәргә куштым. Улым аны төнлә, елгага алып барып, суга ташлады. Сезнең монда киләсегезне белгән булсам, саклаган булыр идем, сезгә тапшырыр идем.

Ортвин Светлананы тагын бер көтелмәгән бүләк белән нык тетрәндерде – Саматның Светага багышлап язган шигырен татар, рус, төрек, алман телләрендә бастырып алып килгән иде.

– Урманчы йортында аның сезгә багышлап бу шигырьне язуына мин үзем шаһит булдым, – диде Ортвин.

Светлана шигырьнең рус телендәге тәрҗемәсен шундук укып чыкты һәм күз яшьләре аша сагышлы елмаеп:

– Блокноты кая? – диде.

Ортвин читенсенеп, үзен гаепле тоеп, аңлатырга кереште:

– Светлана, гафу үтенәм.... Мин аны юл сумкасының кесәсенә тыгып куйган идем... Юлга җыенганда, зуррак сумка кирәк булып чыкты да, әйберләрне күчерергә туры килде... Ә блокнотны күчереп куярга онытканмын, теге сумкада калган... Зинһар, гафу итегез. Мин сезгә аны барыбер тапшырачакмын. Без әле сезнең белән тагын очрашачакбыз.

Кызганычка каршы, алар инде бүтән беркайчан да очрашмадылар.

**23**

Самат белән Ортвин юл борылышында күздән югалгач та, әле Света шактый вакыт шул тарафка карап торды. Үзен кая куярга белмичә, күңелендә бушлык тоеп, посёлок буйлап каугаланып йөргәннән соң, Иван Константиновичның бүлнистә икәнен белеп, ичмаса ул тынычландырмасмы дип, Света шунда юнәлде.

Иван Константинович әле күптән түгел генә әсир яткан бүлмәдә, тумбочкага таянып, нидер язып утыра иде. Ул Светага борылып карап алды да бер сүз әйтмәде, язуын дәвам итте. Улына яки кызына хат язадыр дип, Света аны борчып тормаска булды, Самат белән бергә йоклаган бүлмәгә барып утырды да уйлар диңгезенә чумды.

Шып-шыр калган бүлнистә бүген аның бернигә кагыласы килмәде, дөресрәге, нәрсә дә булса эшләү хәленнән килмәде. Бөтен нәрсә, һәрбер нәрсә, Самат монда чактагы шикелле калуын теләде ул.

Күңеленең бер өлешен үзе белән алып китте татар егете.

Атна-ун көн вакыт узгач, беркөнне, Аглая түтәй яныннан чыкканда, Света кирпеч заводы янында район үзәгеннән килгән машинаны абайлады. Верхнегорскидан бер түрә килгән һәм кирпеч заводы янында кемнәргәдер ниндидер күрсәтмәләр биреп тора иде.

Света, шунда барып, кыюсыз гына, үзен Верхнегорскига кадәр алуларын үтенде.

Һәм бер сәгать тә үтмәде, Света инде район үзәгендә иде.

Әнисенең хәле яхшырган, инде Березнякка үз өйләренә кайтырга теләвен әйтте һәм Света килгәнгә, бергә кайтабыз икән дип, бик сөенде. Әнисе белән сөйләшеп утырганнан соң, Света, түзмәде, шәһәргә чыгып, комендатураны эзләп китте.

Бер катлы озынча баракта урнашкан комендатураның ишеге каршында ябык кына солдат винтовкасын иңенә асып басып тора, читтәрәк киң җилкәле, төптән юан бәдәнле, капитан званиесендәге офицер, әрле-бирле йөреп, тәмәке тарта иде. Света комендантны күрергә теләвен әйткәч, солдат тыңкыш тавыш белән:

– Әнә бит ул, – дип, капитанга ымлады.

Комендант, тәмәке төпчеген җиргә ташлап таптады да ишеккә таба

юнәлде. Әлбәттә, яшь, матур кыз яныннан игътибарсыз үтеп китә алмады ул һәм Светаның үзенә карап торуын күреп:

– Берәр сорау бармы әллә? – диде.

– Әйе, – диде Света, нык каушап. – Сезгә бу көннәрдә әсир немец белән кызылармеец Гарипов килмәделәрме?

– Юк, – диде комендант. – Каян? Нинди әсир?

Светаны курку биләп алды, шуңа күрә барысын да сөйләргә базмады.

– Мин – медсестра... Березняк бүлнисендә эшлим... – диде ул, капитанның таләпчән күз карашыннан шүрләп. – Гарипов... кызылармеец су сорады... Ул әсир немецның конвоиры иде... Верхнегорскига барулары турында әйткән иде...

– Юк, андыйларның монда килгәннәре юк... Килгән булсалар, мин хәтерләр идем.

– Кайда икән соң алар? – диде Света, коелып иңәрдәй булып.

– Мин каян белим. Каян килгәннәр иде соң алар?

– Белмим.

– Ә сиңа нигә соң алар? – дип кызыксынды комендант.

– Болай гына сорадым. Конвоир егетнең хәле начар иде... Алар җәяү киттеләр... Әсир аны үтереп качмады микән дип куркып соравым.

– Башка кайгың юкмыни? – диде капитан салкын гына.

– Башка кайгыларым да бар, – диде Света, кинәт кыюланып һәм борылып китеп барды.

Капитан комендатурага кереп киткәч, Света кире килеп, ишек сагында торучы солдаттан сорады:

– Әсирләрне конвоирлар кая алып барырга тиеш?

– Башта комендатурага инде, – диде солдат, кызны дикъкать белән күзәтеп.

– Тагын кая алып барулары ихтимал?

– Монда Верхнегорскида тагын кая алып барсыннар инде, шушында комендатурага китерергә тиешләр.

Света, башын аска иеп, әкрен генә китеп барды.

– Бәлки алар әсир белән конвоир булмаганнардыр, юри әйткәннәрдер сиңа, – диде солдат аның артыннан.

Света җавап бирмәде.

Әйтерсең лә, аяк астында җир убыла, Света билгесезлектән хафа чигеп, абынкы адымнар белән кая атлавын да аңламыйча барды да барды. Кызның башында берсеннән-берсе куркынычрак уйлар өере бөтерелде.

Адаштылар микән әллә? Шикле кешеләр дип, икесен дә диверсантларга санап, кулга алганнардыр да тикшерү өчен бөтенләй башка тарафка алып киткәннәрдер... Бу тирәдә немецлар юк бугай, аларга юлыкмаганнардыр... Бандерачыларның очравы да ихтимал... Әсир Саматны үтереп качмады микән? Бәлки, икесен дә, дошман шпионнары дип, тиз генә хөкем иткәннәрдер дә атып үтергәннәрдер...

***

Берничә көннән Света белән әнисе Пелагея Березнякка кайттылар. Пелагеянең өянәкләре соңгы вакытта булмаган, тын кысылуы да сирәгәйгән, кыскасы, хәле рәтләнгән кебек иде.

Тора-бара Березнякта тыныч тормыш урнашты – кибетләр ачылды, кирпеч заводын тиз арада торгыздылар һәм, күп тә үтмәде, ул инде эшли дә башлады. Пекарня эшкә керешкәч, Пелагея шунда, элекке урынына урнашты. Бүлнисне ремонтларга тотындылар һәм берничә айдан Светаны анда эшкә рәсми рәвештә чакырдылар.

Иван Константинович кына юкка чыкты. Соңрак аны кулга алганнар икән дигән имеш-мимешләр ишетелде.

Светаның йөкле икәнен әнисе тиз сизеп алды. Кызы аңа барысын да үзе сөйләп бирде, һәм Пелагея кызын ачуланмады, орышмады, авыр сүз әйтмәде. Киресенчә, ире, улы юкка чыкканнан соң тормышта хасил булган бушлыкны бала мәшәкатьләре каплар һәм боегып калган йортка нарасый күпмедер шатлык алып килер сыман иде.

Бала дөньяга килде һәм чынлап та аның белән өйгә шатлык-кинәнү тулды. Света кыз туса да, малай туса да, татарча исем кушам дип йөргәндә, Пелагея, моңа каршы булып, кешеләрдән яхшы түгел, русча матур исем кирәк, ди торган иде. Әмма Света: «Сабит» исеме кушыйк дигәч, бу исем Пелагеягә дә матур яңгырашлы тоелды.

Әнисе:

– Каян таптың соң син бу исемне? – дигәч, Света:

– Кайчандыр укыган бер китапта «татарин Сабит» бар иде, – диде.

Светага эштә дә, күршеләр, таныш-белешләр арасында да, әлбәттә, кырын караучылар булды. Әмма чит-ят кешеләрнең тискәре мөгамәләсенә Света илтифатсыз була белде һәм ачы телле кара җаннарның яман гайбәтләреннән үзен өстен тоярлык, ригаясез калырлык ихтыяр көченә ия иде.

«Врачебный здравпункт» дип саналган хастаханә 1947 елдан поликлиника дип атала башлады. Света анда үзенең медсестра вазифаларын яратып башкарды, Самат белән өч көн, өч төн бергә булган бу бинаны ремонтлаганда ук куанып, йөгерә-йөгерә, эшкә йөрде. Хәзер өйдә аның бәһасез бер хәзинәсе бар бит! Өстәвенә, ул әле Саматка шулкадәр охшаган!

Аллага шөкер, ярдәм итәргә омтылып торучылар да бар, чөнки Светаны шәһәрдә күп кеше ярата һәм аны иң яхшы медсестра дип мактыйлар иде. Светлана аеруча Аглая түтәйгә рәхмәт укыды – әнисе һәм үзе эштә чакта баланы ул карый иде.

**24**

Самат үзенең частен елганың аръягында тапты. Дошман һөҗүм ясарга җыена дигән хәбәр алып, полкның окоплар казып яткан чагы иде.

Взвод командиры Егоровка ул дөресен сөйләде. Дошман радистын тиешле җиргә илтеп тапшыра алмаганына бераз эче пошса да, Саматның исән-имин килеш полкка әйләнеп кайтып җитүенә взводный бик шат иде. Ул инде аны конвоир итеп калдырганына үкенә дә башлаган, чөнки Гарипов Самат аңа бик кадерле, бик якын солдат иде. Самат бит аны үлемнән коткарды, исән булуына аңа рәхмәтле иде ул.

1942 елның кышында Сталинград чолганышында калган Паулюс армиясен коткарырга дип килүче вермахт гаскәрләренә каршы тирән итеп ясалган катлы-катлы оборона сызыкларында бервакыт ике яктан да туплар

эшкә керешеп, бер-бер артлы снарядлар шартлаудан, кайда дошман, кайда үзебезнекеләр икәнне аңлап булмый башлады, бер үк окопта төтен, тузан эченнән әле немецлар, әле безнекеләр күзгә чалынды. Бер мәлне коралын югалткан Егоровка каяндыр пәйда булган киң җилкәле немец карабинын төбәде. Взводный харап була иде, Самат моны күреп йөгереп килде һәм немецның җилкәсенә штык кадады.

Рота командирына: «Радистны урманда качарга ниятләгәндә атып үтердем», – дип әйтергә Егоров Саматка үзе киңәш итте. Ә бандерачылар белән булган хәлнең (рация шуларда калды дип әйтер өчен) дөресен сөйләргә кушты.

Егоров белән Самат доклад ясаганнан соң, рота командиры хәбәрне полк командирына җиткерде. Әмма полк командиры моны игътибарсыз калдырды, әһәмияткә ия вакыйга дип санамады, чөнки алда бөек ыргылыш булырга тора – тиздән безнең гаскәрләр Европага аяк басачаклар, шуңа күрә ниндидер бер радистның юкка чыгуы аның өчен мөһим нәрсә түгел иде.

Елганы кичкән полкка дошман һөҗүм ясарлык көч туплый алмады һәм күпмедер вакытка бу тирәдә тынлык урнашты.

Света Саматның уеннан чыкмады. Адресын хәтерләми – шунысы җанны тырнады. Блокнот әсир кигән пинжәк кесәсендә китте бит... Света үз кулы белән язган иде адресны блокнотка... Самат үзе язган булса, бәлки, адрес хәтердә калган булыр иде. Ичмаса урамның исеме дә, никтер, истә калмаган.

Яу кырында вакытлыча урнашкан тынлыктан файдаланып, Самат шулай да Березнякка хат язды. «Николаев өлкәсе, посёлок Березняк, здравпункт, Малининой Светлане Петровне», – дип язды ул конверт тышына.

Аннан соң да шул ук адрес белән тагын берничә хат язды, әмма бер хатка да җавап килмәде һәм моның сәбәбе фронтның зур тизлек белән көнбатышка күчүенә бәйледер дип уйлады. Частьлар, полклар, дивизияләр, хәтта фронтлар буталып-чуалып беткән вакытта почталардан нинди тәртип өмет итәргә мөмкин...

***

Дүртенче Украина фронтының гаскәрләре тарафыннан үткәрелгән Көнчыгыш-Карпат операциясе 1944 елның ноябрь аенда Украина җирен юлбасарлардан тулаем азат итүне төгәлләде.

Самат хезмәт иткән дивизия Кишинёв янында чолганышта калган вермахт гаскәрләрен тар-мар итүдә катнашты. Дошманның биш армия корпусы чолганышта калып, тиз арада «Көньяк Украина» дип аталган армияләр төркеменең егерме дүрт дивизиясеннән унсигезе юк ителде.

Бу вакытта Самат хезмәт иткән дивизия Өченче Украина фронтына керә һәм бу гаскәрләргә румын армиясен тар-мар итү бурычы куелган иде.

Саматның соңгы тапкыр һөҗүмгә күтәрелүе шушында булды. Көтелмәгән яктан пулемёт сиптерә башлагач, Самат ятарга житешә алмый калды – күкрәккә, күкрәктән өстәрәк иңбашына каты бәрелү тойды. Тән буйлап кайнар дулкын йөгерде... Тир-якта бөтен нәрсә әйләнә-тулгана башлады... Түзалмаслык авырту... Аннары – салкын караңгылык... Төпсез бушлык...

Самат, тылдагы госпитальгә җибәрүләренә җаны-тәне белән каршы

килеп, дивизиянең медсанбатында калдыруларын өзгәләнеп-ялварып үтенде.

Сугыш тәмамлангач та, аңа тылдагы госпитальләрдә озак ятарга туры килде. Ул аякка басты, әмма күкрәк эчендә, үпкәдә бер пуля калды – анысын алу иң оста куллы хирургларның да хәленнән килмәде.

**25**

Самат Казанга 1946 елның көзендә генә кайтты.

Яшәргә кирәк! Әнкәсе Мәдинәнең хәзер исән калган бердәнбер газиз кешесе бит ул.

Самат сугышка кадәр эшләгән мех фабрикасына урнашты, ике айдан ул инде слесарьлар бригадиры итеп билгеләнде. Әнисе дә шул ук фабрикада эшләде, сугышка кадәр тире буяучылар бригадасында иде, сугыштан соң әзер тиреләрне озату бүлегендә контролёр вазифасына күчте.

Самат хәзер әнкәсенең куанычы да, кайгысы да иде. Вакыт-вакыт, бигрәк тә һава торышы бозылганда, беркайчан да тәмам төзәлмәслек яра газиз улын ничек бимазалаганны күрү Мәдинә өчен дә гомерлек газапка әйләнде.

Мәдинә белән бергә эшләүче Фәния исемле хатын күрше йортта яши иде. Алар элек тә дустанә мөнәсәбәтләрдә, аралашалар, бер-берсенә кунакка йөрешәләр иде, аның да ире сугышта һәлак булгач, кайгыларының бертөсле булуы аларны тагын да якынайтты. Фәниянең үсеп, өлгереп җиткән кызы белән Самат арасындагы җылы мөнәсәбәтләрне күрү Мәдинәнең күңеленә куаныч һәм өмет иңдерде.

Самат сугыштан кайтканда, Рузия исемле бу кызга егерме бер яшь тулды, болай ярыйсы гына, матур дип әйтерлек, әдәпле вә акыллы кыз иде ул. Аның ике апасы инде кияүдә иде. Бер үк кайгы, бер үк сынаулар татыган ике гаилә тарафыннан да яшьләрнең үзара мөнәсәбәтләренә куану күренде, һәм ике як та аларның никахлашуын теләде.

Самат та өйләнергә кирәк икәнне аңлый, сәламәтлек кенә начараймасын, гаилә корырлык дәрт-дәрман бар, Рузия дә риза – алар инде бу хакта сөйләшкәннәр иде.

Әмма Самат Светаны оныта алмады. Ул аны өзелеп сагына иде. Үзәкләргә үткән, кайвакыт күкрәк эчендәге пулядан да ныграк авырттырган күңел җәрәхәте дә бар бит аның – Света, Света, Света! Ул гел Украинага барырга хыялланып, Березнякта Светаны очратып, аны кочагына аласы килеп яшәде. Үз агымы белән бертуктамый аккан Вакыт аның теләген кимeтмәде, сагынуын баса алмады.

Шулай да тора-бара эшләр инде Рузия белән өйләнешүгә таба юнәлеш алган иде.

Беркөнне радиодан урам атамалары турында тапшыру булды һәм анда «Красная» дигән урам исемнәренең илебездә бик күп икәнлеге турында сүз барды. Бик еш кулланыла торган атама – «матур» дигәнне аңлата, имеш. Саматның йөрәге дерт итеп куйды. Ничек башына элегрәк килмәгән, дөресрәге, нишләп бу сүз аның хәтереннән чыккан?! Аның кинәт исенә төште – рацияне яшерергә дип, төнлә барганда, Света яши торган урам турында сүз булды бит. Света әйткән иде бит урамнарының исемен. Ләкин «Красная» гынамы, әллә «Красная» янында тагын берәр сүз беләнме?..

Йорт номерын белми һәм белмәячәк инде ул. Ничә йорт икән соң ул урамда?..

Самат Березнякка, «Красная» урамының беренче йортыннан алып, илленчегә кадәр хатлар язарга карар кылды. «Илледән дә артык йорт юктыр анда, мөгаен, илле хатның берсе Светага барып җитми калмас. Хатның берәрсен күршеләре дә бирергә мөмкин аңа», дип уйлады ул.

**26**

Тупырдап торган оныгы белән мәш килеп, бөтен дөньясын онытып куанырга тырышса да, Пелагея барыбер «кызым киләчәктә баласы белән берүзе нишләр», дип хафаланды. Хатын-кызга – ир, балага әти кирәк инде ул, әмма хәзер ир-ат та аз бит, сугыш күпмесен юк итте, күпмесен гариплəп ташлады. Берәр яхшы ир-егет очраса ярар иде дип, Ходайга ялварды ул.

Ә Светлана Саматны көтте. Көн саен, сәгать саен көтте. Бер яктан ярым ятим улы өчен җаны әрнесә, икенче яктан, Саматтан баласы булу аңа киләчәккә өмет биреп тора иде.

Башка әллә нинди уйлар килә. Ул исән булырга тиеш... Исән калам дип, вәгъдә бирде бит ул. Әллә соң теге әсир радист аны үтереп качканмы? Бәлки, фриц Ортвин хәлсез булып кыланган гынадыр?..

Менә Җир йөзенә инде 1948 ел килде. Исән түгелдер, юкса, хәбәр бирми калмас иде. Самат бит ул! Исән калса, йә хат язар иде, йә үзе килеп чыгар иде.

Әмма уйларның мондыйларын Светлана куып җибәрә, аның алай уйлыйсы килми, ул һаман ышана, өметләнә иде.

Районның азык-төлек базасында бүлек җитәкчесе булып эшләүче Кондратьев Фёдор Егорович исемле кеше Березняктагы кибетләрне тикшерергә килгән комиссия әгъзасы иде. Светлана эштән кайтышлый, кибеткә кермәкче иде, кибет бикле булу сәбәпле, бәлки ачырлар дигән өмет белән бераз көтеп торырга булды. Күн плащ, карасу эшләпә кигән, кулына күн папка тоткан түгәрәк йөзле, җәйпәк борынлы, тыгыз гәүдәле ир-егет кибеттән чыгу белән үк Светлана янына килде һәм, куе кашларын чак кына калкыткалап, елтыравыклы соры күзләрен уйнаклатып, Светлана белән танышырга тотынды. Аннары кибеттән кирәкле ризыкларны үзе алып бирде, Светлана биргән акчадан исә баш тартып: «Сезгә миннән күчтәнәч», – диде һәм өйгә кадәр озата барды.

Шул арада якыннанрак таныша башладылар. Светланадан унике яшькә олырак, сугыш вакытында тылда азык-төлек белән фронтны тәэмин итүче частьларның берсендә хезмәт иткән бу кешенең эвакуациядәге хатыны башка кешегә иргә чыккан икән. Балалары булмаган. Үзенең ул яктан кимсетелгәнен, хатынының хыянәтче булуын ачыктан-ачык тәфсилләп сөйләде ул.

Хушлашканда, Фёдор тагын очрашырга тәкъдим итте. Светлананың бик ямансу көннәре иде, ризалык бирде.

Фёдор көнаралаш диярлек эш машинасы белән Березнякка килеп йөри башлады. Өч яшьлек малайга Фёдор Егоровичның мөгамәләсе яхшы икәнне күрү Светлананың күңеленә хуш килде. Бу кеше тормышта таяныч, ышанычлы терәк булыр дип уйлый башлады ул.

Тук чырайлы тыловикны бигүк өнәп бетермәсә дә, кызының бераз

җанланып, канатланып киткәнен, кечкенә Сабитның Фёдор Егорович алып килгән күчтәнәчләргә куануын күргәч, Пелагея каршы әйтмәде, төпле кеше, эш урыны әйбәт, бернәрсәгә кытлык кичермичә яшәргә мөмкин булыр дип өметләнде. «Ата-анасы, туганнары да еракта, комачауламаслар, гаилә эшләренә тыгылучы булмас, ә бу бит шулай ук бик мөһим нәрсә», дип уйлады Пелагея.

Светлана капма-каршылыклы хисләр белән бимазаланганда, Пелагея Фёдорга чыгарга кирәк дигәнрәк юнәлештә кызына төрле фикерләрен әйтте. Шул ук вакытта, Пелагея үзе дә кызының бу кеше белән тормышын бәйләүгә икеле-микеле караштa иде. Пелагея шик-шөбһәләрен әйтә башлагач исә, Светлана үзе, нигәдер, Фёдорга чыгу ягына авыша башлый иде. Кыскасы, кыз белән ана икеләнәләр, шикләнәләр, хәтта куркалар, әмма гаиләсез яшәү дөрес түгел, Сабитка әти кеше кирәк, тормышны ялгыз ярымятим бала белән алга таба алып баруы авыр булачак дип, Фёдорның өйләнешергә тәкъдим ясавын, уртак фикергә килеп, кабул иттеләр.

Шөбһә катыш өмет белән көткән көн килеп җитте. Фёдор гаилә корырга, язмышларны бәйләргә кирәк дип, Светлананы әнисеннән сорарга килде. Бу вакытта инде Пелагея аларның үзара мөнәсәбәтләренә күнгән иде һәм шундук ризалыгын әйтте, фатихасын бирде. Гәрчә Фёдор, кеше буларак, ошамаса да, дорфа холыклы, мин-минлеге көчле икәне күренеп торса да, Пелагея кызының тормышы бу кеше белән начар булмас, дигән өметтә калды.

Фёдор Светлана белән улы Сабитны Верхнегорскига алып китте һәм алар шәһәр уртасындагы шактый иркен фатирда яши башладылар.

Фёдор Егорович Светлананы район поликлиникасына урнаштырды. Моңа Светлана бик куанды, чөнки монда әнисенә кирәкле даруларны табарга мөмкинлекләр бар иде. Өч яшьлек Сабитны көндезләрен күрше әбидә калдырырга сөйләшеп килештеләр. Сабит беренче көннән үк бу әбине яратты, үз итте.

Пелагея берүзе Березнякта торып калды. Хәзер инде ананың гомерлек җан тынгысызлыгына кызы Светлана белән оныгы Сабитны юксыну өстәлде.

**27**

Алдан ук күңелгә кергән шом тикмәгә булмаган икән. Алар бер ай чамасы гына тыныч яшәделәр.

Михнәтле елларда да ачтан интекмәгән, халыкка кайгы килгәндә дә, тәмле ашаган һәм мул тормышка күнеккән Фёдорга тавыш-тынсыз буйсынучы, күз карашыннан ук үзен аңлаучы, кол кебек хатын кирәк иде. Үзсүзле, кире, даими рәвештә үзен генә кайгыртучы эгоист ир Светлана белән улы Сабиттан үзенең колларын «ясарга» тотынды.

Аның шушы авыр заманда, ил-көн ачлы-туклы вакытта үзенең вазифасыннан файдаланып юнәткән ризыкларның тәме тиз арада югалды. Светлана киләчәк тормышын күз алдына китерергә дә курка башлады. Тормыш алга таба да шушылай дәвам итсә, ничек яшәрбез дип коелып иңгән чаклары булды.

Фёдор бик көнче кеше булып чыкты. Ул көн саен диярлек «салып» кайта

һәм юк кына җирдән дә бәйләнергә сәбәп таба иде. Һаман да нәрсәдәндер, кемнәндер канәгать түгел иде ул. Өстәвенә, Светлананың аңардан балага узмавы да ачуын нык китерә иде аның. Күп тә үтмәде, көнче ир хатынына кул күтәрә башлады. Светлана башта, түзәргә кирәк дип, барыбер ирен тынычландырырга, аңлатырга, яратырга тырышты, кыскасы, һәрьяклап аның көен көйләде. Әмма Фёдор тора-бара инде Сабитны җәберләргә тотынгач, Светлана иренә каршы баш күтәргәли башлады.

Светлана инде алга таба бу кеше белән тора алмаячагын белә, әмма әнисеннән читенсенеп кенә яши иде. Бер ел эчендә көнче ирнең бимазалавы инде бөтен гомергә җитәрлек булды. Березнякка хәл белергә кайтканда, кызының сулыгып, ябыгып, хәлсезләнеп калуын Пелагея күрми калмый иде. Бер кайткач, түзмәде, Светлана әнисенә тормышының газаплы икәнен, ачыргаланып елый-елый сөйләде. Пелагеянең җаны нык әрнеде, әмма шулай да түзәргә кушты, бәлки, бәби алып кайтырсыз да, холкы йомшарыр, әйбәт кенә яши башларсыз дип, кызын өметләндерергә тырышты.

Ләкин Светлана, әнисенең киңәшләрен колагы белән тыңласа да, күңеле белән инде башка нияттә иде. Үзенең киләчәген Фёдор белән күз алдына китерми иде инде ул. Нигә болай интегергә?.. Аның Саматы бар, Самат белән уртак газиз улы – Сабит бар. Самат исәндерме, юктырмы – аңа барыбер. Аның өчен бар ул! Аның өчен исән ул! Светаның күңел түрендә, йөрәк белән янәшә Саматның урыны бар. Ул Светаның үзәгендә! Ул һәрвакыт аның белән! Ул – аңарда!

Фёдорны эшендә дә яратмыйлар иде, Светлана моны тиз арада сизеп алды. Чөнки мондый мин-минлекле, кәпрәючән, буш горурлык белән яшәүче кешене беркайчан, беркайда да сөймиләр.

Бергә яши башлап, бер ай узгач ук, Фёдорның Сабитны өнәмәве сизелә башлады. Исерек баштан өч яшьлек малай турында «чурка», «чурбан», «басмач», «басурман», «инородец» кебек ямьсез сүзләр дә ычкындыргалады.

Светлана аңа Самат белән булган мөнәсәбәтләре турында барысын да ихластан сөйләгән иде. Фёдор аңлар, егет белән кыз арасында булган мәхәббәткә карашы дөрес булыр, теләсә кем белән йоклый торган кыз түгел, баласы да мәхәббәт җимеше икәненә ышаныр дип сөйләгән иде бит ул. Сугыштан соң Самат аны Казанга алып китәргә вәгъдә иткәнен дә әйткән иде.

Көнче иргә беркайчан да кайчандыр булган мәхәббәтең турында, башка ир хакында тәфсилләп сөйләргә ярамый икәнне Светлана белми иде шул. Фёдорның ямьсез фантазияләре өчен аның сөйләгәннәре бик «туклыклы ризык» булып чыкты. Күп тә үтмәде, хатынына «татарин»ны телгә алып, «басурман»нан бала табуы турында төрттерергә, ә инде тора-бара: «шлюха», «потаскуха», «үтеп барган солдат астына яткансың» дип битәрләргә тотынды.

Тузынган чакларда Фёдор Саматны еш телгә ала башлады. Светлана: «Самат перестрелка вакытында урманда һәлак булды. Верхнегорскида комендатурада белешкән идем, анда әйттеләр – аны да, әсирне дә бандерачылар үтергән», – дип ялганлаган иде.

Самат инде бу дөньяда юк дип уйласа, көнче ир, бәлки, Сабитны какмас дип өметләнгән иде Светлана. Ә үзе исә Саматны көн саен искә алды, исәндер дип ышанасы килде.

– Ул бит инде юк бу дөньяда, ник минем үткәнемдә казынасың, нигә кайчандыр булган хәлләремә ачуың килә? – дип бусарынып елый иде Светлана.

Ә Фёдор, хатынның өзгәләнүенә җавап итеп, Сабитка төртеп күрсәтә иде:

– Аның караваы, аннан калган менә бу басмач бар! Син сагынасың бит ул татарыңны...

Андый вакытта Светлана ирен тынычландырырга теләп:

– Юк! Мин оныттым инде аны, – дигән була иде.

Ә чынында сагынмыймы соң инде! Светлана көн саен, сәгать саен Саматны сагына иде.

**28**

Фёдор беркөнне Березнякка ниндидер вак-төяк йомышлар белән килгән иде һәм эшләрен тәмамлагач, Пелагеянең өендә капкалап, чәй эчеп чыгарга булды. Пелагея үзе бу вакытта эштә, әмма Фёдор ачкычның кая яшерелгәнен белә иде.

Йортка җитәрәк, Фёдор почтальонканы күреп алды. Бу кыз Светаны белә, алар мәктәптә бергә укыганнар иде.

– Чибәркәй, егерме җиденче йортка бирәр нәрсә бармы? – дип, Фёдор болай гына сораган иде.

– Светага хат бар, – дип җавап бирде почтальон кыз һәм хатны Фёдорга тоттырды.

Конвертның тышындагы «каян» дигән урында: «ТАССР. Казан. Ершов урамы, 14 нче йорт, 31 нче фатир. Гарипов Саматтан» – дип язылган иде.

Көнче ир, әлбәттә, хатны ачып укыды.

«Исәнме, Света! Бердәнберем, Кояшым, күзалмам, сөеклем, җанкисәгем!» дип башланган иде хат. Саматның соңгы дүрт елда үзе белән булган хәлләре язылган бу хатта һәр икенче җөмлә Светаны ничек сагынуы, ничек яратуы һәм кавышырга хыяллануы турында иде.

Фёдор ярсудан урталай ярылырдай булды һәм аның, тизрәк Верхнегорскига кайтып, Света алдында үзенең бәйләнчек сорауларын куясы килде. Нәфрәтен йөгәнли алмыйча ары-бире йөренгәч, кинәт аның башына бер кара уй килде.

«Света былтыр үлде. Аңа атап, бүтән хат язмагыз», дип, нибары ике җөмлә язды ул һәм, посёлок почтасына барып, шушы кыска гына хатны конвертка салды да Казанга Самат адресы буенча җибәрде.

Кичкырын Фёдор Верхнегорскига кайтты һәм ул көнне өйдә коточкыч давыл купты. Кайтышлый, тынычланыр өчен ул шактый гына хәмер эчте, әмма аракы, киресенчә, аның ярсуын арттырды гына.

Аның караңгы кыяфәттә кайтуы гадәти хәл булса да, бу юлысы Светлана иренең кәефе яман икәнне күреп, нык курыкты. Хәтта өч яшьлек Сабит та, өйдә тавыш кубасын сизенгәндәй, әнисенә елышып, тавыш-тынсыз торды.

Өстәлгә әзерләп куелган ризыкны Фёдор бүген кабып та карамады. Озак кына табын янында бер ноктага текәлеп утырганнан соң, сүзен:

– Света, син мине алдама, – дип башлады. – Мине җүләргә санныйсың бугай син...

– Ни дигән сүз инде бу? – диде Светлана, аптырап. – Кайчан алдадым мин сине?

– Син мине көнче дисең... Ә бит кеше тиктомалга көнләшми...

Светлананың йөзеннән газап төсе саркыды:

– Тагын тотынасыңмы инде!

– Дәшмә! – дип җикерде Фёдор һәм куркудан бөрешеп, әнисенә сыенган Сабитка юан бармагын төбәде. – Синең менә бу чурканың этисе татар икәненә ышанам. Арагызда мәхәббәт булганы да, бәлки, дөрестер. Хәер, кем белгән, бәлки, гадәти беләтлектер...

– Фёдор! – дип, тавышын күтәрде Светлана.

Әмма Фёдор инде кызганнан-кыза бара иде.

– Ачма авызыңны, сука! – дип ысылдады ул. – Син аны һәлак булды дидең.

– Әйе, һәлак булды ул, – диде Светлана, караватка утырып һәм улын үзенә тартып китерде.

– Алдыйсы-ы-ың! – дип, бармак янады Фёдор. – Исән ул! Һәм син аны сагынып, аны көтеп яшисең. Мин бит күрәм, сизәм...

Светлана өзгәләнеп, иренә аңлатырга тырышты:

– Фёдор, сиңа барыбер түгелмени – һәлак булганмы ул, юкмы! Аның белән очрашканда, аның белән булганда, мин бит синең дөньяда барлыгыңны белми дә идем. Мин бит инде хәзер гомерем буе шуның өчен иза чигеп яшәргә тиеш түгелдер.

Фёдор, яман усал итеп, авызын кыйшайтты:

– Иза чигеп... Иза чигеп яшисеңмени?! Син бит балда-майда йөзәсең! Яшәве авырмыни сиңа?!

– Синең холкыңа, юкка көнләвеңә түзәрлек түгел, – дип еламсырады Светлана. – Син юк кына җирдән дә көнләшә башлыйсың... Мин бит инде хәзер таныш ирләр белән исәнләшергә дә куркам... Син гел мине күзәтәсең, төпченәсең, хәтта поликлиникага йөрүче пациентларга да көнлисең бит.

Фёдор, йодрыгын төйнәп:

– Димәк, юкка түгел! – диде. – Димәк, сәбәп бар!

– Бернинди сәбәп юк!

– Син минем кочагымда чакта да башка кеше турында уйлап ятасың...

– Синең авыру фантазияләреңнең чиге юк, – диде Светлана, башын чайкап.

Фёдор йодрыгы белән өстәлгә сукты:

– Син ихлас түгел минем белән! Син алдыйсың мине!

Светлана елый башлаган малайны алдына утыртып:

– Кычкырма, баланы куркытасың, – диде.

Фёдор тагын бармагын Сабитка төбәде:

– Әле белгән юк, бу татарчонок, бу басмач кем булып, нинди булып үсеп җитәр.

Светлана улын кочаклап:

– Әйбәт кеше булып үсәр, менә дигән ир-егет булачак, – диде. – Анда синең эшең булмасын.

Фёдор ямьсез итеп елмайды:

– Артык кыюланып киттең соңгы вакытта! Син миңа каршы әйтә башладың...

– Чөнки мин дә кеше, – диде Светлана, тавышын күтәреп. – Мин синең

милкең түгел. Син мине яратам дигән идең... Син кешеләрне дә үз милкең итеп яратырга телисең.

Фёдор, гадәттәгечә, хатыны куркып аклана башлар, тынычланырга өндәр дип уйлаган иде. Бүген исә ул каршы әйтергә маташа. Фёдор сикереп торды да ярсып кычкырды:

– Дәшмә, сука! Алдакчы! Б...!

Фёдор Светлананың яңагына каты иттереп сукты. Әнисе караватка барып төшкәч, Сабит бии-бии чәчрәп еларга тотынды. Фёдор тагын бер тапкыр йодрыгы белән хатынының аркасына орды, Светлананың йөзе кинәт агарып китте, шактый вакыт тын да ала алмыйча ятты. Сабит әнисенең халат итәгенә ябышып үкереп елады, Светлана әкрен генә урыныннан торды һәм хәлсезләнгән куллары белән улын кочагына алды.

– Син ник кыйныйсың мине? – дип ыңгырашты Светлана. – Мин моңа лаекмы соң?

– Ник алдыйсың син мине, шлюха?!

– Минем алдаганым юк сине, – диде Светлана чак кына ишетелерлек итеп. – Миңа пычрак сүзләр әйтмә. Улымны да төрле ямьсез сүзләр белән атама.

Фёдор, кире урынына утырып, алдан пеләшләнә башлаган башын ике кулы белән кысты:

– Мин сиңа шул кадәр күп яхшылык эшләдем, – диде ул, сүзләрен тамак төбеннән этеп чыгарып. – Рәхмәтсез, оятсыз кеше син. Мин синең өчен барысын эшләргә дә әзер. Син мине алдама гына.

Светлана торып, Сабитны караватка күтәреп утыртты да үзе, курыкмыйча, ире каршына килеп басты:

– Фёдор, болай яшәп булмый.

– Иркәләп тынычландырасы урынга, син һаман мине көнчелектә, катылыкта гаепләргә маташасың. Мин сине бала белән алдым... – диде Фёдор. Бу вакытта аның чырае ямьсез булып кыйшайган иде.

– Ник алдың соң? – диде Светлана.

Фёдор, сикереп торып, тагын сукты, тагын бәрде. Йөгереп килгән Сабитны этеп җибәрде, малай, идәнгә егылып, тагын да катырак үкереп еларга тотынды.

Светлана, авыртуга көчкә чыдап, караватка кырын ятты, Сабит идәннән торып, әнисе янына үрмәләп менде.

– Ник бу кадәре дулыйсың?! – диде Светлана, иреннәрен көчкә кыймылдатып. – Кыйна мине, кыйна. Бер гаебем юк килеш кыйна, әмма улыма тиясе булма. Ник болай шашасың соң син бүген? Минем бит синнән башка бер ир-егеткә дә башымны күтәреп караганым юк. Ир кешләр белән сөйләшергә куркып, эштә дә кыргыйланып беттем бит инде.

– Бәлки моның өчен рәхмәт әйтергә тиештер мин сиңа? – Фёдор караватянына килеп, хатыны өстенә иелде: – Ник алдадың мине?

Светлана, тагын сугар дип, ике кулы белән битен капларга әзерләнде:

– Ничек итеп, ни дип алдадым мин сине? – диде ул, калтыранып. – Минем беркайчан ялган сөйләгәнем булмады сиңа. Сиңа хыянәт итү уемда да юк.

Фёдор тәрәзә янына барып, беркавым дәшми торды.

– Син алдадың мине, – диде ул, тәрәзәдән карап. – Теге татарың һәлак булды дип алдадың.

– Алдамадым, – дип киреләнде Светлана.

– Исән ул! – диде Фёдор, кинәт борылып.

– Син үлгән кешегә дә көнләмә инде мине, – диде Светлана, улын кырыена яткырып.

Фёдор тагын карават янына килеп:

– Исән ул! – дип ысылдады.

Светлана торып утырды:

– Арыдым мин. Тилермә, Фёдор, – диде ул, дер-дер калтырап. – Инде мин үзем дә җүләрләнә башладым бугай синең белән.

– Синең татар басурманың исән бит ул! – дип, кинәт кычкырды Фёдор.

Сабит әнисенең артына качып көзге яфрак сыман калтыранды. Ул инде елап арыган, торымнан-торымга сулкылдап куюы гына ишетелә иде.

– Саташасың бугай инде, – диде Светлана, әллә чыгып качарга микән дип уйлап.

– Березнякка аңардан хат килде, – диде Фёдор, ямьсез елмаеп.

– Кемнән?

– Синең шул Саматыңнан. Синең исемгә. Шулхәтле матур, җылы, тетрәндергеч итеп язылган. Мин укыдым ул хатны.

Светлана көнче ирнең әллә ниләр уйлап чыгаруына күнеккән иде инде:

– Юри әйтәсең. Тагын ниләр уйлап чыгарырсың икән инде... – диде ул.

Фёдорның ачудан хәтта тавышы бераз еламсык булып чыкты:

– Ник алдадың мине? Һәлак булмады бит ул!

Светлана тирән итеп сулап куйды.

– Бердәнбер алдавым шул инде минем, Фёдор. Синең көнче икәнеңне аңлагач, һәлак булды дип әйтергә кирәк таптым. Дөресен әйткәндә, исәнме-юкмы икәнен белмим.

– Һәм шуңа күрә син аны гел көтеп яшисең!

Светлана башын күтәреп, инде дошманга әйләнгән иргә нәфрәт белән карады:

– Ник бимазалыйсың син мине?!

Светлана, улын идәнгә төшереп, үзе дә торган иде, шул вакытны Фёдор кизәнеп, йодрыгы белән аның башына китереп сукты. Светлана хәлсезләнеп караватка утырды.

Каты сукты. Авыртты. Инде бөтен тән авырта, баш әйләнә, йөрәк атылып чыгардай булып тибә. Әмма куллары белән башын кысып, караватта йөзтүбән ятканда, Светлананың вөҗүде буйлап шатлык дулкыны йөгереп үтте – Самат исән! Сабитның әтисе исән! Аның бердәнбер сөйгән кешесе шушы дөньяда! Самат исән! Самат исән! Самат исән! Самат аңа хат язган! Хәтта Фёдор йодрыгы белән башына суккач та, аң караңгыланды, әмма шул зольмәт эченнән яп-якты нур – Саматның сурәте чагылды. Исән! Саматтан чынлап та хат килгән. Юкса бу тыл күсесе болай ук шашынмас иде.

***

Икенче көнне кич белән, эштән кайткач, Фёдор гафу үтенде.

– Артык нык кызып киттем. Ну, мине дә аңла инде... – дип мыгырдады ул.

Кыйнаганнан соң ул гел шулай гафу үтенә, вакытлыча тәүфыйклы

песигә әверелә иде. Светлана шул ук көнне эштән китәргә гариза язганны белми иде әле ул. Расчёт алып йөргән көннәрдә дә әле Фёдор хатынының Березнякка кайтып китәргә җыенганын сизмәде.

Менә ул көн килеп җитте һәм Светлана аңа турыдан-туры:

– Мин әнием янына кайтам, – диде.

Менә моны Фёдор бөтенләй көтмәгән иде.

– Ничек инде?! – диде ул, сискәнеп.

– Мин бер ел түздем... Алга таба да түзсәм, ахыры яман булуы ихтимал, һәлакәт белән тәмамланырга мөмкин.

Фёдорның әле ышанасы килмәде.

– Аерылырга мәллә исәбең? – диде ул, котсыз калып.

– Мин болай яши алмыйм. Көнче кеше көнләшергә гел сәбәп табадыр инде ул.

– Син шушы арада гына бу карарга килгәнсеңдер бит? – диде Фёдор, әле араларны рәтләп буласына өметен җуймыйча.

– Аерылырга кирәк икәнне яши башлагач ук әкренләп аңлый башладым мин, – диде Светлана. – Миңа синең белән яшәү бик авыр булды. Улымны кага башлагач, чурка, басурман, басмач, дип үртәргә тотынган көнне үк, мин инде бергә яшәмәячәгебезне аңладым.

– Ачулы вакытта гына әйтелгән сүзләр бит инде ул, – дип, хатынын кочакламакчы булды Фёдор.

Светлана аны этеп җибәрде:

– Минем улым чурка түгел, минем улым – татар! Чөнки аның әтисе – татар!

Фёдор теге көнне катырак кыйнаганына үкенә иде, әмма көнче кешегә хас сер бирмәслек белән:

– Миңа да авыр бит синең аны сагынуыңны, аны оныта алмавыңны сизеп яшәү, – диде.

– Бир миңа Саматның хатын! – дип кинәт җикерде Светлана.

– Мин хатны ертып ташладым, – диде Фёдор борын төбеннән. – Син аны һаман яратасың...

Светлана кычкырып диярлек:

– Яратам! – диде. – Аны яраткан кебек мин инде беркемне дә ярата алмаячакмын!

Фёдор әле һаман бу хәлдән чыгу юлын эзләде.

– Хаты килде дип, юри әйттем, – диде ул, башын читкә борып. – Сиңа ничек тәэсир итәр икән дип ялганладым. Исән түгел ул. Исән булса, күптән хәбәр бирер иде, яисә үзе килеп чыгар иде.

– Алдыйсың! Исән ул! Хат килгән! Күңелем сизә – син ул хатны ачып укыгансың... Кабахәт кеше син! Син бит Саматның тырнагына да тормыйсың!

Фёдор мондый сүзләрдән шок хәлендә калды, хәтта кыҗрарга да үзендә куәт тапмады. Бу көнче, агрессив кеше Светлана аны ташлап китә алыр дип башына да китермәгән иде. Шулай да, бөтен нәфрәтен җыеп:

– Мин сиңа тыныч тормыш күрсәтмәячәкмен, – дип янады. – Киткәнеңә әле үкенәчәксең.

Фёдор әйткән сүзләргә Светлананың һич кенә дә исе китмәде.

Вакытлыча, берничә көн, тәмам расчёт алганчы, бергә эшли торган хатында торганнан соң, Светлана, улын күтәреп, Березнякка әнисе янына кайтып китте.

**29**

Березняктан килгән ике җөмләле хатны укыгач, Саматның бу яман хәбәргә ышанасы килмәде, җан өшеткеч ике җөмләдә ниндидер хата бардыр шикелле тоелды, гүя шул ялгышны табып төзәтсә, чынында бөтенләй башкача булыр шикелле иде.

Юк! Света бу дөньядан китәргә тиеш түгел! Кем язды икән моны? Акка кара белән язганнар шул... Бәгырьгә кара, коры-кытыршы күмер белән тырнап-сызып язганнармыни! Дөрес булса, ничек, нәрсәдән үлде икән? Барыбер ышанасы килми, җан өшеткеч бу хәбәрне күңел һич кенә дә кабул итми. Әмма менә бит язганнар...

Кемдер юри, махсус рәвештә башка кеше турында үлде дип язарга мөмкин дип, Саматның башына да килмәде. Ул көнне Самат каты гына «салды», кемгә дә булса Света турында, аны ничек яратуы хакында сөйлисе килде.

Казанның Дәрвишләр бистәсендә әнкәсенең апасы Галимә бар, гомере буе ялгыз яшәп, мәктәптә китапханәче булып эшләүче бу апа белән Самат кайвакыт эч серләре белән уртаклаша иде.

Галимә апа Саматны бик ярата, үз баласы кебек якын итә иде. Ул, тын да алмыйча, Саматның сөйләгәннәрен тыңлап утырды. Яу кырларында күпме кан, күз яше, кайгы-хәсрәт күреп кайткан солдатның нибары өч көн турында һәм бер кыз хакында шундый тирән сагыш, мәхәббәтле хисләр белән озын-озак сөйләвеннән Галимә апа таң калды.

Бу очракта бернинди киңәш бирерлек түгел иде шул. Һәм Саматның үзенә дә бернинди киңәш кирәк түгел иде. Монда нинди киңәшнең фәтвасы булырга мөмкин?! Кайвакыт аһ-зарларыңны кемнеңдер ишетүе, тыңлавы хәлне җиңеләйтеп куя бит, Саматка да фәкать тыңлаучы гына кирәк иде.

Әлбәттә, Галимә апа тынычландыра торган сүзләрне әйтте, Саматны, гадәттәгечә, мактады, һәрвакыттагыча, аның бала чагын искә төшерде. шуклыкларын, кайвакыт хәтта хулиганлык кылганнарын, гел сугыша торган гадәте булганын, урамдагы дуслары аңа «Чукмар» кушаматы такканнарын көлә-көлә искә алып утырды.

– Шигырьләр язасыңмы соң? – дип, сүзне икенчегә борасы килде Галимәнең.

Самат аның бу соравын ишетмәде. Ул тагын шактый вакыт Березнякта уздырган өч тәүлекнең якты мизгелләрен сөйләде, ә алар сөйләп бетерерлек түгел, аларның чиге юк иде.

Әйтерсең лә, вакытның ул өлеше үтеп китмәгән, ул көннәрнең һәр сәгате, һәр минуты, һәр мизгеле гел яңадан башында әйләнә, кабатлана һәм дә бу әйләнеш – мәңгелек иде!

Самат әле яралангannan соң госпитальләрдә ятканда да шигырьләр язгалый иде. Света үлде дип язылган хатны алганнан соң бүтән инде беркайчан аның күңеленә шигъри илһам килмәде. Берничә тапкыр сөйгәненә багышлап, аның бу дөньядан вакытсыз китүе турында шигырь

язарга нияте булып алды, әмма Светаны тасвирларга, аның сулышын, күз карашын, буй-сынын, атлап йөрүләрен, ике аккош кебек кулларын, елмайганда, мең гөлләрдән нурлырак йөзен, көлгәндә яңгыраган сихри тавышын, сагышлы чагындагы моңын, аңардан килгән хуш исне – ничекләр сүз белән генә кәгазьгә салып булсын!

1950 елда алар Рузия белән никахлаштылар. Березняктан килгән ялган хаттан соң Саматның үзәгендә ниндидер бик кирәкле, иң мөһим нәрсә югалды. Өйләнгәндә, аның Рузиягә булган хисләре дә саеккан иде инде.

Хәзер аның сәламәтлеге дә чамалы иде, шулай да Казан авиация институтының приборлар төзү факультетында укырга, аны уңышлы тәмамларга көче, акылы җитте.

Икенче курста, кичке бүлеккә күчеп, Казан авиация заводының механика цехына эшкә керде, аннары инструменталь цехка урнашты.

Улы Хәйдәр туган 1958 елда, институтны тәмамлаганда, ул инде смена нәчәлниге иде, күп тә үтмәде, цех нәчәлниге итеп куйдылар. Әмма сәламәтлеге генә аның елдан-ел начарая барды, күкрәк эчендә калган пуля үзенең барлыгын гел сиздереп торды.

Рузия, педагогия институтын тәмамлаганнан соң, мәктәптә тарих һәм география укытучысы булып эшләде. Өйләнешеп, әйбәт кенә яши башлаганнар иде кебек, әмма бәла артыннан бәла килә торды. Беренче бала тумады, төште. Икенче бала, карап торуга алма кебек кыз, өч яшендә кинәт авырып, температурасы күтәрелеп, үлеп китте. Нидән үлгәнен белмәделәр, аңламадылар, табиблар әйтүенчә – ниндидер инфекциядән. Самат белән Рузия арасында салкын җилләр исә башлады. Кайгылар, югыйсә, кешеләрне якынайтырга тиеш тә бит... Монда инде, әлбәттә, Саматның торымнан-торымга хәле авыраюы, хәмерне еш эчә башлаганнан холкының бозыла башлавы да сәбәп булгандыр. Әмма, шулай да, аның әле түбәнгә тәгәрәмәс өчен дәрте-дәрманы бар һәм төшенкелеккә бирелмәскә ул үзендә көч таба иде.

1958 елда малай туды, аңа Хәйдәр дип исем куштылар һәм гаиләдә иминлек урнашты кебек, өйгә шатлык тулган, тормышның яңа мәгънәсе барлыкка килгән шикелле иде.

Хәйдәр бик акыллы, сәламәт бала булып чыкты. Ике яшь ярымда алфавитны өйрәнде, дүрт яше тулганда укый башлады. Саматның хатынына булган мәхәббәте генә, никтер, котылгысыз рәвештә көннән-көн сүрелә барды.

Төзәлмәслек яра игътибарны үзенә ныграк җәлеп итә башлады, табиблар да бернишли алмадылар, үпкәдән пуляны алу мөмкин түгел дип әйтә тордылар.

Тагын бер яра – җан җәрәхәте – шулай ук мәңге тынгы бирмәде, Светаны күңеленнән чыгарып ташлый алмады.

Нык үзгәрде Саматның холкы. Хатын белән мөнәсәбәтләр бозылганнан-бозыла барды. Самат үзенә бикләнә башлады, эштә дә аңа өстән дәгъвалар, шелтәләр, кисәтүләр арта торды. Хезмәттәшләре белән дорфа, кырыс, кискен булганы өчен парткомга да чакыргаладылар һәм иң зур хилафлыкны аңа парторг белән низаглашуы китергәндер, мөгаен.

Ил-көн мәсьәләләрендә дә, үзе җитәкләгән цех эшләре буенча да ул

үзенең фикерләрен турыдан-туры әйтә һәм үз сүзендә нык тора иде. Сәясәткә кагылып, ялгыш ычкындырган, ә кайвакыт махсус рәвештә ярып салган фикерләре өчен аны «тиешле» органнарга да берничә тапкыр чакыртып сөйләштеләр. Әмма Самат үзенә каршы бара алмады, үз принципларыннан тайпылмады, адым саен баш имичә әйтәсен әйтте, эшлисен эшләде. Аракы белән мавыгуы барысына да мәгълүм, чөнки ул чырайга чыга, әллә каян күренеп тора иде.

Элеккечә булмаса да, аның әле ихтыяр көче бар иде. Әмма ул яшәүнең мәгънәсен югалтты. Үзе дә: «Югыйсә улым да бар бит, нишләп яшәү ямен җуйдым соң мин?!» – дип хафаланды. Үзе ихлас кеше буларак, башкалардан да гел ихласлык таләп итте, ни уйлаганын туры әйтә торган булды һәм эштән чыгарачакларын сизгәч, аның аз гына да эче пошмады. Бу дөньяда нәрсә кыйммәт, нәрсә кадерле, нәрсә үлемсез – моны төгәл белмәсә дә, чынбарлыктагы, тормыш-көнкүрештәге нәрсәләрнең, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрнең вә бәйләнышларның ясалма һәм зур мәгънәгә ия түгеллеген тоеп яшәде. Ярый әле бу төксе дөньяда өч кадерле кешесе бар аның – әнкәсе, улы һәм... Украинада калган Светасы.

Ул тора-бара сугыш елларын сагына башлады. Дошманга каршы үзеңне аямыйча сугышканда, син – ирекле. Аның хөрлеккә иң нык якынайган халәте – яу кырында иде. Ә инде шул дәһшәтле еллар уртасында Березняк дип аталган посёлокта насыйп булган өч тәүлек кабатланмас дәрәҗәдә бәхетле вакыт иде.

Өч тәүлек... Санаулы сәгатьләр, санаулы минутлар һәм... мәңге санап бетермәслек мизгелләр – шул өч көн, өч төн эчендә ләбаса.

Дәваханәдә еш ятуы, кырыс холыклы, баш имәс шәхес булуы завод җитәкчеләренә, әлбәттә, ошамый иде. Аны цех нәчәлниге вазифасыннан азат иттеләр һәм шул ук цехта мастер итеп калдырдылар. Әмма күп тә үтмәде, ул, гариза язып, үз теләге белән заводтан бөтенләй китте.

Болай да җылылык калмаган гаиләдә гауга купты.

Холкың алама, телеңне тыя белмисең, шундый урыннан мәхрүм булдың дип, хатыны Рузия аның җелеген суырды, кешечә яшәмибез, инвалид килеш аракы эчәсең, дип тинтерәтте, оят, хурлык дип илаулап елады.

Гаилә таркала күрмәсен дип хафаланып, әнисе Мәдинә дә кайгыга батты. Аның да килен белән аралар әйбәттән түгел, дөресен әйтергә кирәк, соңгы вакытта киленен Мәдинә өнәми, күкрәгендәге ярасы төзәлмәгән газиз улына Рузиянең чәчри-чәчри каты бәрелүенә дә нык рәнҗи иде.

Ана – ана инде, Саматны кызганды, ачуланмады, киресенчә, Рузия катырак орына башласа, яклады, улының күкрәгендәге ярасы турында онытмаска үгетләде.

Шулай да Мәдинә аулакта саклык белән генә Саматны да игә китерергә маташты:

– Улым, син бит сугышларны үткән кеше, – диде ул аңа беркөнне. – Аңлыйм, саулыгың чамалы. Шуңа күрә, аракы эчүдән туктасаң иде син... Язмыштан узмыш юк, нишлисең бит... Үзеңне сакларга тырыш инде. Төшенкелеккә бирелмәскә кирәк. Мин бар бит әле... Улың бар...

– Әнкәй, үзем дә аңлый алмыйм, – диде Самат, әнисенең хак сүзе белән килешеп. – Нишләдем мин, нишләп мондый мин хәзер?..

– Әтиеңнең, абыеңның хәтта каберләре кайда икәнне дә белмим... – диде Мәдинә, күз яшьләрен яулык почмагы белән сөртеп. – Бердәнбер якын кешем син генә калдың бит, улым. Яшәргә кирәк, нык бул. Син бит көчле егет идең, хәзер дә көчле син. Мин ышанам, без әле бергә-бергә озак яшәячәкбез. Әле Хәйдәрнең туенда биерсең.

– И әнкәй, ярый син бар әле, – диде Самат, моңсу елмаеп. – Син булмасаң, мин инде күптән гүр иясе булыр идем.

– Шуңа күрә бер-беребезне саклыйк, улым, – диде ана, газаплы йөзенә елмаю яктысы йөгертеп.

– Син бар, хатыным, улым бар, нишләптер барыбер бушлык тоям, – диде Самат, ачынып. – Аңламыйм, әнкәй, аңламыйм.

Мәдинә улына күптән әйтергә теләгән, әмма моңарчы кыенсынган сүзен башлады:

– Улым, син миңа ачыктан-ачык барысын да сөйләмисең кебек. Күңелем сизә, синең үпкәңә эләгеп калган пулядан тыш күңелеңдә чишелмәгән ниндидер тагын бер төен бар шикелле.

Самат авыр сулап куйды:

– Төен түгел ул, әнкәй. Үзем дә белмим. Белсәм, аңласам, бәлки, болай авыр булмас иде.

– Берәр кешене сагынасыңмы әллә?

– Әлбәттә. Сагыныр кешеләрем җитәрлек бит. Әтине, абыйны, тумаган баламны, өч яшендә үлгән кызымны.

– Алардан башка да берәр якын кешеңне югалтмадыңмы син?

– Әйе, әнкәй, югалттым аны да. Украинада иде ул...

– Үлгән кеше артыннан үлеп булмый инде. Бик чибәр идеме?

– Чибәр иде. Искиткеч гүзәл иде ул.

– Исеме дә матур шул – Света, – дип уйга калды Мәдинә.

– Ә син каян беләсең?! – диде Самат, әнисенең Света хакында белүенә гаҗәпләнеп.

– Беләм, улым. Галимә апа әйткәние. Миңа гына, никтер, әйткәнең булмады.

Самат дәшмәде. Шактый вакыт тып-тын утырганнан соң, Самат үзалдына сөйләгән сыман:

– Яу кырында, окопларда, походларда нык алҗыганга күрә, ул өч көн оҗмах көннәре булып тоелгандыр... Күкрәккә әллә ничә пуля килеп тисә дә, мәхәббәтне үтерә алмый. Үзеңне үтергән сурәттә дә, мәхәббәтең исән калачак. Ул кан-тән яссылыгында ятмый, мәхәббәт ул җиһан тирәнлегенә тамырларын сузып тоташкан.

– Гаиләң өчен көрәшергә кирәк, улым. Бала хакына, Рузия белән мөнәсәбәтләрне җайла. Баланың бернинди гаебе юк, ятим итмә. Мин дә сабыррак булырга тырышырмын, арагызга кермәм, тыгылмам, әмма син дә гел үз киреңне генә сукалама. Булган нәрсәне җимерү, вату җиңел... Яңадан төзәтүе авыр, ә кайвакыт мөмкин дә түгел. Моны сиңа аңлатып торасы да юк, син сугышны күреп кайткан кеше, миннән дә яхшырак беләсең.

– Ярар, әнкәй, тырышырмын, – диде Самат, әнисенә якты елмаеп. – Рәхмәт сиңа.

## 30

Әмма гаилә барыбер таркалды. Рузия, икенче класста укучы сигез яшьлек Хәйдәрне алып, әнисенә кайтып китте. Эшләр аерылышуга таба барганны барысы да сизеп йөрде инде, шуңа күрә Рузиянең әнисе дә, Мәдинә дә, Самат та бу вакыйгага тиз күнделәр. Рузиянең әнисе һаман шул күрше йортта яши иде, алар әйберләрен җәяү генә үзләре әкренләп ташып бетерделәр.

– Ярый әле, еракта яшәмәячәкләр, күрше йортта гына, – диде Мәдинә, оныгын еш күрергә мөмкин булганга куанып.

Саматны сугышка кадәр һәм сугыштан соң күпмедер вакыт эшләгән урынга – мех фабрикасына механик итеп алдылар. Әмма күзгә күренеп картая төшкән, чәченә чал кергән ветеран-инвалидның хәле отыры начарая барды.

Самат улын бик ярата, гел аралаша, көнаралаш диярлек үз өйләренә алып кайта, ләкин аерылышканга һич кенә дә үкенми иде.

Хәйдәр әле бала гына булса да, әтисе аның белән җитди темаларга әңгәмә корырга тырыша иде. Ни сәбәптәндер – нәрсәдер аңлатырга, нәрсәдәндер сакларга теләпме, әнисе белән аерылганга үзен гаепле тоюданмы, сугыш ярасы һаман төзәлмәгән әтисенең күңел газабына улы төшенсен дипме, каршысында олы кеше утыргандай сөйләшә иде.

Соңгы вакытта Самат аңа сугыш турында күбрәк сөйләде, бигрәк тә әсир немецны саклап йөргән вакыйганы кат-кат бәян итте. Яу кырында геройлык кылган вакыйгаларны да ул кадәр үк теләп вә тәфсилләп бәян иткәне булмагандыр, ә Березняктагы өч көн турында ул һичтуктаусыз сөйли ала иде.

Самат беркөнне Хәйдәргә әсирдән салдырып алган сәгатьне бирде. Сәгать йөри һәм вакытны төп-төгәл күрсәтә иде. Шатлыгыннан Хәйдәр очыплар китәрдәй булды.

Березняктагы хәлләрне инде әллә ничәнче тапкыр сөйләгәннән соң, Самат тагын да җитдирәк темага кереп китте, әйтерсең лә, каршысында ун яшьлек улы түгел, инде тормышка аяк баскан ир-егет утыра иде:

– Үзеңә каршы барма, улым. Күңелең ничек куша, шулай эшлә, җаның ничек тели, шулай яшә. Исән-сау булып үс. Син бик акыллы малай, укы, югары белем ал. Сиңа ун яшь... Берничә елдан инде егет булачаксың, кызлар артыннан йөри башларсың... Гашыйк булырсың... Ярат! Нык ярат! Әмма яраткан кызыңны югалтма. Син төс-биткә генә түгел, холык-фигылең белән дә күбрәк миңа охшагансың. Димәк, син дә нык яратачаксың. Һәркемгә дә өзелеп ярату сәләте бирелми. Иң беренчесе – үзеңне югалтудан курык. Икенчесе – сөйгән кешеңне югалтудан курык. Башка нәрсәдән курыкма һәм беркемнән дә курыкма. Без әниең белән аерылыштык... Әниең синең әйбәт кеше. Газап минем тәкъдиремә язылган, ул – минеке, фәкать минеке генә. Әниеңнең сүзен тыңла, улым. Әмма мине дә гаепләмә. Сиңа имин заман туры килде, без күргәннәрне күрергә язмасын. Һәм чын кеше булырга насыйп булсын. Минем күкрәк эчендә, үпкәмдә – пуля. Ул анда мәңгегә калды. Беләм, бу тикмәгә түгел. Әмма аңламыйм – нигә, ни өчен ул миңа килеп керде дә... шунда калды?..

Бу минутларда Хәйдәрдә әтисенә карата бары тик кызгану хисләре генә була, ул әле аның сүзләренең мәгънәсен тирәнтен аңларлык яшьтә түгел иде.

Соңгы вакытта Света Саматның төшләренә еш керә, кайберләре шулкадәр ачык, якты – өндәге вакыйгадан да ышанычлырак иде.

Имеш, Самат яп-якты көнне, җәйрәп яткан ачык болын буйлап китеп бара. Артына борылып караса, еракта, аны озатып, Света басып тора – шундый гүзәл, киеме дә матур. «Китмә! Мин бит монда калам!» – дип кычкыра. Әмма бу аерылышу, никтер, авыр түгел. Саматның күңеле шат. Самат белән тагын кемдер бара. Караса, аның белән янәшә әсир Ортвин түгел, ә бите-башы белән ак чүпрәккә төренгән бер зат бара икән. Шомлы, куркыныч булырга тиеш кебек, әмма Самат бу юлдашка шат. Артта Светаның басып торуы, гәрчә ул инде еракта калса да, дәртләндерә, илһамландыра. Света кайдадыр монда, аның белән элемтә бар. Шуны белү дә аны бәхетле итә. Серле, шомлы, сәер юлдашы белән алар якты офыкка таба атлыйлар. Света белән ара ерагая, әмма барыбер рәхәт, чөнки борылып карагач, ул аны күрәчәк.

Имеш, әҗәл якынайганда, кеше үзенең тормышыннан хәтердә нык уелган шатлыклы яки фаҗигале вакыйгаларын төшендә күрә. Төштә бу хатирәләр бәхет тою җепләре белән үрелгән була.

Үләр алдыннан кешегә, нерв системасын тынычландырыр өчен, аңны бу дөньядан китүгә әзерләү йөзеннән, матур төшләр еш керәләрдер, ахрысы. Үлем якынайган саен яктырак вә ямьлерәк төшләр – иркен болыннар, нурлы офыклар кебек искиткеч гүзәл күренешләр, матур-моңлы авазлар – тиздән яңа төрле хәят башланачагын гаиптән хәбәр бирәләрдер һәм дә моның өчен кешенең тәне үләргә тиеш икәнне аңлаталардыр.

Саматтан чыгарга һич кенә дә теләмәгән пуля үзенекен итте. 1968 елның азагында үпкәдә каты ялкынсыну башланды һәм берничә ай дәваханәдә ятканнан соң, Самат вафат булды.

Ун яшьлек Хәйдәр тынсыз яткан әтисенә карап, хыялланып куйды: бәлки, аны күп еллар бимазалаган пуляны менә хәзер, тын алмый ятканда, күкрәгеннән алып буладыр һәм ...әтисенә җан керер, ул торыр һәм, гадәттәгечә, Хәйдәргә: «Сәлам, улым!» – дияр.

Хәйдәр ул көнне аермачык хәтерли. Әтисе ята, әмма ул һич кенә дә үлгән кешегә охшамаган, йоклыйдыр кебек иде. Аның муенында миңе булган икән... Нишләп элек күрмәгән ул аны... Соңгы вакытта әтисе, салып, авырып йөргәч, бетәшкән кебек иде, ә хәзер, бер хәрәкәтсез ың-шыңсыз, тып-тын ятканда, аның кайчандыр җегәрле, батыр кеше булганын күрерлек иде. Гәрчә нык ябыккан булса да, аның әтисе җиңелгән кешегә түгел, җиңүчегә охшаган һәм менә торыр да: «Ник җыелдыгыз?!» – дип әйтер сыман иде.

Батыр йөрәкле, орден-медальле солдат ил-көндәге төкселеккә каршы гына көрәшергә үзендә көч тапмады. Яшисе килми башлагандыр аның, юкса китеп бармас иде.

Хәйдәр әтисеннән ихласлык, тирәнтен уйлый белү, турылык һәм үз принципларына тугрылык сыйфатларын алган. Аерылганнан соң, Рузия әтисе турында яман сүзләр әйтеп зарланганда да, Хәйдәр, әле кечкенә булуына карамастан, әнисенең сүзләре белән килешмәде, әтисен барыбер яратты һәм гомер буе яратачак.

Үсә төшкәч, олыгайгач һәм бүгенге көндә әтисен исенә төшерә дә, ул аның яңадан-яңа затлы сыйфатларын үзе өчен ача кебек.

Рузия 1972 елда алтмышка җитеп килүче, хатыны белән аерылган, балалары инде башлы-күзле булып кайсы кая таралышкан иргә чыкты. Обкомның эчке хуҗалыгында гади бер тәэминатчы гына булса да, фронтовик һәм бераз аксап йөри торган инвалид буларак, аның абруе шактый зур иде. Бәшир Кәримовичның (ирнең исеме шулай иде) Хәйдәргә мөнәсәбәте начар дип әйтмәслек, әмма бигүк җылы да түгел иде.

Гәрчә әнисе үгетләсә дә, Хәйдәр аңа «әти» дип әйтә алмады, гел «Бәшир абый» дип кенә эндәште, аны «әти» дип атау үз әтисенә хыянәт булыр дип санады. Ә күп сөйләшми торган, сабыр холыклы, йомыкыйрак Бәшир Кәримовичның моңа һич кенә дә исе китмәде. Хәйдәрнең башлы булуы, яхшы укуы аны куандырды. Хулиган-мазар булып, үги әтисе белән конфликтка керү мисаллары да күп бит тормышта. Ә бу егет картайган көндә дә терәк булырга мөмкин дип уйлады Бәшир Кәримович. Һәм булдыра алганча, ата вазифаларын башкарырга тырышты, үзеннән шактый яшьрәк хатынга да, аның улына да итагатьле вә игътибарлы булды.

Шуңа күрә ир-хатын мөнәсәбәтләренең кайбер нечкәлекләрендә камиллек булмауга карамастан, белемле, зыялы бу кеше тәэсирендә өйдә иминлек хөкем сөрә иде.

Соңрак Бәшир Кәримовичның Хәйдәргә ярдәме шактый зур булды.

Самат 1975 елда Казан химия-технология институтына кереп, 1980 елда тәмамлады һәм аспирантурага укырга керүдә үги әтисенең һәм аның әшнәләренең ярдәме бик кирәк булып чыкты. Бөтен җирдә әшнә-кодалык, «блат» хөкем сөргән заманда Мәскәүдә урнашып, анда «Ведущий научно-исследовательский институт химической технологии» дип аталган данлыклы фәнни-эзләнүләр институтында хезмәт итә башлавы белән дә Бәшир абыйсына рәхмәтле ул.

Дөрес, Хәйдәр аңардан башка да үз көче белән зур уңышларга ирешкән булыр иде, әмма нинди уңышларга, нинди юнәлештә – әйтүе кыен. Вакытында Бәшир абый кебек терәге булганга, ул зур галим дәрәҗәсенә җитә алды.

Мәскәүгә киткәндә, Хәйдәр әбисен бик кызганды. Мәдинә дә нык хафаланды, кайнар күз яшьләре белән елады. Улының вафатыннан соң, бердәнбер юанычы шушы оныгы, хәзер инде ул да ерак тарафларга китеп бара иде.

Мәдинә, берүземә бик авыр, ямансу, иптәш кирәк дип, Дәрвишләр бистәсендә ялгыз яшәп яткан Галимә апасын Казанга, үзе янына килеп торырга күндерде.

**31**

Көнче ире Казаннан хат килгәнне әйткәч, Светлана Саматның исән икәненә шикләнми иде инде. Бәлки тагын хат килер дип өзелеп-зарыгып көтте ул. Инде үзенең, Казанга барып, Саматны эзләү теләге дә булгалады, әмма ерак юлга чыгарга һич җай чыкмады – эше дә авыр, әнисе дә гел чирләп тора иде. Шулай сагынып, сагышланып, шул ук вакытта өметләнеп, көннәр, айлар үтә торды. Җир йөзендә инде 1954 ел иде, Светланага утыз яшь тулды.

Әтисе белән абыйсы хакында аларга бер хәбәр дә килмәде. Мөгаен, исән түгелләрдер инде, аларның язмышын ачыкларга мөмкинлек тә юк иде.

Әнисе соңгы вакытта тагын каты авырый башлады, әмма район хастаханәсенә барудан баш тартты, анда да шул ук дарулар инде дип, өйдә генә кызы ясаган уколлардан канәгать булып ятты.

Ул:

– Озак булмам инде... Әтиеңне, абыеңны күрми китәрмен микәнни... – дип сыктанганда, Светлана түзми, әнисен кочаклап елый иде.

Светлана үзендә дә гаеп сизә – Фёдор кыйнагач, берничә тапкыр ул Березнякка кайтып елый-елый зарланды һәм әнисе кызының интегүен, ачынып елаганын күреп, урын өстенә ятарлык хәлгә килә иде, хәтта Фёдор янына барып, кызын яклап сөйләшерлек тә хәле булмый иде.

Беркөнне Пелагея кичкырын, бәрәңге ашаганнан соң, ятып торыйм әле, дип ятты да дөнья куйды.

Светлананың бердәнбер юанычы, куанычы, бәхете, яшәү мәгънәсе булып тугыз яшьлек улы Сабит кына калды. Ул шук-шаян, тиктормас малай булып үсте. «Нинди булып үсәр, кем булыр?» дигән сорау Светлананы гел борчып, тынгысызлап торды.

Березняк мәктәбенең спортзалында фронтовик-разведчик абзый бокс түгәрәге ачкач, Сабит шунда язылырга теләк белдерде һәм Светлана моңа каршы килмәде, урамда малайлар белән сугышканчы, тренер карамагында булсын, тәртипкә дә өйрәнер дип уйлады. Тренер Сабитны, тырыш, җитди, акыллы булганы өчен бик яратты, үз итте. Тренерның хатыны поликлиника ашханәсендә эшли һәм алар Светлана белән дуслар иде. Аның инде әллә ничә тапкыр Светланага:

– Әйдә, сиңа ир эзлик, – дигәне булды.

Ә Светлана гел:

– Аларны эзлисе юк, артымнан йөрүчеләр дә күп, – дип җавап бирә иде.

Чыннан да Светланага күз атучылар байтак булды, әмма аның күңеленә хуш килүче очрамады. Беренче урында улы иде, Сабит өчен яшәүне ул үзенең изге бурычы дип санады.

Сабит елгыр, гаярь малай булып үсте, бигрәк тә бокс белән шөгыльләнә башлагач. Ул вакытта әтисез калган малайлар күп, шуңа күрә сугыштан соңгы елларда ятимнәрне кагу юк, булган очракта да Сабит җавап бирә торган, үзе өчен нык торучы егет иде.

Тора-бара Светлананың аны бокска йөрүдән туктатасы килде, улының бу шөгыленә никтер җаны ятмады, ләкин Сабит үзе яратып тренировкаларга йөргәч, әйбер-кара әйтми килгән иде. Бер тапкыр рингта малайларның бер-берсен тукмауларын үз күзләре белән күргәч, ачыктан-ачык каршы килә башлады. Өлкә үзәгендәге ярышлардан кайткач, Сабит үзе дә, бәлки, арыганнандыр: «Кирәк микән бу миңа?..» – дип уйлап куйган иде.

Ә беркөнне тренер үзе дә аңа әйтте:

– Сабит, син мәктәптә «бишле»гә укыйсың, отличник. Мәктәпне тәмамлагач, сиңа югары белем алырга кирәк булачак. Синнән шәп боксёр чыгар иде, әмма сиңа мондый спортны ташларга кирәк дип саныйм. Синең башың йодрык өчен яралмаган, син укымышлы кеше булырга тиеш. Спортның башка төрләре, башыңа сукмый торганнары да җитәрлек.

Моны тренер Светлананың үтенече белән әйтмәде кебек, әмма шулай да әни кешенең мондый спортка күңеле ятмаганны аңлагандыр, ахрысы.

Светлана улын ачуланганда да, мактаганда да, гел әтисе Саматны телгә алып: «Әтиең менә болай итәр иде, әтиең андый түгел иде, әтиеңчә түгел бу...» – дип тәрбияләде. Самат белән өч тәүлек кенә бергә яшәгән булсалар да, Светлана улы үскәндә, аның әтисен тәрбияләүдә «катнаштырырга» тырыша иде.

Сабит мәктәптә яхшы укыды, бик башлы егет булып чыкты. Шул елларда ук инде ул, әтисен эзләп, Казанга бару хыялы белән йөргән иде. Әнисенең сөйләве буенча, аның әтисе – үрнәк алырлык, һәрьяктан камил кеше, ә кечкенәрәк чакта әтисе Сабитның күз алдына бөтенләй әкият герое кебек килеп баса иде. Әтисе аңа бик кирәк иде, беркайчан күргәне булмаса да, ул аны сагынып үсте. Кайвакыт аңа әтисен кайчандыр, кайдадыр күргәне бар сыман да тоела иде.

Урта белем алганнан соң, Сабит Харьков политехник институтының электротехника факультетына, имтиханнарын «бишле»гә биреп, укырга керде. Әнисе шатланды да, шул ук вакытта берүзе калганга кайгырды да.

Имтиханнардан соң, бер атнага әнисе янына кайтып, кичке факультетка күчәргә теләвен һәм эшкә урнашачагын әйткәч, Светлана тагын да ныграк хафаланды:

– Эшләп укый алырсыңмы соң, балакаем?

– Кешеләр эшләп укыйлар бит, мин дә ерып чыгармын, – дип җавап бирде Сабит.

Борчылса да, Светлана ышанды – улы акыллы, максатчан егет, әйткән сүзендә торачак, чынлап та барлык кыенлыкларны ерып чыгачак.

Сабит та әнисенең ышанычын аклады – укыды, аракы эчмәде, тәмәке тартмады, кичке бүлеккә күчеп, вагон төзү заводында башта гади эшче булып, аннары бригадир вазифасында эшләде, ә инде соңгы курсларда укыганда цех нәчәлнигенең энергетика буенча урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелде.

## 32

1969 елда, институтны тәмамлаганнан соң, эштә отпуск алып, Сабит Казанга юл тотты. Әтинең адресын Татарстанның хәрби комиссариатында белешермен, сугыш ветераны, инвалид, орден-медальләр белән кайткан кешене белми калмаслар дигән өмет белән барды.

Татарстанның башкаласы Казанның «Совет» кунакханәсендә ул урнашкан дүрт кешелек бүлмәдә утыз-утыз биш яшьләр тирәсендәге өч ир-егет кәртле уйнап утыралар иде. Шимбә көненең кичкырын вакыты булганга, иртәгә хәрби комиссариатта ял көне икәнне исәпкә алып, ул Казан буйлап йөреп керергә дип чыгып китте.

Июль аеның җанны-тәнне иркәли торган җиңел һавалы бер көне иде.

Данлыклы Казан университетын сорагач, Ленин урамында, биш минут кына җәяү барасың, диделәр аңа.

Ул, университет каршындагы эскәмиягә утырып, үткән-сүткән кешеләрне, университетка керә-чыга йөргән яшьләрне нindiдер бер рәхәтлек белән күзәтеп утырды. Урамнары бигүк чиста күренмәсә дә, Казан

аңа, килү белән үк, ямьле кала булып тоелды. Кешеләр украинлылардан монда нык аерылып торалар, Көнчыгыш шушында башланадыр инде, азиатларга тартым чалымлы кешеләр күп. Кызык, Сабит үзе дә кыяфәте белән Казан егетенә охшаган. Шулай булмый ни, әтисе Казан татары бит аның!

Булачак очрашу нык дулкынландыра, каушата, әмма бу халәттә рәхәтлек тә бар, тормышта зур вакыйга булырга тиеш, күптәнге хыял – үзенең һәм әнисенең хыялы – гамәлгә ашарга тора иде.

Салмак кына адымнар белән килүче нечкә билле, зифа буйлы кызны ул әллә каян ук абайлады. Чәчәкле күлмәк кигән, чәчен җыеп, артка аскан кыз әкрен генә, моңсу кыяфәттә, тып-тын күлдәге аккоштай, ак туфлиләре белән җиргә басып түгел, йөзеп бара шикелле иде. Эскәмия турына җиткәч, Сабит эндәшми булдыра алмады:

– Гүзәлкәй, әйтегез әле, чынлап та Ленин шушы университетта укыганмы?

Аның шаярып сораганын кыз аңлады һәм, бу егет бәйләнергә тели дип, үзе дә саклык йөзеннән кырысрак шаярып җавап бирде:

– Юк, ул монда лаборант булып эшләгән.

– Бигрәк дорфа икән Казан кызлары, – диде Сабит, шелтәләгән булып кыланып.

– Казан егетләре дә бигүк итагатьле түгел икән, күреп торалар минем татар кызы икәнне, ә үзләре никтер русча эндәшәләр, – диде кыз адымнарын тагын да әкренәйтебрәк. – Бигрәк хәтәрләр инде.

Сабит, торып, кызга иярде:

– Мин бит Казан егете түгел.

– Мин дә Казан кызы түгел, – диде кыз, Сабитка карамыйча гына.

– Кайдан соң сез?

– Уфадан.

– Димәк, сез татар кызы түгел, башкорт...

– Син үзең башкорт, – диде кыз, каушаудан «син»гә күчеп. – Мин татар кызы. Башкортстанда татарлар башкортларга караганда да күбрәк, беләсең килсә. Син үзең бөтенләй казакъка охшагансың, – диде кыз, Сабитка туры караш ташлап.

– Әгәр дә мондый чибәр кыз теләсә, мин шайтан булырга да риза, – диде Сабит, көлемсерәп. – Мин казакъка охшаганмын, чөнки минем әтием – чын татар.

– Чын татар булгач, ник татарча сөйләшмисең, кыланып урысча сиптерәсең?

– Мин Украинада туып-үстем.

– Әтиең чын татар булгач, нишләп соң ул сине татарча сөйләшергә өйрәтмәде?

– Минем, кызганычка каршы, әтиемне беркайчан да күргәнем юк.

Сабитның бу сүзләре боек тавыш белән чыкты. Шуңа күрә кыз, саклык белән генә:

– Сугышта һәлак булдымы әллә? – дип сорады.

– Юк, исән ул. Аны күрергә дип килдем дә инде мин Казанга. Ә мин сине әллә каян абайладым. Синең атлап йөрешеңдә аңлатып булмый торган

грация бар. Хәтта тәнгә ниндидер җылы дулкын килеп бәрелгәндәй булды. Уфа... Бигрәк матур сүз... Уфа. – Сабитның бу сүзне җылы итеп әйтүеннән чыннан да «Уфа» сүзенең аңа ошавы аңлашылып тора иде. – Исемең бармы синең? – дип шаярып сорады ул.

Бу сорау кызның күңеленә хуш килде һәм:

– Бар, нишләп булмасын, – дип елмайды ул. – Башкортстанда кызларга исем кушмыйлар дип уйладыңмы әллә? Минем исемем Зөлфия.

– Зөлфия... – дип елмайды егет. – Матур исем. Уфа... Зөлфия... Матур сүзләр. Мин Сабит атлы. Ә минем исемем матурмы? – дип көлеп куйды ул.

– Сәпит дигән сүзгә охшаган, – диде Зөлфия, көлемсерәп. – Бездә малайлар велосипедны «сәпит» диләр.

– Килгән көнне үк монда мине үрти башладылар, – диде Сабит, көлеп. – Казанда укыйсыңмы?

– Минем апам монда укый. Шуның янына килгән идем. Бер көн бергә булдык та, мине ташлап, егете белән чыгып китте. Мин аны сагынып килдем, ә ул мине ташлап, егете белән кайдадыр йөри, – дип, Зөлфия ачусыз гына апасын шелтәләп алды. – Ә мин үзебезнең Уфа каласында укыйм, быел өченче курсны тәмамладым.

– Сер булмаса, кайда укыйсың?

– «Октябрьнең 40 еллыгы» исемендәге Башкорт университетында, биология факультетында.

– О-о-о, менә кем белән сөйләшәм икән бит мин.

– Әйе, авызыңны чамалап ач.

– Шунысы гаҗәп – ничек син шушы хәтле зур шәһәрдә берүзең курыкмыйча йөрисең?

– Нәрсәдән куркырга тиеш соң мин?

– Нәрсәдән түгел, кемнән. Бу якларда кыз урлау бар дип ишеткән идем. Имеш, кызны егет урлый да, шуннан соң тиз генә никах укытып, ир белән хатын булып яши башлыйлар икән.

– Монда кыз урлау юк инде хәзер. Элек кенә булган ул.

– Ә мин сине урлар идем. Капчыкка тыгар идем дә Украинага алып кайтып китәр идем.

Зөлфия көлеп җибәрде:

– Тыным бетсә?

– Ә мин, һава керсен өчен, капчыкта тишек ясар идем. Син нинди капчыкта ятуыңны теләр идең – цементтан бушаган капчыктамы, әллә арыш капчыгындамы?

Зөлфия дә егетнең шаяру дулкынында чайкала иде инде һәм:

– Арыш капчыгы романтикалырак булыр иде, – дип җавап бирде.

Алар шулай көлешә-көлешә сөйләшеп, көннең кичкә авышкан вакытында Бауман урамына төшеп киттеләр. Бернинди максатсыз аяклар үзләреннән-үзләре шул тарафка атладылар. Сөйләшеп бару икесенә дә күңелле, бу – танышуның рәхәт тантанасы иде, чөнки мондый мизгелләрдә кеше дөньяның көтелмәгән якты якларын күрә башлый.

Бигүк озын булмаган кара чәчен матур итеп җыеп, «койрык» ясаган түгәрәк йөзле, кыйгач кашлы, нечкә билле, зифа буйлы бу кыз Сабитның күңеленә бик хуш килде. Кечкенә борыны астындагы кып-кызыл күперчек

иреннәре үзләренә шулкадәр нык тартып тора, дәшә, чакыра кебек иде. Елмайганда, шәрыкча бераз кысыграк күзләре бөтенләй йомылып бетә, ә инде яңагында көлгәндә барлыкка килә торган чокырчыкларының матурлыгын сүз белән генә аңлату мөмкин түгел иде.

Яшь кызның гүзәллеген сүз белән генә тасвирлап булмый. Рәссам да, нинди генә сәләтле булмасын, чын нәфислелекне җиткерә алмый, композитор да көй язып кына, чибәр кызның илаһи чалымнарын тәгаен аңлата алмый. Чибәр кызның күз карашын сөйләп тә, җырлап та кемгәдер җиткерү мөмкин түгел, аның күзләрен үзең күреп, үзеңә генә хас хисләр кичерәсең. Сүзләр, буяулар, ноталар – аз, гүзәл кызның гүзәллеген сөйләргә алар гына җитми.

Сабит кыскача гына үзе турында сөйләде. Бауман урамына җиткәч, алар уңга да, сулга да түгел, туп-туры атладылар, әйтерсең лә шул бер юнәлештә бергәләп атларга сүз куешкан булганнар.

– Димәк, әтиеңне бер тапкыр да күргәнең юк? – диде Зөлфия.

– Юк шул, – диде Сабит, көрсенеп. – Очрашкач, мин күзаллаганча булыр микән ул? – дип өстәде ул, уйга калып.

– Бер фотосы да юкмыни үзегездә?

– Юк шул. Бергә фотога төшәргә аларның мөмкинлекләре булмаган. Әмма әни бәләкәй чагымнан ук миңа аның нинди икәнен гел тәфсилләп сөйли иде, шуңа күрә, аңымда аның сурәте күптәннән бар инде.

– Сине үзенең улы дип таныр микән соң? – дип куйды Зөлфия шөбһәле тавыш белән.

Сабитның исә шиге юк иде.

– Таныр, – диде ул. – Мин бит аның улы. – Сабит Зөлфиягә туры карап, үтә җитди кыяфәт белән: – Минем моңарчы беркайчан да болай нык дулкынланганым юк иде, – дип куйды.

Уң як Болак буенда туктагач, Сабит үзенең ничек дөньяга килүен, ягъни 1944 елда Самат исемле солдат белән Светлана исемле кызның мәхәббәтен бәян итте.

Зөлфиягә ул вакыйга шундый нык тәэсир итте ки, хәтта аның күзләреннән яшьләр агып чыкты. Кызның бәянне болай кабул итүенә Сабит гаҗәпләнмәде, чөнки Зөлфиянең нечкә күңелле кыз икәне болай да кыяфәтеннән үк күренеп тора иде. Зөлфия Болак суына карап, егерме биш ел элек булган вакыйганы күз алдына китереп, уйга калды.

Сабитның тизрәк башка нәрсәләр турында сөйләшәсе килде:

– Син Уфага кайчан кайтып китәсең? – диде ул, кызны моңсу уйларыннан арындырып.

Зөлфия, һушына килеп:

– Иртәгә, – диде. – Озаграк булырмын дигәнием... Апага ачуым килде. Сеңлесен читкә этәреп, егете белән йөри... Үзенең диплом яклыйсы бар... Миңа акыл өйрәткән була әле ул...

Караңгы төшкәнче, Казан үзәгендәге урамнарда йөргәннән соң, Сабит Зөлфияне апасы яши торган тулай торакка озатып куйды.

– Поездның сәгать ничәдә? – дип сорады Сабит саубуллашыр алдыннан.

– Кич белән... Төгәл белмим... Билетны вокзал кассасында алам... Кичке җиделәр тирәсендә бугай...

– Апаң озатадыр?

– Әйе.

– Мин көндез хәрби комиссариатка барып, әтинең адресын белергә тырышачакмын. Сине озатырга вокзалга килсәм ярыймы?

Кыз белән егет һәр икесе тагын очрашырга телиләр, әйтергә генә кыймыйлар иде.

Зөлфия кинәт, көтмәгәндә:

– Әйдә хәрби комиссариатка бергә барыйк әле, – диде. – Аннары, әтиеңнең адресы буенча бергә барырбыз, мин тышта көтеп торырмын.

Сабит үз колакларына ышанмый торганнан соң, гаҗәпләнеп:

– Чын әйтәсеңме? – диде.

– Уфага әтиеңне таптыңмы, юкмы икәнеңне белеп кайтасым килә. Киноларда, китапларда гына була торган хәл бит бу. Күпме романтика монда, күпме драма!

– Бергә барсак, әлбәттә, бик әйбәт булыр иде. Дөресен әйтәм, әти белән булачак очрашу мине нык каушата. Миңа бу эштә иптәш бик кирәк. Бигрәк тә... мондый иптәш, – дип елмайды Сабит.

Кунакханәгә Сабит илһамлы халәттә кайтып китте. «Юлым уңды минем, иртәгә дә, алга таба да көннәр уң булыр, – дип уйлады ул. – Казанга килү белән үк, Зөлфия исемле татар кызы белән таныштым... Бу бик әйбәт фал лабаса!»

**33**

Икенче көнне, сүз куешканча, Куйбышев мәйданында очрашып, алар икәүләшеп, Татарстанның хәрби комиссариатына юл тоттылар.

«1924 елда туган сугыш ветераны Гарипов Самат Габделхәй улы Ершов урамының 14 нче йортында, 31 нче фатирда яши», – дигән мәгълүмат белән алар хәрби комиссариаттан кош тоткандай чыктылар һәм, пилмән кафесына кереп, төшке ашны капкалаганнан соң, шул адрес белән киттеләр.

Йортның ишегалдында шәһәр хәятеннән аерым бер тормыш кайный иде. Малайлар кылычлы уйныйлар, агач күләгәсендә, чүгәләп, ике агай, хатыннарыннан качыптыр инде, як-якларына карана-карана, сыра эчәләр. Тәрәзәдән бер хатын ачы тавыш белән улына, дәшеп, өйгә керергә куша. Кечкенә кызлар туплы уйныйлар. Бер яшь хатынның имчәк баласы елый, хатын «Ә-ә-ә» дип, әрле-бирле йөри-йөри, аны тынычландырырга тырыша. Бер подъездга ике ир-егет тимер караваt кертеп маташалар.

Утыз беренче фатирның икенче подъездда икәнен белгәч, Сабит тирән сулыш алды да шаярырга тырышып, Зөлфиягә:

– Татарча-башкортча белгән догаларыңны укый тор, – дип, ишекләре шар ачык подъезд эченә кереп китте.

Ә Зөлфия комда уйнаучы балалар янына барып, аларның дөньяны онытып, мәш килүләрен күзәтеп утырды.

Сабит ишек кыңгыравының төймәсенә басып алды һәм, колак салып, фатир эченнән тавыш ишетелүен яки ишекнең ачылуын көтте. Тагын басарга туры килде. Өченче тапкыр кыңгырау чылтырагач, ишек әкрен генә теләр-теләмәс сыман ачылды.

Ишекне татар карчыкларына хас пөхтә кыяфәтле олы яшьтәге апа

ачты. Апаның ак яулыгы, яшькелт күлмәге, кулындагы дисбесе һәм бераз җыерчыклы матур йөзе Сабитның каушавын киметте. Аңа, никтер, ишекне этисе ачар сыман иде.

– Исәнмесез, апа!

Кичә Зөлфия аңа татарлар өлкән яшьтәгеләргә ничек эндәшүләрен аңлаткан иде – ир кешегә – «абый» дип, хатын-кызга – «апа» дип. Сабитның исәнләшүе русча килеп чыкты, ә «апа»ны татарча әйтте.

– Исәнмесез, – диде Галимә, шушы бер сүздән үк үзенең русча бигүк әйбәт сөйләшмәгәнен күрсәтеп.

– Гарипов Самат Габделхәй улы монда яшиме?

– Монда яшәде, – диде Галимә. – Ә син кем буласың?

– Мин аның фронтташ дустының улы. Самат абый белән әтием бер полкта, бер взводта хезмәт иткәннәр, – дип, дөресен әйтергә ашыкмады Сабит.

– Үлде ул.

– Кайчан? – диде Самат, йөрәгенең дерт итеп куюын тоеп.

– Узган елны җирләдек.

Көчле рухлы Сабит, моны ишеткәч, кинәт коелып иңәр дәрәҗәгә җитте. Бәгырьне тимерчыбык белән сыдырып үттеләрмени – җан сыкравы аның йөзенә чыкты.

– Мин... – дип нидер әйтмәкче булды ул, әмма ни әйтергә дә белми торды. – Сез Самат абыйның әнисеме?

– Юк, мин аның әнисенең апасы.

– Минем исемем Сабит.

– Мин Галимә апаң булам. Кер, әйдә, уз, – диде Галимә еректан килгән бу егетнең ихластан сөмсере коелганны күреп.

Фатир уртасындагы түгәрәк өстәл янына кара-каршы утыргач, беравык сүз башлый алмый тордылар. Сабит тыйнак кына җиһазланган, тәрәзә төбендәге күпсанлы гөлләрдән җылы нур сирпелгән фатир эченә күз йөгертте. Галимә кан тамырлары беленеп торган ябык куллары белән өстәл япмасын тигезләп куйды.

Ул:

– Мин хәзер чәй куям, – дип, кухняга юнәлмәкче иде, Сабит аңа:

– Рәхмәт, апа, кирәкми. Чәйләр эчеп тормыйм, – диде. – Мине анда, ишегалдында көтеп торалар. Үзем генә түгел мин. Бераз сөйләшик тә... Әнисе эштәме?

– Мәдинә Кырымга дәваланырга китте. Йөрәк белән интегә, аңа эштән санаторийга путёвка бирделәр.

– Кайчан кайта?

– Тиз генә кайтмас әле ул, өченче көн генә киткәние.

Сабитның әле һаман: «Бәлки, әтисе исәндер, бәлки, үлмәгәндер, бәлки, башка Самат вафат булгандыр, ә аның әтисе исәндер», – дигән өмете бар иде.

– Гафу итегез, аның кушаматы «Чукмар» идеме? – дип сорады ул.

Галимә моңсу гына елмаеп куйды:

– Яшь чагында аның андый кушаматы бар иде. Фронтта да шул кушамат белән йөргәнме әллә?

– Әйе, әти дә белә аның кушаматын. Шул Самат микән дип соравым.

Икеләнеп куйдым да... Хәзер инде шик калмады. «Чукмар» булгач, димәк, шул Самат булып чыга.

Сабит үзенең чынында кем икәнен әйтергә бик теләде, әмма кире уйлады, тыелып калды. Ә Галимә Сабитның кыяфәтен җентекләп күзәтте һәм аның башына бу Украина егете турында төрле уйлар килде. Саматның балачагын, үсмер вакытын, егет чагын аермачык хәтерли бит ул. Бу егет аңа нәкъ Саматның яшь чагын хәтерләтте, ләкин Галимә үзенең сорауларын бирергә кыенсынды.

– Нишлисең бит... – дип авыр сулап куйды ул. – Язмыш... Югыйсә типсә тимер өзәрлек егет иде. Каһәр суккан сугыш... Менә синең кебек чибәр, нык егет иде ул. Үзеңнең әтиең исәнме соң?

– Әти... Әйе... Шофёр булып эшли, – дип алдады Сабит һәм үзенең дөресен әйтмәвенә шундук эче поша башлады.

– Гаиләгез зурмы?

– Зур түгел. Әти, әни, мин...

– Украиннармы сез?

– Юк, руслар.

– Үзең рус егетенә охшамагансың... – диде Галимә, Сабитны җентекләп күзәтеп.

– Әйе шул. Бөтенесе шулай диләр, – диде Сабит, читкә карап. – Әтинең Самат абый белән элемтәгә керәсе килгән иде... Хат та язышмадылар алар... Соңгы вакытта әти Саматның адресын белергә иде дигәч, мин монда махсус килдем. Миңа берәр фотосын бирә алмыйсызмы? Әтидә аның бер фоторәсеме дә юк.

Галимә шкаф тартмасыннан чүпрәккә төрелгән фоторәсемнәрне алып килде һәм арадан кайберләрен сайлап алып, өстәлгә куйды.

– Сугыштан соң төшкәненме, солдат чагынмы? – диде Галимә, фотоларны аралап.

– Солдат чагын, – диде Сабит ике дә уйламыйча һәм берничә фоторәсем арасыннан артына «Гарипов Самат. 1944 ел» дип язылганын алды.

Сабит фотосурәткә карап, тын калды – Әтисен беренче тапкыр күрә бит ул. Нәкъ әнисе сөйләгәнчә – ул аны бала чагыннан ук нәкъ менә шушындый итеп күз алдына китерә иде. Гаҗәп! Мәһабәт гәүдәле, көләч йөзле, карап торуга беркайчан әҗәл кагылмаслык батыр солдат! Бәлки әнисе белән очрашканчы төшкәндер, бәлки соңыннандыр. Ничек кенә булмасын, һичшиксез, бу – Березнякка килгән вакыт тирәсендәге фотосурәт иде.

– Син, улым, Украинаның кайсы тарафыннан?

– Чыгышым белән Николаев өлкәсеннән. Хәзерге вакытта Харьковта яшим, вагоннар төзү заводында эшлим... Әни Верхнегорскида яши.

Галимә аның: «Әни Верхнегорскида яши», дигәненә игътибар итте. Күңелендә нишләп «әти белән әни...» дип әйтмәде икән, дигән уй туды..

– Әниең кем булып эшли? – дип кызыксынды ул.

– Әнием – медсестра. Поликлиникада эшли.

– Ничә бала сез?

– Берәү генә. Мин генә.

– Үзеңнең гаиләң юкмы әле?

– Юк.

Галимә тагын:

– Туктале, шулай да, чәй куйыйм әле мин, – дип кузгалмакчы иде, әмма Сабит:

– Юк, юк, апа, мин чәйләр эчеп тормыйм, – диде. – Мине бер кыз көтеп тора... Яхшы түгел... Рәхмәт.

– Украина дигәннән... Сугыштан соң, берничә ел үткәч, Самат Украинадан бер хат алган иде, – диде Галимә, моңаеп. – Миңа килеп, кайгысы белән уртаклашты. Хатта аңа Света исемле кыз вафат булды дип язганнар, шул хәбәрдән Самат шашар дәрәҗәгә җитеп кайгырган иде.

Галимә кунактан бу хакта берәр сүз ишетермен дип уйлаган иде, әмма Сабит:

– Димәк, Украинада Света исемле кызы булган, – дип кенә куйды.

Ул тагын үзенең кем икәнен чак кына әйтми калды.

– Хатыны тарих укытучысы иде, – дип дәвам итте Галимә. – Аерылыштылар алар. Самат сугыштан яраланып кайтты, гел чирләде, бик озак дәваланды. Ярасы төзәлерлек булмады шул – үпкәсеннән каһәр суккан пуляны чыгара алмадылар. Югыйсә, карьерасы да әйбәт бара иде. Бик акыллы егет иде бит ул, яшьрәк чагында шигырьләр яза иде. Хатыны түземсезрәк кеше иде шул. Хәер, ике баласын югалткан хатынны гаепләве дә әллә ничек... Хәйдәр исемле уллары бар, аңа хәзер унбер яшь.

Сабитның шундук, кичектермичә, энесен күрәсе килә башлады. Әмма бу хакта бер сүз дә әйтергә кыймады. Галимә дә бу егетнең кем икәненә төшенде, әмма төпченү кирәк түгел икәнне аңлады.

Сабит инде үзе өчен шундук карар кылды – ул монда тиздән тагын киләчәк! Әбисен, энесен күрәчәк. Хәзер инде ул белә – Казанда аның якын кешеләре бар – әбисе Мәдинә һәм энесе Хәйдәр.

Галимәгә рәхмәт әйтеп саубуллашты да Сабит чыгып китте. Артыннан ишек ябылгач, ниндидер яктылыкны тимер капка каплагандай булды. Йорттан чыккач, ул беравык башын аска иеп торды да әкрен генә китеп барды. Балаларның уенына кушылып утырган Зөлфия еракта ук Сабитның боек икәнен абайлады. Ул аны куып җитте һәм:

– Ничек, күрештегезме? – диде, Сабитның кайгылы кыяфәтеннән пошаманга калып.

Егетнең күзләре дымлы, йөзе тартылыбрак киткән иде.

– Әти былтыр вафат булган, – диде ул басынкы тавыш белән, тамак төбендә төер тоеп.

Галимә белән булган әңгәмәне кыскача сөйләгәч, Зөлфия:

– Үзеңнең кем икәнеңне әйтергә идең, – дип куйды.

– Ә мин тиздән монда тагын киләчәкмен, – диде Сабит, кинәт җанланып. – Шунда сөйләрмен. Әбиемне, энемне күрәчәкмен. Әтинең кабере кайда икәнне сорамадым... Хәзер вакытым тар. Икенче тапкыр килгәч, иркенләп, зиярәт кылырмын.

Ул, Зөлфиягә карап, моңсу гына елмайды:

– Ярый син очрадың әле. Син булмасаң, миңа хәзер берүземә бик авыр булыр иде.

Зөлфия аңа күзләрен тутырып карады.

– Гаҗәп, егет кешенең йөзенә сагыш та килешә икән, – диде ул үзалдына әйткән сыман.

Алар, бер-берсенә карап, шактый вакыт дәшми тордылар. Сабит, кесәсеннән әтисенең фотосурәтен алып, Зөлфиягә күрсәтте, аннары озак кына үзе дә карап торды.

– Син шулкадәр әтиеңә охшагансың! – диде Зөлфия.

«Әтиемне күрә алмаганга, бәлки, Казанда Зөлфия белән танышырга насыйп булгандыр...» – дип уйлап куйды Сабит.

– Иртәгә поезд белән Мәскәүгә китәм, – диде ул. – Мәскәүдән Николаевка авиарейслар булмаса, Харьковка очармын. Аннан Верхнегорскига әни янына кайтып киләм.

– Юлың хәерле булсын, – диде Зөлфия чак кына ишетелерлек итеп.

Әтисен исән чакта күрә алмый калуыннан Сабитның йөрәге әрнеде. Өстәвенә, аның бу гүзәл кыз белән дә аерылышасы бар иде.

– Син бүген кайтып китәсеңме Уфага? – диде ул.

– Юк.

– Иртәгә?

– Иртәгә дә түгел. Берсекөнгә. – Зөлфия егетнең күзләренә карады. – Минем сине озатып каласым килә. – Ул кинәт матур итеп елмайды. – Йә мин Уфага кайтып киткәч, монда калырсың да, берәр Казан кызын табарсың, ә мине онытырсың.

– Сине онытырлыкмы соң! – диде Сабит назлы тавыш белән.

– Әй, бу Казан каласында әллә нинди чибәр, тәти, курчак кебек кызлар бар.

– Елмайганда, синең яңактагы чокырчыклар башка берсендә дә юктыр.

Зөлфия, якты елмаеп:

– Монсы белән килешәм, – диде. – Булса да, бик сирәктер.

– Син үзең Уфага кайтырсың да мине башыңнан чыгарып атарсың әле.

– Алдан әйтә алмыйм. Ничек булыр бит. Минем башымда урын күп әле, бәлки, чыгарып атмам.

– Димәк, мине озатасың?

– Әйе. Сиңа кул болгап калам да икенче көнне кичен поезд белән Уфага – тү-тү. Мине апам озатып калыр.

***

Тимер юл вокзалы меңләгән, миллионлаган кешеләрне бер-берсеннән аера һәм бер-берсе белән очраштыра торган урын. Монда кайвакыт күз яшьләре ага, ә кайвакыт шатлыктан йөрәк атылып чыгардай була.

Сабит белән Зөлфия бер-берсенең адресларын язып алдылар һәм хат язышырга вәгъдәләштеләр.

Алар озакламый тагын очрашасыларына ышаналар һәм, шул ук вакытта, бер-берсен югалтудан куркалар иде. Алар бер-берсенә гашыйк булдылар, әмма бу турыда әлегә бер сүз дә әйтмәделәр.

Поезд кузгала башлагач кына Сабит кызны кочагына алды һәм иреннәреннән татлы итеп үпте. Зөлфия һушына килгәндә, Сабит инде вагон тәрәзәсеннән кул болгый иде.

**34**

Фёдорның кайчандыр Казанга оятсыз, кабахәт рәвештә ялганлап, хат язганын белгәч, инде аннан соң күп еллар узган булса да, Светлана җанның моңарчы булмаган тирән сыкравын тойды. Әле моңарчы аның беркайчан да болай каты рәнҗегәне, бу кадәр нәфрәтләнгәне юк иде, Саматның улы алып кайткан фоторәсемен карап утырганда да, ул еламады. Бу минутларда язмышларның болай килеп чыгуына әрнү хәтта күз яшьләренең агар юлын буып куйган сыман иде. Чарасызлык халәтендә каты рәнҗесәң, елап булмый, күз яшьләре өчен бу хәлне берәр ничек үзгәртергә мөмкиндер дигән аз гына булса да, өмет кирәк.

Светлана улының ничек Казанга барып кайтуы турында, андагы тормыш, татар кешеләре хакында сөйләгәнен фотоны тоткан килеш дикъкать белән тыңлап утырды.

Ул инде хәзер күп нәрсәне белә: Самат каты яраланган, госпитальләрдә яткан, Березнякка хатлар язган булган. Әгәр Фёдор – ерткыч, җанбасар, садист – хатны кулына эләктермәгән булса, алар Самат белән хәбәрләшерләр, кавышырлар һәм, бәлки, тормыш юлыннан бергә атлап киткән булырлар иде. Бергә булгач, ул, бәлки, кырык дүрт яшендә вафат булмас иде, Светлана аны үлем кулына бирмәс өчен әллә ниләр кылыр иде, бар көчен куяр иде, саклар иде, дәвалар иде.

– Татар кызлары бик чибәр икән, – диде Сабит, Татарстан башкаласы турында озын-озак итеп сөйләгәннән соң. – Казан, Уфа кызлары бигрәк тә... – дип өстәп куйды аннары.

– Синең Уфада булганың юк ла, – диде Светлана.

– Анда да татарлар күп бит, шуңа әйтәм...

– Матур кызлар күп инде алар. – Светлана моңсуланып, улына карады. – Сиңа, улым, өйләнү турында уйлый башларга кирәк, – дип, соңгы вакытта еш әйтә торган сүзләрен кабатлады ул.

– Уйларга түгел, өйләнергә кирәк, – диде Сабит көр тавыш белән. – Фатир алгач, өйләнермен, әни. Аннары, Николаевка күчкәч, сине үземнең яныма алып китәрмен.

– Юк, юк, мин бу тирәдән ерак китә алмыйм, – диде Светлана. – Мин анда туган Березнягымны сагынып үләчәкмен. Монда мин, Березняк янәшә икәнне тоеп, тыныч кына яшим. Ә икенче яктан караганда... Әлбәттә, бергә яшәсәк, әйбәт булыр иде. – Ул кулын селтәп куйды. – Әй, сиңа нинди хатын эләгә бит әле... Мин, каенана буларак, сезне күзәтеп торырга, контрольдә тотарга тиеш булачакмын бит. Ә каенананың күзәтеп торуын киленнәр яратмый...

Соңгы сүзләрне Светлана, әлбәттә, шаярып әйтте.

– Әни, татар кызына өйләнсәм, син каршы булмассыңмы? – дип сорады Сабит, көтмәгәндә.

– Ничек инде мин каршы булыйм, – диде Светлана, ягымлы елмаеп. – Син үзең дә татарчонок бит. Әмма бу тирәдә татар кызлары юк.

– Уфада, Казанда күп алар... – дип куйды Сабит.

Светлана тагын Саматның фотосурәтенә карап, үз уйларына чумды.

***

Сабит белән Зөлфия хат алыша башладылар. Хатлар аша аралар көннән-көн якыная барды, хәзер инде алар яшәешнең бер дулкынында тирбәләләр иде.

Танышканнарына ун ай узгач, Сабит Уфага юл тотты. Ике көн алар бергә булдылар һәм үзара мөнәсәбәтләре инде әллә ничә ел элек танышкан кешеләрнеке кебек якын иде.

Зөлфиянең әтисе аграр институтның механизаторлар бүлегендә укыта, әнисе Уфа партия горкомының пропаганда бүлегендә лекторлар белән идарәче булып эшли иде. Бик җитди, зыялы кешеләр буларак, Зөлфия Сабит турында сөйләгәч, аларның эчләре поша башлады, мөнәсәбәтләре тирәнгә кереп, кызлары чит җирләргә олага күрмәсен дип борчылдылар. Шуңа күрә Зөлфия Сабитны әти-әнисе белән таныштырырга әле әзер түгел иде.

Аның каравы, алар ике көн бергә булдылар. Зөлфия ул көннәрне, ике лекция калдырганнан әллә ни булмас дип, укырга бармады. Уфа каласы Сабитка ошады, әмма Казан каласы аңа барыбер якынрак, ямьлерәк тоелды.

Икенче тапкыр Сабит Уфага көзнең октябрь аенда килде. Бу юлысы Зөлфия аны үзләренә алып барды һәм әти-әнисе белән таныштырды.

Яшьләрнең бәхетенә күрә, алар Сабитны ошаттылар: егет укымышлы, үз яше өчен хәйран зур вазифада эшли, әдәпле, тыйнак, төсе-бите, буй-гәүдәсе дә әйбәт... Әлбәттә, алар бердәнбер кызларын үз даирәләрендәге берәр абруйлы гаилә егетенә бирү теләге белән йөргәннәр иде, әмма Зөлфиянең гел Сабитка гына карап торуын күреп, әлегә әйбер-кара әйтмәделәр.

Кунакханәгә илтеп куярга тиешле таксины көтеп торганда, Зөлфия, чиксез куанып:

– Әти дә, әни дә сине ошаттылар, – диде.

– Менә бит, бу фронтта мин беренче җиңүгә ирештем, – дип елмайды Сабит.

Икенче көнне Сабит, бер көнгә генә булса да дип, самолёт белән Уфадан Казанга очты.

## 35

Мәдинә шифаханәгә дәваланырга дип барды, ә аның, киресенчә, ялдан кайтканда, хәле авырайган иде. «Гипертония» дигән куркыныч сүз яңгырашы белән үк яман. Кайткан көннәрнең берсендә аңа инфаркт булды. Шул сәбәпле, Галимә аңа Сабит турында сөйләргә җай тапмады һәм әлегә кирәк түгел дип уйлады.

Кайгыны күп күргән, бик күп югалтулар кичергән, тормышның бөтен ачысын татыган Мәдинә күзгә күренеп кырысланды, йомыкыйланды, соңгы вакытта Галимә апасына карата да дорфаланды, гомумән, беркемне сөймәскә әйләнде. Оныгы Хәйдәрне генә аның ешрак күрәсе килә иде. Ә Рузия элек тә кырыс һәм каенанасын яратмый иде, хәзер инде, карт ир белән яшәп, бөтенләй усалланды, шуңа күрә аның Хәйдәрне әбисе янына бик йөртәсе килми иде.

Күп тә үтмәде, Мәдинә вафат булды.

Рузия улы белән пропискада Мәдинәләрдә тора иде, шуңа күрә, фатир Рузияләргә калды, ә Галимә, сеңлесе вафатыннан соң, тиз генә әйберләрен җыеп, Дәрвишләр бистәсендәге үз йортына кайтып китте.

Галимә бер ялгышлык эшләде – унбер яшьлек Хәйдәргә: «Украинада абыең бар, ул монда килеп китте», – дип әйтеп ташлаган иде. Соңыннан ул бик үкенде, Хәйдәргә хәзер үк түгел, тагын бераз үсә төшкәч әйтергә кирәк булган дип үзен битәрләде.

Эш шунда ки, Хәйдәргә бу хәбәр бик кызык һәм мавыктыргыч булып тоелды һәм шул ук көнне, балаларча куанып, моны әнисенә җиткерде. Малайның сүзенә Рузиянең башта ышанасы килмәгән иде, шулай да ял көннәрнең берсендә ул, Дәрвишләр бистәсенә барып, Галимәдән сораштырды, басымлы итеп төпченде.

Ә Галимә яшереп тормады, барысын да, ничек бар, шулай сөйләп бирде.

Рузиянең ачудан хәтта чырае агарып китте:

– Димәк, шул марҗасын сагынып яшәгән инде ул. Бәлки, шуңа тормышыбызның рәте булмагандыр...

– Нишләп алай булсын! Син үлгән ireңә дә кыҗрап утырма инде! – диде Галимә, кызып. – Ярасы төзәлмичә ничек бимазаланганын күрдең бит. Саулыгы булса, әллә нинди үрләргә менеп, әллә кем булыр иде, балакаем. Кырык дүрт яшьтә китеп барды бит, кырык дүрт яшьтә!

Галимә еларга тотынды, ә Рузия, сукрана-сукрана, тиз генә чыгып китте.

**36**

Сабит, Зөлфиянең әти-әниләре белән танышканнан соң, хәйран күтәренке кәефтә, Уфа – Казан юнәлешендә зәңгәр күкне ерып очкан самолётта татлы хыялларга чумып утырды.

Ул аэропорттан такси белән туп-туры таныш адрес буенча килгән вакытта Рузия белән Бәшир фатирда ремонт ясап яталар иде.

Ишекне Рузия ачты. Сабитның борынына буяу, акшар, ацетон, клей исләреннән торган дулкын бәреп керде, аннары каршысында пычранып беткән яулыклы, буялып каткан халатлы хатын пәйда булды. Хатынның битендә төрле таплар, хәтта керфекләренә дә акшар кунган иде. Аның артында өстенә майка белән трико, башына гәҗиттән ясалган башлык кигән олы яшьтәге ир кеше күренде.

Каршыларында кара плащ, күн фуражка, иңенә җыйнак кына юл сумкасы аскан мәһабәт гәүдәле егетне күреп, башта алар бу кеше фатир номерын бутагандыр, дип уйлаганнар иде.

– Исәнмесез, – диде Сабит.

– Исәнмесез, – диде Рузия, үзенең алама кыяфәте өчен аз гына да читенсенмичә.

– Минем исемем Сабит. Минем әтием белән Самат абый сугышта бергә булганнар, бер взводта...

– Самат вафат булды, – диде Рузия коры гына. – Ике ел элек җирләдек. Хәзер инде фронтташ дуслары аңа атап, дога гына кыла алалар.

– Миңа аның әнисе Мәдинә апаны күрергә иде, – диде Сабит, Рузиягә түгел, аның артында басып торган Бәширгә мөрәҗәгать итеп.

Әмма ире урынына янә Рузия җавап бирде:

– Фронтташлары дога кылганда, берочтан, Мәдинә карчык өчен дә дога кылсыннар. Аны быел җирләдек. Өч инфаркт булды. – Аннары ул салкын тавыш белән өстәп куйды. – Бер кешегә өч инфаркт бигрәк күп шул.

Сабит бу пырдымсыз хатынга үзенең Самат улы икәнне әйтмәскә булды. Әмма үткен күзле Рузия аның кем икәнен чамалады. Аны Сабитның төсе-бите белән Саматны хәтерләтүе һәм хәтта исемнәренең охшашлыгы гаҗәпләндереп тә куйды.

– Аның улы бар икән... – диде Сабит, инде әңгәмәнең дәвамы уңышлы булмаячагын чамалап.

– Бар, – диде Рузия, күзләрен чекерәйтеп.

– Хәйдәр исемле бугай...

– Әйе, Хәйдәр атлы.

– Аны күрергә мөмкинме? – дип сорарга җөрьәт итте Сабит.

– Ник? – диде Рузия усал тавыш белән. – Нигә?

Сабит түземлеген җуеп, тавышын күтәрде:

– Сез нишләп миңа болай ачулы?

– Фатирда ремонт ясаучы шат күңелле булмый инде ул, бигайбә, – диде Рузия, авызын кыйшайтып. – Хәйдәр укый торган класс мәктәптән Ленинградка экскурсиягә китте. Гафу итегез, безнең монда эшләр тыгыз.

– Ярый, сау булыгыз, – диде Сабит, китәргә ашыкмыйча һәм тагын нидер сорамакчы булып.

Әмма ул бүтән бер сорау да бирә алмый калды – ишек шапылдап ябылды. Самат, ишек янә ачылмасмы дигән өмет белән беркавым урыныннан кузгалмый торды һәм сүренке халәттә әкрен генә баскычтан төшеп китте.

Рузия артсыз урындыкка бөтенләй үк пычранып бетмәгән гәҗитне җәеп утырды да кинәт елап җибәрде.

– Ник елыйсың? – диде аңа Бәшир.

– Нишләп болай бәхетсез мин? – дип илаулады хатыны.

Бәшир ремонт эшләреннән йончыган иде, хәзер аның өстенә Рузиянең улавы бәгырен тырнады.

– Бәхетле чакта син бәхетле булырга лаеклы. Бәхетсез чакта син бәхетсез булырга лаеклы, – диде ул кырыс тавыш белән. – Елап утырудан мәгънә юк. Бу дөньяга тугансың икән, димәк, син бу дөньяда яшәргә лаеклы.

Рузия иренең фәлсәфәләреннән тәмам гарык булган иде инде, әмма бу юлысы иренең сүзләренә илтифатсыз калды.

– Беләсеңме, бу егет кем? – диде ул, кул арты белән күз яшьләрен сыпырып.

– Кем?

– Саматның улы.

– Аның тагын улы бармыни? – диде Бәшир, гаҗәпләнеп.

– Бар. Украинада туган.

Бәшир беравык уйланып торганнан соң:

– Ник шулкадәр дорфа сөйләштең соң аның белән? – диде.

Рузия кинәт кызып китте:

– Дорфа! Әдәп! Синең зыялы булуыңның тормышта фәтвасы бармы соң?! – диде ул һәм тагын еларга тотынды. – Минем үземә җиңел булды дип уйлыйсыңмы әллә аның белән сөйләшү?.. Мин курыктым... Саматның улы булгач... Алай-болай Казанда төпләнергә теләге булса, монда пропискага кертүне сорар дип, котсыз калдым.

– Котсыз калырлыкмы соң инде! – диде Бәшир ачулы тавыш белән. –

Моңарчы яшәгән минем өч бүлмәле фатир бар. Хәзер бу фатир өстәлде. Тагын күпме фатир кирәк соң сиңа? Беренчедән, Казанда калырга телиме ул, юкмы, әле билгеле түгел. Икенчедән, теләсә дә, юк, кертмибез дип әйтеп була бит. Өченчедән... Бу чиксез дөнья синең өчен генә яралган дип ялгышасың син, Рузия. Күктәге Кояшны, Айны, йолдызларны сиңа гына якты булсын дип элеп куймаганнар. Җирдәге табигать тә сиңа гына рәхәт булсын өчен яралмаган.

Рузия сикереп торды да:

– Ай-яй акыллы да инде үзең! – дип җикерде. Әмма Бәширнең усал күз карашыннан шүрләп, башка сүз әйтмәде.

– Җитте! – диде Бәшир тыныч, ләкин тыгыз тавыш белән. – Түшәмне акшарлыйсы бар.

Рузиянең каршы әйтәсе килде, талашырга да эчке талпынуы бар иде шикелле, әмма базмады – соңгы вакытта ире кырысланды һәм хатын көенә биемәячәген көннән-көн белгертә килә иде. Ә Рузия абруйлы һәм карт булса да, хәйран гайрәтле Бәширне югалтудан курка иде.

Ул шактый вакыт тып-тын утырды.

– Мин элек мондый түгел идем, – диде ул, бер ноктага карап. – Язмышымны кемдер каргагандыр, күрәсең. Чынлап та, кайвакыт юк кына нәрсәләр өчен дә борчылам шикелле... Илле беренче елда, беренче балам төшкәннән соң ук минем асылынасым килгән иде... Курыктым. Өч яшьлек кызымны утыз градуслы салкында күмгәннән соң да асылынмадым, йөрәк җитмәде...

Бәшир, шомраеп, хатыны янына килде:

– Ни сөйлисең син?!

– Элек мондый түгел идем мин... – дип кабатлады Рузия.

– Тынычлан. Менә ремонтны тәмамларбыз да берәр җиргә ялга барып кайтырбыз.

– Ялга барсаң да, кая китсәң дә, башың үзең белән йөри бит. Вакыт дәвалый, диләр. Дәвалыйдыр, әмма савыктырмый ул. Дәвалый-дәвалый, Вакыт безне теге дөньяга озата.

– Теге дөнья турында сүз катарга сиңа түгел, миңа да иртә әле, – диде Бәшир.

– Минем ике балама иртә түгел идеме? Саматка иртә түгел идеме? – Беркавым дәшми торганнан соң, Рузия, көтмәгәндә: – Бәшир Кәримович, мин бит Саматны сагына башладым, – дип куйды.

Бәширнең кинәт ачуы кабарды, ләкин ул үзен кулга алды һәм тыныч булырга тырышып:

– Син саташа башладың, – диде.

– Синең минеке кадәр югалтулар кичергәнең юк, – диде Рузия сыкраулы тавыш белән.

– Бу дөньяда күпме югалту кичергәнен кеше үзе генә белә, – диде Бәшир һәм, зирәк акыллы кеше буларак, хатынын бу халәттән ничек булса да чыгарырга тырышты. – Ярар... Ни... Рузия, тавышымны күтәргәнем өчен гафу ит.

– Синең гафу үтенүең ниемә хаҗәт соң? – диде Рузия салкын тавыш белән.

– Алай димә. Ял ит. Түшәмне үзем акшарлыйм.

Рузия ямьсез итеп елмайды һәм авызын чак кына кыйшайтып, чәнчүле тавыш белән:

– Акшарла, Бәшир абый, акшарла, – диде. – Агарт түшәмне.

Бәшир аңа аптырап карап торды, әмма дәшмәде.

**37**

1971 елда Зөлфия университетны тәмамлады. Югары белем алучыларга мәҗбүри билгеләнә торган «распределение»дән аны әти-әнисе коткарды, ә кайда эшләячәге турында әле уйламый тордылар, чөнки тиздән Сабит белән Зөлфия никахлашырга тиешләр иде.

Яшьләр башта Казанга барып, Галимә апа белән бергәләп, Сабитның әтисенең каберен зиярәт кылдылар.

Туйга җитәрәк, завод профкомы Сабитка бер бүлмәле «служебный» фатир бирде. Кечкенә бер кафеда оештырылган туйга Сабитның әнисе Светлана Петровна, якын дуслары, хезмәттәшләре, Уфадан Зөлфиянең әти-әнисе һәм туган-тумачалары җыелган иде. Профком монда да ярдәм күрсәтте – туй кунакларына заводның кунакханә сыман җыйнак бинасында торырга рөхсәт итте.

Зөлфиянең туганнары бик шөбһәләнеп килгәннәр иде – имеш, кияү безнең дәрәҗәгә лаек микән соң, үзебезгә тиң микән?.. Алар бит Зөлфия Уфа каласының гомумтуклану системасында карьера ясар дип өметләнделәр – башта берәр ресторан директоры, аннары республиканың азык-төлек министрлыгында эшләр дип күз алдына китерәләр, булачак кияү дә югарырак даирәләрдән булыр дип күзаллаганнар иде.

Әмма килү белән үк бернинди шик-шөбһәләргә урын калмады – кызлары бәхетле – Зөлфия затлы егеткә чыга, сизелеп тора, әнисе дә киленне яратачак һәм мөлаем йөзле, җылы күңелле Светлана Петровнаның үзен дә яратырлык иде. Алар шул арада Сабитның заводта абруйлы егет икәнен дә аңладылар. Зөлфиягә дә эш урынын кайгыртып куйган, әлегә торыр урыннары бар, озакламый Сабитның үзенә аерым фатир бирәчәкләр икән. Иң мөһиме – Зөлфиянең бәхетле икәне әллә каян күренеп тора иде.

Шул ук елның азагында Харьковның приборлар төзү предприятиесендә эшне автоматлаштыра башладылар. Сабитның курсташ дусты, фикердәше шул предприятиедә комсомол оешмасының җитәкчесе булып эшли иде. Ул беркөнне Сабитка шалтыратып:

– Сабит туган, монда хәзер тагын да зуррак эшләр кайнаячак, монда бик кызык булачак! Күч безгә эшкә, – дигән тәкъдим ясады. – Мин инде предприятиенең бер заводында сиңа урын барлап куйдым – көнкүреш продукциясе чыгару идарәсенең товар җитештерү цехында нәчәлник урынбасары булачаксың. Цех нәчәлниге – минем дустым – бик әйбәт кеше.

Сабит тәвәккәлләде.

Ялгышмаганнар Зөлфиянең туганнары.

Сабитны яңа эшендә дә яраттылар, үз иттеләр, ул тиз арада абруй казанды һәм, күп тә үтмәде, ул инде цех нәчәлниге вазифасында эшли башлады, фатирны да озакка сузмыйча бирделәр. Акыллы, максатчан, яңалыклардан курыкмый торган кеше буларак, Сабит бу урында шактый

вакыт хезмәт итте һәм предприятиенең «Электроприбор» заводында директор вазифасына иреште. Аннары, бөтен предприятиенең генераль директоры урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелде һәм лаеклы ялга чыкканчы шул урында эшләде.

Башта бит ул әнисенә якынрак булыр өчен Николаев каласына күчәм дип йөргән иде, ләкин алай килеп чыкмады, тик моңа һич кенә дә үкенмәде – беренчедән, Харьковта карьера яхшы гына үргә китте, икенчедән, Верхнегорскига әнисе янына еш кайтып йөрергә аның мөмкинлеге һәрвакыт бар иде.

Зөлфия сөт комбинатына вакытлыча мастер-технолог булып урнашты һәм декрет ялына кадәр шунда эшләде.

***

1972 елда беренче малайлары туды, ике елдан тагын берне алып кайттылар. Беренчесенә – Сабир, икенчесенә Салих дип исем куштылар.

Көннәр, айлар, еллар үтә торды. Тормыш дәвам итте. Еллар агышында, мизгелләр балкышында Гариповлар нәселе аерым тармак булып сузылды.

Җаны-тәне белән эшкә чумган Сабит беркайчан да энесе бар икәнне онытмады, бер атадан туган Хәйдәр исемле бертуганының кайдадыр бу дөньяда барлыгын белеп, тоеп яшәде.

Гәрчә беркайчан исән чагын күргәне булмаса да, Сабит үзенең улларына әтисе турында сөйләргә ярата иде. Алар әбиләре Светланадан Самат бабайның нинди әйбәт егет, әтиләреннән исә Гарипов Самат Габделхәй улының нинди батыр солдат булганын тыңлап үстеләр.

**38**

Әйе, Гарипов Самат 1968 елда вафат булды.

Әмма китмәде.

Андый кешенең җаны Җирдән ерак очып китмидер. Ярата белгән, мәхәббәткә ия булган кешенең җаны, фани дөньядан бакыйлыкка күчкәч тә, җылылыкка мәңге туймаган кешелек дөньясын ташламыйдыр.

Малинина Светлананың йөрәге сиксән биш яшендә туктады. Саматны ул соңгы көннәренә кадәр барыбер көтте. Гомере буе, хәтта вафат булганын белгәч тә көтте. Һәм, ниһаять, үзе сөйгән кешесе янына китеп барды.

Гомеренең соңгы көннәрендә Светлана Петровна бер үк сүзләрне кабатлады:

– Мин кирәгеннән артык озак яшәдем инде... Без бит аның белән бер елда туганбыз... Самат янына барыр вакыт җитте... Ул көтә мине...

Гомереңнең һәр мизгеле, һәр авазы, төсе, тәме, кешеләрнең күз карашы, сөйгәнеңнең кайнар сулышы – бөтенесе синең үзеңә сеңеп каладыр. Син барысын да хәтерләмәскә мөмкин, әмма алар синдә сакланадыр һәм аларның иң кирәклеләре генә хатирәләр булып калкадыр.

Өч тәүлектәге сәгатьләрне, һәр сәгатьтәге бихисап мизгелләрне хәтер күпсенмәде, аларны гомер буе гел барлап торды.

Светлана көн саен Ходайдан улының, оныкларының исәнлеген, аларга кайгы килмәвен, бәхетле булуларын сорады. Ә үзе өчен бер генә нәрсәне – «тегендә» Самат белән очрашуны үтенде.

Гомеренең соңгы көннәрендә инде начар күрә торган күзләре белән саргаеп беткән фотосурәткә текәлеп карап торганнан соң, Светлана тәрәзәдән, тиздән үз кочагына алачак яңа хәятнең чагылышларын күрергә өметләнеп, шәһәр артындагы офыкка карый иде.

Бу – ерак гасырлар тирәнлегеннән килгән ялварулы, кешеләр дөньясыннан игелек өмет иткән һәм мәрхәмәткә гомер бакый сусап, беркайчан да шул сусыны басылмаячак хатын-кызның үз язмышына күнгән күз карашы иде.

***

Алар очрашып бергә яшәсәләр, бәхетле булырлар иде. Хәер, алар бәхетле булдылар түгелме?..

Нәрсә ул гомер? Мәңгелектәге мизгел генә ләбаса.

Нәрсә ул өч тәүлек? Гомернең мизгеле генә инде.

Әмма нинди мизгелләр бит...

Гомерлеккә сузылган өч тәүлекнең бәхетле мизгелләрендә ике кешенең яшәү мәгънәсе табылган. Өч тәүлектәге мизгелләрнең могҗизалы җимеше булып, Сабит дөньяга туган, аннары аның уллары дөньяга килгән.

Җитмеш ел элек ике яшь йөрәк бергә типкән мизгелләр Сабитның, оныкларның йөрәк тибеше булып дәвам итә.

**39**

Декабрь азагында дәвалану курслары тәмамланды һәм докторлар Хәйдәргә:

–供дә хәзер яман чир юк. Лейкемия китте, – диделәр. – Сез – сәламәт кеше. Әмма гел тикшерелеп торырга кирәк.

Германиягә җәйге киемнән генә килгән Хәйдәргә кышкы киемнәр алырга Катерина ярдәм итте.

Кайтып китәргә ике көн кала, Хәйдәр белән хушлашырга Берлиннан Винфрид Мейер килде.

– Белүемчә, сез Казанга Мәскәү аша кайтасыз? – диде ул.

– Әйе, Мәскәү аша, – диде Хәйдәр. – Дюссельдорфтан Казанга туры рейслар юк.

– Сезне каршы алучы буламы?

– Әлбәттә. Кызым белән киявем.

Профессор, серле елмаеп:

– Сезне аэропортта тагын бер кеше көтәчәк, – диде. – Аның кулында сезнең исемегез язылган плакат булыр. Ул минем дустым, аның сезгә кирәге чыгар.

Шулай итеп, Германиядә Хәйдәрнең гомерен саклап калдылар. Әтисе Самат белән Винфриднең әтисе Ортвин да бер-берсен сугышта үлемнән коткарганнар дип әйтергә була... Димәк, тикмәгә түгел...

Хәйдәрнең чирдән, бүгенге халәтеннән, хәзерге тормышыннан, гомумән, бу заманнан ваз кичеп, әтиләре яшәгән чорга, алар кайнаган хәятнең вакыйгаларына кагыласы килә башлады, зур мәгънәле яшәешкә, могҗизалы рәвештә, үзенең дә катнашы булуын теләде. Ул әтиләренең язмышына кызыга, хәтта көнләшә дә башлады кебек, аның хәзер әтиләренең яшәешенә,

аларның «дөньясына» мөнәсәбәтле булырга, алардан «аерылмаска» ихтыяҗы бар иде.

Кемдер кайбер мизгелләр эчендә кылган гамәлләрне башка берәү гомер буена да булдыра алмаска мөмкин бит.

Хәйдәрнең әтисе ниндидер бөек эш башкармаган. Әмма аның бөек мәхәббәте булган. Мәңгелек өчен кайсысы кыйммәтрәк соң – галимнәрнең цивилизациягә керткән өлешләреме, яисә кешеләр арасындагы мәхәббәтме?

«Җирдәге чын тормыш, гади кешеләр арасындагы бәйләнешләр, үзара мөнәсәбәтләр мин гомеремне багышлаган фәнгә караганда күпкә кызыграк. Әтиләребезнең гомере тулырак, баерак, кызыграк, мәгънәлерәк булган», дип уйлый башлады Хәйдәр.

Әйе, зур галим булуга ирешә ул, әмма әтисенә язган кебек олы мәхәббәт очрамады. Әтисе шикелле герой булмады, миллионлаган кеше сокланып тыңлардай җырга шигырь язмады.

Ярый әле нәселләре дәвам итә – хәзер инде бу хакта борчыласы юк. Хәйдәрнең абыйсы бар! Аның белән очрашмыйча бу дөньядан китү дөрес булмаячак! Аның улларын күрмичә үләргә ярамый, яман чиргә бирешергә, аңа буйсынырга хакым юк. Мин аны хәзер җиңдем, мин аны бүтән үземә кертмим!

Серле, күзкүрмәс җепләр дөнья буйлап, кешеләрдән кешеләргә сузылган. Ике дошманны сугыш очраштырган, алар һәр икесе исән калган, алай гына да түгел, берсе язган шигырьгә икенчесенең оныгы көй язган. Дәһшәтле елларның бер көнендә кыз белән егет арасында мәхәббәт кабынган һәм беркем, бернәрсә, берничек өзә алмаслык җеп киләчәккә яңа буыннар аша сузылган.

Хәйдәр, телефонын алып, әтисенең шигыренә язылган җырны кабызды. Серле вә тылсымлы җыр үзенең аһәңе белән җанны иркәләде һәм, шуның белән беррәттән, кайчандыр балкыган кайбер мизгелләрне, дисбе төймәләрен тезгәндәй, бер җепкә җыйнады кебек.

**40**

Җир белән Күк арасында очкан самолётта Алла рәхмәте һәм Германия табиблары ярдәме белән үлем тырнагыннан котылган илле алты яшьлек татар кешесе утыра.

Җир белән Күк арасында матур җыр яңгырый.

Һәр кеше Җир белән Күк арасында яши.

Кешелек дөньясы Җир белән күк арасында кайный.

Мәхәббәткә дә, нәфрәткә дә, яшәүгә дә, үлемгә дә, чиргә дә, дәвага да урын җитәрлек монда.

Җир белән Күк арасында иң мөһим вә кыйммәт нәрсәләр мизгелләр эчендә хәл ителергә мөмкин.

Хәйдәр белән янәшә Мәскәү аша Красноярск каласына кайтучы егерме яшьләр тирәсендәге чибәр бер кыз утыра иде. Хәйдәр, наушникларын салып, кызга бирде һәм җырны тыңларга тәкъдим итте.

– Матур җыр, – диде кыз, җырны тыңлаганнан соң, колакчыннарны Хәйдәргә кире биреп.

– Бу җырның шигырен җитмеш ел элек минем әтием язган, – диде Хәйдәр

горур тавыш белән. – Татарча язган. Аны алман теленә соңыннан тәрҗемә иткәннәр. Шигырьне ул синең кебек гүзәл бер кызга багышлап язган булган.

– Әтиегез шагыйрь булганмыни? – диде кыз.

Хәйдәр беравык уйлап торганнан соң:

– Кеше булган ул, – диде.

Аның кинәт барысы да ишетерлек итеп: «Бу җырның шигырен минем әти Самат Гарипов язган!» – дип кычкырасы килде. Самолёт люгын берәр ничек ачарга иде, сикерер өчен түгел, бөтен дөньяга аваз салыр өчен, Җир йөзендәге барлык кешеләр ишетсен өчен! Аннары өстәп: «Мин исән! Без исән!» – дип кычкырыр өчен.

Ширәмәт аэропортында Хәйдәрне кызы белән кияве каршы алдылар.

Күрешеп, кочаклашып, бер-берсенә гадәти җылы сүзләр әйткәннән соң, Хәйдәр:

– Мине монда тагын бер кеше каршы алырга тиеш иде, – диде һәм, як-ягына каранып, үзенең исеме язылган плакатлы кешене эзли башлады. – Профессор Мейернең дусты мине көтәргә тиеш.

Озак эзләргә туры килмәде, җиңел тун кигән олы яшьтәге, әмма егетләрчә нык гәүдәле агайның кулындагы катыргыда Хәйдәр үзенең исемен күреп алды һәм аның янына килеп:

– Исәнмесез. Мин – Гарипов Хәйдәр, – диде.

– Әтиегезнең исеме ничек? – дип елмайды плакат тоткан кеше.

– Самат. Хәйдәр Саматович мин. Винфрид әфәнде әйткәние...

– Ә мин Сабит Саматович булам. Исәнме, энекәш!

– Исәнме, абый!


***

Вакыт барысын да үзе белән алып китә дисәләр, ышанмагыз.

Саматның ике улы олы яшькә җиткәч очраштылар.

Әтиләре Самат та бу минутларда алар белән иде. Үткән заманның, ничек кенә еракта калмасын, хәзерге заманда чагылышлары яши һәм ата-бабалар яшәгән чорны да без бүгенге көн буенча тоемлыйбыз, үзебез яшәгән еллар аша аңлыйбыз.

Кайвакыт яшәеш һәр мизгелдә яңадан башланган сыман, шушы сәгать тирәсендә элекке заманның мизгелләре һичтуктаусыз әйләнәдер кебек тоела.



Рашат
Низами

# КҮТӘРЕЛДЕК БЕЗ ДӘ ТҮБӘННӘН

## Вакыт хәтере

Җәйләрнең бар үз төсе: ямь-яшел!
Дәшә үзенә болын, урманнар.
Билгесез солдатын барлагандай,
Кыймылдашып куя курганнар...
Көзләрнең бар үз төсе: сап-сары!
Алтынсу яфраклар – офыкта.
Хәбәрсез югалган солдатның
Язмышында – һаман күп нокта...
Кышларның бар үз төсе: ап-ак кар!
Ак чалмага дөнья уралган.
Ветеранның тәрәзәсен шакып,
Кичен бик еш дулый бураннар...
Язларның бар үз төсе: зәп-зәңгәр!
Яшь чәчкәләр җирдән калкына.
Бөек җиңү барабаннар кага –
Сугышларсыз яшәү хакына...

## Моңсулык

Авылым колхоз авылы иде...
Ул елларның күбесе онытылган,
Хатирәләр ләкин йөрәктә.
Хәтер төпкеленнән күтәрелеп,
Бик еш дөрли алар күкрәктә.
Сентябрьнең сабый уҗымнары
Кырпак кырау белән капланган.
Килер язга барыбер ышаналар,
Ерак калса калды ал таңнар.

Рашат НИЗАМИ (1950) – *шагыйрь, прозаик; Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Кызыл җәй», «Яшьлеккә хат», «Яшәүгә гимн» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Һәр авылның чибәрләре була,
Эшчән хатыннары, әлбәттә.
Коммунизм килеп җитәр, диеп
Яшәделәр авыр хезмәттә.
Офыкларда – әткәмнең сурәте,
Ындыр табагын ул саклады...
Әнкәй исә көн дә ташып торды
Гәҗит-журнал, солдат хатлары...
Күп нәрсәләр вәгъдә ителсә дә,
Бик күбесе чынга ашмады.
Калды җимерек ферма торaклары,
Калды тезелеп кабер ташлары.
Мишәбезнең салкын суларында
Нинди эзләр тора чагылып?
Өмет кечерәйгән. Хак Җәнабтан
Мәрхәмәтләр көтә авылым.
Авыл эшсез, тешсез. Елгыр яшьләр
Зур шәһәргә китеп күченгән.
...Яктырадыр сихри бер нурланыш
Мәңге караңгы төн эченнән.

## Һәйкәл кирәк!

Баемады империя кояшы,
Түрендә бит тагын иблис оясы.
Тотынды ул «китекләр»ен ямарга...
Туган телгә тели балта чабарга!
Көрәш бара... Кирәк безгә көрәштә
Аягүрә баскан килеш калырга.
Бик борынгы мәркәзебез Казанда
Туган телгә кирәк һәйкәл салырга!

## Җырланмаган җырым

***(композитор Рөстәм Яхин монологы)***

Син кайларда, җырланмаган җырым,
Исән-саумы көмеш кылларың?
Өндә түгел, хыялымда сине
Әллә ничә кабат уйнадым.
Тыны белән күкләр михрабыннан
Тартып ала моңлы виртуоз...
Чүпле урамнарның ташын ярып,
Газап белән яңа җыр туа!
Тасма телләр вәгъдә базарында
Уйнаш иткән авыш заманда, –
Күз яшьләре түгеп, муза белән
Яраларны вакыт ямарга.
Киләчәккә илтеп ялгыйсы бар
Тукайлардан калган гамьнәрне.
Ярты юлда туктап калган җырым,
Дәвам итик моңлы сәфәрне.
Үз-үзенә һәйкәл салыр өчен

Ташны ярып чыга үләннәр.
Җырдан һәйкәл салу өчен диеп,
Күтәрелдек без дә түбәннән.
Ядрә очкан, туп шартлаган өннәр
Булмасын дип татар илендә,
Каен шавын, киек казлар моңын
Көйләдем мин муза телендә.
Ишеткәнең бармы, замандашым,
Җырның ничек сулыш алганын.
И-и, яхшы соң, халык бәгыренә
Җырың китә алса ялганып!..
Йөрәгемдә тагын утлар ягам,
Җырланмаган җырым, син кайда?
Сәгать суга! Кичеккәнем өчен
Мин ярлыкау сорыйм Ходайдан...

## Гомер агышлары

Алтын балачакның
Ал көннәрен
Баллы чагын татып, –
Малай чагым үтте...
Болытлардан
Җиргә төшәр вакыт.
Егет чагым килде –
Киң дөньяга
Карыймын шаккатып!
Йорт-җир салыр чаклар,
Малай туар,
Агач үсәр вакыт.
Картлык килеп җитте –
Ишегемне
Шыпырт кына шакып.
Дин юлына басып
Гомер юлын
Барлап чыгар вакыт...

## Диңгездә

Исерек дулкын кыйный корабльне,
Бу дулкыннар
Кәбестә күк ничә катлыдыр?
Каршы искән диңгез җилләренең
Тозларына хәтле татлыдыр.
Мәңгелекнең кыл уртасын кисеп,
Фарватердан бара кораблар...
Диңгезченең ныклы ышанычы –
Фәкать алга таба карап бар.
Үзебезнең татар бугазын да,
Тын океан киңлекләрен дә, –
Кичә алар, штурвалны кысып,
Аягүрә баскан хәлендә.

## Рәхмәтле борчылу

Рәхмәт инде СССРга,
Бушлай бирде белемне.
Тиеннәрне түкми генә
Укып йөрдек күңелле!
Вузларга да бушлай кердек,
Ришвәт-фәлән төртмичә.
Белем алдык, һөнәр алдык,
Һөнәрләр – әллә ничә...
Рәхмәт инде СССРга,
Алды ул кочагына, –
Табибларга керә идек
Чират тормыйча гына.
Карусыз дәваладылар,
Бушлай иде дарулар.
Хәзер энә – бәя «тешли»!
Әҗәл инде
Аптекага барулар.
Рәхмәт инде СССРга –
Бушлай бирде фатирын.
Юкса каян зур акчалар
Табар иде фәкыйрең?
Хәтта азык «талон»нарын
(Берзаманны)
Кулга бушлай бирделәр.
Забастовка дип йөргәнче –
Чират торсын, диделәр.
Без яшәдек. Гомер иттек.
Хәзер дөнья тубыктан.
Кая бакма – акча кирәк,
(ришвәт кирәк,) –
Ничек яшәр оныклар?..

## Бүре белән куян

***(мәсәл)***

Бүре агай баласына
Азык эзләп чапканда,
Ак-караны аермыйча,
«Һоп!» – эләкте капкынга!
Еландай бәргәләнде ул,
Ятып-аунап карады...
Ничекләр ямыйсы булыр
Аяктагы яраны?
Яра – бер хәл, бу тозактан
Ничек соң ычкынырга?
Ярдәм сорап улый-улый
Тотынды кычкырырга...
Әнә-әнә, куян килә
Яшел алан буйлатып;
Колакларын, кылый күзен,
Тәти койрык уйнатып.
Әмма бу озынколактан
Көтмә икән ярдәмне, –
Бүрегә әйтер сүзен ул
Турыдан гына бәрде:
«Әһә-ә, бүркәч, эләктеңме!
Ә мине күр – баш аек.
Аякларың, көчең белән
Йөргән идең масаеп.
Менә хәзер, үч кайтарып,
Каныңа тоз сибәрмен.
Кирәк булса, кушаяклап
Чыраеңа тибәрмен!»
Бу хурлыклы мәсхәрәгә
Бүреме соң түзәчәк?..
Котылсамы – куянны ул
Чәйнәп кенә өзәчәк!
Бүре өзеп ычкындырды
Тозактагы аягын.
Куян абайламый калды
Кая качып таярын...



Асия
Юнысова

# МӘК ЧӘЧӘГЕ

БӘЯН

Кафе ишегеннән озын гына буйлы ханым килеп керде. Ак пәлтәдән, ак итекләрдән. Блондинка икән үзе. Чәчләрен биек итеп баш түбәсенә өеп куйган. Шунлыктан тагын да буйчанрак булып күренә. Чып-чын ханым бу. Кафе эчендәгеләрне карашы белән йөгертеп кенә күзәтеп чыгуында да сизелә бу ханымлык. Үзенә аулаграк урын караштырды. Бар иде андый урын. Тик өстәл буш түгел икән. Ул караган почмакка җайлы гына кереп урнашкан кеше мин идем. Мин дә – хатын-кыз. Мин дә ялгыз. Ике ялгызга бу аулак урында күңелсез булмас микән соң?

Ханым тәвәккәлләде. Аңа иптәш, үзен тыңлардай кеше тансык иде.

– Мин сезгә комачауламам микән?

– Һич юк. Үзем генә бит. Хәтта ки сезнең минем янга утыруыгыз бик әйбәт тә әле ул. Ялгызлыктан өйдә дә йөдим мин. Хәер, ялгыз ук түгел инде анысы. – Шулай дип, үземнең һәртөрле әңгәмәгә әзер икәнлегемне сиздереп куйдым. Бу сүзләр ышыгындагы ишарәне дә аңлап алырга була торгандыр. Димәк, үз касәм дә буш ук түгел.

Ханым, официант кызны дәшеп алып, йолдызлы коньяк, һәртөрле ризыклар китерүен үтенде. Шактый ук туңган да иде бугай. Урамда октябрь хуҗа иде шул. Көннең күзе иртә йомыла торган мәл. Адәм баласы кышка керер алдыннан табигатьнең кырыслана төшүенә елның-елында күнегә алмый аптырый. Һич кенә дә әзер түгел булып чыга.

– Туңдым. Эчемә суык төште. Күңелем дә тулган көн иде. Сәбәпләре бар инде аның. Җылына төшкәч, бәлки әле, сөйләрмен дә. Туңдырма сатып алдым да салкын урындыкка утырып, шуны ашый башладым. Тирә-якта бәйрәм тантанасы. Шәһәр көнен бәйрәм итәргә быел соңлаганнар! Шарт-

Асия ЮНЫСОВА (1947) – *язучы, журналист; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан журналистларының Х.Ямашев исемендәге премиясе, С.Сөләйманова һәм Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Алкалы чәчәкләр», «Асылташ», «Саваплы сабак» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

шарт фейерверклар шартлый, куанып кычкырышалар, көлешәләр... Ә мин елап утырам. Минем кыяфәтемә күз яшьләре килешә торганмы инде, йә! Эчем тулышканга елыйм ла мин. Ә кешеләр аны беләме? Янымнан ике ир-ат узып китте. Минем күз яшьләренә чыланып утыруым көлке күренде боларга: «Апасы бәйрәмне иртә башлаган. Бу сары чәчле марҗага күбрәк киткән, ахрысы». Боларның тозсыз сүзләренә күңел буам тәмам ерылып китте: «Эчмәдем мин! Марҗа да түгел әле мин! Минем елавымда сезнең ни эшегез бар? Бәлки, минем иң бәхетсез көнемдер», – дип, артларыннан кычкырып калдым да тагын да үкеребрәк еларга тотындым. Тегеләр шактый гына ара китеп өлгергәннәр иде инде. Минем ачыргаланып елавым боларны кире борып китерде:

– Матур апа, еламагыз әле. Әйдә, өеңә илтеп куябыз, машина якында гына безнең, – диделәр.

«Ярар», – дидем дә, болар әйләнеп килгәнче менә бу кафега кереп киттем. Әллә нинди кеше булулары бар.

– Шулай-шулай, – дип, мин аның сүзләрен җөпләп куйдым. – Дөньяның кеме генә юк. Елаганың хәзер бик үк сизелми.

– Керешли туалетта төзәтенеп алдым. Чаллыдан мин. Автобуска утырдым да киттем. Минем тулган күңелемне аңлар өчен үзебезнең шәһәр бәләкәй. Кая барып төртелсәң дә, таныш күзләргә юлыгасың. Ә минем бушанасым, онытыласым килә. Менә сез дә, үзегез дә сизмәстән, минем тозакка килеп каптыгыз.

Әйе бит әле, мин – өстәл хуҗасы – бүген иң шәп тыңлаучы булырга тиешмен. Медицинада «подруготерапия» дигән термин да бар. Бер кичлек ахирәт дус. Кызык, ахирәт дус бит ул ахирәттә дә мәңге дус булырга килешү вәгъдәсе. Католик динендәгеләр андый терапияне костёлга барып, үзләре ышанган рухани атакайга гөнаһлы дип уйлаган серләрен түгеп кайтуда тапканнар. Гасырлар буе әйбәт кенә «эшли» торган чара. Ә безнең әбекәйләр «ахирәт дус» табып, ахирәттә дә бергә булырга дип вәгъдәләр бирешеп, бүләкләр алмашып юанган.

Кем белә бит әле, бу икәүнең күзгә күз сөйләшүенә нокта кайда һәм ничек куелыр? Тыңлаучы сыйфатындагы өстәл хуҗасының ягымлы һәм аңлаучан күзләре әңгәмәнең шифалы буласына ышандыра үзе. Ике бармагы белән маңгаен угалап, ханым үзалдына шулай уйланып алды. Бүген кич кенә табылган ахирәте аның, әйтәсе сүзе булып та, әйтми калырга кирәк әле дип тыелып калганда, бармаклары белән маңгаен угалап алу гадәте бар икәнен тиз абайлады. Гаеп итмәде. Аның үзенә дә чәчрәп-чәчрәп чәпчегән хатын-кызга караганда, сүзен үлчәп сөйләүчеләр ныграк ошый иде. Ашыктырмаска, бәйләнмәскә генә кирәк икән бу затлы ханымга. Ни әйтәсен үзе белә ул.

***

– Минем исемем Миңлегөл. Мәшһүр рәссам Иван Айвазовскийның да әнисе Миңлегөл исемле булган бит. Белә идегезме? Ә миңа бу матур исемне бит очыма мәк орлыгы сыман сибелгән миңнәрем өчен кушканнар. Үземә килешеп тора кебек. Алсу йөздә кара бөртекләр гел мәк чәчәге кебек менә. Дус кызларым яратып кушкан кушаматым да Мәк Чәчәге минем. Матур

бит, әйеме? Хәзер генә ул мәк чәчәген затсызладылар. Бакчага сибәргә дә кыймыйлар. Йә начар бәндәләр кызыгыр, йә үзеңә яманат тагылыр. Алла сакласын!

Бала чагымда түтәл-түтәл мәк чәчәкләре үстерә идем мин. Әниемне сөендерер өчен. Күрше әби һаман-һаман үзенә су китергән өчен рәхмәт йөзеннән өч шылтыравык тартма – мәк орлыклары биргән иде. Шуларны сиптем түтәлгә. Ефәк итәкле күбәләкләр кебек җәй буена җилдә җилферди торганнар иде чәчәкләрем. Ел да шулай. Авылдан киткәнче. Авыл кызы икәнлегем күренәдер инде. Чәч буяп, тырнак сырлаган белән генәмени. Без бит, авыл кызлары, садә җанлы, ихлас күңелле, хисчән, әмма нык үзәкле. Мин әле тагын бик иркәмен дә. Иркә үстем. Әти белән әни үстерде иркә итеп. Мин аларның картаеп тапкан балалары. Мин туганда, әнигә – 51, әтигә 62 яшь булган. Бу яшьтә хатыннар ырудан кала. Ә минем әни олыгаеп, әмма бик яратып барган иренә бала табып биргән. Чиксез куандырган.

Әтинең дә, әнинең дә бу икенче мәртәбә оя корулары булган. Әнинең олы кызы – минем түткәй миннән 30 яшькә олырак. Аллага шөкер, исән-сау. Миңа чамасыз нык терәк. Әтинең ике улы, әнинең беренче ире сугышта ятып калганнар. Ике каңгырап калган ояны кушып, бөтен иткәннәр болар. Шул ояда мине – сандугач баласын, и генәм лә, сөеп тә үстерделәр инде, бәгырькәйләрем. Хәлләреннән килсә, мәктәпкә дә арка кочтырып кына илтерләр иде. Өйгә кергән тәмле ризык – гел миңа! Пенсия акчаларын җыйнап, кушып, минем күзем төшкән матур киемне алырлар иде. Мин анда да әле сырланам. Имеш, сандалиның алы түгел, зәңгәре кирәк. Шәлнең чәчәклесе түгел, чуклысы алынсын. Мин теләгәне, эзли торгач, тәки табыла бит, Ходайның хикмәте.

Ачулану юк, кагу юк. Әйтәсе сүз җайлап, кинаяләп, бәет сыман итеп, йә китап кыйссасы аша гына ирештерелә. Аңлыйм үзе. Авыл бит. Тәрбияне авыл да бирә. Кызның анасы кырык – кырык беренчесе чыбык. Авыл өчен иллә дә хак гыйбарә бу. Ләкин «кырык беренчесе чыбык» дигәне миңа бер генә дә кагылмады. Җилкәм чыбык татымады.

– Ник каты бәрелим балага? Болай да иплекәй ул. Бездән яшь калыр дип тә куркам. Дөнья болай да кагар сандугачымны. Ата йортында назланып, татлы йокыларын йоклап калсын, – дип сөйләнә торган иде әнкәй, ахирәтләре белән кич утырганда.

Бу сүзләрне ишетеп калган мин, чаршау артына посып, Алла бабайдан әнкәй белән әткәйне гомерле итә күр, дип ялвара торган идем. Ихлас теләкләрем кабул булды. Сандугачларына 30 яшь тулганын күреп, әле оныкларын да үстерешеп, бу дөньядан бик риза-бәхил булып күченделәр.

Нурлы иде безнең өй. Киң такталардан түшәлгән идән сайгакларыныңкершәндәй аклыгы өй уртасындагы җылы утрау – ак кәгазьдәй акшарланган морҗа яктысы белән кушыла. Мич каршында самавыр җырлый, Морҗа ырмавында песи юына. Ак челтәр тәрәзә өлгеләре морҗадан агылган талгын җылыдан тирбәлә. Тәрәзә төбендә кышкы кына гөлләре чәчәктә, яран гөлләр янып утыра. Кичкырын йон гөнҗәләсен кабага бәйләп, әнкәй җеп эрләргә утыра. Бармак очларындагы орчыгы

пәри кызы кебек зыр-зыр бөтерелә. Аннары әнкәй ике орчыкның җебен бергә кушып ката, киләп сара. Инде ап-ак итеп юылган җепне йомгакка ураганда мин дә кирәк булам. Киләпне ике кулыма киеп алам да кулларымны җитез-җәһәт кенә, әмма тигез ритмда арлы-бирле йөртеп торам. Кайбер көннәрне, безнең белән кич утырырга дип, Мәрфугаттәй белән Вәсилә җиңгәчәй керә. Шуларның сүзләре, әй, кызык кебек тоела иде инде миңа. Бервакыт, алты яшьләр булгандыр миңа, әйтәм икән: «Әйдәле, әнкәй, бәрәңге әрчегән булып, кызык-мызык сөйләшеп утырыйк әле».

– Ничек була соң ул кызык-мызык сүз, балам? – ди икән әнкәй.

– Кияүгә китешләр, бәби табышлар турында сөйләшеп утыру була инде ул, – дип әйтеп әйтәм икән.

Бу, имеш тә, мин әйткән сүзләрне бер мәзәк итеп искә алулары гына булгандыр. Үзем бер дә хәтерләмим. Сүзләрнең зиһенемә сеңеп калганнары да бар. «Кыз бала үзен сакласын инде ул. Югыйсә ишектән кергәндә дә, чыкканда да, башына тукмак төшә ул мескеннең. Нинди тукмак турында сөйләгәннәрен бераз исәя төшкәч, күп ишетә торгач төшенә башладым. Кыз баланың иң затлы бирнәсе – гыйффәте! Кызлыгын югалткан бичараларның бәхетсез язмышы турында да хикәятләр сөйләнелә иде кич утырган заманнарда. «Ишетсен колагың!» «Башыңны сакла!» «Уяу йөр, алдана күрмә!» кебек кисәтүле сүзләр теш арасыннан чыкмый. Юк! Оятыңнан кая качарга белмәс идең. Үсмер чакта андый сүзне ишетү түгел, бәлки кинаяләп әйтү дә намусыңны рәнҗетү кебек яңгырый. Гаепләп түгел, бәлки кисәтеп әйтелгән йогышсыз сүз дә мәсхәрә кебек ишетелә бит ул.

Кыз балалар арасында «профилактика» үткәрү өчен сәбәпләр булып торган икән шул авылда. Хәдичә атлы күрше кызы, әнә, читкә китәргә йөри икән. Алданган мескенем. Егете алмаган. Читкә китми хәле юк бәгырькәйнең. Калым түләргә хәленнән килмәгән үзбәк егетләренә хәзинә инде безнең уңган-булган чибәр татар кызлары. Ахирәт әбиләрдән ишеткәннәрем мине кул-тел тидергесез тәүфикъ иясе итеп бетергән иде инде. «Үзбәккә кияүгә чыккан икән Хәдичә. Болай бер дә зарланмый икән иреннән. Тик менә үзбәк кияүнең генә кайтып күренгәне юк. Кыз баланың бәхете иреннән инде аның. Төшкән җирендә таш булсын, кана!» Дус кызымның үзбәк җизнәсен минем дә күреп калганым булды. Хәйләкәр дә, мут та бугай ул Үзбәк җизни. « Хәдичә бик сагына», – дип, берзаман пылт итеп үзе генә кайтып төште бу. Күрдек җизнине. Тик аңламадык. Ул кайтканга карап, Хәдичә апаның сагынуы ничек басыла торгандыр. Мин үзем кияү дип, чит-ят җирләргә китүгә каршы. Авылдан да китмәм әле.

Инде җитеп киләм. Кичке уенга да чыкканым бар. Егетләр әле мине күрмиләр. Югары Очның Гадиләсе авыл чибәре санала. Менә ичмасам, Гадиләнең хәлләре мөшкел. Клубтан бер генә тапкыр да рәхәтләнеп кайта алганы юк. Гел артыннан бастырып куып киләләр. Ничек качып өлгерә торгандыр? Акыллы да, матур да кыз ул үзе. Миннән өч яшькә генә олырак.

Ялыктырмадыммы әле? Ни дип сөйли торгандырмын инде мин бу әбекәйләр сабакларын. Күрәсең, үзем дә шул карчык-корчыкларны

сагынамдыр. Юк бит инде алар хәзер. Югыйсә тагын бер балачагыма кайтып, итәкләренә башымны салып, агач тарак белән чәчләремне тараттырыр, лыбыр-лыбыр сөйләшкәннәренә оеп ятар идем. Юк шул инде. Үткәннәргә кайтыр юл юк.

– Минем сезне тыңлаудан туйганым юк. Әгәренки, сез арып киткән булсагыз, сөйләшүне башка вакытка кичектерә алабыз. Минем вакытым иркен. Күбрәк үз алдыма, ягъни өйдә эшлим.

– Бәлки шулай килешербез дә. Әле мин җылынып җитмәдем бугай. Ашыкмасагыз, тагын бераз серләшик әле...

Миңлегөл ханым, коньягын иренենә тидереп кенә алды да, бәллүр чәркәне кире өстәлгә куеп, өзелгән сүзне дәвам итте:

– Бер көнне авыл өстеннән эт кояшы шуып үткән кебек кенә ямьсез хәбәр таралды: «Гадилә читкә киткән!» Кыз хакында авыл бер яман сүз чыгармады. Кара төндә коточкыч вәхшилек кылынган. Кызның әнисе Фәрхинур түтәй сарык фермасында төнге каравылда булган. Битенә оек кигән берәү тәрәзәдән төшкән... Моны белүче дә, күрүче дә булган. Әмма кызга гайбәт йокмады. Авыл моны үз өстенә килгән бәла итеп кабул итте. Бәла иде бу. Бәла!

Ник китте Гадилә авылдан? Мин шушы хакта гел уйланып йөрдем. Кызның гаебе юк бит. Ул бит вәхшәт корбаны! Кызлык пәрдәсенең бөтенлеге янәшәсендә кызның үзенең әхлакый пакьлеге, намусы берни дә тормый микәнни? Кеше кулын, аягын да өздерә. Аңа карап, кирәкле, кадерле кеше булудан туктамый. Бәхетсезлек очрагы бит бу! Гадиләнең читкә чыгып китүен табигый адым кебек санаулары да вәхшилек! Әйе, Гадиләне аңлыйм мин. Ул гарьләнгән, үртәлгән, аңа бик тә оят булган. Үз авылында шундый кеше яшәгәненә әрнегән ул. Шуңа күрә Гадилә авылдашлары арасында яшәп калырга теләмәгән. Яши алмаган! Ярый әле үзенә үзе кул салмаган. Андый хәлләр дә була икән...

Яшьлек сукмагыма мин әнә шундый шөбһәле уйлар белән килеп кердем. Мин кулга тиз генә ияләшә алмый торган, һәр саксыз ымнан тетрәнүчән, әмма тоягы каршы һөҗүмгә әзер сизгер болан идем. Берәрегез миңа тиеп кенә карасын!

Ялыктырмадыммы әле?

– Нормально! Сезгә Миңлегөл дип, гади генә итеп дәшсәм, кабул итәрсезме икән?

– Нормально. Минем улларым да шулай кыска тота җавапны. Ә менә мин әле һаман сезнең ни атлы икәнне белмим. Монысы инде нормально түгел, шулай бит?

Икебез дә көлеп җибәрдек.

– Гади минем исем. Гөлсөяр мин. Әйе, минем дә «гөлем» бар. Татар әниләре кызларын «гөлле» итәргә яраталар. Шулай ук «ханым»сыз дәшкәнгә ияләнгәнмен.

***

– Сукмак... Сукмагымның теге башыннан каршыга төшүче бар икән инде. Җәй көне велосипедта, кыш көне чаңгыда гел бер егет юлыма төшә. Рәшит бу. Миңа 16 яшь, аңа 19. Җәй буе Рәшитнең багажнигына

утырып йөрдем. Безнең авылның егетләре күз төшкән кызларына игътибарны әнә шулай күрсәтәләр иде. Велосипедта барганда, әлләни сөйләшеп тә булмый. Егетең, гайрәтен күрсәтеп, җитез генә велосипед педален әйләндерә. Ә син егеткә чытырдатып тотынып барасың. Егеткә шул да рәхәт буладыр, күрәсең. Ул кыз ныграк тотынсын өчен юлның сикәлтәле урыннарын таба. Егылудан курыккан саен егетеңә ныграк сырышасың. Ике арада сәер бер якынлык пәйда була. Егет белән кыз арасында тылсымлы һава дулкыны йөреп тора кебек. Киеренкелекне киметү өчен дөньяда бер мәгънәсе булмаган сүзләр бетәсе түгел. Бернинди үбешү, кочышу дигән нәрсәләр юк. Безнең чорның үсмер егет-кызлары әнә шулай йөри торганнар иде.

Велосипедта әйләнеп килгәч, каз бәбкәсе ояга кушылгандай, кызлар төркеменә кереп чумабыз. Менә шул чагында чытлыкланып көлешүләр була торган иде инде. Егет дигәннәребез урамның аргы ягындагы бүрәнәгә тезелеп утыралар. Кызлар бу яклап. Әй тотынабыз кара-каршы җыр-такмак әйтешергә.

Рәшит Әлмәт малае иде. Кышкы каникулда кунакка килүендә егетем мине кинога чакырды. Ә безгә укытучылар кичке сеанска кинога йөрергә рөхсәт итмиләр иде. Әти белән әни җибәрәләр. Ризалаштым. Кереп утырдык клубка. Бөтен кешенең күзе бездә кебек. Чынында да карап-карап алучылар байтак.

Оялмыйча! Егет белән! Рәшит – шәһәр малае. Аның ише оялулар аңа таныш түгел. Учымны учына алды. Кинодагы хәлләрне сөйләшеп алганда, чәче битемә кагылып китә. Бу инде капка төбенә сарган көрт ышыгында, аякларны өшетә-өшетә сөйләшеп басып тору гына түгел. Бергә кино карау! Файдалы һәм матур итеп аралашу.

Кинәт залда гөлт итеп ут кабынды. Кичке сеанска үтеп кергән мәктәп укучыларын аулыйлар икән. Беттем! Фирая апа – физкультура укытучысы мине күреп алды: «Абдуллина, чык залдан!» Шунда укытучы апа Рәшитне дә абайлады: «Син, Рәшит, минем бу авылда укытканны каян белеп алдың? Килүең шәп булган. Кинодан соң безгә кайтырбыз, яме!» Спорт техникумында сабакташлар булган икән болар. Рәшит соңыннан аңлатты аңлатуын. Мин инде залдан шешәдән атылган бөке кебек чыгып очкан идем. Шул вакыйгадан соң миңа мәктәптә көн бетте.

Фирая апа физкультурадан чаңгыда ук кебек очкан кызга «өчле»ләр тезә. Кичке сеанска кинога йөрүемне директорга да әләкләргә өлгерде. Йөрү дип, шул бер бардым инде. Бу каныгуның очы чыкты соңыннан.

***

Шомырт бураны котырган мәлдә Рәшитне армиягә озаттым. Җырдагыча, айлы нур кичеп, Ык буенда йөрдек. Гаҗәеп моңлы, сихри кич иде ул. Вәгъдәләр биreштек. Капка төбендә үбештек. Минем гомеремдәге иң әкияти төн шулдыр, мөгаен. Әйе, әйе, мин бәхетне татып карадым. Мин чыгарылыш имтиханнарына әзерләнеп калдым. Бөгелмә вокзалыннан Рәшитне армиягә Фирая апа озаткан.

Рәшит Германиядә, десант гаскәрләрендә хезмәт итте. Спортчы бит. Мин дә сынатмадым. Институтка укырга кердем. Тәвәккәл адымым нигезсез

иде. Әткәй белән әнкәй тәмам олыгайдылар. Кая инде ул миңа көндез укулар! Тиздән читтән торып укуга күчтем. Чаллыга, түткәй янына барып, эшкә кердем. Кызыл яулыклы эшче кыз сыйфатында станок янына барып бастым. Студент икәнемне белеп алгачмы, әллә яшьлегемне кызганыпмы, кадрлар бүлегенә дәшеп алдылар. Кәгазь арасына. Хезмәт хакы табелен цехта эшләп йөри торган итеп ябып бардылар. Өс-башны да карап өлгердем. Буй-сыным да рәвеш алды. Миңа монда яңа кушамат табылды – Ландыш. Минем чәчем җитен төсендә бит. Буяткан чәч түгел бу. Швед кызларына охшаганмын, диләр. Актан киенергә яратам. Шулай итеп, Ландыш – Энҗе чәчәк булдым. Хәзер инде миңа кемнең дә күзе төшәрлек.

Сагы барның сагы ятар, дигән гыйбарә бар бит әле. Мин дә үземне бик саклыйм. Югыйсә аулак почмакта кысарга әзер куллар да шәйләнә. Бигрәк тә урындагы абзыйлар азгын. Әмма кытай ефәге кебек нәфис, саф кызның кул тидертмәслеген аңлыйлар. Тыелып кала беләләр. Хөсетлекләрен елмаю ышыгына яшерәләр.

Алай да яшьләр янында күңелле. Контора белән цехлар арасында очып кына йөрим. Күңелнең канатлы еллары иде бу. Бәйрәмнәр күп, комсомол эше мул. Радиогазета чыгарабыз. Мин гел уртада. Егетләргә карамыйм да – минем Рәшитем бар!

***

Яңа ел алдыннан ул кайтты. Без Яңа елны икәүдән икәү генә каршыларга килештек. Түткәйләр кунакка китте.

Рәшит белән сагынышканбыз. Җитлеккәнбез дә инде. Үбешүләрнең тәме үк башка. Егетем килешкә табын корып куйдым. Матур итеп киендем. Мин янәдән Мәк Чәчәге булдым. Яшел чалбар, алсу блузка киеп алдым. Күреп торасыз – мин озын буйлы, зифалыгым әле дә сакланган. Рәшит ул кичтә миңа өр-яңадан гашыйк булды бугай.

Ул тагын да ныгыган, аңа көчле ир-ат кыяфәте кергән. Әрсезләнгән дә. Менә шушы әрсезлеге харап итте бик матур башланган Яңа ел төнен. Могҗизалы Яңа ел урамнарын, әкияти чыршы кызларын карап кердек. Урамга ташып чыга тораган бәйрәм бит ул Яңа ел! Сафланып, алсуланып, янәдән табын янына елыштык. Бәллүр касәләр чыңлаттык. Рәшитнең хәрби хезмәттән исән-имин йөреп кайтуы хакына да бәллүр касә күтәрдек. Мәхәббәтебез хакына да тост әйтештек. Ә менә киләчәгебез хакында әйтергә онытканбыз икән. Ә бит кирәк булган!

Төннең калганы тартышып үтте. Рәшит үбә-үбә мине чишендерергә тырышты. Мин карыштым. Ә ул, бу төнне мин аныкы булырга тиеш, дип юмалады. Сүзе үтмәгәч, мине авыллыкта гаепләде. «Егетләр армиядә әйтәләр иде. 15 яшьтән соң кызлар әниләренә генә кыз булып калалар, – дип. – Мин сиңа да ышанмыйм. Кыланасың гына син».

– Әйе, кыланам. Бар, кыланмый торган кызлар янына кит! – Минем инде ачуым чыга башлаган иде.

– Мине кызганыр идең, ичмасам. Җәфаланам бит. Кыен миңа, – дип үгетләп карады ул мине.

– Кызгана-кызгана үзем кызганычка калыр хәлем юк. Кызгана торганнар табылыр.

– Яратам бит мин сине. Мәхәббәтнең иң бөек ноктасы бит ул физик якынлык. Әйдә, бүгеннән өйләнешәбез.

– Мин риза. ЗАГСтан кайтуга ук, мин – синеке. Бөек ноктага икәү бергә менәрбез.

Озак тарткалаштык без. Бәйрәмнең яме югалды. Ни йокы күрмәдек. Таң беленүгә Рәшитем китте.

– Йә ярар, хуш иттек. Авылга кайтып киләсе бар. Шәп кыз син, Миңлегөл. Безнең егетләр белсәләр иде синең ниндилегеңне!

Ул китте, ә мин җәймәнең чиста калуына сөенә-сөенә, Рәшит белән тарткалашканда, сандык почмагына эләгеп ертылган чалбар балагына матур итеп кызыл мәк чәчәге чигеп куйдым.

Без Рәшит белән бүтән күрешмәдек. Ул тиздән өйләнде. Фирая апага. Мәхәббәтнең бөек ноктасыннан мин егылып төштемме, әллә биегрәк күтәрелдемме – аңламый калдым. Менә мин дә гыйффәт корбаны. Саклап кала алган өчен. Ә менә Фирая апа Рәшит кебек егетне ничек бәялисен белгән. Шушы гыйффәт казасы мине гомер буе эзәрлекләде.

***

Миңлегөл ханым, үзе сизепме, әллә сизмичәме, ишетелер-ишетелмәс кенә бер өн белән «Мәк чәчәге» көен көйли башлаган иде. Мине дә бу көй үзенә суырып алды. Ниндидер сихер, тылсым бар бу җырның көендә. Нечкә моң булып саркып чыга да ул, сине фани дөньядан аерып алып, күңелеңнең үтә дә яшерен бер дөньясына, бүгенге галими тел белән әйткәндә, астралга алып кереп китә:

Мәк чәчәген өздем ялгыш кына,
Чүп үләне белән бутадым.
Мәк чәчәген, белми киләчәген,
Үз кулларым белән утадым...

Без әле ярты сәгать элек кенә бер-берсен белмәгән ике хатын-кыз, шушы җырдагы үзәк өзгеч моң тәэсирендә башларны башка терәп, эреп киткән идек. Берзаман искә килеп, туктап калдык. Алай да кеше арасында утырабыз бит әле. Мәк чәчәгебез дә өзелмәгән. Тик, бу ниткән сәерлек – үзәк өзгеч моң нигә килеп керде соң әле? Ә көй дәвам итә. Сүзсез генә:

Мәк чәчәген...м-м-м-... өздем,
М м м ... м-м-м...
Өзгән чәчәк ... яшәрмәс инде-е-е-е...

Гайре табигыйлектән сискәнеп, башымны күтәреп карасам, яныбызга скрипкасын иягенә терәгән таныш музыкант килеп баскан икән, иелә төшкән дә «Мәк чәчәге»н уйнап тора бу. Ике хыялый ханымга карап, күзләре белән генә назлап, елмая. Елмаю безнең өчен түгел, үзе өчен... Ул да әсәрләнгән. Аннары музыкант, нәзакәтле итеп кенә башын иде дә гафу үтенеп китеп барды. Көйнең соңгы аһәңнәре залда эленеп калды. Кемдер

кул чапты, кемдер: «Браво!» кычкырды. Ә без, берни булмагандай, әңгәмәне дәвам иттек.

– Иң мөһим серемә килеп җиттем. Шуңа күрә шытып чыкты бу чәчәк күңел түреннән. Алҗытып бетергән булсам, шушы урында саубуллашабыз да...

Мин тынычландым бугай инде. Ханым шунда бармагыннан мин кич буе күзәтеп утырган сәер кашлы, кашы өстенә яшен эзе кебек алтын җепләр яткан йөзеген бушата башлады.

– Тагын бер күрешми калмабыз кебек. Минем хикәятем бер кичлек кенә түгел. Йөзегем бушамый тора.Тыгыз ул миңа. Язмышым кебек, миңа язмаган йөзек. Шуны сезгә бүләк итәсем килеп тора. Бәлки, сезнең бармакта йөзекнең бәхетле сәхифәсе башланыр. Бер чегән хатыны әйткән иде аны: «Кара чәчле хатын-кызга тәгаенләнгән йөзек бу. Язмышлы йөзек. Кимә син аны», – дип. Сезгә ядкарь итимче. Каенанам бүләге. Ул чем-кара чәчле иде. Кемлеген, әллә яһүдә, әллә чегән, ул үзе дә белми иде. Балалар йортында үскән бала бирнәсенә бу йөзекне кем салганын да белми иде Раиса Давыдовна. Начар каенана булмады ул миңа. Мин дә начар ауралы кеше түгел. Бүләк итәргә теләвем дә ихластан. Кашы бигрәк үзенчәлекле бит, әйеме? Алтын сызыклар астына дикъкатьләбрәк карасаң, анда чәчәк сызымы бар сыман. Тауда үсә торган чәчәк бугай ул. Кавказ тауларында очраган бер егетне хәтерләтеп, йөрәгемне телгәли бу йөзек. Мин бу сәер язмышлы йөзекне аңа да ядкарь итеп калдырырга ниятләгән идем. Тик соңыннан бу гамәлем дөрес булмас дип уйладым. Юк, юк, вәгъдә бүләге итеп түгел, татар кызы булганым өчен генә... Аның миңа кылган игелекләре өчен рәхмәт йөзеннән генә. Аннары андый ядкарь өчен сайланган йөзектә бернинди шикле язмыш эзе дә булырга тиеш түгел дип уйладым. Инал өчен, егетнең исеме шулай, мин Нальчикта бернинди кашсыз, әмма гаҗәеп челтәрле бизәк үрелгән көмеш йөзек – Кубачи зәрканнәре ясаган йөзек сатып алдым. Мөселман егетләре көмеш йөзек кияргә тиеш дип beләм».

– Бу – бик затлы хәзинә. Әмма мин дә бу йөзекне кабул итә алмыйм. Сез аны зиннәтле алтын-көмеш серләрен аңлый белә торган кешегә бүләк итсәгез, яхшырак булыр иде. Иясен тапсын иде ул адашкан йөзек. Авырга ала күрмәгез. Минем бит бүгенге романны – сезне минем янымa китереп утырткан романның эчтәлеген беләсем, син язган китапны «укып» бетерәсем дә бик килә. Әле соң түгел. Бала-чага вакыты да чыкмаган. Бәйрәм кичендә тоткарлану да гаеп ителмәс.

– Әйдәгез алайса, кайнар ризык китертик. Йолдызларны буйсындыру безнең хәлдән килми икән. – Миңлегөл бушый алмый йөдәгән коньяк шешәсенә ымлап алды.– Бер дә баш бирми утыра... Кызыклар бар әле минем тәрҗемәи хәлемдә. Менә татарчам да начар түгеллеген исбатладым. Әлеге дә баягы шул физиология – гыйффәтем сәбәпче.

– Ә минем хикәяткә ялгыш кына килеп кергән Инал исемен кат-кат ишетәсем килә бугай. Әллә ялгышаммы?

– Иналмы? Шунда тауларда калды инде ул. Тик аның исеме чыккач, үзем дә сискәнеп киттем.

– Нык яшергән серегезнең үзәгенә бастыкмы әллә?

***

– Рәшит китте. Үзенең Мәк Чәчәгенә хыянәт итте.

Син китте дип, йөрәк әрнемәсен.
Яши башлыйм хәзер яңача.
Яңа көнне синсез каршылармын,
Тик бетмәсен дөнья таңгача...

Әнә шулай, хыялымда һаман да әле мине яратучы Рәшит белән шигырь телендә сөйләшеп йөрим. Һаман да шул «Мәк чәчәге»н җырлап йөри торган булып калдым. Минем өчен җыр гына түгел, үкенеч гимны ул. Күңелдә – боз, йөрәктә – ут. Әле ашкынам, әле боегып калам. Ничек яшәп китәремне дә белмим. Мин бит моңа кадәр яратып – көтеп, сагынып, өметләнеп яши идем. Фәкать шулай гына яши белә идем. Ә хәзер ташу киткәндә, атауда ятып калган боз кебек мин. Ташуларга кушылып, елга иңләп ага алмыйм. Эреп бетеп, юк булганчы – әбиләр әйтмешли, кыяметкә кадәр кирәксезмен, ялгызмын. Мондый хисне татып караганнар бу дөньяда мин генә түгелдер инде ул. Ләкин һәр кеше үзе генә дип уйлый. Акыл бит ул соңлап килә. Инде кирәге калмагач...

Тып итеп көзге каршына килеп басам. Аннан миңа томрап торган саф кыз карап тора. Көзгедә чагылган Миңлегөл миңа тереклек көче бирә: син чибәр, син яшь, сине бик күпләр сокланып күзли. Тот та арадан берсен сайлап ярат! Мәхәббәтнең беренчесе генә була. Соңгысы булмый аның. Ярат, ярат!

Шул көннәрдә «КамАЗ»га Грозный нефть техникумын тәмамлап, бер төркем егетләр килеп төште. Завод Бөтенсоюз комсомол төзелеше бит. Әллә кайлардан, әллә кемнәр килә. Бу егетләр мин табельгә беркетелгән цехта эшли башладылар. Цехтагы таныш кызлар мине кыстыйлар: «Миңлегөл, утырма шул кетәклек кебек кадрлар бүлегендә. Безнең арада йөр». Үзем дә кызыгам. Чөнки цехта комсомол эше гөрләп тора. Миндә яшьлек дәрте дә, дәрман да җитәрлек.

Грозныйдан килгән егетләр дә килеп кушылгач, цехтагы кызларның йөрәк яңалыклары, серләре диюем, гүпчим күбәйде. Цехка клубка килгән кебек ашкынып киләләр. Егетләрнең берсе мине укка алды, ахрысы.. Мин цехта күренгәндә, кесәмә шоколад салу җаен таба. Сөйләшми үзе, елмая гына. Гел шулай.

Бер көнне цехтагылар үзләре мине эзләп килгәннәр.

– Миңлегөл, сиңа йомыш бар. Бурычың да әле ул синең. Безнең Кавказ егетләре эшкә йөрми башладылар. Син сәбәбен белеп кайт. Бу бит саботаж! Кадрлар бүлеге инспекторын да моның өчен мактамаслар. Эшеңнән үк кумасалар әле...

– Мин соң нишли алам? Йә, ярый. Алар яшәгән тулай торакка барырмын да, ди. Мәгәр үзем генә бармыйм.

Алай да киттем. Үзем генә. Килсәм, ишек артында музыка! Шакыйм-шакыйм – ишетүче юк. Ачтылар тагы. Ике егет ашарга пешереп йөри. Берсе, душтан гына чыккан, ахрысы – плавкидан гына. Мин оялдым да ишекне яптым. Минем кесәгә шоколад сала торган егет үзе минем янга

чыкты. Саша Касаткин бу юлы елмаймый. Тәрәзә төбенә барып утырдык. Кулы ялгыш кына янбашыма тиеп китте: ток суктымы дип торам. Бөтен тәнем тетрәнеп куйды.

– Китәбез без, Машенька. Мондагы салкыннарга ияләшә алмыйбыз. Җылы киемнәребез дә юк.

– Ничек инде? Сез бит комсомол путёвкасы белән килгән яшь белгечләр. Өч ел эшләү мәҗбүри сезгә!

– Булыш син безгә, Машенька. Эштән азат ителү җаен табарга булыш. Машенька...

– Минем андый хокукларым юк. Булдыра алмам, – дидем, кыюсыз гына. – Китмәгез, Саша!

– Алайса, үзең дә цехка күч.

Күчтем. Баш инженер бәйләнә иде. Аннан качып күчтем. Машиналар җыю цехында конвейерлар туктатылмый. Шуңа күрә эш дүрт сменалы. Дүрт көн эшләүгә завод директоры мине цехта күреп алды:

– Студенточка монда нишләп йөри? Марш моннан. Миңа секретарь кыз кирәк!

Карышып кара хуҗа кешегә!

Түрәләр сөеклесе, дип, бу юлы иренен кыйшайтып елмайды Саша.

Үртәлдем, әмма үз бәямне белгәнгә күрә, бу кыек елмаюга исем китмәде. Кем соң ул миңа? Егетемме әллә? Елмаючылар тагын да бар ул!

8 Март бәйрәме алдыннан Саша үзе мине эзләп, тулай торакка килде. Йомышы һаман да шул иске йомыш икән: эштән китәргә булыш! Машенька...

– Андый кодрәтем юк.

– Бар синең кодрәтең. Беләбез. Куенындагы кәккүккә кем каршы килсен!

– Нәрсә?! Нәрсә дисең?!

– Матурланма. Йоклап йөрисең. Беләбез...

Мин кайнап чыктым. Тәмам ярсыдым. Сафлыгын саклау бәрабәренә сөйгән ярын югалткан чык бөртегедәй саф кызга нинди яла ягып маташа бит бу! Бәлки яла ягам дип белмидер дә. Ул бит телгә кергән гайбәт сүзен генә кабатлый. Димәк, минем хакта ямьсез гайбәт сүзләре таралган. Безнең цехта ниндидер хәшәрәт үрмәкүч миңа карата ятьмә үргән! Шулай да булсын, ди. Тик Саша бөркетләр оя кора торган яктан – Кавказдан килгән егет. Кызларның намусын күз карасы кебек саклый белә торган халык баласы минем хактагы мондый гайбәтне ялгыш та әйтергә ярамаганлыгын белергә тиеш иде ләбаса! Чын булса да, ышанмаска тиеш иде ул! Ышана калган очракта да, минем намусымны яклап, юлбарыс кебек сугышырга тиеш иде. Мин бик гарьләндем.

Чыннан да гарьлек бит бу. Мин үз-үземне ничек яклый алам? Ничек акланыйм? Гомумән, акланып тору кирәкме соң әле? Сүзнең иң зәһәрен табарга иде бит! Бу егетне бетереп ташларлыгын. Кем соң әле ул миңа гаеп ташларга базган егет? Суыкка ияләшә алмыйм дип зарланган Тау бөркете! Хәчтерүш!

Гыйффәтле кыз икәнлегемне акларга тырышып йөрү минем өчен дә түбәнлек бит әле ул. Тик ничек, ничекләр акланыйм соң? Башымда йөз сорау, ә бер җавап юк!

Ә Саша килә дә килә. Чәчәк белән дә, бүләк белән дә. «Яратам!» – ди. – Өйләнешик, Машенька! Мин өйгә хат яздым. Әни белән әти юлда инде.

Кара син моны. Егет була белә икән бит бу.

– Мин бит – Кавказ егете, Машенька! Анда кызлар намусы белән шаярмыйлар.

Шул көнне мин әткәй-әнкәй янына кайтып киттем.

– Мин кияүгә чыгам. Урыска! Кавказ кешесенә! – дидем.

Бу сүзләрем әнкәйгә корт чаккан кебек тәэсир итте:

– Әстәгъфирулла! Әстәгъфирулла! Әстәгъфирулла! Сандугач баласыдай үстергән кызымны урыска бирәмме соң! – Әнкәй җен суккандай, бер урында бөтерелә башлады. Котым алынды – юләрләнә бугай дип торам. Аннары мин алып кайткан күчтәнәчләрне алды-куйды, алды-куйды. Кызыл эчле ялтыравык галушны аягына киеп куйды. Салды. Тагын киде. Тәһарәт алырга булса кирәк, комган тотып, ишегалдына чыгып китте. Ә мин идән уртасында гаепле бала сыман кыймылдарга да куркып басып торам. Әнкәй белән берәр нәрсә булыр кебек. Мин белә идем – минем бу хәбәрем карт атам белән анамны аяктан егарга тиеш иде. Үтерергә! Тик аларның иркә кызларын ярату хисе бу юлы да җиңде.

Шөкер, әнкәй әйләнеп керде. Ләкин миңа бер сүз дә катмады. Әткәй генә телгә килде:

– Анасы, бетеренмә әле. Монда – Татарстанга тиклем килеп чыккан ул бала эш сөя торган егеттер. КамАЗ шундыйларны җыйды. Безнең балабызны яраткан өчен генә аны каһәрләргә ашыкмыйк әле. Мин госпитальдә ятканда, тау халыкларын күрдем. Иманлы халык алар.

– Урыста иман бармы? – диде әнкәй.

– Алла шәфкатеннән ташламасын! – диде әткәй.– Барыбыз да Ходай бәндәләре. Татар барда хәтәр бар, урыс барда милость бар. – Мәкальнең мондыен ишеткәнем юк иде әле. – «Ләүхелмәхфүз»дә – маңгаеңа язылганы булыр. Язмышың шулдыр.

Әткәй бу сүзләрен миңа төбәп әйтте. Иренә каршы әйтергә күнекмәгән әнкәй дә шул сүз белән юашланып калды. «Авылыбызда урыска кияүгә чыккан син беренче булырсың! Ояты да үзеңә булыр!» – дип, миңа фатихасын бирде. Ә мин аларның йөзенә шундый оят китергәнем өчен гомер буе үземне битәрләдем.

Юраганнары юш килде. Саша йомшак кеше иде, әткәй-әнкәйгә миһербанлы булып чыкты.

Ачулансалар, кире уйлый ала идем әле. Әмма...

Әткәй белән әнкәй ак сәке өстенә намазлыкларын җәеп, икәүләшеп намаз укыдылар. Аннары сәке читенә утырып, киңәш-табыш кордылар:

– Кызым, кияүгә әйт. Никахны атнакич укытырбыз. Шул көнне үк әнкәй олы кызын – түткәйне чакырып кайтарды. Бергәләп, төш пешерергә керештеләр. Бал белән катырып, вак конфетлар белән бизәп, туй чәкчәге өйделәр. Күп итеп токмач кистеләр. Әткәй бүлтерек сарык бәрәнен чалды. Хәлләренә күрә сый әзерләнде.

Никахка Сашаныкылар килеп җитте. Папа Чаллыда калды. Мама авылга ук килде. Бик сәерсенеп, каранып йөрде: «Как будто я здесь бывала. Когда-

то, давным давно. Как называется эта деревня? Какое чистое село! Всё белым-бело.

– Тугай называют наше село. А зимой везде белым-бело! У нас любят жить по-белому, – диде чая тутам. – Аның сүзләре «без чиста торабыз» кебек ишетелде.

– Да-да. Я знаю. А всё-таки странно. Будто бы мое детство здесь прошло.

Сәерлекләр тагын да булды әле. Бу юлы әнкәй сәерләнде. Мулла бабай тиз-тиз генә рәвешен китереп, никах догасын укып китте. Саша үзен чат татар кияве кебек тотты. «Риза булып алдыңмы?»га да, кызара төшеп, «да-да, алдым», – дип, оста гына җавап бирде. Никахка чакырылган күрше-тирә таралышкач, якын кардәшләр белән тагын чәй яңартып алдык. Әнкәйнең күзе һаман кодагыеның йөзегендә. Мама баллы чәкчәккә үрелгәндә, йөзеген махсус күрсәткәндәй, бармагын бераз сузыбрак тота: янәмәсе, рәхәтләнеп карагыз әнием ядкаре булган бу йөзекне! Әнкәй карый, бик тә карый. Әмма сүз башлап сөйләшергә урысчасы җитеп җитми.

– Тугайда бывал говоришь. Тут у нас детдом был. Я там санитаркой работал. Там ты была. Маленькая. Тебе пять лет было. У тебя была мешочек. А там лежал это йөзек. Рисунок помню. На молнию охшаган. Тебя Рәйсә зовут. Мама твой панна была. Бомбежкада погибла. Уф ерып чыктым бугай, балалар! – Мама тетрәнеп калган иде. – Менә бит язмыш дигәнең сине кабат безгә китергән. Итәгемдә үстергән идем. Инде кодагыем булдың! Хикмәтле синең ул йөзегең. Язмыш ясый торган йөзек ул. Шуңа күрә анаң аны, югалта күрмәсен балам, дип, танышларына әйтеп куйган да. Балаларны озата кайткан хатын безгә сөйләде. Сакладык йөзегеңне. Киткәндә, әйберләрең арасына төреп җибәрдек. Син дә саклагансың. – Инде әнкәй, русчасын ташлап, тугайчага күчеп бетте. Мама да аны аңлый кебек. Икесе дә елыйлар. Аннары без дә кушылып елый башладык. Минем язмышымны эзләп килгән хикмәтле йөзек турындагы хикәятне озак сөйләде авыл. Ә мама югалган тарихындагы бер ак тапның бетүеннән тәмам әсәрләнде. Үзе исән чагында миңа бер хикмәткә карагандай карады каенанам.

***

Без Сашаның туган көнендә язылыштык. Туй ясамадык. Соңыннан кеше аркылы белдем, Сашаның йөргән кызы калган икән. Миңа әйтмичә генә, Кама Аланына барып, ул кыз белән хушлашып кайткан. Шулай итеп, мин дә берәүнең бәхетен кистем. Әллә берәүнекен, әллә үземнекен...

***

Яшәп киттек. Бер елдан соң улыбыз туды. Аңа мин Азат дип исем куштым. Улым туган елларда без – татарлар, «азатлык» алачагыбызга инанып, шул шигарь белән яши идек: Азатлык! Азат! Саша минем бер гамәлемә дә каршы килә торган кеше түгел иде. Хәзер без Касаткиннар гаиләсе. Гаилә башлыгы тагын иске сүзне кузгатты:

– Китәбез!

Мин дә күндәм ир хатыны хәзер.

Киттек Грозныйга. Әле бу шәһәрнең тыныч, бай, ямьле, төзек вакыты. Урамнарда шәп машиналар гына йөри. Каената белән каенана янында

тату гына яшәп киттек. Әмма мине башта яратмадылар бугай. Бугай дими дә булмый. Яратмау телгә чыкмады, әмма серле татаркадан сагаю бар иде. Гәрчә Тугай кызы булуым мама өчен сандыкта кадерләп сакланган сөлге сыман кадерле иде. Еллар үткәч, яратуларын яшермәделәр: «Безнең өчен синнән дә кадерле килен юк!» – дигән сүзне ишеттем мин. Аңынчы әле яшисе бар. Каенсеңлем Галина миңа бик тиз якынайды. Хәзер дә мөнәсәбәтләребез бик җылы. Каенанам картлыгын минем белән үткәрергә җыенган иде. Өлгерә алмый калды.

Гөлчәчәкләргә күмелгән Усалкалага – Грозныйга бөтенләйгә дип килгән идем. Әткәй белән әнкәйнең йөрәге өзелгәндер инде. Бер атнадан җирси башладым. Бер генә дә яфраклы агач юк. Ә мин зелпеләрне, каеннарны, миләшләрне сагынам. Үлән корып беткән. Урам ташы һәрвакыт мич башыдай кызган булыр. Кыш юк, кар яумый...

Сашам коеп куйган урыс та булмаган лабаса. Әтисе – терек казагы, әнисе әллә яһүдә, әллә татар, әллә поляк баласы. Раиса Давыдовна дип йөрттем мин аны. Каенанамның балалар йортында үскәнлеген тәфсилләп сөйләдем инде. Ә ул аның саен: «Милләтемне белмим мин», – ди торган иде. Яһүдә буласы килә иде бугай аның. Акыллылар дип даны чыккан милләт бит, ни дисәң дә...

Боларга Кавказда гомер кичерү мөһер салган. Тормышлары хәмерсез, гаиләдә ир кешенең сүзе сүз. Папа гел биш адым алдан йөрер. Ике кулына әйбер тоткан мамага борылып карамас. Тәкәббер кыргыйлык инде бу. Гаепләргә итсәм дә, үземә дә шул көн килде. Саша минеке түгел хәзер. Папа ни әйтә – шул, нинди эшкә куша – шунда бара. Миннән ерагайды бу. Гореф-гадәт кушканча яшибез.

Минем сөмсерем коелды инде. Шөгыль дә юк. Көнгә бер мәртәбә эссе урам буйлап, әлсерәп, папаның анасы янына – бабушкаларга барып кайтам. Ул үз йорты белән яши. Бакча-түтәлләре бар. Миңа анда рәхәт. Тик шулай да мондагы һава миңа килешмәде, ахрысы. Гел хәлем бетә.

Азат авырып китте. Хастаханәгә кереп яттык. Саша безнең янга йөрми. Галина гына килә. Мин сабырсызланам. Каенсеңлем алып килгән күчтәнәчләрне кире җибәрәм:

– Саша килсен!

Бу хәл көн дә кабатлана. Түзмәделәр. Саша килеп, мине ирләрчә туздырып китте. Моннан ары гел шулай булачак икән. Миңа үз урынымны беләсе... Холыксызлануымның сәбәбе дә ачыкланды – икенчегә йөкле икәнмен. Хастаханәдән мин бер уйны күңелемә беркетеп чыктым: китәм!

Кайтышлый почта тартмасына күзем төште. Безнең әйберләр: телевизор, карават ише – төялгән контейнер килгәнлеккә язу. Мин бу кәгазьне беркемгә дә күрсәтмәдем. Тимер юл станциясенә киттем. Яшь бала күтәргән яшь хатынның хәле кызганыч күренгәндер инде.

– Акчам юк контейнерны түләп алырга. Үзем дә китәм әле мин, – дип, вокзал хуҗаларына ялварам. Ишетмиләр дә...

Бәхетемә, погонлы егет очрады. «Нинди таныш кеше соң бу?» – дип торам. Ә ул ерактан ук елмаеп килә:

– Бу юлы өлгердемме? Мондый челтерәп көлгән, юк ла елаган тавышны кайдадыр ишеткән идем бит инде, – дип уйлыйм. – Нинди җилләр ташлады сине безнең тауларга, Гөлем – Миңлегөл? Улыңмы? Нинди җил ташлаганын

аңлыйм инде хәзер, – диде униформа кигән чибәр егет. – Соңлаганмын икән. Минем язмыш шундый инде: әле дулкын, әле берәр батыр егет арага керә. Тәки өйләнә алмый калам инде.

Инал икән бит! Бу балкар егете турында бая сүз башлап караган идем бит. Әллә өлгермәдемме әле? Инал минем хәлемне тиз аңлап алды:

– И-и Миңлегөл, ханым булгансың икән лә! Сине Усалкалада очратырмын дип уйлаганым да юк иде. Теге вакытны тау сукмакларыннан бергә атлаганда ук, күңелем синдә калган иде. Тагын да юллар кисешәсен белгән булсаммы, алып кына кала идем үзеңне. Чулман кызы илен сагыныр дип уйлап батыраймаган идем. Ялгышканмын. Батыраясы булган икән. Саф күңелле кызыкайны чит-ят җирдә адаштыру ярамас, дип тә тыелып калдым. Минсез дә адаштыручы табылган икән. Менә сиңа серемне ачтым да бетердем. Син һаман чибәр икәнсең. Ә мин һаман шул – коткаручы. Тик хәзер инде туристлар юлында йөрмим. Минем сукмаклар хәтәррәк. Ә сиңа булыша алам мин. Боер гына!

– Инал, Инал! Әллә шаярып сөйләшәсең, әллә чынлап. Әмма өстенә бастың. Сагынам мин туган илемне. Шуңа күрә кайтып китү уе белән йөрим. Сезнең илдә берәүгә чыккан идем кияүгә... Ирем кала. Син дә үз туфрагыңда түгел бугай. Син дә илеңә кайт, Инал!

– Миңлегөл, Гөлем-ханым, беләсең бит инде. Минем илем – бөтен Кавказ! Мин гомерем азагына кадәр шушы тау араларында йөрермен инде. Теге вакытта булса, синең бер ым кагуың җитә иде. Белешеп, югалтышмыйча яшик. Минем язмышыма берәр төрле ачыклык керсә, бәлки әле... Мин синең коткаручың булып кала бирәм...

Инал җөмләсен төгәлләп тормады. Бу сөйләшүнең бик җитди сөйләшү була алуын уйлап, икебез дә сүзне өздек. Вакыты да, урыны да хәзер түгел.

«Адрес дөрес язылмаган» дигән сылтау белән контейнер Чаллыга кайтып китте. Әлбәттә инде, ГРУ офицеры Инал Адылов ярдәме белән. Кулыма визиткасын тоттырды: « Кирәк була калсам...» Визитканы сакладым. Инал Адылов бу юлы ир хатынының яңагына иренен тидермәде.

***

– Сиңа юллык акчабыз юк, – диделәр өйдә.

Түткәйгә телеграмма суктым. Бер атнадан юлга җыендым. Моңа кадәр Кавказ ир-аты кебек кыланып йөргән Сашам мин чыгып киткәндә сикереп торды!

– Гаиләм кайда – мин шунда!

Бусы да таулар кануны иде. Анда гаиләгә мөнәсәбәт җитди. Шаярмыйлар.

Юлда тату кайттык. Тату гына яшәп киттек. Үз фатирыбыз булды. Икенче улыбызга исемне мин – Халит, Саша Алеша дип куштык. Ике бала бага-бага диплом алдым. Җәмәгать эшләрендә яратып катнаштым. Бездән дә бәхетле гаилә юк сыман. Минем әткәй белән әнкәйне үзебезгә алып килдек. Өйдә гел Коръән сүзе, Коръән ашы, татар ризыгы. Христианнарның Раштуа, Пасха бәйрәмнәрен уйлаган да юк. Гает коймагын Саша бик ярата, әмма барыбер рус бит. Малайлар рус

фамилияле татарлар. Татар мәктәбендә укып йөриләр. Өйдә сөйләшүебез дә күбрәк татарча.

Хәзер уйлап куям: бичара Саша бик йөдәгәндер. Үз бәйрәмнәрен, үз ризыкларын тансыклагандыр. Пар казанын нык томаласаң шартлый, диләр бит.

– Карале, Миңлегөл, – дип туктатты бер көнне кече улымның тәрбиячесе. – Безнең йортта сезнең берәр кардәшегез торамы соң? Иреңне гел шунда күрәм.

– Әйе шул, кодачабыз бар, – дидем. Сер бирмәдем әле. Гайбәтнең ачысын татыган кеше лә мин.

***

Саша Яңа ел табыныннан юкка чыкты.Тәрәзә пәрдәсен ачып-ябып, йә булмаса, утны сүндереп-яндырып хәбәр бирешәләр икән. Конспираторлар, имеш. Иртән кайтты. Кертмәдем. 13-14 яшьлек ике улын калдырып чыгып китте теге «кодача» янына.

Аерылышкач, судтан соң урам буйлап, икәү җитәкләшеп, елап кайттык. Әтиләренең хыянәтен малайлар авыр кичерде. Халитем сөннәтле минем. Әтисе шуны белми дә калды. Башын-күзен чит хатыннар тәмам әйләндергән моның.

Хатыннар дим, чөнки теге китүдән соң кайтты әле ул. Тик тегермән ташы яларга өйрәнгән эт бизми икән ул. Беркөнне сөеклем, йөзенә хәсрәт көле сибеп, серен ачты: «Минем Иринада кызым үсә. Ул баланы өзелеп яратам мин. Малайларымнан артыграк күрәм. Әгәр син ул баланы кабул итсәң, килеп йөрүен тыймасаң, матур яшәр идек без. Синсез үләм бит мин».

Мескенем, минсез дә үлә, ансыз да тора алмый.

– Сашенька, кит син. Кызыгызны бөтен гаиләдә үстерегез. Миңа кеше баласын такма. Без бит акыллы кешеләр.Тәмсезләшмик. Килеп йөр, – дидем.

И, сөенде ирем, и, сөенде.

– Без барыбер синең белән бергә картаербыз. Иринаны сөймим мин. Бала хакы бит... Кызым үсеп җитүгә без синең белән кабат кавышырбыз, яме!

– Шулай итәрбез, Сашенька. Мин дә сине бик яратам. Бәхетле генә була күр. Безнең малайлар өчен борчылма. Югалмабыз. – Әнә шулай Мексика сериалы уйнап булаштык без. Әйбәт уйнадык. Сериал инде менә! Саша китәр алдыннан теге сез алырга теләмәгән йөзегем югалып торды. Аннары кинәт кенә табылды үзе. Киеп йөри башладым. Шул йөзек аша Сашама бозым кергән. Иярләшкән хатыны чуваш иде аның. Алар яр сөйдерү, яр биздерү сихерен яхшы белә, диләр бит. Берара ирем борчулары белән дөньядан онытылып тордым. Исем китмәсә дә булган икән. Бозыммы, сихерме тигән кеше гаиләсенә барыбер кире кайтмый икән ул. Кайтса да, үзе гомерле булмый икән. Шулай булып чыкты да. Чуваш хатыны минем иремнән ике кыз тапты. Ә мин ике улымны ятимлекне тоймаслык итеп тәрбияләргә тырыштым. Алар өчен кызыклы әни булдым. Акча таптым. Мул яшәттем. Улларымны спорт, сәяхәтләр белән мавыктырдым. Машина

алдым, рульгә утырдым. Теге тау юлларын бер елны машинада уздык. Алай иткәндә, күбрәк күрәсең икән. Кызыклы урыннарда озаккарак тукталасың.

Язмыш миңа әле сериалның хәтәррәген дә әзерләгән булып чыкты.

Малайлар җәйге каникулларын Грозныйдагы әби-бабайда үткәрә торганнар иде. Мин дә бара идем. Шәһәрнең, шәһәр тирәсендәге гейзерларның тәнгә сихәте бик күп. Альп болыннарының гүзәллеген дә ачтым, чишмәләреннән бәреп чыккан шифалы суларын да яраттым. Ул сәяхәтләрдә кайвакыт Саша да безгә кушыла торган иде. Андагы туган-тумача безне аерылган дип тә белмәде. Улларым чатнатып, чечен телендә сөйләшәләр иде. Мин моны да казаныш итеп санадым. Телләр белгән саен байлыгың артыр, диләр бит. Минекеләр татарча, русча, чеченча белүләре белән үзләре дә бик мактана торганнар иде.

Тагын берничә елдан мин бу тауларга кабат килермен, елый-елый, ерактагы карлы кыяларга карап ялварырмын дип уйлаган идеммени?

Сәяхәтемнең иң аяусызы Грозныйга булган икән. Әйдә, үткәннәргә кайтып киләбез. Алайса син минем хикәятемнең җеп очын буташтыргалап куя торгансыңдыр.

***

Таулар иленә мин тәүге тапкыр Рәшит белән арабыз бозылгач, онытылып алу өчен дип кузгалган идем. Ул вакытта егерме яшьлек кызга тулай торак төрмә кебек тоела башлаган иде. Рәнҗетелгән күңел юаныч эзләде, ниндидер бер үзгә ямь тансыклады. Мин югалган мәхәббәтем урынын ни белән булса да тутырырга тиеш идем. Әле бит Саша белән якынаймаган чагым. Авылга – әниләр янына да кайтып күренәсе килми. Минем изге җаннарым сандугачларының канаты каерылганын бик тиз сизеп алырлар иде. Нигә дип әле аларның сак бәхетен өркетеп йөрим, ди. Кызлары бәхетле, шат, тамагы тук, өсте бөтен дип сөенеп яши бирсеннәр.

Иптәш дип йөргәннәрем, моның сөмсере коелган, ахрысы, дип, сөенергә ашыкмый торсалар да ярый. Бәлки сөенмәсләр дә иде. Минем бит боеккан, усалланган чагым. Шуңа күрәдер бер гөнаһсыз кешеләргә карата да күңелемдә тигәнәкләр йөртәм бугай. Каядыр югалып торырга кирәк. Минем белән еш кына шулай була: берәр нәрсә хакында өзми-куймый уйлана башласам, көтмәгән җирдән уйлаганым алдыма килә.

Профкомга чакырып алдылар. Балаларның җәйге каникуллары алдыннан чакыргач, шунда ук болар мине берәр лагерьга вожатый итеп җибәрмәкчеләрдер инде дип уйладым. Алай түгел икән, киресенчә, үземне ял иттермәкчеләр: «Бик әйбәт юллама бар Төньяк Кавказга. Яшьләр өчен үтергән инде. «42 нче маршрут» буйлап сәяхәт. Алдагы елларда бездән баручылар булды. Бик канәгать кайттылыр. Менә юлламага язылганнар белән танышып кара әле».

Таныштым. Рюкзаклар аскан туристларның, тау сыртлары аша үтә торган маршруты, Төньяк Осетиянең башкаласы Орджоникидзедан башланып, Аджария башкаласы Батумига барып чыга икән. Юлның сынаулары байтак буласы, юл азагында Кара диңгез көтә!

– Романтика бит, әйеме, Машенька! – дип, минем өчен куанудан кулларын чәбәкләп куйды профком кызы.

– Тагын да теләүчеләр бармы соң?

– Бар! Нишләп булмасын. Июнь аенда ял итү, гомумән, сирәкләр өлешенә тия торган бәхет инде ул безнең цехта. Ярты еллык планны куып тота торган чор бит. Конвейерлардан ут-ялкын бөркелә торган көннәр. Ә без менә сине җибәрәбез. Ел буе актив булганың өчен бүләклибез дип сана.

– Рюкзак асып йөреп караганым юк иде әле.

– Анысына исең китмәсен. Юлламада гына язылган ул рюкзаклар. Әйбереңне чемоданга тутыр. Анда ике пункт арасындагы күчештә машиналар туристларны көтеп кенә торалар икән. Күтәренеп йөрисең дә булмас. Сәяхәт итүчеләрнең күбесе хәзер хатын-кызлар бит. Ир-ат курорт-санаторий ишеләрне яратарак төшә. Ә без – хатын-кызлар күп белергә, күпне күрергә телибез. Бу дөрес тә. Кешенең утта янмый, суда батмый торган иң зур байлыгы – хатирәләре, туплаган тәҗрибәсе, белеме түгелмени? Бар, Машенька. Ике дә уйлама, – дип, сүзгә профком анасы булып беткән Мария Алексеевна да кушылды.

Очтым мин Орджоникидзега. Тик очкычым Минераль Сулар һава аланына килеп төште. Ерак ара түгел, диделәр. Тик мин бу араны ике көнгә суздым. Мин түгел инде. Һава юллары конторасы. Аэропорт кабул итми дигән сәбәпкә һава торышы өстәлде. Очкычлар очмаса ни! Аның каравы, автобус алты сәгатьтә илтеп җиткерә икән. Җиткерде анысы. Тик Орджоникидзеда (хәзерге Владикавказ) төн уртасы иде инде. Куе кара төнгә чумган ят бер кала өчен мин чып-чын Казан ятиме идем. Юлламама карыйм. Иртәнге алтыда минем маршрутым Орджоникидзедагы ике көнлек экскурсияне тәмамлап, Алагир дигән турбаза тарафына чыгып китә. Мин – көтүдән калган сарык бәтие, тау араларындагы төркемемне ничекләр эзләп табармын соң? Димәк, миңа хәзер таң атканын көтеп утырырга ярамый. «42 нче маршрут»ның койрыгына эләгеп калырга, ничек тә өлгерергә кирәк. Бер белмәгән җирдә! Ят кавем арасында! Кемгә сүз кушып карыйм?

Колагыма өзек-өзек татар сүзләре, таныш авазлар чалынып калды. Бер хатын-кыз белән бер егет әңгәмә корып утыралар лабаса! Татар бит болар! Шатланып «татарларыма» эндәшәм:

– Юк, без татарлар түгел, балкарлар...

– Татарча сөйләштегез бит.

– Үз телебез шул безнең.

Хәзер инде алар мине сораштыра: кем мин? Кайдан килдем? Кая барам? Хәлемне аңлатырга тырыштым. Аңладылар. Озын буйлы, кара бөдрә чәчле, куе зәңгәр күзле егет яныма ук күчеп утырды. «Кара төндә яшь кызны адаштырырга ярамас. Мин сине шәһәрдәге турбазага илтеп куярмын. Төркемең чыгып китәргә вакыт бар әле. Көтүеңә килеп кушылгач, барысы да җайланыр», – диде егет.

Аның машинасына чыгып утырмый чарам булмады. Бүтән ни эшли ала идем соң мин төн уртасында? Бөркү һәм куе караңгылык мине ә дигәнче йотып алыр иде.

– Танышыйк. Минем исемем Инал. Сиңа кем дип эндәшим?

– Урыслар ничек диләр әле: «Хоть горшком называйте, только в печку не сажайте!» – дидем мин, инде шактый кыюланып.

Инал елмаеп куйды. «Без мичкә тыгучылардан түгел, коткаручылардан. Тауларда шундый һөнәр ияләре дә бар, иптәш Горшок!»

– Миңлегөл минем исемем. Урыслар, үзләренә җайлап, Маша диләр. Фамилиям Абдуллина. Алай-болай пешереп ашарга уйласагыз, ярлык шундый минем. Татарстаннан икәнемне әйттем инде.

Инал миңа карап, ягымлы гына елмаеп куйды: «Нацмен нацменга ярдәм итү җаен таба белер. Кардәшем дә икәнсең. Барыбыз да Аспарух хан бабай оныклары лабаса без – болгарлар, балкарлар, татарлар. Бәлки әле тау гизгәндә, тагын да очрашып куярбыз... Иналны эзлим, дисәгез, мине бик тиз таба белерләр».

Маршрутны дәвам иттем. Шактый михнәтле сәяхәт көткән икән мине. Профком кызлары, мөгаен, мине нинди сәфәргә чыгарып җибәргәннәрен белгәннәрдер инде. Чын дөреслекне әйткән булсалар да, китә идем бит инде югыйсә. Ул чагында кулыма чемодан тотмас идем. Рюкзагым бар иде бит минем. Походларга йөрмәгән кеше түгел. Безнең «42 ләр» юл багажларының артыгын, почтага барып, соңгы пунктка озаткан булып чыктылар. Аларга әле биштәрләр дә юнәткәннәр. Мин бер дивана сыман сары чемоданымны әле уң кулыма, әле сулына, әле җилкәмә куя-куя, иптәшләрем белән бер адымда атларга тырышып азапланам. Әле инструктор – чибәр осетин егете, бу илдә мин хуҗа дигәндәй, мут елмаеп, команда биреп кенә тора: «Җырлыйбыз!»

«Мы по Осетии идём,
Всем подарки раздаём!
Кому – сына, кому – дочь,
Чтоб Осетии помочь!»

Үзләреннән көлгәнне төшенмиләрме соң, яшь, чибәр, томана студент, комсомол, спортсмен кызлар дәртләнеп-дәртләнеп җырлыйлар. Чөнки инструктор чибә-ә-р! Һәм ул һәр кызга бик тә вәгъдәле итеп күз кыса, елмая, каш сикертә...

Менә Алагирга җиттек. Эчтәлекле экскурсиядә булдык – осетин шагыйре Коста Хетагуров музей-утарын манзара кылдык. Гаҗәеп архитектура комплексы иде бу. Көнләшеп куйдым: менә ничек зурларга кирәк кадерле затларыңны! Инде пикник ясап аласы икәнбез. Зур түгәрәк ясап утырыштык. Утызлап кеше җыелганбыз икән илнең төрле тарафларыннан. Болар инде үзара танышып өлгергәннәр. Дуслашканнар. Дуслары белән үк килгәннәре дә бар. Ир-ат халкыннан дүртәү генә. Бу вак-төяк арифметика соңыннан үзен сиздерер әле.

Менә түгәрәк буйлап әйләнеп килә торган зур алюмин кружка миңа да килеп җитте. Мин аны ниндидер символик эчемлек салынган гөнаһсыз бер «сәяхәтче» чәркә дип торам. Ә ул чәркә, кружка инде, чыннан да үтә символик булып чыкты. Литрлы кружка эчендәге самогон кояш нурларында ымсындыргыч ялтырап тирбәлә. Мин бу «символиканы» кул аркам белән читкә этәрәм. Инструкторның күзендә шайтан балалары биешеп ала.

– Безнең йоланы хөрмәт итмәүме бу, Маша! – Исememне белеп алган. Димәк, мин аның яшерен исемлегенә кергәнмен.

– Юк, бик тә хөрмәт итәм мин тау егетләрен. Тик мине ирем бик каты кисәтеп озатты. Үземне сакларга кушты. Йөкле бит мин! – Аклан күтәрелеп көлде:

– Безгә күбрәк тияр. Саклыйк бәбине! Ирең батыр икән синең. Таулар аша сәяхәткә җибәрергә курыкмаган!!!

– Разговорчики! Тау егетләре ана хакын хаклый беләләр! Машага бәйләнәсе түгел!

Уф Аллам! Бу сәяхәттән исән-сау кайтсам, беркайчан да үз баламны шикле сәфәрләргә аяк та атлатмас идем.

Төнне палаткаларда кунасы икәнбез. Бу төн программага туризм күнекмәләре алу дигән пункт белән теркәлгән. Учак яктык. Боткалар пешердек. Утын әзерләү теге дүрт ир-атка, көндезге кружкадан соң, бик авырга туры килде. Чача дигән самогон егетләрнең беләк егәрен нык кына йомшаткан иде булса кирәк.

Йокы капчыкларын киеп, палаткаларга кереп аудык кына, палатка тирәсенә сәер-сәер ир-атлар җыела башлады. Таулардан төшкән көтүчеләр икән болар. «Караимнар», – диде инструктор. Имеш, булачак хәлләр өчен җаваплылык осетиннар өстендә түгел.

Кызларның бер-икесе таң атканда гына кайтты. Кәефсез түгел иде үзләре. Димәк, караим егетләре сары чәчле кызларны назлый беләләр. Һәр «яңа маршрут» килү белән репертуар да үзгәреп тора боларга. Тау арасында зарланырга профком юк. Осетин инструктор да өлешсез калмый торгандыр. Хәер, инструктор егет үзе дә бер чибәребез тозагына капты. Инде безне икенче алмашына тапшырганның соңында да Батумига кадәр күзгә чалынып йөрде әле ул. Көнләшә-көнләшә озата барды Олесяны. Һәр шөгыльнең осталары табыла аның. Олеся йөрәк яндыра белүчеләрдән иде.

Җылы диңгезгә таба юлда маҗаралар чамасыз мул булды. Болытлардан да өстәрәк урнашкан Кармадон ике катлы «тау алачыгында» («Горная хижина» дип теркәлгән пункт иде ул) үткәргән төн онытырлыкмы? Кызыгы, хәтәре чиратлашып кына торды. Көн яктысында болытларның синең аша йөзеп үтеп, туган якка таба гизүләрен кул болгап озатып каласың. Төнлә шул ук болытлар сине салкын кара юрган кебек төреп ала. Йомышың белән чыгып керим әле дип, бусагадан ары атлавың була, мизгел эчендә упкын-төн йота. Ялгыз йөрергә ярамый монда. Йөрмибез дә. Ятар алдыннан чыгып керми дә булмый бит инде. Чыкмый хәлең юк. Төнлә өч кат тире юрган ябынып ятканның соңында кузгалырга азаплану да файдасыз.

Барыбер йоклап китеп булмый. Салкын! Көндезләрен эссе. Менә шунда физика законнарын «үз җисемеңдә» тоя башлыйсың да инде. Атмосфера катламы адәм балаларын салкыннан да, эсседән дә саклаучы могҗизаи юрган икән ләбаса. Тауларда кислород микъдары сирәкләнә, ягъни һава тыгызлыгы нык кими – табигый юрган «юкара».

Аның каравы, төнне туңып уздырганнан соң кызган ташка утырып кызыну бер ләззәт икән ул. Тик ул ташка синнән алда берәр елан уралып урнашкан булуы бик тә ихтимал. Күренеп ятса, бер хәл. Еланның үз мәкере

бит аның. Син кызган ташка артыңны терәгәч кенә: «Монда без дә бар әле», – дигәндәй, таш ярыгыннан шуышып килеп чыкса... Туган ягыңдагы кебек зыянсыз елан булмас ул. Чактымы – үтерә! Һәрдаим уяу булу зарур тауларда. Беркөнне мин юләр, бүтәннәрдән алда торып, тау елгасы ярына басып юынып алмакчы идем. Ык яры түгел бу сиңа! Аздан гына ташкынга агып китми калдым. Алдавыч ярда җиңелчә хәрәкәт сизеп алуга артка таба сикердем. Басып торган ташым убылды да, бөтерелеп-бөтерелеп, ташкын уртасына кереп тә китте. Елгалар бик ашкын табигатьле монда. Икенче юлы, исем китеп, тарлавыкны урталай ярып, түбән таба ургылып төшеп килгән ташкынга карадым да каттым. Имеш, тау елгасының кодрәтенә сокланып торам. Ә ташкыным чыннан да кодрәтле таш агымы булып чыкты. Гаҗәеп күренеш иде бу.

Безнең турбазалар аша үтә торган сукмагыбызның исеме үк дәһшәтле. Ул башта Хәрби Грузин Юлы булып килде-килде дә, аннары Алагирдан соң Хәрби Осетин Юлына әйләнде. Бу халыкларның кайсы хәрбирәктер? (Белешмәлектән осетиннарның егерме генералы, алтмыш Советлар Союзы Батыры бар дип укыдым. Грузиннарда ничегрәк икән?) Дәһшәт исемдә генә түгел. Мондый да биниһая тау кыялары ышыгыннан барган, түбәндә Ардон елгасы (Котырган елга) кайнап аккан үткелне Юл дип зурлауда ук ниндидер акыл ирешмәслек Хәтәр бар!

Хәтәр нәрсә гел үзенә тартып, ымсындырып тора бит ул. Биеклеге 3100 метрлы Турист пигының берничә чакрымга сузылган боз теленнән чанада – штормовкаларга утырып шуганны онытырлыкмы! Бездә башсызлык җитәрлек ул! Штормовкаңның «тормозына» басып өлгермәсәң, шуган шәпкә тарлавыкка, яхшы дигәндә, тау куышына очып китүең дә бик тиз. Ярый әле мин дуслашып өлгергән Рязань кызлары, өчесе дә Лена исемлеләр, кисәтеп кенә торалар: «Машенька, о малыше подумай! Может он не желает космонавтом стать!» Мин шунда ук аңыма килгәндәй итәм.

Тарлавык! Бу сүз үткән төндә калган куркыныч әкият кебек тагын бер кыйссаны искә төшереп сискәндерә.

Кармадондагы алачыгыбыз да көтүче егетләр өчен оҗмах урыны икән. Караңгы кабуга кемнәрнеңдер ишекне дөпе-дөпе селкеткәннәрен ишеттек. Алачык хуҗасы Мамсур дәдә белән аның хатыны Нигәр, ду килеп, өстәге каттагы ояларыннан ишелеп төштеләр. Дәдәнең кулында башы тимердән коелган резин тәпәч. Абзыйның бәдәне дә, беләкләре дә, типсә, тимер өзәрлек. Ишеккә килгән «кунаклар» моны беләләр булыр. Шуңа күрә башта ипле генә сөйләшмәкчеләр, уртак тел тапмакчылар иде. Әмма утыз кешелек отрядтагы туристларның дүртесе генә җебегрәк ир-атлар икәнен көндез үк абайлаганнар инде болар. Чебешләрне дәдә үзе генә саклап кала алмас дигәннәрдер.

Килүчеләр – бишәү. Мамсур дәдә хатынына ым гына какты. Тегесе бер мизгелдә иренә кыска мылтык сузды:

– Корылган!

– Хатын, син үзең иң әрсезен мушкага ала тор. Өчкә кадәр саныйм. Китә бирегез. Мәскәү кызлары сез этрәк-әләмнәр өчен түгел. Тау егетләрен хур итеп йөрмәгез монда!..

Төнге кунакларның аерата әрсезе Леналарның берсен үзенә тартып китермәкче генә булган иде, Мамсур дәдә, тау барысы кебек, әрсезнең өстенә сикерде. Шул арада уң аягы белән икенче кунакның бөеренә типте. Без дә кызык карарга чыккан идек. Берәүнең йонлач кулы минем билемә үрелде. Мин шәрран ярып кычкырып җибәрдем. Татарча кычкырам икән: «Коткарыгыз!»

Нигәр ханым тәтегә басты бугай. Гөрест иткән аваз тау өстеннән яңгырап үтте. Ә мине инде буркага төреп, каядыр өстерәп тә баралар. Сарык бәрәнен кебек. Аяусыз тибенәм. Кычкырам. Тимер куллар йомшарга уйламый да:

– Красавитса! Не бойся. Джигит тебя нэ обидит. Шашлык угостит. Потом сюда вернёт. Посидим, поболтаем. О Москва расскажешь... – Мин һаман тибенәм. Йонлы кулны тешләп алуга авызым ачылды. Тагын таулар арасын яңгыратып, кычкыра башладым.

– Нэ кричи, да. Скалы обвалятся. Всэ погибнем!

Татарча кычкырам икән: Инал! Инал! – «Чакыр гына, килеп җитәм, мин якында гына булам», – дигән иде бит! И, мин сабый...

– Инал зовёшь, да? – ди йонлы чикмән иясе.

Бетүем шушы икән дип уйларга да өлгермәдем, буркам-нием белән бергә дөбердәп, ташка килеп төштем. Монда гел таш дигән идем бит инде. Упкынга тәгәрәтмәсәләр ярар иде!

– Кардәшем! Каты бәрелмәдеңме? Бу мин – Инал. Синең тавышыңны танып, килеп җиттем. Мамсур дәдәдә кич утырган чак иде. Ул төнгә кунаклар көткәнен сиздергән иде. Без – рейдерлар, тауларда коткару хезмәте командасы егетләре, аларның нинди кунаклар икәнлеген бераз чамалаган идек инде. Тик дәдә үзе генә чыгып киткәч, хәтәр нәрсә юктыр дип, тыныч кына утырып калдык. Чак кына сине урлатмадык бит, Миңлегөл. Гөлем минем! Бу югалтуны да кичерә алмас идем мин. – Нәрсәнедер әйтеп бетермичә сөйләшә егет.

Мин әле һаман калтыранам. Куркудан да, салкыннан да. Өнемме бу, төшемме икәненә дә ышана алмыйм. Әкияттә генә бит ул Дию пәрие урлаган патша кызы сөрән салуга коткаручы пәһлевән егет килеп җитә! «Инал! Чыннан да синме соң бу? Мин исән калдыммыни? Ник күренми торган идең соң моңынчы ? Бетә идем бит!»

– Йә тынычлан инде, кардәшем. Бетми идең. Якында гына идем, дидем бит инде. Буркага төренебрәк, миңа сыеныбрак утырсаңчы. Курыкма. Әйттем бит инде: мин угры түгел, коткаручы гына. Юлыңда мин очраганга сөенергә кирәк, тиле кардәшем!

Сыенып утырдым. Җылына да башладым. Хәзер үксеп-үксеп елыйм гына инде. Чыңлатып елыйм. Тавышым шундый музыкаль минем. Рәшитне югалтуым өчен елавым тауларга калган икән. Инал аны беләмени? Тик барыбер юатырга тырыша.

– Мин дә елыйммы? Минем дә елыйсым килә. Елый гына алмыйм.

– Ә син нигә елыйсың? Син дә сөйгәнеңне югалттыңмыни? – дим мин, борынымны лышкылдатып.

– Сорама, кардәшем. Ярама тоз салма. Мин сөйгәнемнән дә кадерлерәк нәрсәмне югалттым. Вөҗданымны! Ләйлә эзеннән йөрүем дә шуңа. Шушы

маршрут аша диңгезгә барганда югалттым мин аны. Таулар хәтәр монда, кардәшем. Берүк үзеңне саклый күр!

– Ничек югалттың син аны? Ничек? Миңа һаман үзеңне сакла, диләр. Ничек сакланырга кирәклеген генә өйрәтмиләр.

– Өйрәтермен. «Ярамый!» дигән сүзне ишетә белергә өйрәнергә кирәк, Миңлегөл. Саклану шуннан башлана. Ләйләгә охшагансың син. Тик ул кара чәчле иде. Тау юлыннан тыныч кына барганда, күзе кыяга сырышып үскән эдельвейс чәчәгенә төште кызның. «Өзеп бир дә, өзеп бир!» дип ялына гына. «Ярамый бит ул чәчәкне өзәргә. Саклауга алынган чәчәк бит ул», – дип, чәчәкне яклямакчы булам. Карыша гына Ләйләм: «Син өзмәсәң, үзем менеп өзеп алам», – дип, кыяга үрмәләргә тотынды. Шунда оясыннан тирә-юньне күзәтеп утырган зур бөркет гайрәтле аваз салмасынмы! Мәгъруур таулар тынлык ярата. Өркетте бөркет Ләйләне. Ләйләне генә түгел, тынлыкны да сискәндерде. Кыз сул аягын терәгән таш түбәнгә томырылды. Ярый әле янәшәдәге ташлар аңа иярми калды. Барыбыз да бетә идек. Ни талпынсам да, кызны эләктереп кала алмадым. Атып төшерелгән кош сыман, ал блузкасын җилфердәтеп, тарлавыкка очты. Билемдә саклавыч аркан – пружина керешле лонжа иде. Ике дә уйламый кыз артыннан сикердем. Бик тирән упкын иде ул. Төбеннән ашкынып, юлындагы ташларны чөя-чөя, Ардон елгасы ага! Ләйләнең суга чумып, бөтерелеп киткәнен күреп калдым. Минем лонжам кыскарак булып чыкты, аны очып төшкән җайга чишеп ыргыттым да үзем дә суга чумдым. Бәлки әле кыз яр читендәге кыргый алыча ботакларына тотынып кала алгандыр дип, үз-үземне алдалыйм. Кая ул? Мин үзем ботакларны сыдырып кына үттем. Тотынырсың бар! Башым белән ташка бәрелгәнмен. Үземне дә иптәшләр генә коткарган. Ләйләне атна буе эзләдек. Хәзер инде мин аны ялгызым гына эзлим. Шушы маршрут буйлап елына бишәр тапкыр узам. Бер юлысы талга эленеп калган ал тасма таптым. Шул тасманы саклыйм. Бәлки ул Ләйләнеке дә түгелдер... Вөҗданым газаплый мине. Ник туктатып кала алмадым икән? Ник ул гүзәл чәчәкне үзем генә менеп өзмәдем икән?

– А-а-а-аh! – Йөрәгемне ярган аһылдау авазына мәгъруур таулар кашларын да селкетмәде. Таулар – таш бәгырьле. Андый гына фаҗигаләрне мең кат күргән инде алар. – Бичара Ләйлә!

Гүзәллеге белән шаштырырлык таулар арасында акылдан яздырырлык дәһшәт!

– Таулар таш бәгырьле, дисең. Ә бит кыяларның йөзләре адәмнәр хәсрәтеннән ермачланып беткән. Күзләреннән аккан яшьләре әнә ничек бөтерелеп, дулап ага. Таулар да елый. Шашынып елый. Әле алда сәяхәтегез дәвам итә. Син ташларның йөзләренә игътибарлабрак бак әле. Сабыр бул, кардәшем. Тауларны да елатырлык бу дөньяда синдәй назлы җаннарны сакларга кирәк лә. Бу хикәятемне сөйләп ялгыштым. Уйламаска тырыш. Үтә нәзек күңелле син, Гөлем. Алай эндәшкәнемә ачуланмыйсыңмы? Кальбемә тупланган назны тамчылап кына булса да ирекә чыгарасым килгән мәлем. Яшьле күзләреңнең моңын үземә алыймчы!

Күрешербез әле...

***

Иртәгәсен без кабат тау юлына төшкәндә, Инал киткән иде инде. Минем күзләремдә генә түгел, иреннәремдә дә сәер бер төш кебек, төтен, тоз, наз тәме сеңгән кайнар үбү эленеп калган...

***

Туристлык базаларындагы биналарның диварлары еш кына пыяла була торган иде. Картина дип караганың – соклангыч манзара. Кипарислар, таулары-ниләре белән – әнә шул тәрәзәләргә керә дә утыра. Матур җирләрне күп күргәнем булды. Ләкин Төньяк Кавказның гүзәллектә тиңдәше юк. Кырыслыкта да.

Менә бу төштә, дустым, мин сиңа бөек әдипләрнең Кавказ турында язып калдырган сүзләрен укытасым килә. Мин ул соклану сүзләрен блокнотыма күчереп алган идем. Гел үзем белән йөртәм. Мин дә бит синең кебек укытучы идем. Аннары гына журналист булып киттем. Син дә мәктәптән радиога күченгәнсең икән, ә мин – газетага. Халыкка хезмәт итүче каләм әһеле үзе дә киң белемле булырга тиеш. Шулай бит, Гөлсөяр. Син дә минем блокнотымдагы шушы асыл сүзләрне үзеңә күчереп ал әле. Сәяхәтләрдә йөрергә туры килгәндә, төрле викториналар уздыра торган җирләр бар. Мин аларда катнашам. Күп вакыт җиңеп тә чыгам. Татар интеллигентының бәясен күтәрәм үземчә. Язасыңмы?

– Сиңа карышып булмас. Кая, озынмы соң язмаларың? Түгел икән. Иң яхшысы, син әйтеп тор. Мин тиз язам ул. Тагын ни эшебез бар соң әле? Бераз каләм тибрәтеп алыйк.

– Менә тыңла. Әүвәле Чехов сүзләрен китерәм. Әйдә, русчасын теркәп куй: «...пережил я Военно-грузинскую дорогу. Это сплошная поэзия, не дорога, а чудный фантастический рассказ, написанный демоном, влюбленным в Тамару». Шәп бит, ә? Ничек ди бит Чехов: «пережил», диме? Димәк, тәэсирләре бер гомер яшәгәнгә тиңләшерлек. Ә менә Пушкинны тыңлап кара әле син: «Чем дальше углублялись мы в горы, тем уже становилось ущелье. Стесненный Терек с рёвом бросает свои мутные воды через утесы, преграждающие ему путь.Ущелье извивается вдоль его течения. Каменные подошвы гор обточены его волнами. Я шёл пешком и поминутно останавливался, пораженный мрачною прелестью природы». Син инде, дустым, минем маршрутны кабатламый түзә алмассың дип уйлыйм. Бу тиклем көчле хисси атакадан соң. Әле мин сине Лермонтовтан бер өзек белән «кадаклап»та куя алам:

Я видел горные хребты,
Причудливые как мечты...
В снегах, горящих как алмаз,
Седой, незыблемый Кавказ, –

ди, матурлыктан әсәрләнгән шагыйрь. Менә шул «незыблемый» Кавказны ул дәвердә дә үзләре соклана-соклана какшатырга омтылып яшәгәннәр. Элекке заманның әдипләре ярты сүз белән дә тау кешеләрен түбәнсетмәгәннәр югыйсә. Аларның кыюлыгына, әдәбенә, йолаларына ихтирамнары зур

булган. Толстойның «Хаҗи Морат» бәянын укып, таң калганым истә. Ә Лермонтов тудырган образлар – Бэла, Азамат... Үзең дә хәтерлисең булыр.

Менә бит үзем Кавказ юлларын узудан алган тәэсирләрне ничек оста гына синең күңелеңә салып куйдым, әйеме? Ә бит Бөек Ватан сугышы вакытында биниһая таш кыяны дот итеп чокырга да базганнар. Хәзер ул кыяташ «Ермолов ташы» дип йөртелә. Табигать гүзәллеген җимерүдә адәм баласының тиңдәше юк.

Бераз гына, әдәбият укытучылары теле белән әйткәндә, «лирик чигенеш» ясап алдык. Әле бит диңгезгә ерак. Батумига килеп чыкканчы Грузияне кичәсе бар. Ышанасыңмы-юкмы, чемодан күтәреп, Мамисон үткелен кичү сынауның да сынавы булды ул. Минем сары чемодан өч Ленага да җитте. Сорап та тормый гына кулымнан йолкып алалар да китәләр. Чыннан да студентлар, спортсменнар иде алар. Тормыштагыча, тауга менү берни түгел, түбән төшү михнәт. Бигрәк тә өстеңә тропиклар яңгыры койганда, аяк астыңдагы сукмагың кәбестә күчәнедәй чуер ташлар белән түшәлгәндә. Түбәнгә таба аяклар тыелгысыз тайганда, газиз башың «кәбестә күчәне» белән очрашып, ярылу ихтималы зур булганда, таш башлар арасында көлчә-көлчә сыер тизәкләре түшәлеп ятканда... Күрде инде бу томана башлар!

Фрунзеның атлы гаскәре (кайбер чыганакларда Киров дип язалар. Мин үзем Фрунзе тарафдары) кичкән Мамисон үткеленнән үтеп барышыбыз безнең. Мәктәптә укучыларыма сөйләрлек кызык хәлләр (хәзер кызык ул) байтак тупланды инде минем баш багажымда. Завод цехларында йөгереп йөргән чагым иде бит әле. Укытучы да түгел.

Берзаман үзән җиргә, яисә Альп болынлыгына килеп егыласың. Яланаяк бозлы тау елгаларын ерып чыкканың да, тау якасына үрмәләгәндә тезеңнең сеңере өзелеп, гомерлек казалы булачагың да онытыла. Син тагын сихри гүзәллек әсиренә әйләнәсең. Ләкин уяу булырга кирәк. Чөнки уң ягыңнан күккә ашкан, хисарлыклар сыман, тау-кыялар озата бара. Битараф кына озатулары түгел. Менә-менә баш өстеңә ишелеп тә төшәрбез әле дигәндәй, югарыдан түбәнгә иелеп карагандай, дәһшәт белән эленеп торалар алар. Ә сул ягыңда – төпсез упкын. Сукмагың шушы ике хәтәр уртасыннан бара. Менә ни өчен бу юлдан үтәр алдыннан һәр төрле кәгазьләргә кул куйганбыз икән. Янәмәсе, үзебез теләп алган каза!

Ләйлә хакындагы кыйсса башымнан чыкмый... Сакланырга өйрәнәсе бар!

Тау бөркетенең таң җиле кебек үтә сак үбүе күзләремдә, иреннәремдә саф чык кебек эленеп калды да Рәшит күләгәсен, аның әрсез кулларын уйларымнан куды да чыгарды. Мин, ахрысы, мәхәббәтнең чыны ниндилеген белмим икән әле, бары эзлим генә икән. Тау сукмакларыннан мин хәзер дулкын чәчле, зәңгәр күзле Иналны уйлап бара башладым. Аның: «Күрешербез!», – дигән бер сүзе дөньямны кояш кебек балкытып бара сыман.

Күрешсәк иде шул!

Хәтәр колына әйләнмәс өчен инструктор егет җырларга куша. Җырлыйбыз! Бу юлы нинди җыр да ярый. Мин үзебезнең җырны җырлыйм: «Без җиңә алмаган дошман тумаган, Без чыга алмаган юк кара

урман!» Вәт шулай. Үткел сукмагы бик тарайган чакларда автобуслардан төшеп, аркабыз белән кыяга сыенып атлыйбыз. Җырламыйча гына, тын гына. Сулышыңны тирәнрәк итеп алсаң да, тигезлегең югалыр сыман. Хәтәр юлны автобуска утырып үтәсе булганда да җырлыйбыз – батырлык өчен! Чытырдатып, күзләрне дә йомабыз. Аллаһы Тәгалә үзенең оҗмахына туристлык маршрутларында автобуслар йөртүчеләрне чиратсыз үткәрә икән. Чөнки тулы бер автобус халык чын күңелдән Аллаһыга ялвара – савап!

***

Хәтәр юл артта калды кебек. Инде безгә грузин егетләре елмая. Кутаисига кадәр җилдереп кенә, машинада илтәселәр икән. Мин кызларны үгетлим: «Утырмыйк. Көн җылы, кояшлы, иплән кенә тәпилик», – дим. Биек үкчәдән сәяхәткә чыккан студенткаларның утырасылары килә. Котыртучы мин икәнен чамалап, әле генә джентельмен булып кыланган машиналы егетләр безне юлдан кысрыклап, юл буе ташына аударып дигәндәй, выжылдап китеп баралар. «Совет власте юк монда!» – дигән сүзләре сагайта. Бәлки, чыннан да, юктыр.

Сталинның туган авылы Шовига якынлашабыз. Һәр тау сыртыннан елмаеп карап кала мыеклы кеше сурәте. Авылын да күрдек. Инде Батумига!

Зәңгәрлеге белән ымсындырап торган Кара диңгезгә җиттек. Батуми безне җырчы фонтаннары, шау чәчәктәге гортензияләре белән шатланып каршы алды. Тик кызларыбыз гына ангина белән егылдылар. Бозлы тау елгаларын яланаяк кичү, аннары тропик яңгыр астында көне буе тәпиләү нәтиҗәсе инде бу. Диңгез буена ялгызым гына төшеп киттем. Кыя ышыгындагы ярымдага сыман комлыкта кызынучылар бихисап. Тик, нигәдер, берсе дә суга чумарга ашыкмый. Ә мин ашкынам. Дулкыннар куенына атыласым килә. Бер изге җан мине кисәтә: «Диңгездә шторм. Керсәң, чыга алмассың. Дулкыннарның кирегә суырып алып кереп китү гадәте бар. Син бу хакта беләсеңме, кызым?» Бу кешегә мин әле дә йөрәгемдә рәхмәт хисләре саклыйм. Тик үз-үземә ышанычым шул кадәрле зур иде. Ык буенда үскән кыз ла мин! Дулкыннар да әллә ничә баллы түгел. Тәвәккәлләдем. Тукай әкиятендәге сыман, мин суда уйныйм, йөзәм, башым белән суны сөзәм. «Беркадәрле шул рәвешле уйнагач, инде, шаять бер сәгатьсез тирләмәм, дип уйлагач», ярар, чыгыйм инде дип, ярга карап борылгач...

Изге җан дөрес әйткән. Диңгез мине җибәрми. Җибәрергә уйламый да! Дулкынына яткырып, йөгертеп кенә ярга хәтле якын ук китерә дә кабаттан ялый да ала. Ярдагылар минем диңгез белән көрәшкәнемне тыныч кына карап утыра бирәләр. Ә нәрсә, кисәткәннәр иде бит инде бу кызыйны. Тауларда бер егет мине тыңлый белергә кирәк дип тә кисәткән иде әле. Ә мин бәләкәйдән иркә бала. Мин телим булгач, телим! Диңгез мине тиң күрмәдеме соң? Минем иркәлектән хәбәре юкмы шунда? Җибәрми генә. Ярдагылар да каршы килеп, кул сузмый. Ишетмәде, тыңламады бит. Хәзер үзенә карасын. Иң сөймәгән киңәшем ул минем: үзенә карасын!

Башымдагы бу гомеремдә туплаган акыллы киңәшләрне барлый башлыйм. Дулкын белән көрәшкәндә, ягъни өстеңә биек дулкын килгәндә,

дулкын астына чумарга кирәк. Бу булды – бер! Диңгез түренә карап йөзгәндә ярый бу киңәш. Ә бит миңа яр кирәк. Гел карышып кына булмыйдыр. Буйсынып карыйм әле диңгезгә.

Миңа бер генә юл кала: дулкыннан җитезрәк булырга кирәк. Ихтыярымны бер йодрыкка туплыйм. Тирән итеп үпкәмә сулыш алам». «Без җиңә алмаган дошман тумаган!» Иң биек дулкынның ялына утырам да, ул мине ярга китереп сылауга, ялт сикереп торып, тамашачылар тезелеп утырган ярга ыргылам. Сикереп торырга өлгерә алуым ук җиңү иде. Инде спринтер җитезлеге белән алга омтыласы! Бүтән чарам юк! Шулай эшләдем дә. Учларым әчетә. Вак таш – гравий учыма инкрустация ясаган. Авыртуга гына түзәрмен. Иң мөһиме – үземне саклап калдым. Битараф тамашачыларымның аяк астына исән-сау килеп егылдым. Ә дәү дулкын, ак ялларын усал тузгытып, кире шуышты. Ачулы иде ул – корбан ала алмады бит!

– Кардәшем, саклана күр димәдемме мин сиңа! Ишетә белмисең шул син. Син дә... – Минем канлы учларымны үбә-үбә тиргәп торучы кеше, әлбәттә, Инал иде.– Сезнең маршрут килеп җиткәнне ике көн көтәм инде. Сезнекеләр палаталарда «кызынып» яталар. Син юк. Диңгез буена эзләп килдем. Һәм, күрәсең, бик вакытлы килгәнмен. Диңгезгә чума идем, үзең учыма чыгып өлгердең.

– Бу юлы мин үзем... үзем котылдым.

– Үзең, үзең, Гөлем! (Миңлегөл дип әйтү кыен, ахрысы, егеткә) Кардәшем, саклана күр. Мин тагын китеп югалам. Мин сине үзем табармын әле. Ә хәзер ашыгам. Сиңа бәйләнгән теге дулкын кебек, миңа ачуланып калма!

Икенче көнне Яшел Куен турбазасының директоры үзе көн дә диңгезгә башы белән чумып коена торган урында һәлак булган. Теге минем белән уйнаган усал дулкын корбан алу әмәлен тапкан: су төбендәге ташны күчереп куйган. Директор аны белмәгән. Ташлар кешеләр белән, тауларда гына түгел, диңгездә дә үчләшә икән монда. Бу илдә ташлар яшерен корал икән!

***

– И минем сабыр әңгәмәдәшем. Инде сүземнең, сезне әңгәмәдәш итеп сайлап алуымның максатына килеп җиткән идек. Ләкин тукталам. Бүгенгә җитәр. Адресыгызны бирегез. Мин сезгә хат язармын. Серләрне телефонга ышандыра торган заман түгел. Фәкать колактан колакка гына. Хатым килмәсә дә, аптырамагыз. Димәк, тәвәккәллегем җитмәгән дип аңларсыз. Минем поездым китәргә ярты сәгать вакыт калды. Мәскәүгә китеп барышым иде бит. Без очрашырбыз әле. Улымны коткарып калу юлындагы михнәтләремне бүтән бер күрешүдә сөйләрмен.

– Ә Инал белән очраштыгызмы соң?

– Сез һаман Иналны сорыйсыз. Безнең арада дикъкатегезне җәлеп итәрлек берни дә булмый калды шул. Булганын сөйләрмен! Кая битеңнән үбим әле. Йөзекне алмадыгыз инде. Сезгә зыян сала алмас иде ул! Бәлки, син хаклыдыр. Мин аңа барыбер берәр ия табам. Шалтыратырмын. Чаллы ерак ара түгел. Тагын бер очрашырга кирәк безгә. Иң мөһим сүз сөйләнмәде

бит әле. Хәрби сер. Чын-чын әйтәмен! Үткәндә калган булса да, «хәрби сер» булудан туктамаган серем ул минем. Шуны түгәсе бар сезнең сабыр җаныгызга. Күркәм кеше сез!

– Күрешербез! – дидем мин, бу сүзгә эчке мәгънә салып. Шулай вәгъдә бирү рәвеше ошап калды миңа. – Күрешербез!

***

Миңлегөл шалтыратты. Вәгъдә ителгән хатны язарга вакыты булмаган икән.

– Югалттыгызмы мине, Гөлсөяр? Мин үзем дә дөньялардан югалып торгандай булдым. Минем белән гомеренең калган өлешен җитәкләшеп яшәргә җыенган Александр Касаткин көтмәгәндә вафат булып куйды. Йөрәк! Югыйсә чирләшкә түгел иде ул. Яшь хатын бик иркәләп боздымы шунда. Әллә, киресенчә, кадерләп бетермәдеме? Мин хәзер бәхетле булу өметеннән дә мәхрүм. Ярый әле ике улым бар.

– Сез, Миңлегөл, гаҗәп тә бәхетле. Олыгаеп барганда, уң ягында – бер улы, сул ягында икенче улы булган анадан да бәхетле кеше юк.

– Әле нинди уллар диген! Төп серем дә кече улым язмышына бәйле иде бит минем. Тыңлар булсагыз... Киләсе атнада Казанда йомышым бар. Очраша алырбыз микән?

***

– Гөлсөяр!

Бер кочак хризантемалар күтәргән Миңлегөл килеп кергәч, җыйнак бүлмәм хуш-искә тулды. Минем туган көнемне каян белде икән соң бу Мәк Чәчәге? Әйтмәгән идем бугай. Балдак үлчәмен дә әйтмәгән идем. Иллә дә үткен ханым булып чыкты бу! Якут кашлы йөзек алып килгән. Атсыз бармагыма тап-таман. Алтын балдакны салгач, бушап калган бармагыма иптәш булды бу йөзек. Тырнакларымны чия төсенә буяп йөри башлармын әле.

– Рәхмәт яусын сезгә. Мине зурлаган өчен Аллаһыбыз үзегезне зурласын. Бу юлы күз яшьләрегезне ишек артында калдырып кергәнсездер кебек. Гәрчә хәсрәтегез дә бәләкәй түгел.

– Хәсрәтем гомерлек булыр инде ул. Башка парым юк бит. Тик соңгы ике елда кичергән-күргәннәрем мине чыныктырган иде инде. Ай чыныктырды. Әмма җиңеп чыктым. «Чыктык!» дип сөенеп йөри ала торган хәлгә кердем инде мин. Чәеңне әзерлә. Үлән-фәлән салма. Чын чәй тәмен тоеп эчәсем килә. Безнең авылның йөзьяшәр Майбәдәр карчык кебек итеп. Вакытың булса, мин синең башыңа ике елга сузылган хәвеф-хәтәр тулы маҗараларымны сөйләрмен. Теге очрашуда без яшьлек илендә йөргән идек. Бу юлы, классик язучылар язганча, вакыйгалар «20 ел узгач!» булыр. Сез язмышка ышанасызмы ул?

– Ышанам да, юк та.

– Ә мин ышанам. Ышанганга күрә шул язмыш кортка иләп тә куйды соң мине. Юк, Кортка түгелдер ул! Галиҗәнап патшабикәдер... Шул тиклем дә үзенә буйсындыра белмәс, кодрәтеннән килмәс иде. Ә мин сезгә мәк чәчәге белән бизәлгән чәйнек алып килдем бит әле, йөзеккә өстәп. Төсем

итеп тотарсың. Йөзек дигәннән. Мин ул йөзеккә «Язмыш йөзеге» дигән исем куштым да кече улыма бүләк иттем. Тарихлы йөзек гаиләдә калырга тиеш. Халит аны хатынына бүләк итәр. Теге чакны ул йөзектән баш тартып, дөрес эшләгәнсез. Зирәк хатын шул сез!

– Нәрсә инде сез дә сез. Күптән сингә күчәргә инде безгә! Иллә дә дөрес эшләгәнсең син дә! Чәйнек шәп!

– Мондый гүзәл чәйнек янында рубин кашлы йөзек чүп кенә булып күренә, әйеме?

– Юләр! Әллә чәйнегең дә комплимент яратамы? Чәйнең хасиятен беләләр минем өйдә. Рәнҗетмәм бүләгеңне.

– Чәең каты, сөтең куе, балың татлы булса, егәрләнеп китә буыннар, ди торган иде минем әни. Ул гел шулай шагыйранә телдә сөйләшергә яратты. Жәл, син аны күрми калдың инде. Әйдә, сүзне чәйдән олы итмик әле. Аннары иркенләп сөйләшербез.

– Бәлки әле тагын елашасы булыр...

– Кара әле моны. Хәзердән үк кулъяулыгын йомарлап тора.

– Их, белмисең шул син...

– Сөйләсәң, белермен.

***

– Минем улларым үсеп җитүгә әфган сугышы тукталды дип сөенеп кенә йөргән чакта чечен сугышы башланып китте. Шөкер, олы улым Азатны комиссовать иттеләр. Күзлек кия ул, балачактан. Югары уку йортына да кереп куйды. Ул арада Ичкериядәге «беренче сугыш» дигәннәре дә тынды. Әмма ул сугыш уллары булган аналар йөрәгенә кара кан булып укмашып калды. Матбугаттагы җан өшеткеч язмалар, бөркәүле япмаларны ачтырып, югалган улларын эзләүче аналар хәсрәте бөтен илне басты. Бу ачы хәсрәт берәүне дә тыныч яшәтмәде. Тыныч заманда, үз илеңдәге сугыш бит бу! Дөреслекне эзләп йөреп тә табып булмый торган чорга кердек. Ә минем икенче улым Халит армия хезмәтенә яраклы дип табылды. Югыйсә ябык кына бала иде инде ул. Яраклы дип табылды да солдат шинеле дә киде. Вагоннарга төяп алып та киттеләр. Ярый әле, Кавказ тарафына түгел, Оренбург ягына дип юанып калдым.

Солдат аналары берләштек. Һәр дислокацияне белеп кенә торабыз. Үткенрәк аналар балаларын йолып калу хәстәренә керešте. Чөнки Оренбургтан яшь солдатларны менә-менә бүтән юнәлештә алып китәселәр дигән хәбәрләр ирешә. «Кая әле аларга, хәрби ант кабул итмәгән килеш. Мылтык тотарга өйрәнәселәре бар», – оптимистлар шулай фараз кыла. Мин язмышына ни язгандыр бит, дип, һаман әле Халитемнең бәхетле йолдызына өмет баглыйм. Язмышның барлыгына ныгытып ышандырып куйган бер вакыйга, дөресрәге фаҗига булды. Өлкән улымның сыйныфташы шулай ук Оренбургта тупланып, гаскәрләргә китәсе иде. Бу егет баруга лазаретка эләккән. Калган яшь солдатларны вагоннарга төяп алып киткәндә, аны онытып калдырганнар. Бу бәгырь, лазареттан чыккач, буш казармаларда исәнгерәп йөргән-йөргән дә өенә кайтып киткән. Беркем тоткарламаган, беркем туктатмаган. Бернинди гаепле гамәл кылмаган бит инде бу.

Уллары үз аягы белән кайтып кергәнгә сөенгән ата-ана Илшатны яшергәннәр. Ул иптәшләре армиядән урап кайтканчы өйдән чыкмыйча яшәгән. Аның белән армиягә киткәннәр кайткач, алар белән күрешергә барган, әлбәттә. Аның шулай «качып калуын» мәзәк күреп көлешкәннәр. Әмма гаепләмәгәннәр. Ул вакытта качып калу хәйләсен күпләр корып карады. Тыныч заманда яу кырында кемнең үләсе килсен?! Әлбәттә, сугыш батырларны да барлады. Ләкин гомер – исән калу иң зур бүләк ләбаса!

Гимнастёркаларын салып аткан иптәшләре су коенганда, Илшат та аяк бармагы белән генә суны, яр читен капшап караган. Шунда, гөнаһ шомлыгына каршы, егетнең аягы таеп киткән. Яр буе булса да, су тирән икән. Егетнең су төбенә киткәнен абайламый калганнар.

– Миңлегөл, улым үлде бит! Суга батып! – дип, Мансура шалтыраткач, аңышмый торам.

– Кайда, Ичкериядәме? – дим.

– Армиядән калган иде бит ул! Өйдә, тик яткан җирдән, – ди әнкәсе. – Язмышның шуклыгына, әллә аяусызлыгына димме, хәйраннар калдым. Сиңа язганы барыбер алдыңа килә икән. Суга батасың булса, ләгәнгә төшеп үләрсең кебегрәк гыйбарә дә бар бит, гөнаһ шомлыгына каршы!

Улым юлдан хат салган: «Без вагонда гына Хәрби ант кабул иттек. Көннәр җылынганнан-җылына бара. Мөгаен, Кавказга якынлашабыздыр».

Солдатлар төялгән поезд артыннан ук без дә – тынгысыз солдат аналары да кузгалдык. Аңынчы ук шактый активлашып алдык әле. Мәгълүмат туплыйбыз. Әнә бит Мордовия, Чувашия, Удмуртия үз балаларын алып калган икән. Нигә Татарстан алып калмый?

– Бирмим улымны сугышка!

– Алып кайтам!

– Мәскәүгә барам!

– Аналар, берләшик! – дип, көне-төне чабышабыз. Депутатларга бәйләнәбез: «Кайда сезнең, Татарстан уллары Татарстанда хезмәт итәргә тиеш, дип язган кануныгыз? Нигә ул көчендә түгел?»

Бар белгән ишекләрне шакыйбыз. Мәскәүдәге Солдат аналары комитеты «акыллы» киңәш бирә: «Барыгыз да алып кайтыгыз!» Әллә без кайтуга ук аларны хәрби трибунал хөкем итәчәген белмибезме? Алай да барып алып кайтучылар булды. Аларга чыннан да акыллы киңәш бирүче депутат табылган: «Кайтуга өегезгә түгел, хәрби комиссариатка барып, хак дөресен сөйләгез. Хәрби прокурорга гариза языгыз. Балагызның бүтән гаскәрләрдә хезмәт итүдән баш тартмавын әйтегез», – дип. Ул киңәшне тыңлаучылар булды. Оттылар.

Ә мин, әлеге дә баягы, язмыш дип, тагын өч ана белән бергә Моздокка киттем. Башта Минеральные Водыга, аннары гына Моздокка. Төрле тарафлардан хезмәткә алынган яшь солдатлар Ханкалада туплана икән. Без дә шунда килдек. БТРларга утырып. Балалар белән күрешү мөмкинлеге юк. Бераздан аларны өйрәтелмәгән килеш сугышка керттеләр. Гаҗизләнеп калдык. Бәбкәсен тилгән алган ана каз хәлендә идек без.

Палаткалардан гына торган зур базада яшибез. Өч минут саен һавага кайдандыр хәрби очкычлар күтәрелә. БТРлар ары-бире йөреп тора. Көне-төне вертолётлар оча. Бөтен җирдә башларына каска кигән солдатлар...

Шом.

Ханкалада бөтен мәгълүмат туплана – исәне дә, һәлак булганы да шунда. Аналар һәр вертолётның каршысына өерелешеп йөгерә. Һәр ана вертолёт ишеге ачылып китәр дә улымның үле гәүдәсен күрермен дип, кан калтырап яши. Улымны янәдән Ханкалага кайтарганнарын белгәч, һәр көнне диярлек сугышка китеп барган балаларны озатышып, башкалар хәсрәтен бүлешеп беркадәр шунда яшәдем дә Чаллыга кайтып киттем.

Минем улым элемтәче иде. Бер көнне аңа да чират җиткән. Кодор тарлавыгында Халитләр ротасы сугышка керде. Улыма нибары 19 яшь кенә иде бит. Сабый гына кебек. Урамда кузна уйнап йөрер генә яшьтә кебек. Ниләр күргәндер ул анда – сөйләмәде. «Улым «чисткаларда» син дә катнаштыңмы?» – дип сораганым булды. «Әни, рәхмәт синә. Мине үз янына эшкә алып, элемтәче һөнәренә өйрәткәнең өчен. «Чистка»ларда мине катнаштырмадылар. Башкалар сөйләвеннән ул эшнең ничек булганын беләм. Бүтән сорама!»

Кораллары – Ватан сугышыннан калган снарядлар икән дип сөйлиләр иде. Моның ише сүзләргә ышанмадым. Шул сугышта улым әсирлеккә эләкте. Менә кайчан башланды ул минем ут йотып яшәр көннәрем. Мин кабаттан таныш юлдан, поезддан-поездга, аннары БТРга утырып, Ханкалага килдем. Ары чаптым, бире чаптым. Йөрүләрем нәтиҗәсез булгач, янәдән Чаллыга кайтып киттем. Инде өйдән торып, командирларны тинтерәтәм. Инал Адылов – хәзер инде ул ГРУ майоры икән – ни булса да, миңа мөрәҗәгать ит, дип үзе әйтте бит. Берәр хәбәр алуга элемтәгә чыгармын, дип тә сүз бирде. Бер төнне үзе шалтыратты:

– Гөлем ханыммы? Син исән-саумы? Безнең эшнең очы чыгар кебек. Көенмә! Улың исән. Безнең эчке элемтә эшли. Тиздән коткарабыз! Килсәң, каян килгәнеңне сөйләп йөрмә. Исемең бүтән булсын.

– Ә син мине... Ә мин сине ничек табармын соң?

– И Гөлем, мин бит разведчик! Мин моннан да синең Чаллыдагы хәлләреңне белеп торам.

Икенче көнне үк Моздокка киттем. Түзеп буламы соң?

Яңа ел каршыларга Халитем янына барам әле дигән уем болай да бар иде. Бу юлы улым Азат белән. Ул да борчыла. Менә шул көннәрдә Иналның туганнарча ихлас кайгыртуын йөрәгем белән тойдым. Әйткәнемчә, ул Разведка идарәсендә эшли. Әсир төшкән солдатларны табуны үзенең бурычы саный. Минем улымны коткарса, ул гына коткарыр да. Коткаручы ла ул! Балаларның язмышы өчен Инал кебек егетләр борчылып торганын белгәч, тынычлангандай булдым.

Коткарышырга тиешле кешеләр тагын да бар иде кебек. Чөнки Халитнең дәдәсенең ике улы каршы якта сугыша икән. Үз туганнарын йолып кала алалардыр бит инде. Ә Халитне чечен телен белүе дә коткарган бугай. Үзе сөйләде:

– Бервакыт мине сакларга куелган чечен егете белән сөйләшеп киттек: «Сине Грозныйда күргәнем бар минем, – ди. – Мин бит бөтен бала чагымны Грозныйда үткәрә идем. Әтием Грозныйныкы бит. Син бит

Солтан. Без синең белән футбол тибә идек. Урам аша гына яшәдек, – дигәч, күзе шар булды. – Дәдәләрем сезнең белән бергә Рәсәйгә каршы сугышып йөри», – дидем. Дуслашып киттек. Ач тотмады. Кыйнатмады. «Чистка»ларда катнашканым булмаганны белгәч, башкалар да миңа яхшы мөнәсәбәттә булды. Минем алда хәрби серләр дә сөйләшенә иде. Ә минем бит теләгем – качу! Иртәгәсен Солтан урынына бүтән сак куймаслар дип ышана ала идеммени мин? Ә алар безнең кебек үк хисле, уйчан егетләр иде. Тауларын, илләрен сөяләр. Берсе шунда сөйләгән иде: «Беләсеңме, татар малай, безнең тау кешеләре эдельвейс чәчәге кебек. Ул бик матур. Аңа бөтен кеше кызыга. Әмма ул шундый хәтәр кыяларда гына үсә. Аны үрелеп өзәм дигән адәми зат кыядан упкынга мәтәлгәнен сизми дә кала. Чеченнар да шулай – безне өзәргә, безнең илебезгә кызыгырга ярамый».

– Ә без – татарлар мәк чәчәге кебек, – дидем. – Без бик нечкә күңелле халык. Әмма безне, мәк чәчәген кебек, булмаган гөнаһларда гаеплиләр. Хәтта ки мәк чәчәген үзен бакчада үстерергә дә ярамый. Татарларның да хокуклары мәк чәчәгенеке кебегрәк.

– И улым, ул мәк чәчәге турында мондый тасвирлауны кайлардан белдең соң син?

– Бала чактан синең җырларың колагыма кереп калды. Чеченнарга бу образ ошады. Алар татарларның аянычлы язмышы хакында бездән ким белмиләр икән. Кырым татарлары белән тигез күрәләр безне. Инал абыйлар безне тапканда, мин безнең разведкага чеченнарның радиотелефоны аша хәбәр бирә алдым. Миңа комачау ясаучы булмады. Үзләренең эзләрен яздыра белделәр. Шуңа күрә мин дә сезнең белән бергә 2000 елны каршылый алдым. Яхшы халык алар!

– Шулай, улым. Яхшы булудан курыкмаска кирәк.

Ә үзем эчтән генә уйлап куйдым. Инал безнең балаларны әсирлектән коткарганчы йокы күрмәде, җылы аш капмады. Ә менә Халитнең Грозныйда туып-үскән үз атасы минем белән бер тапкыр да Ичкериягә бармады. Гәрчә әти-әнисе исәннәр иде әле. Шул иске адреста яшиләр иде. Илен сагынмый иде микәнни? Куркак иде шул ул! Бәлки, хатыны җибәрмәгәндер.

Мин үзем Ичкериягә дүрт тапкыр бардым.

***

Өченче баруым Яңа ел алдыннан булды. Азат белән бардык, дидемме? Яңа 2000 елны ике улым белән каршылый алган бәхетле ана идем мин. 30 декабрь кичендә әсирлектән котылган ротаны алып кайткан вертолёт бортын үбеп йөрдем. Инал елмаеп карап тора:

– Гөлем ханым, техниканы түгел, мине үпсәңче!

Йөгереп килеп, аны да үптем. Яңа елны безнең белән каршыларга чакырдым. Безне Ханкаладагы гарнизон башлыгы кунак йортына урнаштырган иде. Ә мин бәйрәмебез матур буласын юрап, каклаган казын да, чәкчәген дә алып бардым. Моздокта тукталганда, андагы базардан да тәмле ризыклар җыйдым. Азат улым энекәшен сөендерү өчен хәтта җыелма чыршы да алган булып чыкты. Гарнизон башлыгы Инал белән

нык дуслар икән. Менә ни өчен ике гаилә өчен көйләнгән кунак йортын безнең карамакка биргән икән. Шул ук йортның икенче канатында ГРУ майорлары Инал белән Андрей Мәскәүдән килгән таныш офицерлары янында утырырга дип уйлашканнар. Мин аның өчен боегып тормадым. Иң мөһиме – улларым янымда.

Мичкә ягып җибәрдек. Үзем кискән токмач (киптереп алган идем), Моздок тавыгы белән хуш-исле тәмле аш пешердем. Матур итеп табын әзерләдем. Монда электр юк иде – гирляндаларны элеп булмады. Аның каравы, матур фигуралы шәмнәр кабыздык. Шампан ачмадык. Без утлардан да, шартлаулардан да туйган егетләр белән Яңа ел каршыларга җыена идек бит! Гарнизон башлыгының сеңлесе Айтаҗ белән тиз дуслаштык. Ул да – балкар кызы. Дүртәү булдык. Безгә болай да күңелле дип торганда таныш майорларыбыз, ерактан килгән Казан кунакларын нәүмиз итәселәре килмичә, безнең табынга керделәр.

– Гөлем ханым пешергән татар токмачы, тавык шулпасы исе котыртып кына тора бит. Түзмәдек, – дип көлешәләр. Күрәсең, теге табын янында болай да токмачлар куерып җиткәндер. Шыпырт кына ычкынырга җай чыккандыр.

– Өлкән улың белән таныштыр инде, Гөлем ханым. Бездә калырга теләге юкмы аның? – диде Инал, уенын-чынын кушып.

– Элемтәче түгел шул ул. Бүтән һөнәре юк. Аннан хәрби кеше чыкмас, иптәш майор, ә сез Азат белән күптәнге танышлар. Грозный вокзалында моннан егерме ел контейнер озатып торганда, мин кәгазьләр тутырганда, сез күтәреп торган малай шул үзе бит инде.

– Менә ичмасам, сюрприз!

Ике егетнең колактан колакка сөйләсе сүзләре җыелган. Аннары солдат улым командирлары белән бер табында утыруны яхшысынмады да. Шулай итеп, Андрей, Айтаж, Инал, мин – дүртәү генә түгәрәк өстәл ясадык. Татарның каклаган казын бик мактадылар. Кавказ балы белән чәй эчтек. Иң кызыгы, беләсеңме, нәрсә булды, Гөлсөяр? Барыбыз да белеп җырлый торган җырларыбыз уртак икән безнең:

> «Маленькой ёлочке холодно зимой,
> Из леса ёлочку взяли мы домой, –

дип көлешә-көлешә җырладык. Барыбыз да Совет балалары икәнбез ләбаса. Тауларда нәрсә бүлешә торганбыздыр? Барыбызга да тынычлык, исәнлек, матур гомерләр генә кирәк!

Безнең җырлаша башлаганны ишетеп, Азат портатив магнитофонын безнең якка чыгарды: «Әнием, синең җырыңны куям».

– Кая әле, кая әле, нindирәк җыр икән ул?

Әкрен генә «Мәк чәчәге»нең үзәк өзгеч аһәңе яңгырый башлады. Андрей белән Айтаҗ бу көйне вальс әйләнү өчен яраклы дип таптылар. Ә мин магнитофон янына ук килеп басканмын да еракта калган яшьлегемне сагынып, уйланып торам икән. Инал да урыныннан торып, минем янәшәмә килеп баскан:

– Нинди нәфис моң. Нинди тирән хисләр бу җырда. Синең үзең кебек.

Без биемәдек. Балкар егетләре вальс биергә түгел, очышлы биюләргә һәвәсрәктер дип беләм.

Андрей белән Айтаҗ улларым янына чыгып киттеләр. Безгә музыка тыңларга комачауламыйк дигәннәрдер инде.

Йорт тирәли ныклы сак торганын әйтмәгәннәр иде. Саклаганнар икән безне. Егетләр кабаттан кисәттеләр: «Өегезгә кайткач та, кая барганыгызны әйтмәгез. Юлда сораштыручылар булса, исемегез бүтән булсын».

– Бу киңәшләр Азат белән миңа әйтелде.

Халит кала бит әле. «Җибәрә алмыйбыз. Ул – бик кирәкле кадр. Аның кебек шифровальшик әлегә юк бездә. Ул китсә, мөһим мәгълүматларны табу каналы ябыла. Хезмәт вакыты да бетмәгән».

Икенче көнне Азат белән миңа юлга. Бәйрәм арасында гына киленде бит. Хәер, минем күңелдә болай да бәйрәм бит инде. Тиздән улымның дембель вакыты да җитә. Күбенә сабыр иткәнне азына түзәрбез.

Атна буе тау арасында минем улымның гомерен кайгыртып, аны да, иптәшләрен дә әсирлектән азат итү өчен чапкан Инал бик арыган иде. Кобурасын салып куйган да, мин утырган диван читенә авып төшкән. Йоклый. Миңа тулы ышаныч! Үзем урынымнан кузгалып, аның аякларын диванга күтәреп куйдым. Мин әле поездда да йоклармын. Инал бәгырь ял итсен! Шәмне өреп сүндердем дә караңгыда утырам. Майор миңа өченче улым кебек якын. Аны да бәбчекләп йоклатасым, йокысын саклыйсым килә.

Иналның дулкын чәчләрен бармакларым белән аралыйм. Иелеп, ике каш арасыннанан үбеп алам. Бу минем аңа рәхмәтем. Чынлыкта битенең, иягенең, маңгаеның һәрбер ноктасын үбеп чыгар идем. Инал минем хәтеремә кырыслыкны, кыюлыкны, сизгерлекне, назны бергә туплаган бер олы йөрәк булып кереп калачагын әле үк тоям бугай мин.

Йокласын!

Чекист йоклый беләме соң ул? Урам якта кар шыгырдаганы ишетелгәндәй булды. Бу илдә кыш булмый, кар яумый. Алайса нәрсә шыгырдады. Таш! Тагын таш! Гравийдыр инде. Шыгырдауны йоклый дип уйланылган Инал да ишеткән. Сикереп торды. Икенче ишектән Андрей атылып чыкты.

– Назларың өчен рәхмәт, Гөлем! – Сак кына кагылган идем югыйсә – сизгән икән! – Бу миңа озакка җитәр әле, – диде Инал, колагыма пышылдап. – Без киттек. Уяулыкны югалтырга ярамый. Бигрәк тә кичәге кебек кыю операциядән соң. Күрешербез. Сезне поездга илтеп куярлар, Билгесез ханым! – Әйе шул. Мин хәзергә исемсез. Билгесез дә. Инал өчен шулай булып калырмын микән?

– Күрешербез...

– Күрешсәк иде шул!

***

Халитнең дембеленә ике атна калгач, частьтан шалтыраттылар:

– Бүген таңда алты солдат юкка чыккан. Улыгыз, өегезгә кайта калса, шалтыратыгыз!

Кайтмаганнарын беләләр инде. Урлаганнар солдатларны. Соңыннан

алыштырып алу өчен. Көн дә шалтыратып торам. Инал белән дә сөйләшеп алдык:

– Барысы да җайланыр. Без шөгыльләнәбез! – диде ул. – Психолог сыман сөйләшә. – Улың исән. Аңа берни дә булмас! Монда хәзер үк килеп йөрмә. Вакыты җиткәч, хәбәр итәрбез.

Иттеләр дә. Без өйгә кайткач, өч-дүрт көннән төнлә телефон шалтырады: «Гулем Хамзиевна!»

– Улым исәнме?

– Гөлем ханым! Улыңны азат иттек. Халит минем янымда басып тора. Ул хәзер кайтып та китә ала. Ләкин, үтенеп сорыйм, калып торсын әле ул. Аның кебек яхшы элемтәченең кирәк чагы иде. – Ни дияргә дә белмим. Тизрәк ут эченнән йолып аласы да килә. Инал кебек кешенең гозерен санламасам да, ярамый дип тә уйлыйм.

– Башкалар да каламы?

– Юк, алар ризалашмадылар. Ә без солдатны дембельдән соң тоткарлый алмыйбыз. Фәкать ирекле рәвештә генә. Сезнең дә гозерне кире кагу хокукыгыз бар. Тик мин чекист намусы белән ант итеп әйтәм: улыгызның чәч бөртеге дә төшмәс. Саклarбыз!

Ризалаштым. Улым да миңа бу адымым өчен бер тапкыр да үпкә белдермәде.

Ә теге коткару операциясе хакында ОРТ каналыннан тапшыру булган. Чекистлар үзләре күренмәгән. Әмма минем Халитемне сөйләткәннәр. Кызганыч, күрми калдым. Югыйсә бу ике майор, мин улын күрсен әле дип, махсус чыкканнар икән «Вести» тапшыруына. Солдатларны урлатуга юл куйган командирларга суд буласы. Мине шунда чакырдылар.

Бу юлы самолётта очтым. Минем өчен яңа исем белән паспорт әзерләнгән иде. Инал белән дусты – ике майор каршы алдылар. Халит та алар белән иде. Улым белән икебезне кунакханәгә урнаштырдылар. Суд буласы көннәрдә бу ике чекист безне килеп алалар иде. Суд утырышлары төрле шәһәрләрдә узды. Без шул рәвешле бөтен Кавказны карап йөрдек. Пятигорскига да, Эльбруска да бардык. Кавказ буйлап экскурсия булды ул. Бер генә утырыш та Ичкериядә узмады. Өч көн Нальчикта да тордык. Кайдан килгәнне әйтмәскә куштылыр. Шул кадәр кайгырту, кадер күргәнем юк иде. Кавказ кухнясы белән дә нык таныштык. Безне ресторannarда гына ашатып йөрттеләр. Ресторан ресторан инде ул! Аклы-зәңгәрле Эльбрус фонында Инал белән янәшә басып, фотога төшү генә дә миңа гомеремә җитәрлек бәхетле булу тойгысын бирде.

Кыя якасында басып торам үзе. Курку юк. Чөнки мине хәтәрдән сакларга торган учның җылысы сулыш алган саен күлмәгемә кагыла кебек. Минем өчен бәхетнең үзе иде кебек бу халәт. Мине төпчек улымның осталыгы бәрабәренә саклыйлар иде. Мин әле һаман Инал белән минем арадагы җылылык хакында кыеп, сүз әйтергә әзер түгелмен икән, Гөлсөяр.

– Ләкин ул булган бит! Шундый да дәрәҗәле чекистларның, тагын да мөһимрәк бурычларын калдырып, атнага якын сезне көйләп йөрүләре...

Миңлегөл кадерлем, үзең уйлап кара инде. Ирләр бездә хатыннары белән театрга да бармый. Ә бит алар кайдадыр якында гына үзләренә таба төбәлгән «калашлар» барын белә торып, сезне саклап йөргәннәр. Сезнең яңа паспортлар да күпне хәбәр итә. Бу Иналга мин үзем гашыйк булып беттем инде. Шул атнада синең урында мин йөргән булсам иде ул! Чын егет бит, ә?! Кая, Эльбрус фонында төшкән фотогызны мин дә смартфоныма күчерим әле. Чын егетләр күрәсе килгәндә карап-карап алырмын. Син аны барыбер миңа бирмәссең инде. Югыйсә синдә телефоны бар бит аның?

Миңлегөлнең ике бармагы белән маңгаен уып кую гадәте бетмәгән икән әле. Димәк, ни хакындадыр әйтергә тели, ләкин әйтә дә алмый:

– Бар иде телефоны. Беләсең. Суд ярты юлда тукталды. Без улым белән кайтып киттек. Киткәндә дә, самолётка яңа паспортлар китерделәр. Мин тагын бүтән кеше. Өйгә кайткач, кайда булуыбызны әйтмәскә куштылар. Ләкин, ни хикмәттер, бөтен кеше белә иде инде.

– Атна буе аралашканда, бер-берегезне аңлый алу мөмкинлеге чыккандыр бит инде?

– Әйе, күп нәрсәләр хакында сөйләштек. Нальчиктагы өен дә күрсәтте. «Бу юлы чакырмыйм. Икенче судка киләсең бар бит әле. Шунда алып керермен», – диде. Күрәсеңме, ул һәр адымын уйлап ясый торган кеше иде. Соңгы тапкыр мине озатып калганда, ул нигәдер: «Күрешербез», – димәде.– «Хәтерлә мине. Онытма!» – диде. Онытмыйм. Оныта да алмыйм!

Өйләнмәгән иде әле ул, гәрчә бик яшь түгел иде. Миннән ун яшь чамасы өлкәнрәк булгандыр ул. Бәлки, кырыс режимда яшәү аны өлкәнрәк итеп күрсәткәндер. Анда бит таш кыяларның да йөзләрен хәсрәт җыерчыклары баскан. Гел хәтәр арасында йөрү кемне дә картайтыр. Мин атна арасында да һәр күләгәне игътибарлап йөрүдән арыдым. Ә алар көн туган саен утлы табада. Тынычлык тансыклау бар бит әле.

Инал да тансыклаган иде аны. «Тыныч көннәрне якынайту, яшь малайларны үлемнән алып калу өчен үземне аяп тормыйм. Кавказ сугыш полигоны булырга тиеш түгел. Яралышыннан бирле Кавказ яшәү өчен дау мәйданы. Матур булганы өчен, – дигән иде ул. – Минем егетләрне бөркетләр, диләр. Әмма минем, бөркетләр кебек, кыядан гына торып, чечен малайларының рус, татар малайларын кыерлаганнарын карап торасым килми. Шуңа күрә тау араларына барам. Әсирләрне җыям».

Менә аның кыйбласы нинди иде. Шул кешене яратмау мөмкин идеме соң? Гөлсөяр җаным, әллә мине хиссез дияр идеңме? Мин дә Инал йөрәгенә юл эзләп карадым: көмеш йөзек бүләк иттем – беләсең!

– Ә ул сиңа... Кубачы көмешчеләре янына чакырмадымы соң?

– Кая аның вакыты?! Без бит суд утырышлары графигына, географиясенә карап гиздек Кавказны. Алай да ул миннән: «Гөлем, сиңа ни бүләк итә алыр идем икән? – дип сорады. – Татар хатын-кызлары ни ярата?» Көлдем рәхәтләнеп. Имеш, шулай күңелдәге серемне шаянлык пәрдәсе белән яшердем:

– И Инал, татар хатыны эш ярата. Әгәр инде берәүгә күзе төшсә, шул

егетнең күлмәген гел үзем генә юар идем, дип хыяллана татар кызы. – Инал да рәхәтләнеп көлде: «Күлмәгемне юарга хыялланучы булса, мин дә бәхетле булыр идем. Тик безнең махсус киемнәрне махсус службалар кайгырта. Алай да берәр күлмәгемне югалта алам».

– Миңа киелгәне кирәк шул. Яңа булса, дөрес булмый. Татарларда шундый ырым бар. Алайса, егетнең күңеле башкаларга төшүе ихтимал.

Әллә юри, әллә чынлап, Инал бер кыяга менеп төшкәч, тәмам тиргә баткан күлмәген кыя читендәге арканга элеп куйды. Онытып китте. Мин күлмәкне сумкама төреп тыктым. Улым елмаеп карап торды. Ул бик ярата иде Инал абыйсын.

– Шуннан соң нишләттең инде ул хәрбиләр күлмәген? Үзең киеп йөри алмыйсың, улыңа да бирә алмыйсың. Әйдә, миңа бир, әле дә исән булса...

– Син, җаным, әллә чын-чынлап, Иналга төбәп, Амур угы очырырга уйлыйсың инде? Күлмәкне юмадым мин. Шкафыма элеп куйдым. Әле дә юганым юк. Егерме бер ел үтте инде Иналны күрмәгәнгә. Судка бара алмадым мин. Шалтыратып сөйләшеп алдык. Судның икенчесе аның кәефен җибәргән иде. Үз фикерен үткәрә алмаганга үртәлгән бугай иде ул.

– Шуннан бирле хәлен белмәдеңме бүтән?

– Белдем. – Миңлегөл маңгаен угалый башлады. – Инал юк инде. Без синең белән беренче мәртәбә кафеда сөйләшеп утырган көннәрдә – мин вакыйгалар хакында кайта-кайта сөйләгәч, җеп очын югалткансыңдыр, бәлки, – аларның Нальчиктагы офисына зур һөҗүм булган. Күрәсең, минем сине беренче күргәндәге ярсып елауларым таулардагы шул фаҗигане сиземләүдән булгандыр. Интернетка Эльбруста төшкән фотоны куеп: «Белүчеләр бармы?» – дип сорадым. Абыйсы элемтәгә керде. «Инал геройларча һәлак булды. Өйләнә дә алмый калды инде ул. Әтиебез исән әле», – дигән җавап алдым. Тынмый Кавказ.

Мин Иналны яраткан булганмын икән. Мин моны тора-тора аңлыйм. Теге күлмәкне алып китеп, дөрес эшләгәнмен. Ядкарьне шкафтан алып-алып исним. Күлмәктән таулар исе, төтен исе, сугыш исе килә. Һаман җилләми. Һәлак булган хәбәрен белгәч, күлмәкне йөрәгем турына куеп тордым. Сизәм, йөрәк тибешем кабатланып, дөп-дөп тибә башлагандай булды. Әллә исәнме икән ул дип тә уйлыйм. Паспорт алыштыру галәмәтләре дә искә төшә. Бәлки...

– Бәлки, чыннан да исәндер...Үз фотоңны «ВКонтакте» га куеп кара әле син. Кемне эзләвеңне сорамыйча гына.

– Юк инде, исән булса, хәйләсен табар иде. Эзли белә иде бит ул.

– Ә бит абыйсы, өйләнмәгән дә иде дип, сиңа мәгълүмат, димәк ки, өмет биргән. Андагы халыкның байтагы сугыштан соң башка илләргә күчеп яши икән дип тә сөйлиләр. И, без ни беләбез соң? Безнең белгәннәр – шул имеш-мимеш инде. Алдагы гомерең күлмәк кочаклап, күлмәк иснәп кенә үтмәсен иде дә бит.

***

Гомер уза. Улларым үз гаиләләрен кордылар. Бик тату яшибез. Инде Халитнең улы Булат та егет булып килә. Шул малай: «Мин армиягә барам, – дип атлыгып тора. – Минем әтием кебек солдат шулпасы татыйсым килә.

Солдатта булмаган егет егетмени ул, – дип тә җибәрә. Аннары читенсенеп кенә, миңа сәер сораулар да биреп куя: «Дәү әни, иң көчле хис кайсы хис микән ул: сагынумы, нәфрәтме, мәхәббәтме?»

– Башыңа төшкәч, белерсең, улым, – дим. – Мәхәббәт кешеләр белән уйный, кайвакыт адаштыра да. Ул берәүгә гашыйк булган берәүне әллә кайларга алып китә, ялгышлар ясата. Менә синең бабаңның кабере Чаллыда. Югыйсә илендә генә яшәсә, Грозныйда күмелгән булыр иде. Бәлки әле алай кыска гомерле дә булмас иде. Читтә сагынып яшәү гомерне кыскарта бит ул. Димәк, җирсү, яшьләрчә итеп әйткәндә, ностальгия хисе мәхәббәттән көчлерәк булып чыга.

– Дәү әни, ә, дәү әни, синең иң яраткан җырың нинди? Син гел «Мәк чәчәге» дип җырлыйсың, шул җырны яратасыңмыни?

– Мин татар җырларын яратам. Ә «Мәк чәчәге» – минем язмыш җырым ул!

– Язмыш җыры? Аңлат әле, ул ничек була?

– Ничек була, ничек була? Шул җыр белән юләрләнәсең дә әллә кайларга китәсең. Аннары гел дә гел:

> – Безнең ил – сандугач сайрар җир,
> Безнең ил гөл-чәчәк арасы.
> Мин дә бит шул җирнең
> Былбылы, сөекле баласы, –

дип, «Илкәем»не җырлап йөри башлыйсың. Беләсеңме ул җырны?

– Әзрәк кенә беләм.

– Әзрәк кенәдер шул. Хәзер дә бит син «Бисамо мучо» дип акырып йөрисең. Шул җырыңа ияреп, Америкаларга чыгып китә күрмә инде, балам.

Халит безне тыныч кына тыңлап утыра. Бигрәк сизгер күңелле инде ул. Ни уйлап утырганын миңа биргән соравыннан аңлыйм. Мине һаман Иналны оныта алмый дип уйлый ул. Янына да килмәгән үз әтисен түгел, аның өчен җанын бирергә әзер булган майор абыйсын юксына.

– Әнием, Ичкериядә беркайчан да сугыш булмасын, Рәсәй белән бу ил тыныч-тату яшәсен өчен ни эшләргә кирәк икән соң? Югыйсә Кавказ халыклары Рәсәй хакын яклап, байтак кан түккәннәр бит. Кан хакын онытырга ярый микәнни соң? Хәтерлисеңме, тау кыясына уеп ясалган Ана һәйкәлен? Аңа әле Рәсүл Гамзатовның «Торналар» шигырен дә язып куйганнар иде.

– Сугышка җиде улын озатып калган Анага куелган һәйкәлне әйтәсеңдер инде. Ул Ананың җиде улы җиде урыс шәһәрен дошманнан азат иткәндә һәлак булган. Күп мәгънәле, гыйбрәтле мисал бу. Аңлый белгәннәргә.

Беренче соравыңа җавапны өч сугыш күргән Хәмзә бабаң – минем атам бик акыллы итеп бирә белгән булыр иде. «Бер як гафу сорый, икенче як кичерә белгәндә генә, татулык урнаша», – дия иде мәрхүмкәем. Чөнки тарткалашып яшәүнең файдасыз икәнлеген үз башыннан кичергән кеше ул. Хәмзә бабаң борынгыча яшәп өйрәнгән кеше иде. Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан. Ичкериядәге кебек гражданнар

сугышында йөргән. Ватан сугышына ике улы белән бергә киткән. Уллары ятып калган. Үзе, Суслонгерны кичеп тә, исән калган. Ә бит аның күңеле каткан, ул күңелдә Совет властена карата рәнҗеш сакланган булырга да мөмкин иде. Атам колхозга сугыш башланыр алдыннан гына кергән. Атларын, җирен тартып алганга, өйләреннән куып чыгарганга, аягындагы олтанлы итеген салдырып алганга үчләшергә тиеш иде кебек. Әмма Ватан куркыныч хәлдә калгач, ул, аягына чабата киеп булса да, сугышка киткән. «Мал табыла ул, Ватан бер генә була», – ди торган иде Хәмзә бабаң. Сугыштан кайтуына өйдә калган кызы да, хатыны да үлгән була. Ә бабаң тормышын яңадан башлап җибәрергә үзендә көч таба алган. Аңа яңа хатыны Шәмсеходага – минем әнкәемә булган мәхәббәте көч биргән. Әнкәем исә, балаларын җуеп, каңгырып калган иренә 51 яшендә мине табып биргән. Күрәсеңме, һәр кеше үзе өчен кадерле тормыш кыйммәтләрен үзе сайлый.

Белмәссең инде иң көчле хиснең кайсы икәнлеген: мәхәббәтме, Ватанны яратумы, вөҗданмы, гаделлекме, тугрылыкмы – алар берсе-берсеннән аерылгысыз. Кешене язмыш йөртә. Кайвакыт бер гамәлең бөтен тормыш юлыңны билгеләп куя. Ялгышмый яшәргә өйрәнәсе бар ла ул. Ялгышмасаң, үкенечләр дә булмый. Инал абыең «вөҗдан» дигән төшенчәгә табына иде. Татулыкка ирешү юллары хакында да аның белән сөйләшкәнебез булды: «Иленә корал белән кергән баскынны бер генә халык та сөйми», – дигән иде ул бервакыт. Аның белән мин дә килештем. Ялгыз сиңа гына килгән җәберне кичереп була торгандыр ул. Илеңне бетерәм дип килгән дошманга ачу озак сакланадыр.

– Әнием, ачуланмасаң, сиңа бер сорау бирим әле: син Инал абыйны яраткан идеңме?

– Яраткан идем. Ул сине яраткан өчен. Синең хакка гомерен аямаганы өчен. Без аңа бурычлы, улым.



Сирень
Якупова

# КҮҢЕЛ ГАЛӘМЕНДӘ ҺИЧ ТЫНГЫ ЮК...

***

Чакрым белән түгел, вакыт белән
Үлчәнәләр хәзер аралар.
Бер сәгатьтән кайтып җитәм, диеп,
Йөз чакрымнан хәбәр салалар.

Бер белән йөз – җир белән күк иде
Кайчан гына әле, кайчан гына.
Атлар корыч, кошлар көмеш бүген,
Тизлекләрдән мәгәр аң чагыла.

Бер белән йөз шундый якын инде...
Ераклаша күздән күзләр генә.
Кәрәз-чытырманда адашкандай,
Колакларны ярып бәргәләнә
Күзгә карап әйтер сүзләр генә...
Һәм... йөрәккә җитми өзеләләр,
Тезеләләр кыска гудок булып...
Тизлекләрдән җан ялыккан заман,
Кошлар – көмеш, юллар – асфальт,
Атлар – корыч...

***

Күңел галәмендә һич тынгы юк –
Кабына да сүнә йолдыз-уйлар.
Теләк теләп өлгерәлми йөрәк,
Кабына да сүнә... елгыр еллар.

Ә яшь чакта, һай, өлгерә идек!
Әллә күпме алдан күрә идек,
Сөю көтә анда, бәхет, диеп,
Йолдыз тамган якка йөгерә идек...

Сирень ЯКУПОВА (1961) – *шагыйрә, прозаик; Һ.Такташ, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Йолдызлы уйлар», «Яшәү сере», «Кар юлы» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Күңел галәмендә һич җылы юк,
Шул ук кояш ласа… Без – тирәли.
Йөрәктәдер хикмәт, йөрәктәдер,
Җылы алып җанга өлгерәлми...

## Ачыш

Очканда кош астан өскә, өстән аска
җилпегәндәй тоела канатын.

Ә ул исә, сигезлеләр ясап,
талпына ла икән, канәтем!

Сигезле – чиксезлек тамгасы,
азагы юк, башы...
Кош очышы – мәңгелеккә ашу?..

## Кайтаваз

Кар шыгырдый...
Җанга рәхәт аваз...
Кайтаваз
Балачак кышыннан –
«Кистекле», чаналы,
Ятимлек хисеннән
Күңеле яралы...
Юк, булмас, дисеңме,
Мамык шәл читеннән
Шук карый күзләре?!
Шук карый күзләре…
Тик әнә пәлтәсе
Төс салган, таушалган,
Ямаулы тезләре...

Кар шыгырдый...
Җанга тансык аваз...
Кайтаваз
Кышыннан яшьлекнең –
Кар кызы шикелле
Алсу йөз, пар толым,
Кыскасы, бәхетле!
Тик... сагыш күзендә,
Ник сагыш күзендә?!
Дертләгән керфектән
Яшь-бөртек өзелә...

Кар шыгырдый...
Җанга якын аваз...
Кайтаваз
Кышлардан...
Тукталам, тын калам.
Кар... һаман шыгырдый.
Колакта?! Йөрәктә?!
Буталам...

## Чаллы урамында

**1**

Туктап-туктап сайрый бер кош,
Әллә моңы бетәме?
Дөнья зары-газабыннан
Әллә аңы китәме?

Сулыш-тыны кысыламы
Таш йортлар арасында?
Җырын бүлеп, яшь коямы
Җанының ярасына?..

**2**

Без ярар...
Кошлар нишли икән бу шәһәрдә?!
Башка урын тапмыйлармы яшәргә?!
Алданамы алар
Таш йортларны таш кыя, дип,
Кыркылган куакларны – тугайга,
«Мамык яшь» койган тупылларны
Урманга тиң күреп?
Сайрыйлар да бит әле, ичмаса,
Өзеп-өзеп!

Ярар без... Гомер иттек түзеп.
Төшкән җирдә таш булдык!
Дан алды кемдер,
Шул «ташлардан» шәһәр төзеп...

Кошларга ник түзәргә?
Канатлары бар ич!
Дүрт яклары – кыйбла,
Бар җиһан – оя...
Тоела...

Ярый без...
Ярыйбыз
Туганга, дусларга... дошманга...
Әллә соң кошлар да,
Ихлас ышанып
«Кошлар – безнең дуслар!»га,
Яшиләрме ярап
Безгә?..
Күңелебезне юатып,
Гомеребезне озайтып?
Мөгаен, шулайдыр...

**3**

Туктап-туктап сайрый бер кош,
Телә лә бәгырьләрне.
Ишетелә йөрәгенең
Асфальтка бәрелгәне...

***

Урам белән тыкрык кисешкән чат,
Әни язда суган җилгәрә...
И сызгыра сайрар коштай сузып!
Аптырагач,
Кычкырып бер җырлап җибәрә.

Җил чакыра шулай. Миңа кызык,
Ерганаклар ерам, көлә-көлә...

(Күпме еллар,
Яз килдеме, хәтер-гөрләвектә
Суган кабыклары бөтерелә...)


Җил чакыра әни... Белми аның
Урлап китәчәген хисле кызын...
Кичерденме икән, әни-бәгърем,
Җил һәм мине – ике тыңлаусызны?!

Җил чакыра әни... Юк ла, үзем
Сызгырам да моңсу җырым сузам:
Дала үзәгендә – җилле кала...
Һай, гомерләр җилдәй генә узган...

## Иртән

Йортсыз кеше артыннан хуҗасыз эт «сөйрәлә»...
Күр әле, күр, бертөслеләр!
Башлары иелгән, юынмаган, кырынмаган...
(Эткәме кырынырга, җүләр!) Төкселәр...
Кеше...
Кулында зур янчык. Туп-тулы. Ни белән?
Кем белгән... Белергә язмасын...
Эт...
Аксый. Артык ябык...
Ә бит зур янчык туп-тулы... Ни белән?
Этем дә белми... Белмәсен...
Калмый иярсен... Өмете үлмәсен...
Үзе дә...

Йортлы кеше алдыннан хуҗалы эт йөгерә...
Күр әле, күр, кешесе, абына-сөртенә,
Артыннан чак өлгерә!..
Ычкындыр бавыннан!
Юк!
Кеше... Телефоннан күзен алмый.
Эт... Ирек сулап туялмый.
Икесе дә кызганыч... Үзем дә...
Нигә?
Азапланам зерә,
«Ятмый» заман шигырьгә...



Солтан
Шәмси

# ӘШРӘФ БАБА ХӨҖРӘСЕНДӘ

хикәя

Сафагәрәйне Казанга озаткач, Сөембикә беркадәр тынычланып калды. Күпмедер вакыт Сафагәрәе әле нугай гаскәре белән юлда булачак. Озын юлның нинди икәнен Сөембикә яхшы белә. Сафагәрәй ялгыз түгел, шуңа күрә ире өчен аның күңеле тыныч иде. Ә менә Казанга барып җиткәч, нәрсә буласын ул күз алдына да китерә алмый. Әмма күңеле белән сизенә, Сафагәрәе тәхетен һичшиксез кайтарып алачак, монысына ул шикләнми иде.

Көннәр бер-бер артлы үтә торды, тормыш үз эзенә төште. Сафагәрәйнең Сарайчыкка алып кайткан хатыннарыннан Фатыйма күбрәк үз туганнарында була, Нурҗиһан белән Сәгадәтбану да, Йосыф мирза йортындагы тәртипкә җайлашып, кул кушырып утырмыйлар, үзләренә эш-шөгыль табалар. Хатын-кызга өйдә эш беткәнмени.

Сөембикә исә уйлаган ниятен тормышка ашырырга булды. Бер көнне ул, күчтәнәчләр алып, Әшрәф Баба янына чыгып китте. Үзенең Сарайчыкта күпме торасын белмәгәнгә, укымышлы карт белән ешрак аралашып каласы килде. Аннан сорашасы нәрсәләре дә байтак иде.

Әшрәф Баба Сарайчык уртасындагы мәчеттән ерак түгел генә бер кечерәк өйдә тора иде. Карчыгы үлгән дип ишетте Сөембикә, ялгызы гына яши икән. Соңгы вакытта кеше белән күп аралашмый, фани дөнья мәшәкатьләреннән ераграк торырга тырыша. Берәр үтенеч белән килсәләр, һәрвакыт ярдәм итә. Чакырган җиргә бара, үзе теләсә кая кысылып йөрми. Бер дәрвиш кебек япа-ялгызы яши, гомере буе Бохарадан, Сәмәркандтан, ислам дөньясының башка шәһәрләреннән алып кайткан, сәүдәгәрләрдән сатып алган китапларына чумып, намазлыгыннан аерылмыйча көн күрә, дип сөйлиләр иде нугай тормышы өчен шактый сәер бу карт турында.

Таныш урамнардан барганда, Сөембикәнең күңелендә әле бер, әле икенче хатирә калкып чыга башлады. Шушы урамнарда үткән балачагы,

Солтан ШӘМСИ (1946) – *прозаик, тәрҗемәче; Ф.Хөсни, А.Алиш исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Еллар эзе», «Идел Болгарстаны», «Низаглы йортта», «Күк капусы ачылса» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

үсмер еллары исенә төште. Балачакта зур булып тоелган кала аның өчен хәзер кечерәеп калган, шуңа күрә ул үзен сәер хис итә иде. Казанда үткән еллар аны бик нык үзгәрткән, ул хәзер бар нәрсәгә бөтенләй икенче күз белән карый, бу хәл аны хәтта гаҗәпләндерә дә иде.

Сөембикә Әшрәф Баба өенә җиткәч, туктап калды. Беравык кыюсызланып торганнан соң, аның бусагасына килде. Ишеге суык кермәсен өчен тире белән тышланган. Сөембикә үзенең дулкынлануын сизеп алды. Бу ишекне ничек ачып керергә? Ул ишек яңагына бер-ике тапкыр кагып алды. Эчтән тавыш ишетелмәде. Кыюланып китеп, тагын какты. Бу юлы эчтән: «Керегез, кер!» – дигән тавыш ишетелде. Һәм Сөембикә, бисмилласын әйтеп, ишекне тартеп ачты, эчкә атлады.

Ул кергәндә, бүленмәгән өй уртасында ак сакаллы, башына ак кәләпүш, өстенә озын итәкле иркен ак күлмәк белән куй тиресеннән тегелгән җылы камзул, юллы тукымадан тегелгән ыштан кигән, урта буйлы, чандыр гәүдәле, ак сакаллы, ачык йөзле карт басып тора иде.

– Саумы, Әшрәф Баба? – дип исәнләште Сөембикә.

– Аллага шөкер, кызым. Әйдүк, түрдән уз. – Карт аның өске киемен чөйгә эләргә булышты, аннан тәбәнәк өстәле янында торган тал чыбыгыннан үрелгән кәнәфидән урын күрсәтте.

Сөембикә күрсәтелгән урынга барып утырганчы, кулындагы төенчеген картка сузып:

– Әшрәф Баба, мин бераз күчтәнәчләр алып килгән идем. Зинһар, кабул итеп ал, – диде.

– Рәхмәт, кызым. Садака дип кабул итәм. Савабы үзеңә булсын.

Әшрәф Баба төенчекне алды да мич янындагы аш әзерли торган өстәлгә куйды. Аннан һаман әле нишләргә белмичә басып торган Сөембикәгә кабат урын күрсәтеп:

– Утыр, кызым, – диде һәм үзе дә ачык китап яткан өстәле артына кереп урнашты. Беравык кунакка төбәлеп карап торды да:

– Танып бетермим, кызым. Сине кем дип белергә соң? – дип сорады.

– Мин Йосыф мирза кызы Сөембикә булам.

– Ә-ә, шулаймыни... Сөембикә-ханбикә үзе минем хөҗрәмә килгән икән алайса. – Картның йөзе яктырып китте, күзләрендә җанлы очкыннар биешеп алды. – Ишеттем, ишеттем... Сафагәрәй хан гаскәр белән Казанга тәхетен кайтарып алырга китте, дип сөйлиләр.

Сөембикә бу сүзләрдән уңайсызланып китте, ни дип җавап бирергә белмичә торды. Ул дәшмәгәч, Әшрәф Баба үзе дәвам итте:

– Мондый зиннәтле киемнәр киеп, яныма кем килгән дип торам. Күз тимәсен, балам, син икәнсең. Хөсне багка[1] охшагансың.

Сөембикәнең, оялудан, йөзенә кызыллык йөгерде. Ул уңайсыз хәлдән чыгу өчен карттан сораштыра башлады:

– Әшрәф Баба, карчыгың гүр иясе булган дип ишеттем, ялгыз яшәү авырдыр бит?

Карт сүзне икенчегә борды:

– Аллаһы Тәгалә хозурына китте шул карчыгым, урыны җәннәттә булсын. Әйбәт холыклы җан иде, – диде.

[1] Хөсне баг – матурлык бакчасы.

– Амин, – дип куйды Сөембикә.

Әшрәф Баба:

– Йә, кызым, китергән садакаңа дога кылып алыйк, – дип, кулларын күтәрде. Сөембикә дә аңа иярде.

Дога укылып, бит сыпырылгач, Сөембикә тагын кызыксынды:

– Әшрәф Баба, сине карауччылар бармы соң? Тормышың ничек бара?

– Аллага шөкер, кызым, ташламыйлар ырудашларым. Садакасы да килеп тора, өс-башымны да юып, карап торалар. Кирәк җиргә чакырмыйча да калмыйлар. Рәхмәттән башка бер сүзем юк.

Сөембикә карт алдында яткан ачык китапка игътибар итте:

– Әшрәф Баба, минем килүемә гаҗәпләнмә, зинһар. Әле Казаннан кайтканда юлда ук синең белән күрешермен дип, күңелемә беркетеп куйган идем. Мин сине нугай халкының иң зур голямаларыннан дип саныйм.

– Рәхмәт, кызым, хөрмәтеңә, ихлас сүзләреңә. Гомерем китаплар белән узды шул, анысы хак. Голүме нәкълия юлы белән, ягъни кешедән ишетеп кенә зур гыйлем туплау кыен ул. Китаплар кирәк, китаплар...

Әшрәф Баба артындагы диварга ымлады, андагы киштәләр китаплар белән тулган иде. Сөембикә, үзен баядан бирле кызыксындырып, Әшрәф Баба алдында ачык килеш яткан калын китапка ымлады:

– Әшрәф Баба, мин килеп кереп, сине эштән аердым бугай.

– Зыян юк, кызым.  Кызыксынып килүең минем өчен үзе бер хозурлык, – дип, карт җыерчыклы кулы белән китап битен сыпырып алды.

– Әшрәф Баба, сер булмаса әйт әле, алдыңда нинди китап ята ул?

Сорауны ишетү белән карт җанланып китте, Сөембикә аның карашы җылынуын сизеп алды.

– Бу, кызым, Коръәни Кәримнән кала, китапларның иң кадерлесе. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллалаһу галәйһи вәссәламнән калган изге хәдисләр.

– Хәдисләр?

– Әйе, кызым, Мөхәммәд әл-Бохари туплаган хәдисләр. Мәшһүр әл-Бохариның нинди зат булганын ишеткәнең бардыр бит?

– Ишеткәнем бар барын, тик аның турында бик аз беләм. Мин бит гарәпчә укысам да, телне белмим диярлек, – диде Сөембикә.

– И-и, гаҗәп укымышлы  зат булган ул әл-Бохари. Бик яшьли ятим калып, анасы тәрбиясендә үскән. Тырыш, зиһенле малай, җиде яшендә инде бөтен Коръәнне укып чыккан. Бохарада туып, бик күп гомерен Шәрекъның зур-зур шәһәрләрендә уздырган. Багдадта, Басрада, Бәлхтә, Мисырда, Димәшкъта, Хиҗазда, Нишапурда төрле дин әһелләре, шәехләр, хәдисләр җыючы мөхәддисләр белән аралашкан, зур гыйлем туплаган. Үзе дә акрынлап пәйгамбәребезнең хәдисләрен җыя башлаган. Бу изге эшкә ул уналты ел гомерен багышлаган. Риваятьләргә караганда, үз гомерендә төрле кешеләрдән пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам әйтеп калдырган бихисап фикерләр язып алган. Соңыннан аларны чагыштыра-чагыштыра, төрле бүлекләргә туплап, хәдисләр китабы «Ас-Сахих»ны төзегән. Ул күп китаплардан тора. Менә шул китапларның берсе минем алдымда ята инде.

Әшрәф Баба алдындагы китап битен сыйпап куйды.

– Әшрәф Баба, җыйган хәдисләрнең барысы да шушы «Ас-Сахих»ка кергәнме соң?

– Юк, кызым, кермәгән. Мәшһүр мөхәддис әл-Бохари хәзрәтләре бу эшкә бик таләпчән килгән. Китабына бары тик берничә кеше тарафыннан дөреслеге расланган хәдисләрне генә керткән. Шулай алты йөз мең хәдистән ике мең җиде йөз алтмыш бишен генә «ас-сахих», ягъни «ышанычлы» дип кабул иткән. Шуңа күрә хәдисләр китабы «Ас-Сахих» дип атала да инде.

– Ни кызганыч, гарәп телен белсәм, мин дә укыр идем, – дип үкенеп әйтеп куйды Сөембикә.

– Безнең халыкта гарәп телен белүчеләр әлегә бармак белән генә санарлык шул, кызым. Кызганыч шул, бик кызганыч...

Әшрәф Бабага затлы мирза кызының хәдисләр кебек мәсьәлә белән кызыксынып утыруы ошап китте, ахрысы. Ул дулкынлана төшеп сөйләргә кереште:

– Беләсеңме, Сөембикә кызым, бу хәдисләрне укыганда, мин үземне Мөхәммәд пәйгамбәр белән мөхадәсә[2], ягъни әңгәмә кылып утыргандай хис итәм. Кайвакытта хәтта күзләремә яшьләр килә. Нинди зур байлык калдырган безгә әл-Бохари, нинди зур хәзинә. Аның гомере җитмеш яшендә Сәмәркандта өзелә.

– Әшрәф Баба, ә син хәдисләрне безнең үз телебезгә тәрҗемә итеп караганың юкмы?

– Тәрҗемә иткәнем юк, әмма бу хакта уйлаганым бар.

– Тәрҗемәләре булса, һәркем укып таныша алыр иде.

– Дөрес әйтәсең, кызым, тәрҗемәләр кирәк. Әмма бу бик зур һәм җаваплы эш. Кем генә алыныр икән аңа?

Сөембикә сораулы карашын Әшрәф Бабага төбәде. Карт, хатынның нәрсә әйтергә теләгәнен шундук аңлап алды.

– Нигә бу эшкә алынмыйсың дип әйтмәкче буласыңмы, кызым? – дип сорады Әшрәф Баба.

Сөембикә башын кагып куйды.

– Андый зур эшкә алына алмыйм, кызым. Картайдым. Яшьрәк чакта кирәк иде. Инде күпме гомер калган...

– Казанда да тәрҗемә итүче юк. Барысы гарәп телендә укый, – диде Сөембикә.

– Казан ул – мәшһүр кала. Анда гарәпчә белүче галим-голяма җитәрлек, андый ихтыяҗ юктыр.

– Казанны шагыйрьләр каласы дип тә атыйлар. Тик анда шигырьләрне гарәпчә түгел, татарча язалар бит. Мөхәммәдьяр атлы шагыйрьне ишеткәнең бармы, Әшрәф Баба?

– Беләм Мөхәммәдьярны. «Нуры содур» әсәрен Казаннан бер мулла алып кайткан иде. Төрки телне сөюче, үтә дә дини, үгет-нәсыйхәтне алга сөрүче олуг затлардан икән шагыйрь Мөхәммәдьяр. Китабы олуг солтан мөгаззәм Сәхибгәрәй хан хәзрәтләренә багышланган. Укып, зур ләззәт алдым.

– Әшрәф Баба, мин бит шагыйрь Мөхәммәдьярны күреп беләм. Бик тыйнак адәм. Дөрес, ул күпләрдән аермалы буларак, хан сараеннан ерак йөрергә тырыша.

[2] Мөхадәсә – әңгәмә.

– Шулайдыр. Чын шагыйрьләр дан-дәрәҗә эзләми.

Сөембикә беравык карт әйткән сүзләр турында уйлап торды. Казанда гаять әрсез, хан сараена эләгеп, үзен күрсәтергә тырышкан шагыйрьләрне күп күрде ул.

– Әшрәф Баба, миңа хәдисләрдән берничәсен укып күрсәтмәссеңме икән?

– Гарәпчәсен укысам, аңлап җиткерерсеңме соң?

– Ә син тәрҗемә итеп укы.

– Ярар, карап карыйк. – Карт алдында яткан хәдисләр китабының битләрен ачкалап, бармагын китап юлларыннан йөртә башлады. Ул кайсы хәдискә тукталыйм дип сайлый иде. Ниһаять, берсенә тукталып, елмаеп куйды: – Менә монысында Мөхәммәд пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вәссәлам үзе турында әйтә: «Алдагы пәйгамбәрләр бары бер халык өчен булса, мин бөтен халыклар өчен җибәрелдем», – ди.

Карт әйтелгән сүзләрнең Сөембикәгә ничек тәэсир итүен беләсе килеп булса кирәк, беравык аңа карап торды. Аннан тагын бер хәдисне тәрҗемә итеп күрсәтте:

– Менә тыңла: «Аллаһыныкы булмаган бүтән милек җиһанда юк», диелгән. – Ул тагын бер хәдискә тукталды: – Ә монысы белем алу турында: «Кытайга барып булса да, белем алыгыз, чөнки белемгә өйрәнү һәр мөселман өчен фарыз». Менә тагын: «Мөселман кеше белемгә өйрәнеп, белгәнен дин кардәшенә өйрәтсә, шул садаканың иң яхшысы булыр», диелгән.

Әшрәф Баба китап битләрен ачуын дәвам итте һәм сайлап алган хәдисләрне тәрҗемә итә торды: «Белем гыйбадәттән өстен, ул диннең төп өлеше».

Бу хәдис Сөембикәдә каршылыклы хисләр уятты, шуңа күрә ул картка сорау бирмичә кала алмады:

– Әшрәф Баба, дин әһелләре гыйбадәтне беренче урынга куялар түгелме соң? Мин нәрсәдер аңлап җиткермим...

– Син хаклы, кызым. Тормышта күп очракта шулай килеп чыга шул, – диде карт, тирәнгә керергә теләмичә, чөнки бу бик зур мәсьәлә иде. Ул тагын тәрҗемә итәргә кереште: «Ике төрле белем бар: берсе күңелдә – анысы файда китерүче, икенчесе телдә – анысы Аллаһы Тәгаләнең адәм балаларына китергән дәлиле».

Әшрәф Баба Сөембикәгә күтәрелеп карады. Сөембикә исә:

– И-и Әшрәф Баба, гарәп телендәге бу хәдисләр безнең халыкка барып җитми бит. Аны бары тел белүчеләр генә укый ала, – диде.

– Әйе шул, кызым. Безнең халыкта гарәп телен белүчеләр бармак белән генә санарлык. Нугай җәмгыяте әле бу дәрәҗәгә җитмәгән.

– Нишләргә соң, Әшрәф Баба? Бу хәлдән чыгу юлы бөтенләй юкмыни?

– Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә әйтелә: «Йа, Аллаһның бәндәләре! Утрак тормыш! Утрак тормыш!» – ди. Бик дөрес сүзләр, утрак тормышка күчмичә торып, халыкта белемгә омтылуны уяту бик кыен. Шуңа күрә әлегә бу эшкә алынучы адәм күренми, – диде карт, уфтанып. Аннан Сөембикәнең йөзенә күтәрелеп карады:

– Тагын берничәне укыйммы?

– Тыңлыйм, тыңлыйм, Әшрәф Баба. Арымасаң, укы.

– Менә аналар хакында ни әйтелгән: «Җәннәт – аналарның аяк астында». Менә тагын: «Сезне ата-анагыз икесе берьюлы чакырса, иң элек анагызга җавап бирегез», диелгән.

– Әшрәф Баба, аталар турында берәр хәдис бармы?

Карт тагын елмайды, ак сакалын сыпыргалап алды:

– Бар андый хәдисләр, кызым, бар. Хәзер табам. – Ул китапны тиз-тиз актарырга кереште. – Менә ул, тыңла: «Атаң мәхәббәтен сакла, кисә күрмә, юкса Аллаһы Тәгалә синдәге нурны сүндерер», диелгән.

Әшрәф Баба беравык сүзсез генә Сөембикәнең нурлы йөзенә карап торды да:

– Сөембикә кызым, карап-карап торам да, син бик кызыксынучан, белем эстәргә омтылучан бала икәнсең. Мин бүген синең белән мөхадәсә кылып, зур сәгадәт кичереп утырам. Беләсеңме, пәйгамбәребез бер хәдисендә ни дип әйткән: «Кем акыл нигъмәте белән ризыклана, шул котылу таба», дигән.

– Рәхмәт, Әшрәф Баба, мине зурлап әйткән сүзләреңә. Ләкин минем гыйлемем бик аз шул әле.

– Иҗтиһад итсәң, белем ул арта бара, кызым. Тырышлык куй, тукталма.

– Әшрәф Баба, минем синнән тагын бер мәсьәлә хакында сорашасым килгән иде.

Карт, «туктап тор» дигәндәй, ике кулын күтәрде:

– Сөембикә кызым, әйдә синең белән башта китергән күчтәнәчләрең белән тәмләп чәй эчик. Сорауларыңны аннан соң бирерсең. Килештекме?

– Ярар, Әшрәф Баба. Мин сине ардырдым бугай, – диде Сөембикә, гафу үтенгәндәй.

– Зыян юк, кызым. Синең кебек затлы ханым белән әңгәмә корып утыру – минем өчен зур куаныч. Бу өйдә андый хәлнең әле булганы юк иде.

Карт хәдисләр китабын ябып, бер читкә куйды да, урыныннан торып, мич кырындагы өстәл янына килде. Сөембикә алып килгән төенчекне чишә башлады. Моны күреп, Сөембикә урыныннан торды:

– Әшрәф Баба, әйдәгез, булышыймчы үзеңә, – диде.

– Кызым, син бу нигъмәтләрне өстәлгә куй, ә чәйне мин үзем әзерлим. Минем тәртипләрне белеп бетермәссең.

Сөембикә керәч җамаякларга нигъмәтләрне бүлгәләп салды да өстәлгә тезде, аннан кабат кәнәфигә килеп утырды. Ул Әшрәф Бабаның бүлмәсен күздән кичерә иде. Монда бер артык әйбер дә юк. Диварларда берничә шәмаил, чигеп эшләнгән Кәгъбәтулла сурәте, китаплар белән тулган киштәләр. Каршы якта картның гади генә ятагы һәм кечерәк кенә мич. Әшрәф Бабаның эш өстәле тәрәзә каршында тора. Идәнгә калын соры киез җәелгән. Шушы кечкенә генә хөҗрәдә гыйлем туплауны үзенең төп максаты иткән нинди гали җан иясе яшәгәнен нугайлар аңлап та җиткерми бугай әле. Дөнья малына битараф, китаплардан башкага исе китми торган бу картны ырудашлары хөрмәт итсәләр дә, аңа сәер бер зат, фани дөньядан аерылган сәер, карт суфи дип карыйлардыр, шәт. Ләкин мирзаларда хезмәттә торган мулла-мунтагай дини мәсьәләләр хакында киңәшергә гел Әшрәф Баба янына килә, дип ишеткән иде Сөембикә. Ул бу какча гәүдәле, балалар кебек самими һәм ачык күңелле картка карата үзендә хөрмәт, олылау

хисенең торган саен үсә баруын сизде. Ырудашлары арасында шундый асыл затның булуына сөенеп кенә түгел, горурланып утырды. Мәшһүр Казан каласында күпме гомер яшәсә дә, чыгышы белән нугай кызы булып калуын, Сарайчыкка кайткач, үзендә нугай тамырларының ныграк сиздерә башлавын тойды ул.

Чәй эчкәндә, Әшрәф Баба Сөембикәнең хәл-әхвәлләрен сорашты. Ул инде кайбер нәрсәләрне ишеткән икән. Шулай да Сөембикәгә кыскача гына булса да, Казанда башланган фетнә һәм аларның Сафагәрәй белән монда нигә кайтуларын сөйләп бирергә туры килде. Карт аны сораулар бирмичә генә тыңлап утырды һәм, Сөембикәнең сөйләгәннәреннән бер нәтиҗәгә килгәндәй, көтмәгәндә:

– Мөхәммәд пәйгамбәр бервакыт: «Руза, намаз һәм садакадан да өстен тагын ни бар?» – дип сораган, үзе үк җавап биргән: «Ике шәхес арасын төзекләндерү, чөнки аралар бозыклыгы бер биек тау ул», – дип, хәдис китерде.

Картның бу сүзләре Сөембикәне  нык гаҗәпләндерде. Бу, һичшиксез, ул әле генә сөйләгән Казан хәлләренә, Сафагәрәйнең башкаланы ташлап чыгуына карата киная сыйфатында әйтелгән хәдис иде. Димәк, Әшрәф Баба үзенчә нәтиҗә чыгарган, Казандагы Мәскәү фиркасе белән Сафагәрәй арасындагы низаг, килешмәүчәнлек, капма-каршылык, чыннан да, биек тау кебек бит. Бу тауны ничек юк итәргә, ничек илдә тынычлык урнаштырырга? Сөембикә моны белми иде.

Сөембикәнең тынып калганын күреп, Әшрәф баба:

– Ә икенче бер хәдистә: «Иман белән гамәл – берсе икенчесенә тиң, алар бер-берләренә юлдаш булмый торып, төзек хәлдә тора алмыйлар», диелә, – дип әйтеп куйды. – Сабырлык – Аллаһтан, ашыгу – шайтаннан. Сабыр итү кирәк, кызым. Барысы да үз эзенә төшәр, – диде.

– Әйе шул, Әшрәф Баба, миңа хәзер сабырлык белән Казаннан яхшы хәбәрләр көтәсе генә калды инде, –  дип җавап бирде Сөембикә.

– Аллаһы Тәгаләгә ианудан соң иң беренче гамәл – халыкка карата мәхәббәт күрсәтү, – диде Әшрәф Баба.

Сөембикә аңлады, бу сүзләр дә, һичшиксез, хәдисләрдән иде. Карт аларның күбесен яттан белә икән.

Чәй эчү тәмамланды, Сөембикә калган ризыкларны, савыт-сабаны өстәлдән җыеп алды, аннан урынына килеп утырды.

Әшрәф Баба аңа карап елмайды да:

– Йә Сөембикә кызым, миңа соравым бар дигән идең. Тыңлыйм сине, – диде.

Сөембикә беравык сүзне ничек башларга белмичә аптырап торды, аннан кыюлана төшеп әйтте:

– Әшрәф Баба, без нугайлар – ислам динендәге халык. Төп китап безнең өчен Коръәни Кәрим, хәдисләр. Әмма без бит төрки кавемнән. Борынгы заманда төрки кавемнәр башка аллаларга, рухларга инанганнар. Исламга күчүебез ничек булган, кайчан булган? Шуны аңлатып бирә алмассыңмы икән?

Әшрәф Баба зур кызыксыну, хәтта гаҗәпләнү белән берара Сөембикәгә карап торды. Сизелер-сизелмәс кенә үзалдына елмаеп та куйды бугай әле.

Чыннан да, сорау нугай дөньясында яшәүче хатыннар бирә торганнардан түгел иде. «Мәшһүр Казан, андагы зыялылар арасында яшәү менә нишләткән мирза кызын», – дип уйлап алды Әшрәф Баба.

– И-и Сөембикә кызым, син бик кызыклы сорау бирдең бит әле. – Карт ягымлы итеп елмайды, канәгать калуы йөзенә чыкты. – Бу сорауны миңа моңарчы берәүнең дә биргәне юк иде. Бер-ике сүз белән генә җавап бирә торган сорау түгел, кызым. Түземең җитсә, тыңла.

– Үзеңә көч килмәсә, рәхәтләнеп тыңлыйм, Әшрәф Баба, – диде Сөембикә, гафу үтенгәндәй.

– Иң элек, кызым, төрки бабаларыбызның мәҗүсилек дәверендә нәрсәләргә инанып, тереклек итүләре турында әйтеп үтәргә кирәк. Аларның мөселман булып киткәнче, мәҗүсиләргә хас гадәт буенча, үз илаһлары, инана торган күп төрле рухлары булган.

– Тәңре шуларның берсеме, Әшрәф Баба?

– Әйе, кызым, Тәңре, дөресрәге, Күк Тәңре шуларның иң зурысы булган. Күкләрдә яшәүче, ил-көннең, халыкларның, каганнар белән ханнарның язмышын хәл итүче, һәр адәми затка кот, ягъни җан бирүче Күкләр Рухы Тәңре дип аталган. Аны кайвакытта хөрмәт белән Тәңре хан дип тә атаганнар.

– Тәңрене төркиләр әле дә онытмый бит, Әшрәф Баба. Ислам динендә булсалар да, аны еш телгә алалар. Мәсәлән, татарлар яңгыр чакырганда, аңа мөрәҗәгать итәләр:

Яңгыр яу, яу, яу!
Елга аксын юллардан,
Матур яңгыр соңында,
Хуш ис чыксын кырлардан.
Яңгыр яу, яу, яу!
Игеннәр дә күп булсын,
Сыерлар да тук булсын,
Безгә катык, сөт булсын.
Яңгыр яу, яу, яу!
Нык яварга онытма.
Без сорыйбыз Ходайдан,
Бир, Тәңре, бир, Тәңре,
Биргәнеңне кире алма,
Яңгыр яу, яу, яу!

Әшрәф Баба кеткелдәп көлеп куйды:

– Сөембикә кызым, син хан сараенда яшәп, боларны каян белеп бетердең соң? – дип кызыксынды ул.

Сөембикә тыйнак кына елмаеп куйды:

– Мин бит көннәр буе хан сараенда ябылып ятмыйм, Әшрәф Баба. Авылларга да чыккалыйм. Бер чыкканда ишетеп калган идем. Аны тулгый-тулгый, бик озак әйтәләр, мин бер өлешен генә отып калдым.

– Әйе, Тәңрене безнең нугайлар да онытмый. Аны хәтта Аллаһы Тәгаләгә тиңлиләр. Бу инде мәҗүсилек дәвереннән калган гадәт. Һаман чыгып бетә алмый.

– Тәңре Күкләрнең Бөек Рухы булгач, аны халыкның Аллаһы

Тәгаләгә тиңләве табигыйдыр, – дип, башына килгән уен әйтеп салды Сөембикә.

Әшрәф Баба башын чайкап куйды:

– Әмма Тәңре белән Аллаһы Тәгалә арасында зур аерма бар, кызым. Син ялгыш юлга кереп китә күрмә, – дип, җитди итеп әйтеп куйды ул.

– Аллаһы Тәгалә – бер һәм бердәнбер Бөек Зат. Ул – галәмнәрне тәрбия кылучы. Ә төрки бабаларыбызның Тәңресе бердәнбер зат түгел. Аның ишләре бар. Төркиләрдә Тәңредән башка Җир-Су, Умай, Эрклик дигән илаһлар да булган. Алар шуларга табынып, корбан биреп яшәгәннәр. Җир-Суны, мәсәлән, төрки бабаларыбыз туган илне, Ватанны кайгыртучы, сугышларда җиңү китерүче гүзәл хатын-кыз рәвешендәге илаһ дип күз алдына китергәннәр.

– Чыннан да, Җир-Суның – Туган илне кайгыртучы, саклаучы илаһ икәне исеменнән үк күренеп тора, – дип, картның сүзен җөпләп куйды Сөембикә. Башланып киткән әңгәмә аның өчен торган саен кызыграк була бара иде. Шушы зирәк, укымышлы карт янына килүенә ул сөенеп куйды.

– Төрки бабаларыбыз адәми заттан башка бөтен табигать, җир йөзендәге бөтен тереклек ияләре Җир-Су кайгыртуында, аның тәрбиясендә яши дип инанганнар, – дип өстәде карт.

– Ә Умай дип аталган илаһ нәрсәләрне кайгырткан? – дип сорады Сөембикә.

– Умайны да хатын-кыз рәвешендәге илаһ дип күзаллаганнар төрки бабаларыбыз. Ул баш илаһ Күк Тәңренең җәмәгате саналган. Адәм балаларына үзенең мәрхәмәтен өләшкән, аларга яшәү көче биргән. Шулай ук Умайны хатын-кызның бала табу әгъзаларының саулыгын кайгыртучы, ана карынындагы баланы саклаучы, халык санын арттыруда ярдәм итүче илаһ дип белгәннәр. Бала таба алмаган хатын-кызлар бала сорап, аңа мөрәҗәгать иткәннәр.

– Казан татарларында ул нигәдер билгеле түгел, ахры, – дип куйды Сөембикә.

– Ерак заманнарда аны белгәннәр, тик тора-бара халык хәтереннән җуелган булса кирәк. Әгәр дә без төрки телне тикшерә башласак, анда ум, ым, им, ам – кебек тамырлардан барлыкка килгән сүзләр табачакбыз. Аларның күбесе ана белән балага, хатын-кызның җенес әгъзасына бәйле сүзләрне ясауда катнаша. Мисал өчен: имү, имчәк, имезлек, ам һәм башкалар. Умай-Ымай исеме бу тамырларга бик якын тора бит, кызым.

Әшрәф Бабаның бу сүзләреннән Сөембикә оялып, бераз кызарынып утырды. Карт сүз белән мавыгып, аның бу халәтенә игътибар итмәде. Шулай да төрки телне тирән белә икән Әшрәф Баба, Сөембикәгә ул бөтенләй яңа яктан ачылып китте. Ә карт сүзен дәвам итте:

– Ерак бабаларыбызның Эрклик дип аталган илаһына килгәндә, аны ике мөгезле, икегә аерылган озын сакаллы ир-ат кыяфәтендә күз алдына китергәннәр. Ул җир асты дөньясының хуҗасы саналган. Явыз рухлар аның хезмәтендә булган. Адәми зат үлгәч, аның коты, ягъни җаны күккә, Тәңре катына очкан, ә гәүдәсе Эрклик карамагында җир асты патшалыгында калган. Җир йөзендә була торган иң авыр хәлләр, һәлакәтләр, меңәрләгән кешене теге дөньяга алып китә торган төрле авырулар, дала боз белән

капланып, җөт барлыкка килеп, мал-туарның күпләп кырылуын да төрки бабаларыбыз Эрклик эше дип уйлаганнар.

– Эрклик тәмуг хуҗасын хәтерләтә икән, – дип әйтеп куйды Сөембикә.

– Юк, кызым, җаһилият, ягъни исламга кадәрге заманда бабаларыбыз әле тәмугның нәрсә икәнен белмәгәннәр. Шулай да алар җир астында ниндидер куркыныч дөнья барлыгын, төрле явыз рухлар, өрәкләр яшәгәнен чамалаганнар. Бәлки күзгә күренми торган өрәкләр хуҗасы булганга, ул алланы Эрклик дип атаганнардыр, – диде Әшрәф Баба.

– Әшрәф Баба, төрки бабаларыбызга ислам диненә күчү бик авыр булмагандыр, ахры...

– Нигә алай дип уйлыйсың, кызым? – Карт, кызыксынып, карашын Сөембикәгә төбәде.

– Күк Тәңрене Күкләрнең Бөек Рухы дип кабул иткән төрки бабаларыбызга Аллаһы Тәгаләнең шулай ук Күкләрдәге Бөек Зат икәнен аңлау кыен булмагандыр, дип уйлыйм.

– Бик кызык сүз әйттең әле син, кызым, сөбханалла, – дип гаҗәпләнеп карап куйды Әшрәф Баба. – Чыннан да, төрки бабаларыбыз мәҗүсилек дәверендә күкләрдә Күк Рухы Тәңре яшәвенә ышанганнар. Ислам диненә күчкәч тә, Тәңре белән Аллаһы Тәгаләне бутау халыкта озак вакытлар әле дәвам иткән.

– Ул әле дә онытылып бетмәгән, Әшрәф Баба. Әнә, татарларда яңа өй нигезенә арбау әйтү гадәте һаман яши икән. Менә тыңлап кара:

Күк Тәңре исеме белән,
Ак кояш исеме белән,
Көмеш ай исеме белән
Җир-Су исеме белән,
Ияләрне чакырам,
Күк биягә утырам.

Тәңре йөзенә багып,
Бер чүгәлим, бер торам...
Кулларны күккә чөеп,
Сулламагыз, уңлагыз,
Шушы яңа нигезгә
Арбау әйтәм – тыңлагыз! –

дип башлана ул йола.

– Һай, Сөембикә кызым, карап-карап торам да, син тәмам татарлашып беткәнсең икән, – дип, сөякчел бармаклары белән өстәлгә сугып алды Әшрәф Баба.

– Мин бит Казан ханбикәсе, Әшрәф Баба, – дип, горур гына әйтеп куйды Сөембикә. – Яшәгән илем тормышы, гореф-гадәтләре белән кызыксынырга тиешлемен.

Әшрәф Бабаның уйчан карашы аңа төкәлде. Бу зиннәтле киемнәр кигән мирза кызының күңел дөньясы башка нугай хатын-кызларына бер дә охшамаган иде. Ул ир-атлар да белмәгән нәрсәләр белән кызыксына, сорауларына җавап эзли, тынгысыз рухының гадәти тормыш мәсьәләләре белән генә канәгатьләнеп яши алмавы һәр сүзеннән сизелеп тора.

– Сөембикә кызым, мин синең төп соравыңа җавап бирмәдем бит әле. Син төрки бабаларыбызның ислам диненә ничек күчүе турында сөйләвемне сораган идең.

– Әйе шул, Әшрәф Баба. Бу мәсьәлә мине күптән кызыксындыра, – диде Сөембикә. Шунда аның күңелендә тагын бер сорау туды:

– Әшрәф Баба, зинһар, гафу ит. Бабаларыбызның исламны кабул итүенә күчкәнче тагын бер мәсьәләгә ачыклык кертеп үтик инде.

– Нинди мәсьәлә, кызым?

– Гарәпләр ислам диненә күчкәнче нинди дә булса илаһларга табынганмы?

– Әйе, кызым, табынганнар. Җаһилият заманында аларның Лат, Манат, Узза исемле илаһлары булган. Бу хакта Коръәндә дә телгә алына.

– Рәхмәт, Әшрәф Баба. Бүлдерүем өчен тагын бер кат гафу үтенәм.

– Зыян юк, Сөембикә кызым, синең сорауларың миңа илһам гына өсти. Ә хәзер икенче соравыңа күчик. Бу сорауга җавап бирү өчен, Сөембикә кызым, безгә ерак тарихка күз салырга кирәк булыр. Безнең халык бүгенге көндә нугай исемен йөртә. Әмма элекке заманда без мангыт исемен йөрткәнбез. Ничек алай килеп чыккан соң? – Карт тирән итеп сулап куйды да сүзен дәвам итте. – Безнең бабаларыбыз борынгы заманда Аму Дәрья буйларында, Бохара тирәсендәге далаларда тереклек иткән. Ул чакта алар әле мәҗүси кавем булган. Инде әйтеп үтелгәнчә, күп илаһларга, төрле рухларга инанып яшәгәннәр. Мангыт ыруларының Аму Дәрья буйларына кайдан килеп урнашуы ачык түгел. Күрәсең, Көнбатыш Себер җирләреннән килгәннәрдер. Бабаларыбыз бирегә монгол яуларына кадәр үк күченеп килгәннәр. Соңрак бу җирләрне монголлар басып алган, аларның да мангут дип аталган кабиләсе булган. Шулай итеп, бабаларыбыз монгол-мангутлар арасында яши башлаган. Тора-бара мангут кабиләсенең исеме бабаларыбызга да күчкән, тик мангыт рәвешендә. Күрәсең, монгол-мангутлар хакимлек итүче кабилә булгандыр. Тарихта кайвакыт андый хәлләр булгалый. Кечерәк кабилә хакимлек итүче көчле кабилә атамасын йөртә башлый. Әмма монда бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк. Безнең бабаларыбыз инде мангыт исемен йөртсәләр дә, үзләренең кыпчак асылын саклап калганнар. Ягъни элеккечә төркиләр булып калганнар. Монголлашып китмәгәннәр.

– Әшрәф Баба, бабаларыбыз мангытлар булып киткәнче ничек аталганнар соң?

– Менә анысы билгеле түгел, кызым. Мин дә бу мәсьәлә белән бик кызыксындым, тик җавап таба алмадым. Ул сер булып, тарих караңгылыгында кала бирә, – диде Әшрәф Баба.

Сөембикә сизеп торды, хикәянең иң кызыгы әле алда, шуңа күрә ул картны зур игътибар белән тыңларга әзерләнде. Бераздан Әшрәф Баба сүзен дәвам итте:

– Монгол-мангутлар арасында күпмедер заман гомер иткәч, мангыт бабаларыбыз тормышында зур үзгәрешләр башлана. Алар арасында ак сакаллы, бик укымышлы бер карт күренә башлый. Аның исеме Хуҗа Әхмәд Баба Төкләс була. Бу хәл Алтын Урда тәхетендә Үзбәк хан утырган чакка туры килә. Син беләсең булыр, мәшһүр Алтын Урда мәмләкәтендә ислам

дине фәкать Үзбәк хан хакимлек иткән заманда ныгып китә, хәтта бу дин мәмләкәттә рәсми рәвештә кабул ителә. Хуҗа Әхмәд Баба Төкләс бу вакытта нәкъ менә Үзбәк хан биләмәләрендә, ягъни Җүчи Олысында яши. Хәтта әйтер идем, фәкать аның вәгазьләре Үзбәк ханны Алтын Урда мәмләкәтендә исламны рәсми дин буларак кабул итәргә этәрә. Хәер, без читкәрәк киттек бугай. Сүз бит мангыт бабаларыбыз хакында иде, – дип, Әшрәф Баба үзен төзәтеп куйды. – Хуҗа Әхмәд Төкләс Баба төрки мангыт кабиләсе арасында агарту эше башлап җибәрә. Галәмнәр тәрбиячесе Аллаһы Тәгалә турында сөйли, Коръән укый, аны аңлата, бу изге китапның егерме өч ел дәвамында Мөхәммәд пәйгамбәргә вәхи рәвешендә күктән иңүен, тупланып барган сүрәләрдән соңрак Коръән Кәрим барлыкка килүен мангытлар арасында армый-талмый аңлатып йөри. Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәдисләрен китереп, мөселман булып яшәү тәртипләренә өйрәтә. Ахыр чиктә Төкләс Бабаның иҗтиһад итүе, зур тырышлык куеп алып барган изге эше нәтиҗә бирә. Мәҗүси мангыт бабаларыбыз аның сүзләренә инанып, аларны кабул итеп, ислам диненә күчә башлый. Әлбәттә, бу күчеш җиңел генә бармагандыр. Гасырлар буе башка илаһларга, рухларга табынып яшәгән халык байтак вакытлар элекке инануларын да ташлап бетерми. Бүгенге көнгә хәтле халыкның, Аллаһы Тәгаләне күз алдында тотып, аңа Тәңрем дип мөрәҗәгать итүе мәҗүсилек дәвереннән калган гадәтләрен һаман әле онытып бетермәве турында сөйли. Әмма ни генә булмасын, мангыт бабаларыбыз ислам диненә күчә, мөселманнарча яши башлый.

Әшрәф Баба, урыныннан торып, буш касәгә су салды да кипкән тамагын чылатып алды. Сүзсез генә бүлмә буенча йөренеп килде, аннан кире урынына килеп утырды.

– Әшрәф Баба, мангыт бабаларыбыз Аму Дәрья тирәләреннән Җаек буена кайчан күчеп килгән соң? – дип сорады Сөембикә.

– Сорауны бик вакытлы бирдең, кызым. Үзем дә шул хакта сөйләмәкче идем. – Әшрәф Баба, фикер туплагандай, беравык бер ноктага карап торды. Аннан дәвам итте: – Төкләс Баба, мангыт бабаларыбызның ислам диненә күчүенә ирешкәннән соң, алар арасында икенче зур эш башлап җибәрә. Ул күчмә тормыш алып барган бабаларыбызны яшәү шартлары әйбәт булган киң далаларга күчеп китәргә үгетли башлый. Исәбендә кыпчак мангытларны мәҗүси монгол-мангутлардан аеру, ераккарак  күчерү дә булгандыр, дип уйлыйм. Ә кеше яшәмәгән киң далалар төньяктарак аккан Эмба белән Җаек елгалары тирәсендә җәелеп ята. Әмма Аму Дәрья буйларыннан, ягъни Мәвәрәэннәһердән андый ерак далаларга күчү берничә дистә елга сузыла. Бабаларыбыз иң элек Мәвәрәэннәһердән Арал диңгезенең көньягында урнашкан Харәзем җирләренә күченәләр. Бераздан соң гына, Арал диңгезен сул кулда калдырып, казакъ далаларының көнбатышына үтеп керәләр. Тик монда аларга тынгысыз күршеләр белән яшәве кыенрак булган, күрәсең. Шуңа күрә алар казакъ даласында озакка тукталмыйлар, көнбатышта агып яткан Эмба белән Җаек елгалары арасындагы буш далага күчеп китәләр. Тора-бара бу далалар бабаларыбызның дастаннарда җырланган асыл ватанына әверелә, биредә башлангыч дәүләт сыманрак Мангыт Йорты барлыкка килә, Алтын Урда заманында төзелгән Сарайчык каласы аның үзәгенә әверелә. Эмба белән Җаек буйларына күчеп утыру белән мангыт

бабаларыбыз Алтын Урда мәмләкәтенең сул канаты халкы санала башлый. Алар хәзер Алтын Урда ханнары кул астына керәләр. – Әшрәф Баба тагын касәдән су йоткалап алды. – Исеңдә калдыр, Сөембикә кызым, Хуҗа Әхмәд Төкләс Баба безнең халык өчен ике искиткеч зур эш башкарган затлардан ул. Беренчедән, халкыбызга мәҗүсилектән ислам кебек пакь дингә күчәргә ярдәм итсә, икенчедән, мангыт бабаларыбызга, яшәү өчен уңайлы буш далалар барлыгын күрсәтеп, аларга үз ватаннарын табарга юл ачкан шәхес ул. Шуңа күрә халкыбыз, аның изге эшләрен онытмыйча, һәрвакыт хәтерендә саклый.

Әшрәф Баба тынып калды. Бүлмәдә тынлык урнашты. Карт сөйләгән тарих Сөембикәгә нык тәэсир итте, аның шушы тынлыкны бозмыйча утырасы да, утырасы килде. Башында уннарча сораулар, күңелендә гаҗәпләнү катыш горурлык хисе уянды. Ул ундүрт яшендә туган җиреннән аерылып, күпме еллар үз-үзен дә, туган халкының тарихын да белмичә яшәде бит. Әшрәф Баба белән бүгенге күрешү, аның шулай шәкертенә аңлаткандай, барысын да җентекләп сөйләп чыгуы аңа шул кадәр күп нәрсәләр ачты, күңелен шулкадәр баетты, Сөембикә бу изге күңелле картка нинди рәхмәт сүзләре әйтергә белмичә аптырап утырды. Ләкин тынлык озаккарак сузылды бугай.

– Мөхтәрәм Әшрәф Баба! – дип, батыраеп башлады ул сүзен. – Синең белән бүгенге күрешү минем өчен иң бәхетле көннәремнең берсе. Син олы башыңны кече итеп, вакытыңны кызганмыйча, миңа шулкадәр күп нәрсәләр ачтың, мин синең яннан бөтенләй башка кеше булып кайтып китәм. Минем белән шулай ихлас сөйләшкәнең, үз-үземне, туган халкымны аңларга ярдәм иткәнең өчен сиңа чиксез рәхмәтемне белдерәм. Аллаһы Тәгалә сиңа саулык, озын гомер, яңадан-яңа ачышлар ясап, хозурланып яшәргә язсын.

– И-и Сөембикә кызым, Казан ханбикәсе дәрәҗәсенә ирешкән нугай баласыннан шундый сүзләр ишетү минем өчен дә зур сәгадәт. Мин дә бүген синең белән мөхадәсә кылып, зур ләззәт алдым. Казанга әйләнеп кайтуыңа, гомерең тәхет тирәсендә узачагына шигем юк. Үзеңнең кем икәнеңне, тамырларың кая барып тоташканын бервакытта да онытма. Дәрәҗәңне төшермә, башыңны горур тотып яшә. Бәхетле бул, кызым... – Әшрәф Баба урыныннан күтәрелде дә Сөембикә янына килде. Аңа үзенең сөякчел кулларын сузды. – Рәхмәт, кызым, килгәнеңә. Син миңа бүген чын бәйрәм ясадың. Сорауларың булса, тагын рәхим ит.

– Рәхмәт, Әшрәф Баба. Мин китим инде. Болай да вакытыңны күп алдым. Исән-сау тор, – дип, күңелен дулкынлану биләп алган Сөембикә чөйдән киемен алып киде дә ишеккә таба атлады.



Әлфия
Ситдыйкова

# МИН КЫЯДА БАСЫП ТОРАМ...

## Үзем бәйлим

*Кайсыгызның кулы җылы,*
*Бәйлисе бар йөрәкне.*
*Х.Туфан*

Җылы качты... Дөньясында бер учак юк җылынырга.
Күпләр мохтаҗ булып яши ихлас җылы, якты нурга.

Ничә тапкыр андыйларга җәлләмичә суздым кулым.
Кемдер аңлап рәхмәт әйтте, кемдер бүлде барыр юлым.

Кем сөйләде гайбәт итеп, имеш, ул дип беркем түгел.
Рәнҗемәдем, гайбәтләрдән өстен минем садә күңел.

Кемсә берәү көнләшүдән күрмәмешкә үк салышты.
Кайберәүләр аңа кушылып, кабатлады шул ялгышны.

Уңга карыйм, сулга карыйм, сирәгәйгән дуслар саны.
Тик мин тыныч, суындырмый бу вак борчу минем канны.

Дошманнар да кайчагында яшәү көче бирә икән.
Әрсез җилләр исә диеп, сыгылмый ул, сынмый имән.

Тугры дуслар янда калды. Һәрберсенең кулы җылы.
Соңгы учак сүнгәндә дә, җылытачак алар тыны.

Туңа калсаң, кил син, дустым! Кулым җылы, ышан миңа!
Йөрәгеңне үзем бәйлим, яшә генә, берүк туңма!

Әлфия СИТДЫЙКОВА (1957) – *шагыйрә; С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. «Утлы җимеш», «Тансык бәхет», «Яктылык сулышы» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

## Көмеш чык
***(триптих)***

**1**

Җәйге таң. Ямь-яшел үләндә
Энҗедәй ялтырый көмеш чык.
Бер чуар күбәләк гөл-таждан
Чык эчә, җилпенә... кыланчык.

Чыкларга чыланып атлый пар...
Тотынып кояшның нурына.
Бәхетле йөрәкләр кушыла
Бергәләп яңа таң җырына.

Сер тулы сылуның күзләре
Төбәлгән егетнең күзенә.
Керфек тә какмыйча тыңлый ул,
Мөкиббән һәр әйткән сүзенә.

Дөньяда беркем дә юк башка,
Әйтерсең, ул гына – табынган.
Сөюгә зарыккан йөрәктә
Сүрелмәс ут-ялкын кабынган.

Ямь-яшел келәмдә көмеш чык,
Түштәге төймәләр чәчелде.
Бәхетле елмайган күзләрдә
Нур тулган энҗедәй яшь инде.

**2**

Ал кояш нурында чык кибә,
Күр, пешкән хуш исле җиләкләр.
Ирендә сут тәме җиләкнең,
Күңелдә иң ихлас теләкләр.

Йөрәкнең бигенә яраган
Ачкычы төшмәсме кулыннан?
Болын киң. Тар сукмак офыктан
Офыкка кадәрле сузылган.

Атлыйлар икәүләп, соклана
Гөлләр дә: «Пар килгән бигрәкләр!»
Мәңгегә бер булып тибәрме
Сөюдән кабынган йөрәкләр?

Күбәләк канатын кагына,
Үбә ул гөлләрен болынның.
...Өлгергән җиләкне татыган
Сөюнең ул тугры колымы?!

Мизгеллек бәхеттән исереп
Кунмасмы башка чит гөлләргә?
Мәңгелек ярым дип ышанып,
Калмасмы яшь белән түләргә?

**3**

Җәйге таң. Ямь-яшел үләндә
Энҗедәй ялтырый көмеш чык.
Ак канат-күбәләк гөл-таждан
Чык эчә, җилпенә... кыланчык.

Чал чәчле пар йөри болында,
Аралап чык төшкән үләнне.
Басарга куркырсың, бигрәкләр
Җиләкле, чәчәкле келәме.

Өлгергән җиләкнең исеннән
Башларың әйләнеп китәрлек.
...Шушымы, кадерлем, әйт әле,
Без җиләк татыган кишәрлек?!

Яшь кыздай кызара битләре
Ак яулык ябынган гүзәлнең.
Энҗедәй ялтырый көмеш чык...
Бүләккә муенса тезәрлек.

## Юану

Үтеп китте яшьлек... Карап калдым...
Ап-ак иде кигән күлмәге.
«Сау бул!» – диеп дәштем, борылмады,
«Хуш инде!» – дип кулын бирмәде.

«Кире кайтыргадыр исәбе» – дип,
Юаттым мин шулчак үземне.
Бөре булып өмет борын төртте,
Кояш үпте сулган йөземне.

Яшәрепләр киттем... бер ым җитә
Яшәтергә өстәп көч һәм дәрт.
Күңел һаман унсигездә булгач,
Яши анда керсез мәхәббәт.

## Бар иде...

Бар иде авылның яшьнәгән,
Шаулаган, яшәгән чорлары.
Тыкрыкка, сукмакка, клубка
Сыймады яшьлекнең җырлары.

Урамга, яланга, кырларга
Таралды моңнары гармунның.
Җыр итеп таратты халкыбыз,
Яңгыратты дөньяга бар моңын.

...Искәндә үзгәреш җилләре,
Кызгана белмәде замана.
Искене сүттерү, ваттыру
Кызыктыр юлыннан язганга.

Кырларның хуҗасы – чүп үлән,
Арышлар очырмый серкәсен.
Таралды авылның өйләре,
Ятимлек басканга иңсәсен...

Урамда буш йортлар ишәя,
Моңаеп авышкан капкалар.
Авылым тураер шикелле
Киткәннәр әйләнеп кайтсалар.

## Синсез калгач

Мин кыяда басып торам,
Аска баксам, башым әйләнә.
Егылмаска теләп, ташка түгел,
Тотынып торам хыял-хәйләгә.

Синең иңнәр миңа терәк түгел,
Син еракта, миннән читләштең.
Башым каурый болыт итәгендә,
Тәмен тоям әче миләшнең.

Йөрәгемне яшен телмәде лә,
Китүеңнән җаным канады.
Язмыш күктән җиргә аткан чакта
Онытадыр, ахры, чаманы.

Дөньям синсез калгач, сыным катты,
Аңым кабул итми бу хәлне.
Болыт итәгенә башны салып,
Кыя тауның иң очына басып
Күзлим җанны яшен телгәнне.

## Өч аршын җир

Аттай җигелеп эшләп, хәлдән тайдым, –
дип уфтанма әле юкка да.
Эт көнедәй каһәрләнгән язмыш
Көтәр булса соңгы ноктада,
Үкенерсең чәчләреңне йолкып,
Еларсың да бәлки карганып.
Дөнья малы – дуңгыз каны ич ул,
Яши күрмик берүк алданып.

Гомер хакың күпме тора, бәндәм,
Аңла шуны тормыш иткәндә?!
Беркем үзе белән берни алмый,
Мәңгелеккә күчеп киткәндә.
Өч аршын җир көтә...
Өч аршын җир җитә...

## Аллаһка ялвару

Галәмне тәрбия кылучы
Аллаһ бар һәм Ул бер, инанам.
Әл-Вәли, юлымнан яздырма,
Аерма зиһеннән, иманнан.

Әгәр дә ялгышып кемнедер
Гаепләп сөйләсәм кешегә,
Ярлыка, Әл-Гафур, гайбәт сүз –
Зур гөнаһ, исемә төшер дә.

Догада оеган чагында
Әл-Вәһһәб, ялварам Үзеңә.
Тәнемә-җаныма саулык бир,
Җиткәндә гомерем көзенә.

Бүләгең – чын иман, хак дин һәм
Гамәлләр ихластан кылынган.
Картлыкта күрсәтче, Әл-Кәрим,
Шәфкатең кызымнан, улымнан.

Каршыңа киләчәк колың мин
Ахирәт, мәңгелек илендә.
Әт-Тәүүәб, Әр-Рахим, Әл-Гадел,
Әл-Галим, Әл-Газыйм Син генә!

## Юл күрсәттем

Үтә икән бу гомерләр
Искән җил кебек кенә.
Үпкәләмим тәкъдиремә,
Һичкемгә тотмыйм кинә.

Таулы-чокырлы юллардан
Барганда алга атлап,
Кара янып йөрмәдем мин,
Кояшның нурын каплап.

Юл күрсәттем адашканга
Чытырман арасында.
Җылы сүзем ямау салды
Йөрәкләр ярасына.

Сикәлтәле тормыш юлын,
Шөкер, сыгылмый үттем.
Шатлык яше белән юып,
Бәхетнең күзен үптем.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



*Илфак Хафизов Мөслим районының Рус Шуган авылында туа, Түбән Табын урта мәктәбен тәмамлый. 2004 нче елны Казан театр училищесына укырга керә, 2008–2014 нче елларда Казан федераль университетында читтән торып белем ала.*

*2008 нче елдан Кәрим Тинчурин исемендәге Татар Дәүләт драма һәм комедия театрында артист булып эшли. 2016–2018 нче елларда «Болгар радиосы»нда «Иртәнге чәй» тапшыруының редакторы була һәм алып бара. 2018-2019 нчы елларда «Мәйдан» телеканалында баш редактор булып эшли. 2019 нчы елның августында янәдән Тинчурин театрына кайта. 2018 нче елдан КФУда «Мизгел» яшьләр театрын җитәкли. 2021 нче елның октябреннән «Тәртип» радиосында «Тәртипле иртә» тапшыруын алып бара.*

*2016 елда «Идел» журналында «Нәргизә белән Таңсылу» дип исемләнгән хыялый хикәясе басыла. «Чаян» журналында, «Ватаным Татарстан» газетасында шигырьләре дөнья күрә.*

*Хатыны Альбина белән 3 кыз үстерәләр.*

Илфак
Хафизов

# ХИКӘЯЛӘР

## ИКЕНЧЕ ӘНИ

### Кереш

**Карлы-яңгырлы ноябрь көнендә булды бу хәл. Юешләнеп, туңып беткән кичне мин гомеремә җитәрлек җылылык алдым. Моңа кадәр «яшьләр үзгәрде» дигән сүзләрне үземә кабул итеп, киресен дәлилләргә тырышкан мизгелдә миннән дә яшьрәк егетләр бик яхшы сабак бирделәр. Бу әсәрдәге барлык кеше образлары чын тормыштан алынган. Вакыйгасы да, әйткәнемчә күз алдымда булды. Ни кызганыч, мин аның ахыргы мизгелләрен генә күрдем. Ә башын бераз хыял белән, егетләрнең сөйләвеннән чыгып язам. Шуңа күрә дөреслеккә туры килеп бетмәгән урыннар булса, ачуланмагыз.**

### Дима

Әллә салкын карлы яңгыр, әллә инде дөньядагы вазгыять кешеләрне кырыс, усал итеп бетерде?.. Менә бүген дә бәйрәм көн булуга карамастан, барысы да башларын аска игән килеш каядыр ашыга... Барлык эшчеләре дә килеп бетмәгән Мәскәү базары әкрен генә, көйсез бала кебек уянып килгән мәлдә Дима, пыр туздырып, чәчәк сатучы Венера ханым белән бәхәсләшә...

– Каян килеп өч мең? Кичә генә мең ике йөз иде бит.

– Кичә алырга иде. Бүген үзең беләсең – бәйрәм, – диде шактый гына олы яшьләрдәге кырыс булырга тырышкан Венера ханым. Тик аның эчкерсез күзләре, яхшы күңелле кеше икәнен әллә кайчан саткан иде инде.

– Менә шундый шул сез, кеше бәхетендә акча эшлисез, – дип, Дима бераз кызгандырмакчы булды. Тик көннәр буе нинди генә сүзләр ишетмәгән Венера ханым кашын да селкетми, үзенекендә торды. Үтенеп тә, Роспотребнадзор чакыртам дип тә янап карады Дима, тик ханым чигенмәде.

– Сез бит бары ике очракта гына чәчәк аласыз: хатыннарыгыз белән талашканда һәм бәйрәмнәрдә. Ә безгә аренда өчен түләргә кирәк. Бүген урак өсте, алмасаң, комачаулап йөрмә. Бар, иртә таңнан кәефемне кырма әле, – дип, Венера ханым борылды да чәчәкләр саклана торган суыткычка кереп китте. Шул мизгелдә Диманың башында искиткеч хәйлә туды. Ул урамга чыгып, бөтен базарны котлады. Һәм бары тик бүген, бәйрәм хакына, Венера ханымның кибетендәге чәчәкләр ярты бәядән сатылачагын, кичә генә өч мең торган бәйләмнәрне исә мең ярымнан гына сатып алу мөмкинлеге барлыгын, аларның да бик аз калуларын игълан итте.

Зур-зур роза төргәкләре тоткан Венера ханым суыткыч ишеген аерым осталык белән арт саны ярдәмендә генә ачып җибәрде. Көтелмәгән шаушудан сискәнеп китеп, чак кына егылмый, ишек янындагы урындыкка чүмәште. Рәхмәт төшкере. Безнең халык гади бит ул, очсыз дисәң, кирәкме, кирәк түгелме – сатып ала. Әгәр илле процент «скидка» дисәң, йолкып алырга да күп сорап тормас. Шулай итеп, бәләкәй генә чәчәк кибетендә кеше саны шул кадәр күп иде ки, кая ул метр ярым ара саклау, бер-берсенең өстенә басмасалар – рәхмәт әйтерсең. Ә иң алда күзләрен майландырып, өч мең акча тоткан егетебез тора. Венера ханымның иртәдән бирле көянтәгә охшаган авыз читләре, ниһаять, елмая башлады.

Дима, умарта күче кебек гөжләп торган кибеттән ике матур чәчәк бәйләме тотып чыкты. Аның икесе дә әниләренә иде. Карлы яңгыр никадәр генә бу шат күңелле егетнең кәефен төшерергә теләмәсен – берни дә барып чыкмады. Дима, түш кесәсеннән телефонын чыгарып, ватсап төркеменә «Зиратта күрешкәнчегә кадәр» дип яздыра-яздыра Шамил Усманов урамыннан атлый иде...

## Марат

Ватсапка язма килгәндә, Маратның ванна бүлмәсендә теш чистарткан чагы иде. Дөресрәге, теш щеткасын микрофон итеп тоткан килеш Элвин Грейны да уздырып, «Роза-роза – сөю гөле...» җырын башкара. Эх, дусты Рәдиф кебек көйне ишетә белсә икән. Юк шул, табигать аннан мәхрүм иткән. Шуңа күрә ул, фатир тутырып, бии-бии җырлый. Моңа кадәр Элвин Грей да ясый алмаган мондый шоуны плитәдәге чәйнек сызгыруы бүлде. Марат йөгереп чыгып, газны сүндерде. Су артык күп салынганлыктан, түгелә башлаган чәйнекне тиз генә күчереп куймакчы иде, кулы пешеп, әле генә матур җырлар яңгыраган Марат авызыннан, миңа монда язарга ярамаган катлы-катлы сүзләр бәреп чыкты. Кискен авыртуга түзеп кара әле син... Ул шунда ук кранны ачып, кулын салкын су астына тыкты. Аннан сул кулы белән музыканың тавышын кысты да:

– Гафу ит, әнием. Ялгыш ычкынды, – диде. Ул беркайчан да әнисе каршында сүгенмәде. Бәләкәй чакта, әлеге дә баягы дуслары белән «крутой» булырга теләп сүгенеп сөйләшә башлагач, әнисе аңа: «Чын егетләргә сүгенү килешми, бигрәк тә, янында хатын-кызлар булганда», – дигән иде. Шуңа

күрә Марат үзен бик гаепле санады. Үсмер чакта, егетләр генә булганда, үзара ычкындыргаласа да, менә инде 5 елдан артык аның, гомумән, сүгенгәне юк.

– Бәйрәм белән сине, әнием. – Ул үзен тиз генә кулга алырга тырышты. – Без бүген, гадәттәгечә инде, әнием. Соң кайтам, ачуланма, яме.

Ул кул астында гына торган кечкенә лейкага су тутырып, әнисенең гөлләренә су сипте. Аннан ашыгып кына киенеп, стенада эленеп торган зур фото янына килеп басты да:

– Яратам мин сине, әнием. Гафу ит, синсез чәй дә эчәсем килми. Ачуланма, – дип чыгып йөгерде.

## Сәйран

Сәйран, смс килгәндә, сазлыкка баткан машина тирәсендә маташа иде. Әле бер сәгать элек кенә көзгедәй ялтырап торган ботинкалар шактый гына саз ерган, кап-кара чалбарның балагы җыелган, юка кара куртканың җиңнәрен сызганган килеш лач-лоч атлап, ботак җыеп йөри. Ул күбесен тәгәрмәч астына тезеп куйды да берничәсен шофёр утыра торган ишек астына ыргытты. Ни дисәң дә, кредитка алынган «Ауди» машинасына пычрак ботинка белән утырырга ярамый. Сәйран дуслары арасыннан иң беренче булып, шундый кыйммәтле чит ил машинасы алган иде. Бу аның күптәнге хыялы. Ләкин текә әрмән малаеның хыялдан гайре бурычлары да бар.

Кайда гына, нинди генә хәлдә булса да, яңа ел төнеме, сигезенче мартмы һәм, әлбәттә, әниләр көнендә ул төп йортка, әнисе янына кайтып килергә тиеш. Биш кенә минутка булса да. Юк, аңа әнисе бернәрсә дә әйтмәгән дә булыр иде. Әмма бала чактан килгән әлеге йоланы Сәйран таш яуса да, бозмаячак.

Ул әкрен генә машинасын әле алга, әле артка тарттырды. Тик шәһәр асфальты өчен яратылган кыйммәтле чит ил машинасы, авыл сазыннан арына алмады. Болай да тиз кызып китә торган Сәйран ялгыш газ пидәленә ныграк басып җибәрде. Ни кызганыч, бу мизгелдә ул, тәрәзәсен төшергән килеш, ботакларның тәгәрмәч астына эләгүен үрелеп караган иде. Машина бер үкереп алды да, шофёрны суытырга теләгәндәй, якынча бер чиләк сазны, Сәйранның нәкъ битенә томырды. Ярый әле, ботаклары эләкмәде...

Кешенең холкы һәрвакыт киресен эшләргә күнеккән бит инде. Кая ул тынычлану, Сәйран, машинасыннан сикереп чыгып, бар көче белән алгы тәгәрмәченә типте. Әйтерсең бу хәлдән соң, аның тимер аты торып чабарга тиеш... Ул болынны яңгыратып кычкырып җибәрде. Нишләп шәһәрдә сәгатьләр буе бөкеләрдә утырган, меңләгән машиналарның берсе генә булса да, ялгыш кына үтеп китсен? Юк шул, шәһәр белән авыл аермасы километрларда гына түгел, елларда да исәпләнелә, ахры... Бераз тынычлангач, ул, битен сөртте дә, телефонын алып, БАНДА төркеменә бар булган вакыйганы сөйләп бирде.

## Айнур

Сәйранның зарын Айнур көлә-көлә руль артында тыңлады. Ул үзе, буйга нибары метр да алтмыш сантиметр булса, киңлеккә бер метрдан чак кына таррак иде. Дуслары аннан, «Легче перепрыгнуть, чем обойти», – дип еш көлсәләр дә, ул аларга үпкәләми. Чөнки «зур» кешеләр яхшы күңелле

булалар. Менә ул үзеннән чак кына зуррак булган совет «внедорожнигы» – «Нива» машинасында авылдан шәһәргә тупырдап торган сыр кисмәкләре ташый. Бу аның зур бизнес дөньясына беренче адымнары... Кешеләр бит хәзер теләсә нәрсә ашамый. Химия кушылмаган, чын ризык сорый. Сәламәт буласылары килә. Тик һич кенә дә, авылга кайтып, мал үрчетәселәре, яшелчәләр үстерәселәре килми. Ә нигә мәшәкатьләнергә? Акча барында Айнур кебек егетләр өеңә үк китереп бирергә мөмкин.

Ә Айнур иренми, тырыша. Аның бигрәк тә әти-әнисенә, сеңлекәшләренә булышасы килә. Ни дисәң дә, абый кеше абый булырга тиеш. Ул бер шалтырату белән, сеңлекәшләре янында була, аларны яклый, кирәксә акча бирә, яки укудагы вак-төяк эшләрен җайлый. Һәм әлеге серне беркайчан да әти-әниләр алдында ычкындырмый. Шуңа да аны сеңлекәшләре бик хөрмәт итә, ярата. Менә ул таныш адрес буенча килеп, Галимә апаларга сырын калдырды да, акчасын кесәсенә салып, Сәйран җибәргән геолокация буенча саздан чыга алмый тилмергән немец машинасына таба китте.

### Рәдиф

«Сәйран, гафу ит, мин килә алмыйм, соңрак аңлатырмын», – дип яздырып бетерде дә Рәдиф кабалана-кабалана, сәхнәгә чыгып йөгерде. Аның шырпы таягы хәтле генә нечкә аякларына, ян белән басса, үтәкүренмәле гәүдәсенә яңа кызыл концерт костюмы бик килешеп тора иде. Килешмәслек тә түгел... Ул аны тектерер өчен ничәмә-ничә туй-юбилейлар алып барды, тиененә кадәр санап җыйды.

Әллә шул кызыл костюм, әллә тамашачы залында әниләр генә җыелган булганга, Рәдифкә бик озак кул чаптылар. Хәтта биска тагын бер җыр сорадылар. Моңа кадәр кадет мәктәбендә укып, яңа гына сәхнәгә чыгарга теләгән Рәдифнең шул бер җырына гына аранжировка ясалган иде шул. Тик ул югалып калмады, сәхнә артындагы гармунчыны чакырып, «Су буеннан әнкәй кайтып килә» җырын башкарды. Ул аны үзәкләргә үтәрлек итеп, чын йөрәктән тамашачы залындагы әнисенә карап җырлады. Моны тамашачылар да бик тиз аңлап алдылар. Бу мизгелдә улының уңышын күргән Гөлфия ханымнан да бәхетлерәк кеше юк иде...

Бу җырга тамашачы тагын да күбрәк кул чапты. Хәтта берничәсе үзләренә бүләк иткән чәчәк бәйләмнәрен Рәдифкә бирергә теләделәр. Ул аларны алмады. Рәхмәт әйтеп баш иде дә: «Бу чәчәкләр бит бездән сезгә бүләк. Без нәрсә генә эшләсәк тә, сезгә булган рәхмәтебезне җиткереп бетерә алмыйбыз. Шуңа күрә гафу итегез, мин сезнең чәчәкләрегезне ала алмыйм», – дип, сәхнә артына чыкты.

Концерт тәмамланып, тамашачылар чыкканда, Рәдиф әнисен машинасы янында көтеп тора иде.

– Рәхмәт, улым. Бик матур җырладың, барысы да сине генә сөйлиләр.

– Ул кадәр үк түгелдер инде, әни, – диде Рәдиф бераз читенсенеп.

– Хагы шул, – дип дәвам итте Гөлфия ханым. – Син мине көтмә, иптәш кызларым белән бергә кайтырбыз дип килештек.

– Салкын бит, әнием, әйдә мин сезне үзем кайтарып куям, – дип кыбырсыды Рәдиф. Аның бер дә әнисен бу карлы яңгыр яуган көнне урамда җәяү йөртәсе килмәде.

– Борчылма, улым. Без башта кафега кереп чыгабыз, аннан такси

чакыртырга килештек. Үзең беләсең, Роза апаң бер сөйли башласа, сүзе тиз генә бетә торган түгел. Шуңа күрә син бар, дусларың көтәдер...

– Рәхмәт әнием, гафу ит, бүген соң кайтам инде, яме, – диде Рәдиф, әнисен кочаклап.

– Беләм, борчылма. Миннән дә сәлам әйт, – дип, Гөлфия ханым иптәшләре янына китте.

Сәгать инде ике тулып киткән, ашыгырга кирәк. Рәдиф телефонын алып, БАНДА төркеменә юлга чыгасын һәм бер сәгатьтән зиратта буласын әйтте.

## Тимур

Зират капкасына иң соңгы булып Рәдиф машинасы килеп туктады. «Без инде Айнурны синең арттан җибәрмәкче идек. Кая батып яттың болай озак? Бер сәгатьтән булам дигән кеше. Сәйран инде әнисенең тәмлүшкәләрен суктырып килеп җитте, ә син һаман юк...» – дип төрттерделәр дуслары. Рәдиф исә пәлтә якаларын күтәреп куйды да багажнигыннан чәчәкләр бәйләме чыгарды. «Фанаткаларыңның чәчәкләрен әрәм итмә инде, кайткач иснәп хозурланыр идең әле...» – дип көлә башламакчы иде Дима, Алинә аны бик тиз урынына куйды: ул Диманың кулын җай гына чеметеп алды. Дима нидер әйтергә теләп, Алинәнең күзенә караган иде, сихерләнгән төсле коелды да төште. Күрәсең, мәхәббәт дигәннәре шушыдыр инде.

– Йә, керәбезме инде? Бер дә кояшлы рәхәт көн түгел, – диде фырт киенгән һәм шунлыктан туңып та өлгергән Сәйран.

– Бисмиллагызны әйтергә онытмагыз, – дип искәртте Айнур.

Алинә җитез генә машинадан футбол җанатары шарфын алып, Димага сузды да, кочаклап, зиратка кермичә машинада гына көтәчәген әйтте. Дима аның бит очыннан гына үпте дә кысып кочаклап алды.

– Егетләр, без Диманы югалтабыз, ахры. Алинәнең итәгеннән аерыла алмый, – дип төрттерде Рәдиф.

Шул сүзне генә көткәндәй, Дима егетләрне куа китте. Алар зират эченә йөгерешеп килеп керделәр. Бары тик Айнур гына «уң аяктан» дип кычкырып калды. Әйтерсең, алар зиратка түгел, ә балалар бакчасында чабыша.

Мәчет манарасы төшерелгән мәрмәр ташта «Хәйруллин Тимур Илдар улы. 1996-2019» дип язылган иде. Биш дус бер сүз дә дәшми аның каршында басып торалар. Әллә карлы яңгыр тамчылары, әллә егетләрнең бәхетле хатирәләре яңаклары буйлап әкрен генә аска таба йөгерде. Алар бер-берсенә сиздермичә генә битләрен сыпырып алдылар да төп ниятләренә тотындылар. Айнур эченнән генә әбисеннән отып калган бисмилласын укыды, Сәйран белән Марат иске чәчәк калдыкларын, корыган яфракларын тазартты, Рәдиф исә матур итеп, яңа чәчәк бәйләмнәрен урнаштырды.

Тик берсе бер сүз әйтмәде. Әйтү кирәк тә түгел, чөнки алтынчы класстан бергә кадетлар мәктәбендә укыган егетләр бер-берсен сүзсез дә бик яхшы аңлый иде.

## Икенче әни

Әлфия апа белән без иртәдән бирле кибеттән-кибеткә ризыклар, көндәлекләр, машина өчен кечкенә догалык, көмеш беләзек һәм тагын әллә нинди мин аңламаган әйберләр җыеп йөрдек. Дөресрәге, хатыным Альбина

белән аның Әлфия апасы җыйды, мин ташыдым... Ярты көн машинада, карлы яңгыр астында йөргәнгәме, әллә кибетләрне яратмагангамы, кәефем бик кырылган иде. Сиздермәскә тырышсам да, Альбинадан яшереп буламы соң инде? Ул килеп колагыма гына: «Түз инде, бераздан бетә» дигәч тынычланам тагы. Гәрчә тиз генә бетмәгәнен бик яхшы аңласам да. Ярар, юкка-барга зарланмаска кирәк. Ни дисәм дә, Әлфия апага булышам бит.

Әлфия апа минем тёщамның (каенанамның) сеңлесе, ул Тимурны бәләкәйдән берүзе карап үстерде. Укытты, кеше итте. Киләчәктә таянычым, яклаучым булыр дип тәрбияләде. Тимур кадетлар мәктәбен тәмамлагач, аш-су остасы булырга укып чыкты, армиядә хезмәт итеп кайткач, эшкә урнашты. Кем сиңа яхшы урын белән әйбәт хезмәт хакы әзерләп куйсын, ди? Шуңа күрә Тимур каравылга эшкә урнашты. Вакытлыча, яхшырак эш табылганчы гына... Тик насыйп булмады... Төнлә бер явызы Тимурны атып китте. Тикшерүләр, эзләнүләр булды, ләкин берәү дә Әлфия апаның бердәнбер малаен кире кайтара алмады... Кайтара алмады. Ә бүген әниләр көне!..

Мин залда кыздырылган тавык ботларына, биш-алты төрле салатка, матур итеп туралган кыяр-помидорларга, пар бөркелеп торган өчпочмакларга ач күзләрем белән карап утырам. Дөресрәге, күрмәскә тырышып, телефонымда казынам. Ишектә звонок булуга, Әлфия апа алъяпкычын салып атты да, көзгедән үзенә карап, чәчләрен матурлап, ишек тоткасына тотынды. Ул бер мизгелгә икеләнгән кебек булды. Әйтерсең, нәкъ менә Тимур кайтып керер кебек тоелды. Авыр сулап куйды да, елмаеп, ишекне ачты. Анда стенада эленеп торган фотодагы алты кадет егетнең бишесе басып тора иде. Алар берәм-берәм эчкә уздылар. Һәрберсе кочаклашып исәнләште, бүлмәгә узды. Иң ахырга иртүк алган чәчәк бәйләмнәренең берсен тоткан Дима белән Алинә калган иде.

– Әни, таныш бул, Алинә. Минем йөргән кызым. Синнән хәер-фатыйха сорарга алып килдем.

– Хәер-фатыйхасын үз әти-әниеңнән сорарга иде, мин бит ул дәрәҗәдә түгел, – диде Әлфия апа, читенсенеп кенә. Ул җайлап кына, Алинә сузган күчтәнәчләрне алды.

– Алардан сорадым инде, менә сиңа күрсәтәсем килде.

– Хәзер, тукта әле! – Әлфия апа кинәт нидер исенә төшкәндәй, кухнядагы пакетларны актара башлады. Дима белән Алинә эчкә үттеләр. Өске киемнәрен салып, элеп маташканда, Әлфия апа алар янына килеп:

– Менә, йөрәгем сизгәндәй алган идем, сиңа булган икән, балам, – дип, көмеш беләзекне Алинәнең кулына кидерде.

– Нинди матур, – дип шатланып куйды да Алинә, салып, Әлфия апага сузды. – Кирәкмәс, бик кыйммәтле бит бу.

– Дима, улым, иртәгә үк өйләнсәң дә, риза. Бигрәк яхшы кыз тапкансың, молодец, – дип аркаларыннан сөеп, залга алып керде. Марат белән Рәдиф инде телевизордан музыкаль каналны кушкан, Сәйран компот бүлә башлаган, ә Айнур исә стенадагы фотоларны күзәтә иде.

Альбина кайнар ашлар бүлеп, барлык тәм-томнарны да чыгаргач, без мыштым гына киенеп, ишекне ачтык. Бу мизгелдә Әлфия апа Сәйранны яңа машинасы белән котлап догалык, Айнурга бизнесында төгәллек булсын өчен көндәлек, Рәдифкә матур кызыл күбәләк-галстук, Маратка кырыну машинкасы, ә Димага бик затлы колакчыклар бүләк итә иде.

Без саубуллашмый гына киттек. Аларны бүлдерәсебез килмәде. Сөйләшсеннәр рәхәтләнеп икенче әниләре белән. Ни дисәң дә, бүген бит Әниләр көне...

## ЗИРАТТА ҖЫР

Зират капкасы ябылуга, Зиннур абый, кулларын җәеп, тешен кысып бии башлады. Нинди бию икәнлеге дә, күңелендә нинди көй уйнаганы да билгесез, әмма һәр күзәнәге тартылып, һәр чәч бөртегенә кадәр ярсып бии иде. Ә яңаклары буйлап кайнар яшь ага...

Юк, ул акылдан шашмаган, ә бары тик әйткән сүзендә торды. Моны аңлаган янәшәсендәге берничә туганы, сүз дә әйтә алмый, үкси-үкси елады.

Бу аның тормыш законнарына, итагатьлелеккә, куркуга карата соңгы тамчы яшьләре иде.

Бу вакыйгадан соң 2-3 ай үткәч, коронавирус дигән афәт авылыбызны ярсып-ярсып кыра башлады. Көн саен диярлек 3-4 кешене больницага алып китәләр, күбесе өйләрендә авырый, явыз кабахәтнең кулы җитмәгән гаилә калмады да кебек... Беркөнне мәчет манарасыннан азан тавышы урынына хәзрәтнең зиратка кабер казырга чакыруы яңгырады. Халык чыкмый, һәркемнең яшисе, туганнарын саклыйсы килә. Мин дә куркам. Үзем өчен түгел, минем дә яшь балаларым, карт әти-әнием бар. Шулай да түзмәдем, берсенә дә әйтми-нитми, ындыр аркылы гына зиратка киттем. Капка ачык, кешеләр күренми. Тик бераз эчтәрәк кенә ниндидер моңсу җыр сузылган тавыш ишетелә. Зиратта җырласыннар әле. Якынрак килеп карасам, Зиннур абый икән. «Ай әле бик еракта идек без, җитмеш чакрым җирдән килдек без», – дип җырлый-җырлый, җир ата. Мине күргәч, танымаган сыман туктап калды.

– Бу мин, түбән оч урамы Шакир оныгы, – дим. Ул көрсенеп куйды да тагын казый башлады. – Кая, алыштырыйм, ял ит әзрәк, Зиннур абый!

Әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә туктыйсы килмәде, һаман казый, җирне ала да ярсып-ярсып, өскә ата. Үзе һаман җырлый. Күңелем әллә нишли. Моңа түзә алмаганлыктан:

– Зиннур абый, син бит кабер казыйсың, җырлама инде, – дидем. Ул шунда ук туктады да, көрәген калдырып, өскә чыкты. Рәнҗеттем, ахры... Телемне тыйсам, ни була? Олы кеше белән шулай ярыймы соң?

Ул ерак түгел яткан пластик шешәсен күтәреп, су эчте дә чардуганга терәлеп утырды. Мин, көрәгемне эләктереп, чокырга сикердем. Бер-ике көрәк алганнан соң, Зиннур абый миңа карап:

– Бу аның яраткан җыры иде.

Чыннан да, 20 елдан артык безнең мәктәптә физика һәм математика укыткан Роберт абыйлар безгә башка районнан күченеп килгәннәр иде. Алты ай элек кенә аның хатыны – рус теле укытучысы Роза апаны җирләгән идек. Балалары булмады. Минем качып килүем дә укытучыларыма булган хөрмәтем иде. Башкача булдыра алмадым.

– Бу дөньяда кешеләрне тыңларга кирәкми, ә күңелең кушканны эшләргә кирәк. Юкса соң булуы бар. Ә аннан үкенүдән башка чара юк. Менә мин бердәнбер кызымны югалттым. Бердәнбер! Бик үк яхшы әти дә була белмәдем үзем. Көн-төн эш дип чаптым, ә баламның үсеп җиткәнен

күрмәдем. Менә шушы кулларыма күтәреп, балалар тудыру йортыннан алып чыктым һәм менә шушы куллар белән кабергә салдым. Әйткән сүземдә торырга тырыштым. Барысын да эшләдем, тик бер үкенечем калды. Соңгы кыңгырау бәйрәменә бара алмадым. Эштә идем. Төнлә кайтканда, кызым капка төбендә утыра. Минем кайтканны күргәч, күз яшьләрен яшерергә теләп, кул арты белән сөртте дә читкә карады. Ни булды дип сорагач, бәйрәмдә барлык кызлар да әтиләре белән биегәнлеге, ә аның берьялгызы читтә калганлыгы ачыкланды. «Борчылма, кызым, туеңда биербез», – дип, вәгъдә бирдем. Бер ай, туйга бер ай вакыт калгач вафат булды.

Ул башка сүз әйтмәде, шешә бөкесен ачып, су эчте дә, «Ай, әле бик еракта идек без...» дип җырлап җибәрде. Зиратта җырлады... Мин дәшмәдем, күзләремне аңардан яшереп, кабер казуымны дәвам иттем. Ә күз алдымда Зиннур абыйның ярсып-ярсып биюен тойдым. Җырласын әйдә, күңеле ничек куша – шулай эшләсен.

## КҮРШЕ ЭТЕ

Бу вакыйга моннан бик күп еллар элек минем әбиемнәр авылында булды. Безнең каршыда Раил белән аның сеңлесе Фәйрүзә яши. Ә уң як күршеләренә, Рәзинә апага, җәй башлану белән оныгы Альбина кайта иде. Алар бик якын дуслар булып, бер-берсенә кунакка йөрешеп, уйнап үстеләр.

Бер җәйне Альбина кайтуына Раил белән Фәйрүзә чихуахуа токымлы бик матур эт алып куйганнар. Бәләкәй этләр бик тавышчан була шул. Альфредның нечкә, күңелгә ятышсыз ләң-ләң килүен күпләр яратмый. Ә Альбина исә этләрдән бөтенләе белән коты очып курка иде.

Беркөнне иртә белән Альбина Альфред күрмәсен дип, тавыш-тын чыгармый, Фәйрүзәләр капка төбенә килде. Кычкырса, этнең ишетүе бар. Ул вак таш алып, тәрәзәгә атты. Тик ни кызганыч, ташны Раил белән Фәйрүзә түгел, ә нәкъ менә Альфред ишетеп алды. Ул капка астындагы җилемне күтәреп, урамга атылып чыкты. Моңа һич әзер булмаган Альбина үзләренә таба йөгерде. Шәһәр баласы авыл эте белән ярыша аламы соң инде? Эт куып тота дигәндә генә, Альбина язмышының соңгы саламына ябышты. Дөресрәге, әбисенең такта коймасына сикерде. Авыл җирендә бит күршедән ким булмасын дип яшиләр. Бу яшел койманың да өске такталарын тигезләр өчен нечкә ап-ак рәшәткә кадаклаганнар икән. Эт инде корбанының беркая да кача алмавына инанган, ярсып-ярсып чәңгелди.

Әллә рәшәткә кагучылар үз эшләрен җиренә җиткереп эшләмәгәннәр, әллә шәһәр гамбургерлары ашап үскән Альбина гәүдәсенең авырлыгына түзә алмыйча, ап-ак рәшәткә гафу үтенгәндәй, бер шыгырдап куйды да урталай сынды. Шундый зур корбанының үз авызына төшүен һич кенә дә көтмәгән Альфред ләң дә дия алмыйча, җаны күккә ашты.

Раил белән Фәйрүзә аның өчесен, җидесен, кырыгын үткәрде. Алар хәтта Альбина белән бер ел сөйләшмәделәр. Ә икенче елга исә Альбинаны аю кадәр немец овчаркасы көтеп тора иде.



Галимҗан
Гыйльманов

# БАТЫР АСТЫ

хикәя

Авыл Сабан туенда Әлфәт өч ел рәттән батыр калды. Быел да батыр калачак. Ул үзенә ышана. Бөтен авыл аңа ышана. Бу бик мөһим: ышаныч. Чынлыкта, Әлфәт – иң гадәти кеше, иң гадәти көрәшче. Гадәти көрәшче һәр алышта җиңелергә мөмкин. Ә менә ул җиңә. Чөнки белә: аңа ышаналар. Бу ышаныч хакында аңа ел буе искәртеп, белдереп торалар. Авыл картлары, аркасыннан кагып: «Булдырасың», – дип китәләр. Әтисе белән әнисе дә олы итеп сөйләшәләр. Ышаналар. Күрше апалар ел буе яңа сауган сөт, аертылган каймак кертеп тора. Биргән чакта: «Минем сыерның сөте көч бирә», – дип әйтергә дә онытмыйлар. Очраган кызлар да елмаеп узалар. Ышаналар, димәк. Мәдинә генә елмаймый. Ләкин Әлфәт белә: ул күңеленнән елмая, күзләре белән елмая... Чөнки Әлфәт аңа ошый, ә ул – Әлфәткә. Алар әлегә, очрашканда, бер-берсенә баш кагып китүдән узмыйлар. Ләкин икесе дә белә: алар кайчандыр бергә булачак. Бәхетле булачаклар... Мәдинә дә аңа ышана. Башкаларга караганда ныграк та ышанадыр әле. Ышанмаса, былтыргы Сабан туенда батыр булып калгач, беркемгә карамыйча, бөтен мәйдан аркылы үтеп, баш-башларына пар аккошлар чигелгән сөлгене Әлфәтнең кулбашына салып китмәс иде...

Нишләптер, алар һаман якынаеп китә алмыйлар. Югыйсә бергә эшлиләр. Әлфәт ашлык амбарларына җитәкчелек итә: аның мөдире дә, механигы да, ә Мәдинә – ашлык җилгәрү цехында оператор. Алар икесе дә район үзәгендәге авыл хуҗалыгы көллиятен тәмамлап кайттылар, бергә укысалар да, аралашырга туры килмәде, икесе дә оялчанрак шул. Юаш, диләрме әле?.. Кайтып-китеп йөргәндә дә, нишләптер, юллары бергә туры килмәде. Әлфәт авылга ялгызы гына кайта иде шул. Кайчакта Рәлиф иярә. Сабакташлары җыелышып, юлга чыгып киткәндә, бер төркемдә укып йөргән әнә шул Рәлиф белән көллиятнең спорт залында милли көрәш серләренә өйрәнеп кала иде...

Ә менә быел... Быел башкача булачак. Сабан туенда батыр булып калсын гына әле! Шул көнне үк Мәдинә янына барып, аңа үз хисләрен белдерәчәк. Бу хакта Рәлиф белән дә сөйләшеп-киңәшеп алды. Тегесе: «Шәп булыр! Аның да күңеле синдә, бу хакта бөтен авыл белә...» – дип, басынкы, моңсу тавыш белән хуплап куйды. Кәефсезрәк ул бу араларда. Нindидер борчуы бар, ахры... Соңгы вакытта районнан килеп йөрүче бер кавказлы белән еш күрәләр үзен. Авыл өстенә, «Сәлмән дигән кара кешедән машина сатып алырга тели икән, ләкин акчасы җитми, имеш», дигән сүз дә чыгып алды. Рәлифнең кәефсезрәк йөрүен Әлфәт шуңа юрады. Ләкин дустының күңеленә бик якын барырга теләмәде ул. Имеш-мимешләргә ышанып, аны кыен хәлгә куясы килмәде. Очрашканда, кул бирешеп, арка кагышып кына күрешәләр дә, саубуллашу урынына: «Әзерләнәсеңме?» – дип, икесе ике якка китеп баралар. Аңлашыла инде: Сабан туена әзерләнү турында сүз бара. Бу сүзгә җавап биреп торасы да юк. Икесе дә әзерләнә, ныклап әзерләнә, чөнки икесе дә батыр калырга җыена...

...Әлфәт кабат йокыга китә алмады. Гел шулай: ул иртәрәк уяна да берәр сәгать уйланып ята... Барысын да кабат күздән, дөресрәге, күңелдән кичереп чыга: үткәнен дә, бүгенгесен дә... Хәтта киләчәген дә. Соңгы вакытта уйлары бер айдан соң узачак авыл Сабан туе тирәсендә бөтерелә. Менә хәзер дә ул үзен түшәктән күтәреп торгызып, урамга алып чыгып китәргә тиеш. Ул көн саен иртән шулай авыл читендәге әрәмәлек буйларын йөгереп урап кайта. Кыр уртасына тукталып, физик күнегүләр ясап ала, гаражлар яныннан үткәндә, ташландык машина шиннарын тәгәрәтеп йөртә... Анысы мәҗбүри дә түгел, күнекмә төрләндерү өчен генә туктала. Аның үз эшендә дә ашлык тутырылган авыр капчыклар җитәрлек. Күпме телисең, ат та ат!

Менә бүген дә ул күнегелгән сукмактан китте. Ләкин тәгәрмәчләр өеменә барып җитә алмады, аның каршына, җилкәсенә тимер торба салып, бил күнекмәләре ясаучы Рәлиф очрады.

– Нихәл, әзерләнәсеңме? – дип сорады Әлфәт, маңгаендагы бөрчек-бөрчек тирне бармак очлары белән сыпырып.

– Әзерләнәм, брат, хәлләр ярыйсы.

– Нишләп ярыйсы гына?

– Әй... Сорама лутчы. Бар инде мәшәкатьләр...

– Туктале-тукта... Мәшәкатьме, проблемамы?

– Әлегә үзем дә әйтә алмыйм...

– Ну, ярый... Әйтә ала башлагач, бер сөйләшербез әле, – диде дә Әлфәт тәгәрмәч шиннары өеменә таба китте. Ул арада Рәлиф тә, торбасын койма буена ташлап, үр буенда юк булды.

Берничә көннән авылга «Рәлиф машина алган» дигән хәбәр таралды. Аларны көллияттә үк машина йөртергә өйрәткәннәр иде, правага укып, вакыт үткәреп торасы булмагандыр, бердәнбер көнне Рәлиф яңа машинасы белән Әлфәтләр капка төбенә килеп туктады. Әлфәтнең төшке ашка кайткан чагы иде. Ашаган ашын калдырып, әнисенең битәрләвенә дә карамыйча, ул, бәрелә-сугыла, урамга атылып чыкты. Руль артында Рәлиф дустын күргәч, адымын акрынайтты...

– Нихәл? Ну, проблемалар хәл ителдеме? Күреп торам: барысы да тәртиптә, котлыйм, котлыйм...

Ишегеннән җәһәт кенә чыгып, аны «күрдеңме, брат» дигән кебек үзенчә кыланып ябып куйгач, күрешер өчен кулын сузды.

– Да, брат, тәвәккәлләдем. Ярты акчасы гына түләнсә дә, алып кайтырга булдым. Ничек тә җае чыгар әле...

– Чыгар, чыгар... Синең кебек егетләр җай тапмыймыни?! Яңамы?

– Юк ла, илле мең йөргән. Әлегә ярты хакын гына түләдем. Проценты да бар бугай... Анысын Сәлмән томанлы гына сөйләште. Каяндыр акча табарга кирәк, брат... Синдә шабашка юктыр?

– Юк шул. Чәчү чоры узып бара, уңыш чорына ерак әле... Үзебез дә күбрәк вак-төяк белән шөгыльләнәбез. Мехамбарга да график буенча чиратлап кына йөрибез...

– Алай икән... Ну... барыбер истә тот әле... «Озакка сузма», диде теге бәндә...

– Нинди кеше соң Сәлмән дигәннәре? Нишләптер, безнең авылга ияләште әле ул. Халыктан очсызга гына бәрәңгесен, ашлыгын җыеп ала да кайдадыр читтә кыйммәткә сатып кайта, имеш...

– Өй борынча бәрәңге соранып йөргәндә таныштым да инде мин аның белән. Брат, ай-һай сәер кеше ул. Серле. Күзләре дөрес карамый аның... Сак бул, яме...

– Үзең сакландыңмы соң? Бурычыңның процентын да белешмәгәнсең...

...Гөнаһ шомлыгы шул буладыр инде: берничә көннән Әлфәт янына Сәлмән үзе килеп чыкты. Күптәнге таныш кешеләр кебек әллә каян тавышын күтәреп исәнләште, иелә-бөгелә, ике куллап күреште.

«Кара» диләр иде, чынлап та, кояшта елкылдап, дулкынланып торган чәчләре, борын астына бөтерелеп җыелган мыеклары гына түгел, бөтен йөзе-бите, тәне дә кап-кара иде аның. Килбәтсез рәвештә бөкрәеп алга чыккан борыннары янында эчкә батыбрак торган күзләре дә кара... Ниндидер шаукымлы күзләр... «Хәзер мин сине үземә суырып алам» дигән кебек җанга үтеп карап торган бу күзләр бер дә йомылмый кебек тоелды Әлфәткә... Керфекләре кайчандыр бер өскә күтәрелгән дә, башка төшмәскә ант иткән, ахры... Әлфәт хәзер генә аңлады: шул шомландырып тора икән аның күңелен...

– Сәламәләйкум, братан!..

– Исәнмесез. Нинди братан булыйм мин сиңа, без беренче тапкыр күрешәбез. – Нигәдер Әлфәтнең әйбәт итеп каршы аласы килмәде бу шикле кешене. Шуңа да үртәлеп җавап бирде.

Кара кеше амбар башлыгының үртәлүенә игътибар итмәде. Котсыз йөзендәге ясалма елмаюын саклаган хәлдә ашлык җилгәрә торган җайланманы өйрәнә башлады...

– Син Әлфәт буласыңмы? Миңа ул чиряк иде… – Көтелмәгән кунак йомшак «ә» хәрефен «я»ләндереп сөйләшә икән. Димәк, чынлап та, Кавказ ягыннан… – Ашлык алырга килгян идем, братан…

Армиядән кайткан егетләр шулай «братан» дип сөйләшүчән. Димәк, анда да булып өлгергән бу адәм заты. Әлфәткә әле көзгә генә караласы...

Алай дисәң, аның Рәлиф дусты да шулай «брат» дип сөйләшә... Кыланчык. Тукта, нәрсә ди ул? «Ашлык» диме?

– Ашлык алырга?

– Әйе, ашлык. Ну, зерно...

– Нигә ул сезгә?

– Нигә дип... Сатарга инде! Тиешле урынга илтеп, киммәтряк сатарга. Акчя эшләргә....

– Юк, андый эшкә бездә ашлык юк.

– Не понял... Бөтен җирдә бар... Ә сездә юк?..

– Юк, спекуляция өчен юк...

– Мин бит бушка димим! Табыш уртак булачак: яртысы миңа, яртысы сиңа. Башкаларга егерме биш процент кына бирәм. Риза булалар... Син генә башка камырдан әвәләнмәгәндер бит?..

– Әйе, мин башка камырдан шул...

Чыгып киткәндә, кунак теш арасыннан гына:

– Ярар, истә калдырырбыз бу хәлләрне... Мин сине контрольгә куйдым, егеткәй... – дип «чыелдады».

Шул ук көнне Рәлиф килеп җитте.

– Ник кире бордың инде теге кара кешене? Унбиш-егерме капчык сатсаң, үзең дә бөтенәеп калыр идең, башкаларга да өлеш чыгарыр идең...

– Син әйттеңме аңа минем хакта?

– Әйттем шул. Машина акчасының процентын киметәм, диде.

– Ишкәнсең икән ишәк чумарын! Машина дип, бөтенләй акылдан язып барасың бит, Рәлиф!..

– Йә инде, ачуланма, брат. Дуслык хакына кичер... Болай булыр дип, һич уйламаган идем... Бик тә машиналы буласы килгән иде шул. Машина булмагач, кызлар белән дә эш пешми... Әнә Мәдинә дә сиңа китеп бара...

– Миндә дә машина юк бит, ни сөйлисең син, Рәлиф? Акылыңа кил, ә?!

– Анысы шулай икән... Ну, брат, нинди киңәш бирәсең соң? Нишләргә хәзер? Ничек котылырга ул кара адәмнән?

– Кире бир син аңа машинасын. Булыр әле. Иртәгә дөнья бетми бит...

Рәлиф дәшмәде. Шулай аерылыштылар. Әлфәт дустына төпле генә киңәш бирә алмады. Шуны гына аңлап калды: Рәлиф бу кара бәндәдән тиз генә котыла алмаячак... Машинасын да кире бирә алмаячак... Сәлмән кебекләр капкынына бер эләккән кешегә, гадәттә, йөрәк маеның соңгы тамчысына кадәр сыгып бирергә туры килә...

Теләр-теләмәс кенә машина ишеген ачып, шулай ук теләр-теләмәс кенә утыргычына утырып китеп барган Рәлиф ягына карап, Әлфәт озак кына басып торды әле. Ләкин барыбер нindидер фикергә килә алмады. Шулай да, дустын бу авыр хәлдә ташлап калдырырга ярамаганын күңеленә беркетеп куйды ул.

«Авыр хәл» озак көттермәде. Берничә көннән Әлфәткә «Рәлифнең йөзен җимергәннәр» дигән хәбәр килеп ирешде. Ул шундук дусты янына йөгерде. Түшәктә үк ятмаса да, Рәлифнең кеше күзенә күренерлек кыяфәте калмаган иде. Ул көтелмәгән кунакны үртәлеп каршы алды:

– Нәрсә, брат? Кызык карарга килдеңме? Ну, биреп карадым мин машинаны. Сөйләшеп тә тормадылар, дөмбәсләделәр дә китеп бардылар.

– Ә машина?

– Машина калды... Түлисе акчага шактый процент өстәп куйдылар... Шул булды.

– Бөтенләй сөйләшеп булмыймыни?

– Күреп торасың бит...

...Сәлмәннең икенче килүенә Әлфәт ныклап әзерләнде. Бу адәм актыгының тагын бер киләсен белә иде ул. Бандитларның кануны шундый. Ике «подход» ясала. Өченчесендә инде – кан чыкканчы, кайчакларда җан чыкканчы эләгешү... Кара бәндә көтмәгәндә килеп керде. Бу юлы ул үзе генә түгел, әзмәвердәй өч ир иярткән. Әнә – ашлык амбарына алып керә торган биек капка төбендә, бездә сезнең кайгыгыз юк, үзегез аңлашыгыз, дигән кебек, үзара гамьсез генә сөйләшеп торалар...

– Ну, егеткяй, уйладыңмы, ничек хәл итябез? Ничек хәл итсяк тә, кергян акчаның ун проценты гына синеке булачак.

– Ә мин башка вариант тәкъдим итәм. – Шунда Әлфәтнең башына әллә каян гына бер уй «сукты». Бу уйдан үзенә дә кызык булып китте. Һәм ул аны, зиһенендә артык чарлап тормыйча, шундук кара кешегә тәкъдим итте: – Әйдә, көрәшәбез. Кем җиңә – шуныңча була. Син бит Кавказдан. Ә анда барысы да көрәшә. Син дә көрәшкәнсеңдер, әнә билләрең ничек калын, тән-буыннарың төптән ныгып күтәрелгән... Ризамы? Көрәшергә ризамы?

– Күряшкяме?.. Риза... – Кара кешенең тавышы ишетелер-ишетелмәс чыкты. Ризалыгын бирсә дә, ул бу минутта шик-шөбһә эчендә изалана иде.

Әлфәт аңа артык уйланырга ирек бирмәде, уенның төп шартын да әйтеп салды:

– Әгәр син җиңсәң, үземә дигән ун капчык ашлыкны бүген үк чыгарып бирәм, җиңелсәң, бу авылдан юк буласың, һәм без башка күрешмибез...

Теге кеше чын кавказлы булып чыкты. Менә аның эчкә баткан күзләрендә очкын ялтырап китте, йөз-кыяфәтенә азарт чаткылары бәреп чыкты, һәм ул, ниһаять, телгә килде:

– Риза! Син «кара күряш» дигән әйберне беләсеңме? Беләсең кился, мин – шул күряш буенча Кавказ чемпионы. Курыкмыйсыңмы?

– Курыксам-курыкмасам да, хәзер соң инде. Сүземне әйттем, тәкъдим ясалды. Ризамы шуңа?

– Риза. Кайчан күряшябез?

– Хәзер үк, нигә сузып торырга?! – Әйткән сүзенә ышандырырга теләп, Әлфәт җиңнәрен сызгана да башлады.

Сәлмән, үз телендә дәшеп, иярченнәрен чакырды. Каян гына сизенеп алганнар диген, Әлфәт янына да амбарның төрле почмагыннан кыз-хатыннар, ир-атлар җыела башлады. Алар арасында Мәдинә дә бар иде.

Иң элек көрәш шартларын ачыкладылар. Кем дә кем, тәкмәч атыпмы, тәгәрәпме аркасы белән төшә – шул җиңелгән санала. Җиңелгәннең аягы җирдән кубарып алынган булырга тиеш. Монысы – иң беренче шарт. Шактый сатулашканнан соң, билгә билбау салып көрәшергә булдылар, шунда ук каяндыр ике сөлге дә табып китерделәр. Көрәшчеләр шулай ук бер-берсе белән сугышмаска, төртешмәскә, тырнашмаска сүз бирделәр. Төп шартлар татар көрәшенә туры килсә дә, кайбер алымнар Әлфәт өчен чит-ят иде. Моны көрәш башлангач ук аңлап алды ул. Кавказ якларында

аяк чалырга ярый икән. Беренче «бил кысышу»да ук Әлфәт, Сәлмәннең аягына абынып, артка авып китте, аркасы белән чәчрәп барып төшә язды. Бу хәл тагын берничә тапкыр кабатланды. Ләкин, алымнарын дөрес кулланса да, Сәлмән көндәшенең аякларын җирдән каерып ала алмады. Биле кысыла башлау белән, Әлфәт, арткы санын сузып, Сәлмәннең билбавын аркасы буйлап шудыра башлый... Шулай бер-берсенә бил бирмичә, бераз «биешеп» йөргәннән соң, Әлфәт үзе дә Сәлмәнгә «һөҗүм итеп» карарга булды. Ләкин төптән юан чыккан гәүдәне күтәрерлек көче юк иде аның. Бер генә юл кала: билбауны Сәлмәннең биле тирәли кысып, гәүдәсен үз гәүдәңә кочып алырга да арткарак авыша башларга!.. Шунда аның аягы җирдән кубарылырга тиеш. Һавада эленеп калган гәүдәне шушы бер мизгел эчендә үз гәүдәң белән сикертеп алырга да бер якка тәгәрәтеп җибәрергә... Шуннан соң, үз тирәсендә әйләнеп, очып барган гәүдәне куып җитеп, аны арка ягы белән җиргә сылап куясы гына кала.

Әлфәт шулай эшләде дә. Менә берзаман аяк өсте әүмәкләшеп йөргән килеш Сәлмәннең берничә алымын үткәреп җибәрде дә үзенең «татар көрәше»нә кереште. Ләкин кулындагы егәрлекне беләкләре буйлап янбашларына, аннары биленә таратканчы, янәшәдә басып торган авылдашларына карашын сирпеп алырга өлгерде. Башка йөзләрне йөгереп кенә узса да, урта бер җирдә кулларын йөрәгенә кушырып басып торган Мәдинәдә тукталыбрак алган кебек булды. Бик куркынган иде кыз. Йөзен чытып, иреннәрен кысып, йодрыкларын бер йомгакка төреп, үзенчә көч биреп торган кебек иде ул. Чынлап та, Мәдинәне күргәч, Әлфәткә көч кергән кебек булды. Һәм ул кочагындагы әзмәвердәй гәүдәне читкә атып бәрде...

Янәшәдәге ашлык өеме янына чәчрәп барып төшкән Сәлмән янына шундук иптәшләре килеп җитте. Әлфәт үзе дә, сөлгесен хатын-кызлар ягына ташлап, әле һаман ахылдап, торалмыйча яткан «кара көрәш» остасы янына юнәлде. Кулын биреп, тартып торгызырга теләде. Ләкин тегесе Әлфәтнең ярдәменнән баш тартты. Икенче караганда, ул, дусларының янбашларына таянып, аксаклый-туксаклый, амбар капкасыннан чыгып бара иде инде. Әлфәт тә тизрәк эчкә, үз конторасына кереп китү ягын карады. Аны үз ишегенә кадәр һаман әле амбар уртасында җыелып басып торган кешеләрнең: «Булдырдың, Әлфәт!», «Чын егет икәнсең!», «Татарларны хур итмәдең!» дигән сүзләре озата барды. Бу сүзләр арасында Мәдинәнең «Ярдәмеңнән ташламадың, рәхмәт сиңа, и Раббым» дигән сүзләре Әлфәтнең ярсынган йөрәгенә шифалы дәва булып ятты.

...Сабан туе көне якынлашты. Инде колга күтәреп, урам әйләнеп, бүләк җыеп чыктылар. Бала-чага: «Кар-кар!» дип, «Карга боткасы»нда йөреп кайтты. Халык бәйрәменә өч көн кала Әлфәт иртәнге разминкасына чыкты. Әрәмәлек буенда Рәлифне очратты. Ул да әзерләнә, аның да Сабан туенда батыр каласы килә. Быел аеруча үҗәтләнеп әзерләнә. Үзенәме, әллә тагын берәрсенәме, үзенең баш батыр булуын расламакчы була, ахры. Бу юлы да сүзе шул хакта. Хәтта ялынып-ялварып сорарга да кыенсынмый:

– Әлфәт, брат, быел җиңәргә бир миңа, ә?! Беләм, мин сине җиңә алмыйм, ләкин син миңа җиңелә аласың... Бер ел... Бары бер елга... Беренче һәм соңгы мәртәбә сорыйм. Шулай кирәк!..

Әлфәт берни аңламады. Җиңәм дип инде... Кеше шулкадәр түбәнлеккә төшәр икән...

– Аңламыйм мин сине, Рәлиф. Син бит мондый түгел идең... Кайда синең егетлегең, горурлыгың кайда? Син бит көчле. Тырышсаң, мине дә җиңә аласың... Без бит бер чамада көрәшәбез. Каударланма гына, ашыкма, уйлап көрәш. Көрәштә көч беләктә түгел, башта, зиһендә. Аннары... йөрәктә. Йөрәк белән зиһен дус булырга тиеш... Оныттыңмы әллә? Безне көрәшергә өйрәткән агайлар шулай диләр иде. Әйдә чын-чынлап көрәшәбез. Көчебезне көрәштә күрсәтәбез, көрәшеп раслыйбыз. Мин шулай гына булдыра алам, калганы минем табигатемә каршы килә...

– Их син, Әлфәт, аңламыйсың мине!.. Мин боларны синең өчен сорыйм. Синең җиңелүең үзең өчен дә кирәк. Барысын да әйтеп бетерә алмыйм, әмма сак бул, брат, синең җаның белән уйнамакчы булалар...

– Кемнәр? Йә әйт, тагын теге кара кешеләр юлга аркылы төшәме әллә? Сабантуйга, көрәшкә аларның ни катнашы бар?

– Мин башка берни дә әйтә алмыйм. Йә, хуш, Сабан туенда, көрәштә очрашканга кадәр! Тырышырмын. Җиңәргә тырышырмын... Шулай кирәк... Брат...

Әлфәт тәмам аптырашта калды. Быелгы Сабан туен шулкадәр борчулы булыр дип уйламаган да иде. Дустының ниндидер күңелсез хәлгә калганын аңлый ул. Шул машина белән бәйләнмәгән булса соң!.. Юк-юк, Рәлифнең борчуы күбрәк Әлфәт белән бәйле, ахры... Бу кадәр ярсынмас, өзгәләнмәс иде. Нәрсә ди? Син – җиңелергә, мин җиңәргә тиеш, диме?... Кем аны шул хәлгә китереп җиткергән? Ашлык сорап йөргән бәндәләрме?.. Алай дисәң, алар теге көннән соң авыл тирәсендә күренмәделәр... Шулай да, Рәлиф сүзенә карап кына, бил бирәсе килмәде Әлфәтнең. Ул җиңәргә тиеш! Калганын Сабан туеннан соң хәл итеп бетерерләр... Ул бит хәзер үзе өчен генә көрәшми, ә үзенең исем-аты өчен, ата-бабасы, ата-анасы өчен, аңа ышанган авыл кешеләре өчен көрәшә, аннары... Мәдинә өчен, аның белән бергә узачак алдагы гомере өчен...

Күңел борчуын баса алмагач, Әлфәт берничә мәртәбә Рәлифләргә кереп чыкты, хәлне ачыкларга теләп, теге кара адәмнәрне дә эзләп карады, әмма ни дустын, ни Сәлмәнне туры китерә алмады. Менә ул, бераз тынычлангандай булып, бөтен игътибарын булачак көрәшкә бирде, Сабан туена ныклап әзерләнергә кереште... Соңгы ике көндә режимын тагын да кискенләтте, ашау-эчүгә дә талымланды. Йомыркаларны чи килеш кенә эчте, ат ите, казылык капты, йөргәндә дә, кузгалак чәйнәп йөри башлады...

...Сабан туенда көрәш нәкъ Әлфәт уйлаганча килеп чыкты: кояш өйләгә күтәрелеп җиткәндә, мәйданда ике генә кеше калды: булачак батыр һәм... батыр асты. Кем кайсы булыр?.. Көрәшне оештыручы абзыйлар, аларны бер-берсе белән очраштырмыйча, махсус рәвештә шулай иң ахырдан тәмләп көрәштермәкче булдылар, ахры. Һәркем белә бит: Әлфәт белән Рәлиф – авылда иң оста, иң көчле көрәшче егетләр. Һәм ахырда алар көрәшергә тиеш! Финалга очраклы кешеләр яисә чит-ятлар үтмәсен өчен дә эшләнә бу. Авыл Сабантуйларының үз кануны.

Финал алдыннан ун минутлык ял игълан иттеләр. Әлфәт күңелсез

күренә. Шулай үз эченә бикләнеп көрәшкә әзерләнәме? Элеккеге борчулар тынгылык бирмиме?

Әлфәт, авыр гына кузгалып, Рәлиф янына китте. Дусты аны күтәрелеп карамыйча гына каршы алды. Киресенчә, Әлфәт аның күзләренә карарга тырышты, шул күз карашларында Рәлифнең уйларын, эчке күңел гамен белергә теләде. Шундук аны чигә тирәсендәге тырналган урыннар, ирен читендәге җәрәхәт җәлеп итте. Юк, бу галәмәтләр – көрәш яралары түгел, ә яман кеше кулларыннан калган эзләр...

– Ни хәлләр?

– Ярыйсы.

– Тагын нәрсә булды? Йөзеңне кем «сыйпады»?

– Анысы нигә сиңа? Егет кеше ярасыз булмый...

– Рәлиф, мин синең белән чын-чынлап сөйләшмәкче булам. Дөресен генә әйт әле – нәрсә булды?

– Әйтсәм, шуннан нәрсә үзгәрә? Әйдә, барысын да көрәштә ачыклыйбыз. Бу хакта сөйләштек, килештек бит инде. Мин үзем сиңа тиз генә җиңелергә теләмим. Мин сине җиңәргә телим, шуны бел. Бу минем өчен бик мөһим.

– Ни өчен мөһим? Ник әйтеп бетермисең? Әйдә, егетләрчә сөйләшик әле. Теге көндә сөйләшкәннәрне оныт. Йә, нәрсә булды, Рәлиф?

Рәлиф җавап бирмәде, аяк астыннан үлән кыягы өзеп, ирен читенә кыстырды да, әллә җәрәхәт әрнешеннән, әллә уйларының очына чыга алмыйча, йөзен чытып куйды. Ләкин дәшмәде.

– Син дөресен әйтмичә, көрәшкә кермим, Рәлиф. Мин бит сизәм: бер авыр хәл бар монда. Һәм син бу хакта әйтергә тиеш...

– Җиңелсәм, мине юк итәчәкләр, Әлфәт.

– Нәрсә? – Көтелмәгән җаваптан Әлфәт торып ук басты. – Син ни сөйлисең? Бу заманда андый хәлнең булуы мөмкинме? Шаяртмале, Рәлиф!..

– Нинди шаярту, ди... брат... Әле генә ике көн таш базларында ятып чыктым. Үзем тиле булдым. Шул машина аркасында килеп каптым. Хәзер сиңа үчләшергә җыеналар. Миңа шарт куйдылар: «Ашлык хуҗасыннан җиңелсәң, юк итәбез», – диделәр. Шуңа күрә миңа ничек тә җиңәргә кирәк. Һәм мин җиңәчәкмен дә!

– Ярый, ярый, ә минем нинди катнашым бар?

– Ашлык бирмичә, кәефләрен җибәргәнсең... Алар, авызымны дөмбәсли-дөмбәсли: «Дустыңның кәефен ничек җибәреп була?» – дип сорадылар. Ә мин: «Җиңелсә, кәефе китәчәк», – дидем. Менә шул, алар миңа сине җиңәргә куштылар. Шул очракта гына безгә тимәячәкләр... Хәтта машинаның процентларын да кичерергә булдылар... Бу шундый уен, Әлфәт, әшәке уен!

– Ну бит... мин сине җиңәчәкмен, Рәлиф!..

– Беләм, Әлфәт. Ләкин мин дә тырышачакмын... Тырышачакмын! Башка юл калмый... Син юкка килдең минем янга. Хәзер сиңа кыен булачак... – Болай килешик, Рәлиф: чын-чынлап көрәшик. Көрәш барышында барысы да хәл ителер. Син ризамы?

Рәлиф дәшмәде. Әлфәт дустының кулбашына җиңелчә генә кагылып алды да үз урынына китте.

Ул арада егетләрне мәйдан уртасына чакырдылар. Мәйдан халкы

көрәшчеләрне кул чабып каршылады. Судья урынына баскан Зиннәт абзый берәм-берәм сөлгеләр бирде. Егетләргә генә ишетелерлек итеп, төп кагыйдәләрне исләренә төшерде, көрәш вакытында тыелган алымнарны әйтте. Соңыннан: «Йокламагыз, көрәшегез!» – дип, үзенчә дәртләндереп куйды.

Әлфәт тә, Рәлиф тә көрәшә белә. Бу якларда аларга тиңнәр юк. Егетләрнең беренче хәрәкәтләреннән үк шул аңлашылды: көчләр тигез, көрәш озак барачак, шуңа күрә кызык та, мавыктыргыч та булачак! Чын көрәшкә сусаган халык тын да алмый күзәтә башлады. Берничә минут үткәч кенә, әле Әлфәткә, әле Рәлифкә карата әйтелгән киңәшләр ишетелә башлады. Иң элек Рәлиф талпынды. Ул хәтта Әлфәтне күтәреп ала язды. Билен сузып өлгермәсә, билләһи, күтәреп сала иде аны. Ләкин барыбер янтаеп, тәгәрәтеп җибәрә алмас иде, Әлфәт чүгәләп өлгерде... Шуңа күрә тезләренә төшү белән чикләнделәр. Зиннәт судья беренче тапкыр шелтәләп алды:

– Нәрсә сез, маңка малайлар кебек кыланасыз?! Торыгыз тезегездән!

Аннары Әлфәт Рәлифнең биленнән кысып алды. Тегесе, үзе дә сизмәстән, тонык кына аваз чыгарып, аһылдап куйды. Кабырга! Сынык кабырга... Әлфәт ничек сораганын сизми дә калды:

– Кабыргамы?

– Әйе, кичә берсе тибеп сындырды... Көрәш давай, ник биеп торасың?! Жәлләмә! Түзәм мин...

– Син үзең көрәш. Әйдә күтәр... Тизрәк хәл итик, син озакка чыдамаячаксың...

Тагын Зиннәт судья килеп җиткән.

– Сөйләшне туктатыгыз! Җәһәтрәк, җәһәтрәк, егетләр! Йокламагыз!

Чынлап та, егетләр җанланып киттеләр. Аеруча Рәлиф ныграк көчәнә башлады. Бераздан ул ике баллга, аннары тагын бер баллга ия булды. Әлфәт бер балл белән көрәшүендә булды.

Тиешле вакыт узгач, Зиннәт егетләрнең сөлгеләрен билләренә бәйләргә кереште. Шушы берничә мизгелдә Әлфәт бөтен мәйданны сөзеп карап чыкты. Кемнедер эзләдеме – үзе дә төгәл генә әйтә алмас иде. Мәдинәне күреп алгач кына, нәкъ менә аны эзләгәнен аңлап алды. Кызның йөзе моңсурак иде. Әлфәтнең карашы белән очрашкач, үзенең күңел халәтен белгертергә теләмичәме, борчулы карашын читкә алды. Нидер сизенә кызый, сөйгәненең күңел дулкыннарын сизенә, ахры... Әлфәтнең күңеле бүген иләс-миләс шул...Сер бирмичә көрәшергә тырышса да, күңеленең һәм зиһененең ерак бер почмагында бәргәләнгән уйдан һич котыла алмый ул: «Җиңелергә кирәк булачак, дуслык хакына, изгелек хакына, фаҗига алдында торган җан бөртеге хакына!..» Кыен хәлдә калган дустын, коткарса да, ул гына коткарып калачак. Тик... бөтен хикмәт тә шунда: халык, бигрәк тә теге кара кешеләр, Әлфәтнең юри җиңелгәнен белергә тиеш түгел.

Тарткалаш дәвам итте. Рәлиф тагын бер балл алды. Бандитларны үз җиңелүенә ышандыру өчен Әлфәт чиста җиңелергә тиеш. Рәлиф тә белә моны. Рәлиф тагын шуны да белә: кызганып, Әлфәт аның билен ныклап кысмый, нык кысмагач, алымын да эшли алмый... Бу хәлне Зиннәт судья

да аңлап алды булса кирәк. Бер тукталган арада ул Әлфәтнең аркасыннан шапылдатты:


– Әлфәт, син дөрес эшләмисең... Өйрәнмә мондый кәсепкә... Көрәш!

Тагын көрәшеп киттеләр. Тагын берәр балл алдылар. Әлфәт нишләргә белмәде, болай биеп тә йөреп булмый бит инде, ләкин дустының сынык кабыргасын умырып-каерып та ала алмый лабаса!.. Тагын нидер уйларга, нидер хәл итәргә уйлады Әлфәт, әмма аның бу уйлары дөнья йөзендә өзгәләнеп-чәбәләнеп калды, ул үзенең җирдән кубарылуын тойды, ләкин билен артка ташларга да, аска чүгәләп, Рәлифнең кулларын аркасы буйлап өскәрәк шудырырга да соң иде инде. Ул, аяк астында җирне югалтуга ук, бер якка янтая барып, Рәлиф гәүдәсе аша тәкмәчләп, келәмгә барып төшүен сизми дә калды. «Дыңк!» итеп килеп төшкән Әлфәт озак ятмады, ә менә җиңүче Рәлиф чалкан яткан җиреннән тиз кузгалып китә алмады, аңа Әлфәт торырга булышты, шунда ук дустының кулын өскә күтәрде. Зиннәт судья да хөкемен җиткерде:

– Чиста! Рәлиф батыр калды!.. Әлфәт – батыр асты...

Мәйдандагы халык кул чабаргамы-юкмы дигән кебек бермәл тынып калды, аннары гына дәррәү алкышларга тотынды, төрле яктан хуплап кычкыра-сызгыра башлады... Авылның яңа батырын тәбрикләргә авыл кешеләре берәмләп тә, төркемләп тә, мәйдан уртасына ашыкты... Алар арасында Әлфәт белән Мәдинә генә юк иде. Ә, әнә алар – бер читкә барып басканнар да, кулга-кул тотынышып, күзгә-күз карашып, нәрсә турындадыр кызып-кызып сөйләшәләр... Бераздан алар мәйданнан ук чыгып киттеләр, дусларын эзләп, ары-бире чапкан Рәлифнең һаман ерагая, тоныклана барган тавышын ишетеп, елмаешып куйдылар. Иңендәге чигүле сөлгене ике куллап, баш очына күтәргән Әлфәт бу мәлдә ике канатын як-якка җилпеп, офыкка таба очып баручы кошны хәтерләтә иде...

...Кичкә кадәр алар шулай авыл читендәге тау битендә утырдылар, Сабантуй мәйданыннан кайтып, үз йортларында мәҗлес корып, күңел ачарга керешкән авылдашларын күзәтә-күзәтә, үзләренең якын киләчәктәге яшәеш-тормышлары, ният-хыяллары хакында гәпләштеләр. Алар үз хыялларында шулкадәр мавыгып киткәннәр иде ки, хәтта, батырның иңбашына тәкә салганнарын да, бәйрәмнән соң Рәлифнең, ындыр артыннан гына килеп, Әлфәтләргә кереп киткәнен күрми дә, сизми дә калдылар.



*Әзрәт Али улы Акбаев – танылган карачай-балкар язучысы, шагыйрь, публицист. Карачай автономияле өлкәсенең Карачай районындагы Югары Тәберде авылында туа. Бала чагы Казакъстан һәм Кыргызстан республикаларында үтә, шунда биш мәктәптә укып, башлангыч белем ала. Туган иленә әйләнеп кайткач, Сарытөз һәм Югары Тәберде мәктәпләрендә, Карачай шәһәренең 3 нче мәктәбендә, Черкесск шәһәрендәге интернат мәктәптә укып, урта белем ала. Карачай-Черкес дәүләт университетында, Россия Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте академиясендә укый. Әзрәт Акбаев Карачай-Черкес Республикасында төрле җаваплы эшләр башкара, РФ Дәүләт Думасы депутаты була. Ул – юридик фәннәр кандидаты, Петровский Академиясе академигы, Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия һәм СССР Язучылар берлекләре әгъзасы. Россия Язучылар берлеге идарәсе секретаре. Карачай-Черкес Республикасының халык шагыйре.*

Әзрәт
Акбаев

# БЕЛГӘНЕМНЕ ЯЗАМ МАНЫП КАНГА...

## Сынау

Хәтеремдә: сабый балаларның,
Вәхшилектән шашкан аналарның,
Гарипләрнең, хәлсез калганнарның,
Яу кырыннан кайткан солдатларның:
«Нәрсә өчен безгә бу җәза?!» – дип,
Җан ачысы белән сораулары.

Барысы алар минем хәтеремдә:
Котлар очты язмыш хәтәреннән.
Билгесезлек аңны томалады,
Кайгы карчыгасы канатланды
Замананың мондый дәһшәтеннән.

Телсез калды зирәк аксакаллар,
Кемнәр генә бу халәтне аңлар,
Хәтта куе ап-ак сакаллары
Юка гына кара кайма белән
Тиз арада матәм төсе алды.

Кавказ халкы, син бик күпне күрдең,
Мең терелеп, янә мең кат үлдең,
Әмма яшәү көчле – моны белдең.
Күпме кеше юлда харап булып,
Казакъстанда, Урта Азиядә
Ачтан газапланып, янып, туңып
Интеккәндә, барыбер исән калдың,
Тарихыңнан өмет уты алдың.

Карачайлар, балкарлар, төрекләр,
Чеченнар, ингушлар һәм калмыклар
Бер язмышны уртак итеп барды.
Яуда дошманнарны җиңсәгез дә,
Тиран сезне корбан итеп чалды.
Әйе, өндә булды бу вакыйга,
Бу вәхшилек мәңге сыймас аңга.
Товар эшелоны төшкә керә...
Белгәнемне язам манып канга.

Күрсәгез сез әгәр юл буенда
Калкулыклар яки түмгәкләр,
Ул – каберләр, бер гаепсезләрне
Ашыга-ашыга шунда күмгәннәр.

Хәтеремдә: чәчен йолкый-йолкый,
Ана елый, дәшә кемнедер,
Күзләредә – каргыш, чарасызлык...
Бәлки аның соңгы көнедер.

Тау халкының изге аналары
Буш җирләрдә йөрде каңгырап,
Тирә-якка, яман набат булып,
Авазлары торды яңгырап.

Хәтерем бар минем! Хыялым да.
Ул хыялым тынгы бирми җанга –
Иң күренеп торган берәр җирдә
Урын кирәк бөек бер һәйкәлгә –
Чиксез газап чиккән аналарга,
Балачагын җуйган балаларга,
Бер гаепсез изге корбаннарга
Һәйкәл куйыйк!
Шул хыялым тынгы бирми җанга.

Төзәлерләр микән бу яралар,
Эрер микән күңелдәге бозлар?..
Дәвалы җәза син, и Хәтерем,
Үндүрт елны саклыйсың син һаман, –
Беркайчан да онытылмаслык еллар.
Рәхмәт, Хәтер, синнән башка мин кем?
Син бит бүген минем иң зур милкем.
Безне читкә үтерергә куганда да,

Тамырларны саkладың син аңда,
Илдән аермадың син, Хәтерем.

Оныттырма, Хәтер, тираннарны,
Хөкем итә дөньялык аларны.
Җиңү мөмкин түгел икән халыкларны,
Җиңеп булмаган күк бу тауларны.

## Ышану

Вакыт җиле үзе белән алып китә
Җирдә яткан сары яфракларны,
Себерә җил чүпне, тырыша ул
Күрсәтмәскә җинаяти пычракларны,
Онытсыннар өчен үткәннәрне,
Вәхшиләрнең кылган гамәлләрен.
Тик хәленнән килми аның арындыру
Кешеләрне үткен күзле хәтереннән,
Газап уйган күңелдәге җөйләреннән.

Бик күп төрле була икән ул яралар,
Тынгы бирми, бимазалый җанны алар,
Төзәлмиләр кайберләре, бетми икән,
Вакыт җилләренең көче җитми икән.

Ул яралар сыкрый, үткәннәрнең
Кайтавазы булып гомерләргә,
Чыдаса да ул газапка, һәрбер кеше
Үзе белән алып китә аны гүргә.
Себерә җил, илтеп түгә тираннарны,
Бирә тора Ходай җиргә балаларны,
Ә шулай да яраларның саркый каны,
Кем дәвалар михнәт күргән аналарны?!
Уйлап куям: әллә җилләр искән саен,
Җәрәхәтләр тагы да ныграк сызлыйлармы?


Халыкларны изгән бөек «юлбашчылар»
Китеп барды күз күрмәгән тарафларга,
Нигә һаман сызлый икән бу яралар,
Ник җылый җил ята-ята ап-ак карга?..

Күз карашын төбәп күкнең үзәгенә,
Мәрхәмәтлек өмет итә таулар иле,
Хакыйкатькә уңай урын эзли-эзли,
Җирне тырный көне-төне Вакыт җиле.

*Карачай-балкар теленнән* **Зөлфәт ХӘКИМ** *тәрҗемәсе.*

# «ДИН БЕЛӘН ФӘН ТОРА...»

## ХАРИС ХӘЗРӘТ САЛИХҖАНГА – 95 ЯШЬ



*Россия Гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы, дин галиме, Бөек Ватан сугышы ветераны, Татарстан Эчке эшләр министрлыгының «Хәтер» мәчете имам-хатыйбы, милиция полковнигы Харис хәзрәт Салихҗан әдәбият дөньясында да үз кеше. «А.Пушкин, Г.Тукай иҗатында дөньяви һәм дини мотивлар һәм бүгенге көндә әхлакый тәрбия бирү проблемалары» дигән монографиясе өчен ул 2017 елда Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнде. Тукай иҗатындагы Коръән мотивларын дин галиме буларак тикшергән әлеге хезмәт беренче һәм төгәл, тулы булуы белән милли мәдәниятне тагын да баетып, Тукай шәхесенең, шагыйрьнең мирасында тәрбияләнгән буыннарның рухи офыкларын тагын да киңәйтеп җибәрде.*

*Хезмәтнең авторы Харис хәзрәт быел 95 яшен каршы ала. Ул әле дә иҗтимагый-дини тормышның үзәгендә кайный, яңалыкларга карата әле дә дин һәм фән берлеге ноктасыннан торып, нигезле, дәлилле фикерләрен белдереп бара. 2020 елда аның туган авылы – Балтач районының Чутай авылы тарихын, үзенең бай тәрҗемәи хәлен тасвирлаган «Чутай бабай малайлары» дигән мәҗмугасы дөнья күрде. Шушы һәм юбилей уңаеннан без аның белән әңгәмә корып алдык. Тынгысыз җанлы, озын гомеренең сәбәбен – Аллаһтан, серен хәрәкәттә күргән Харис хәзрәт бу юлы да үзенең мәсләгенә тугры: һәр сорауга җавап фән белән дин үлчәве аша уза. Ягъни үзе Тукайга ияреп әйткәнчә:*

*«Пар тату йолдыз кеби
Дин белән фән тора».*

**– Харис хәзрәт, Сез мәктәпләргә дини мәдәният нигезләрен укытуны кертү мәсьәләсенә карата фикерләрегезне вакытлы матбугат аша да, монографияләрегездә дә һәрдаим җиткереп тордыгыз. Асыл проблема нәрсәдә соң?**

– Диннәр мәдәниятен бала күңеленә сеңдерү өчен энциклопедик белемнәргә ия булырга кирәк. Ләкин мондый укытучылар мәктәпләрдә бик аз. Ни кызганыч, муллаларның күбесе – фәнне, галимнәрнең шактые динне белми. Нәтиҗәдә, әхлаксызлык белән көрәшү өчен дин әһеле бүгенге көн таләпләренә бәрабәр фәнни дәлил китерә алмаган кебек, фән әһеле дә дини исбатлауларга мохтаҗ. Монысы проблеманың бер ягы гына әле.

Россия – күп милләтле, поликонфессиональ дәүләт. Барлык диннәрнең дә, шәригать таләпләрен онытмыйча, Конституцияне вә диннәр турындагы гамәлдәге кануннарны

искә төшерсәк, илебездә яшәүче кеше нинди генә милләттән булып, нинди генә телдә сөйләшмәсен, ул Аллаһы Хак Сүбхәнәһү Тәгалә хозурында да, Төп канун һәм башка кануннар алдында тигез. Бер генә дин дә, бер генә милләт тә вә шәхес тә алда да, артта да, аста да, өстә дә түгел. Алай булгач, православ мәдәнияте нигезләрен рус мәктәпләрендә укыту кирәклеге барлык кискенлеге белән көн тәртибенә куелган икән, ул чакта ислам мәдәнияте нигезләрен татар-мөселман балаларына укыту катгый үтәлергә тиешле гамәл икәнлеге көн кебек ачык. Башка диннәр вә милләтләр белән дә шул ук хәл.

Россиядә барлыгы 20 миллион тирәсе мөселман яши. Татарстанда 1 миллион 500 мең әһле ислам исәпләнә. Башкортстанда да шул тирә. Төньяк Кавказ җирләрендә бер миллион тирәсе Аллаһының берлегенә, Мөхәммәд (с.г.в.)нең хаклыгына иманда булган милләтләр бар. Барлыгы – 4 миллион. Бу мөселманнарның тупланып яшәгән урыннарында балалар ислам мәдәниятен өйрәнерләр дигәнгә шартлыча гына ышансак та, калган 16 миллион мөселманның баласы кайда, кем тарафыннан ислам мәдәниятен өйрәнер? Курск, Рязань, Пермь һ.б. төбәкләрдән килгән мәгълүматларга караганда, андагы мәктәпләрдә 1-3-5 мөселманның баласы православие мәдәниятен өйрәнә. Ягъни бу балаларны христианлаштыруга юл куела. Ә бу хәлләрнең, үз чиратында, мәдәният өйрәнәбез дигән булып, милли һәм дини крашылыклар китереп чыгару ихтималы бар. Ә безнең максат – диннәр мәдәниятен бала бәгыренә сеңдереп, тәүфыйк вә һидаятькә ирешеп, җәмгыятьне афәттән коткару иде. Мәсьәләнең куелышы хак. Вәләкин, ни кызганыч, чишелеше юк. Диннең мәдәниятен бала күңеленә сеңдерү өчен аның тарихын гына түгел, идеологиясен – рухи өйрәтүләрнең эчтәлеген белергә кирәк. Гамәлдә балаларны милләтләргә, диннәргә бүлү, бер-берсеннән аеру килеп чыга.

**– Димәк, нишләргә инде?**

– Дин белән фәнне капма-каршы куймаска кирәк. Әгәр дә бала Аллаһның барлыгына инана икән, ул үзеннән-үзе шәригать кушканча яши башлый. Ә динебез гыйлем алуны кире какмый, киресенчә, Коръәндә дә, пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) хәдисләрендә дә белемгә омтылу хуплана. Әхлаксызлыкка каршы глобаль системалы дин вә фән берлегендә аңлату эше кирәк!

Аллаһны кабул кылган кеше үз-үзен аңлый. Үз-үзен аңлаган кеше Аллаһ кушканча яши.

**– Сезнең истәлекләрдән аңлашылганча, иманга килү юлларыгыз хак һәм туры булган. Дәһрилек чорында да иманыгызны камил рәвештә саклагансыз, тәкъва булгансыз.**

– Тәкъвалык – Аллаһ газабыннан саклану – адәм баласы өчен тышкы шартлар белән билгеләнми. Ул кешенең күңелендә, кальбендә. Ләкин Аллаһ динен белмичә, тулы мәгънәсендә тәкъвалыкка ирешеп булмый. Миңа башлангыч дини белемне әтием Салихҗан бирде. Мин әтине бик ярата идем, ул үзе гап-гади игенче иде. Намуслы, эш сөючән һәм бик диндар кеше. Гарәп, латин имлясында укый-яза, русча иркен аралаша, Коръән нигезләрен, география, астрономия, математиканы яхшы белә иде. Җәдиди белем алган олпат шәхес. Шуңа да гыйлемгә омтылуым да, диндарлыгым да әтидән. Ул мине сугышка озатканда: «Аллаһы Тәгалә сүзен ишет, тыңла, улым. Үзеңә кыен чакта гына түгел, ә бәлки һәрвакыт ялвар. Аллага дога кыл. Шуны бел: безнең ил җиңеп чыгар...» – диде. Мине бит шушы озын гомеремдә үлем биш тапкыр якамнан тотты. Аллаһ рәхмәте белән бишесендә дә исән калдым.

Аннан соң Совет хөкүмәте динне тыймады, ә аны пропагандалауны тыйды бит ул. Ә сугыш вакытында, аннан соң 1953 елга кадәр дин тоткан кешегә каршылык булмады. 1943 елның сентябрь аенда И.Сталин үзенә православие дине җитәкчеләрен чакырта һәм: «Страна перенесла огромные потери. Надо помочь народному духовному

возрождению. Какие у вас предложения?» дигән сорау куя. Архиерейлар Сталиннан бу вакытта тоткынлыкта булган 16 дин җитәкчесен азат итүен сорыйлар. Бу турыда безнең командирлар да хәбәрдар иде, шуңа күрә дә куак төпләрендә намаз укыганда, алар безгә каршы бер сүз дә әйтми иде.

Сугыштан соң мин Европада 1947 елга кадәр калдым әле. Харьков хәрби училищесында укыдым, шуннан Мәскәүгә НКВДның Югары чик буе гаскәрләре мәктәбенә күчерелдем. Мәскәүдә Ленин китапханәсенә йөрдем, шунда Коръәнне, башка дини китапларны алып укый идем. 1953 елда дин белән кызыксынуымны белеп, эштән җибәрделәр. Аннан Татарстанга кайтып, милиция полковнигына кадәр хезмәт иттем.

Яшерен-батырын түгел, Советлар чорының соңгы дәверендә партия үз-үзенә хыянәт итә башлады. Җитәкчелектә дә әхлакый бозыклык барлыкка килде. Без бит милициядә эшлибез, күреп торабыз. Ә дөрес яшисе килә, чөнки ата каны, ана сөте белән сеңгән. Бу омтылыш тагын мәчеткә алып китте мине. Ижевск шәһәрендәге Сталинград сугышларын үткән Вафа хәзрәт Гыйлаҗига әнә шулай хак юл эзләп барып чыктым. Бөек кеше иде ул, аның вәгазьләрен тыңлап, үземә күп нәрсә алдым. Аннан соң 1991–1993 елларда Казанда Исламның 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсәдә укып чыктым. Бер-бер артлы «Исламның кыскача тарихы» (1997), «Тукай кем ул?» (1997), «Ислам мәдәнияте контекстында ислам тарихы һәм нигезләре» (2000) һ.б. хезмәтләр язылды. 2005 елда Татарстан Эчке эшләр министрлыгының мәдәни-мемориаль үзәге территориясендә «Хәтер» мәчете төзелде. Шул көннән хәзергә кадәр мәчетнең имам-хатыйбы булып эшлим.

**– Сез диндар кеше генә түгел, үзегез дә дин галиме, аң-белем таратучы.**

– Элек Татарстанда мәчетләр дә, чын мәгънәсендә дини белемле имамнар да аз, ләкин кешеләрдә иман көчлерәк иде. Хәзер 1500дән артык мәчет бар, ә әхлакый йөзебез кыек көзгедәге кебек... Бу нидән шулай? Гаделлек, намус, әдәп-әхлак эзләп, иманга кайткан кеше буларак, динне халыкка яңадан кайтарырга кирәклеген дә яхшы аңлый идем. Тагын шунысы бар: Коръәннең 30 процентка якын өлеше, ягъни нәкъ менә фәнгә кагылышлы аятьләре яңгыратылмый. Ислам нигезләренә өйрәтү башлыча кадими юнәлештә алып барыла. Ягъни аятьнең асылын, эчтәлеген аңламыйча ятлап кына өйрәнсәң дә җитә, янәсе. Халык укый-яза белмәгәндә, алай ярагандыр да ул. Хәзер исә югары белемле кешеләрнең бик күп сораулары туа, һәм әгәр дә ул имамга биргән соравына тулы җавап алмаса, аңа ышанмаячак. Заманында мине әнә шундый диннең асылын аңламаган наданнар кыйнаганнар да иде. Ләкин халыкка динне аңлату эшен туктатмадым. Әгәр моңа күпмедер өлешем кергән икән, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булсын...

*Әңгәмәдәш* – **Ландыш ӘБҮДӘРОВА.**

# КАРТАЮНЫ БЕЛМӘС КАРТЛАЧ

## РИФАТ СВЕРИГИНГА 90 ЯШЬ

Бу ни хәлдер, гомерем буе өлкәннәргә тартылып яшәдем. Ә өлкәннәр – миңа тартылды. Бу турыда минем шигырем дә бар. Әле бер ел чамасы элек кенә язылган шигырь. Бу мәкаләмне язар өчен кулыма каләм алырга сәбәпче булган әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм педагог Рифат Сверигинга багышлап язган шигырь ул. Быелтыр туксан яше якынлашкан Рифат аганың уена озын-озак гомерендә үз башыннан кичкәннәре хакында эчкерсез юмор белән сугарылган автобиографик язмалардан торган китап чыгарырга дигән фикер килгән. Озак еллар китап нәшриятында мөхәррир булып эшләгән һәм дистә елдан артык үз нәшриятымны ачып, шәхси эшмәкәрлек белән шөгыльләнгән кеше буларак, әлеге язмаларын карап, редакцияләп чыгуымны үтенеп, миңа мөрәҗәгать итте Рифат ага. Язып бетергәч, ул аны минем тәкъдим-киңәшне тыңлап китап итеп чыгарды.

Сүземне өлкәннәргә тартылуым турында шигырем бар дип башлаган идем. Әйткәнемчә, Рифат Сверигинга багышланган шигырь ул. Һәм мин аны Рифат аганың шушы китабы өчен махсус язган идем. Ул аны китабының «Картлыкта дуслар каян иңә?» дигән соңгы бүлегенә кертеп тә җибәрде. Юбилярга мәдхия булып яңгыраган ул шигырьне мин дә бу язмама кертергә кирәк дигән фикергә килдем.

### Сверигин

*Өлкәннәргә күңел тартылды гел,*
*Ә өлкәннәр – миңа тартылды.*
*Үзем әле малай-шалайларның*
*Минем өчен күңеле тар булды.*

*Бер уңайсыз ягым булды бары:*
*Һич тормадым карап яшен мин,*
*Атам кебек өлкән агайларга*
*«Син» дип кенә бары дәштем мин.*

*Дус – дус инде, ничек каршы килсен,*
*Ничек тыйсын ди сүз иреген?*
*Үзе миңа «Сез» дип дәште һәрчак*
*Әти яшендәге Сверигин.*

*«Син»дәмени хикмәт, «Сез»дәмени?!*
*«Сез» дип дәшкән кайбер яшьләрнең*
*Күп күрсәтте тормыш күңелендә*
*Бөгәрләнеп Иблис яшәвен.*

*Олыгайгач, дуслар кими икән,*
*Бер ел саен бер дус ким икән.*

*Берән-сәрән калган дусларымның*
*Иң өлкәне бүген Син икән.*

*Рифат абый, Рифат агай, ага.*
*Сиңа бара «картлач» сүзе дә.*
*Абый дигән сүздән читенсенеп,*
*Абзый диләр яшьләр үземә.*

*Кемдер миңа: «Нихәл, картлач?» – дисә,*
*Киткән кебек булам яшәреп.*
*Яшә әле, картлач Сверигин,*
*Син яшәсәң, мин дә яшәрмен!*



*Алда – Рифат Сверигин. Артта басканнар (сулдан уңга): Роберт Шакиров, Солтан Шәмси, Рафис Корбан.*

Әйткәнемчә, гомерем буе өлкәннәргә тартылып яшәүнең бер күркәм нәтиҗәседер инде, шул картлачлар белән әледән-әле бергә җыйналып, тормыш хәлләребез, әлбәттә инде, дөнья хәлләре, әдәбият, каләмдәшләребез хакында гәпләшеп, фикерләшеп утырырга яратабыз без. Безнең ул компаниядә иң өлкәнебез Рифат абый, аннары өч академиянең – Педагогика фәннәре, Мәгълүмати технологияләр, Социаль-гуманитар фәннәр академигы, педагогика фәннәре докторы Роберт Шакиров, каләмдәшләрем Солтан Шәмси белән Равил Рахмани. Галимнәр, гадәттә, очрашуларны гади әңгәмәләр белән генә уздырмыйча, шахмат бәйгесе оештырып җибәрәләр. Без, язучылар да, карап кына утырмыйбыз, әдәбият дөньясындагы хәбәрләребез белән уртаклашабыз. Күңелле һәм файдалы уза «мальчишник» дип йөрткән очрашуларыбыз. Монысы, әлбәттә, кыш көннәрендә. Ә җәйгә чыккач, очрашулар сәйранда, табигать кочагында, Битаман янындагы Ашыт елгасы буенда балык каптырып, учак тирәсендә гәп куертып уза. Картлачларның озын-озак гомерләрендә баштан кичкән гыйбрәтле хәлләр хакында сөйләр сүзләре күп. Өлкәнебез Рифат аганың күргәннәре дә ул чыгарган китапка гына да сыеп бетмәле түгел, әлбәттә.

«Әтием Хәсәнгата Сверигинның сөйләгәннәре буенча җиде буын бабамның шәҗәрәсен беркадәр беләм-белүен», – ди Рифат ага. «Ә Сверигин дигән фамилия каян килеп чыккан? Әллә нәсел башыгызда берәрсе урыстан булганмы?» – дип сорагач, бу сорауны аңа тормышта бик еш ишетүе хакында көлеп, шактый ук мәзәк хәлләргә да калуы хакында искә төшерә.

Менә нәрсәләр яза Рифат ага үзенең нәсел шәҗәрәсе хакында: «Шәҗәрә агачының төбеннән, тамырыннан башламыйча, үземнән тамырга таба төшеп, бабаларымның исемнәрен язып чыгыйм әле.

Рифат. Монысы инде мин үзем булам. Миннән аста әтием Хәсәнгата килә. Аның атасы – минем дәү әтием Мөхәммәтсафа була. Мөхәммәтсафаның атасы – Мотыйгулла. Мотыйгулладан алда Гаделша бабай килә. Гаделшаның атасы Зөбәһир, ягъни Зөбәер булуы билгеле. Иң төптә, тамырда Ишмөхәммәт бабай тора... Бабайларымны санап

чыкканнан соң ихтыярсыз рәвештә, «Ә Сверигин фамилиясе каян килеп чыккан?» дигән сорау туа, әлбәттә».

Шул сүзләрдән соң, Рифат ага Сверигин фамилиясенең килеп чыгышына багышлап, китабында махсус бүлек яза. Бактисәң, гади генә «севердан килгән кеше» дигән сүзләрдән килеп чыккан икән «Сверигин» фамилиясе. Гражданнар сугышы елларында калмык далаларында тиф эләктереп, чирләп, бер авылда отрядыннан аерылып калган Хәсәнгата Мөхәммәтсафа улын дәваларга алып калган калмык хатыны, шул авылга килеп чыккан кызыл гаскәр командиры тифтән саташып ятучы кызылармеец егетнең документларын, фамилиясе ничек булуын сорагач: «Бу егетнең иптәшләре севердан килгән сугышчылар иде», – дип җавап бирә. Солдатлар көлешеп: «Алай булгач, фамилиясен «Северин» дип языйк», – диләр. Берсе шунда: «Андый фамилия булмый, әйдә, Сверигин» дип языйк», – дип тәкъдим итә. Шулай итеп Хәсәнгата Мөхәммәтсафа улы гражданнар сугышыннан туган авылына «Хәсәнгата Сверигин» дигән документлар белән кайтып төшә.

Менә шушы Сверигин Хәсәнгатаның өченче баласы булып, 1932 елның 1 августында Саба районының Байлар Сабасы авылында дөньяга килгән Рифат абый. Аннан соң да әле тагын бер ир бала – Ренатны тапкан әниләре Шәмселатыйфа апа. Кыскасы, дүрт бала үскән алар – 1926 елгы апасы Рауза белән, 1929 елгы абыйсы Равил һәм 1937 елгы энесе Ренат. Абыйсы белән апасы инде вафат, ә энесе Ренат исән-сау, бүгенге көндә Воткинск шәһәрендә яшәп яткан көне икән.

1900 елда бүгенге Кукмара районына караган Түбән Өскебаш авылында туган Хәсәнгата, 1925 елда Тәкәнеш районының Лубян урман техникумын тәмамлагач, 1929 елга тиклем милиция органнарында эшләп алганнан соң, Байлар Сабасы авылына килеп төпләнә һәм партия эшенә керешеп китә. Аны башта Төньяк Норлат районына, аннары Яңа Кенәр авылында урнашкан Кызыл Юл районы ВКП(б) райкомына секретарь итеп билгелиләр. Әлбәттә инде, һәр авылга да ул гаиләсе белән күченеп йөри. Шуңа күрә бәләкәй Рифатның күңелендә бу авылларда яшәүләре балачак истәлекләре булып сакланып калган һәм ул алар турында «Һәр кошның үз куначасы» китабында бик тәфсилләп яза.

1940 елда Кенәр мәктәбендә укый башлаган Рифат, әтисе сугыштан соң югары партия мәктәбендә укып кайтып, Байлар Сабасына партия эшенә җибәрелгәч, 1946 елда шунда укуын дәвам иттерә. 1950 елда кулына урта белем алуы хакында таныклык-аттестат алган егет, Казанга килеп, Владимир Ильич Ленин укыган университетка тарих-филология факультетының тарих бүлегенә укырга керергә гаризасын тапшыра. Чит тел түгел, урысчасын да чиле-пешле генә белгән абитуриент немец теленнән экзаменны «өч»легә генә тапшырып, аның алдында чак кына укырга керә алмый калу куркынычы туа. Кабул итү комиссиясеннән бер мәрхәмәтле абый аңа: «Татар теле бүлегендә ике урын бар, керергә теләсәң, татарча сочинениене уңышлы язсаң, шул урыннарның берсе синеке булыр», – дип киңәш бирә. Соңыннан, үзе китабында язганча, республика җитәкчеләренең берсе булган, Татарстан Фәннәр академиясенең беренче президенты дәрәҗәсенә күтәрелгән Мансур Хәсәнов белән бер парта артына утырып, бер-берсеннән күчерешә-күчерешә сочинение язып, икесе дә «яхшы» билгесе алып, университет студентлары булып китәләр.

Мәшһүр Казан университетында биш ел (1950-1955) укып, югары белем алып чыккан яшь белгечне ул чактагы тәртип буенча распределение белән Аксубай районының Иске Ибрай авылына эшкә юллыйлар – мәктәп татар теле белгеченнән бигрәк немец теле укытучысына мохтаҗ икән. Университетта алманчаны чит тел буларак өйрәнгәнлектән, аз-маз булса да сукалый торган була. Җитмәсә, уку елы башлануга район мәгариф бүлегеннән килеп төшкән тикшерүче инспекторларның берсе, дәресенә кереп утырып, аның эшенә уңай бәя куя; соңыннан аның белән аерым сөйләшеп, дәресне методик яктан дөрес алып баруы, ә менә немецчаны бик начар белүе,

дөресрәге, немец сүзләрен бозып сөйләве турында әйтә һәм үзенең киңәшләрен бирә. Немец телендәге пластинкаларны тыңларга, сүзлек ярдәмендә немец газеталарындагы язмаларны тәрҗемә итәргә куша. Моның өчен үзе үк Рифат Сверигинга Берлинда ук чыга торган «Нойес Дойчланд» газетасын яздыра, озак та үтми хат ташучы ул торган фатирга немецча газета китерә башлый. Немец теле буенча мәктәптә туплаган тәҗрибә соңыннан, ИЯЛИ аспирантурасына укырга кергәндә ярап куя, әлбәттә. Чит телдән имтиханны бу юлы ул җырлап кына бирә!

Иске Ибрайда ике генә ел эшләп кала Рифат ага. Шул ике елы да аның өчен гаять истәлекле вакыйгаларга бай булып, гомер дәфтәренә язылып кала. Биредә ул көтмәгәндә-уйламаганда өйләнеп куя. Беренче уку елы тәмамланыр алдыннан мәктәп директорының кушуы буенча ул «Красная Татария» газетасына Иске Ибрай авылының табигатьнең искиткеч матур урынында урнашкан булуы, мәктәптә тырыш, булдыклы укытучылар коллективы эшләве һәм аны яшь, белемле кадрлар белән тулыландыру соралуы хакында хат язып җибәрә. Р.Сверигин дигән авторның хаты булып, ул газетада басылып та чыга. Бу Казан педагогия институтын тәмамлаучыларны мәктәпләргә билгеләү көннәренә туры килә. Римма Галимова исемле кызны министрлыкта Иске Ибрай мәктәбенә юллыйлар. Дөньяны күп күргән инспектор барыргамы-бармаскамы дип икеләнеп торган кызга: «Ул татар авылы үзе. Ләкин синең урысчаң яхшы, анда урыслар да яши, газетага чакырып хат язган әнә шул урыска кияүгә дә чыгып куярсың әле, бәхетең булып», – дип шаяртып ала. Яңа уку елы башында мәктәпкә яшь белгеч булып, физика укытырга дип, эшкә килгән Римма Галимова бик өлгер булып чыга, Рифат Сверигин белән танышырга да өлгерми, беренче елда яшәгән фатир хуҗасының, бу елны сине үземдә торырга кертмим, дип белдерүенә зарланып торган егеткә: «Фатир эзләп интегеп йөрмә, мин яшәгән фатирда сиңа да урын җитәрлек, бергә торырбыз», – дип, аптырап йөргән җиреннән фатирлы да, хатынлы да итеп куя. Өченче уку елына яшь гаилә Кукмара районының Сабадан ерак та булмаган Ошторма-Юмья дигән удмурт авылы мәктәбенә, Рифат – рус теле һәм әдәбияты, Римма физика, астрономия фәннәре укытырга урнашалар.

1959 елны Рифат аганы Кукмараның Ядегәр сигезьеллык мәктәбенә директор итеп күчерәләр. 1961 елны ул Сабага җәйге ялга кайткач, сабакташы Азат Әхмәдуллинны очрата. Мәктәп проблемалары белән башы әйләнгән, яңа мәктәп бинасы саласы бар дип борчылып йөргән дустына Әхмәдуллин: «Бик зур эшләрең бар икән. Салырсың да, эшләрсең дә, тик болай итеп син тарихта эзеңне калдырмаячаксың бит, – ди һәм үзенчә тарихта эз калдыру юлларын күрсәтә: – Озакламый ТӘҺТИгә (ИЯЛИ) аспирантлар кабул итү башлана. Син ул мәктәбеңдә картайганчы, институтка урнашып, фәнни эзләнүләр, ачышлар, әдәби тәҗрибәләр ясасаң, сине күпләр таныячак, даның үсәчәк, – ди, Гали Халит җитәкчелегендәге әдәбият секторына аспирантурага керергә киңәш бирә. Әнә шулай мәктәп проблемаларына кереп баткан укытучы бер диңгездән икенчесенә – фән дөньясына кереп чума.

«...Әдәбият фәне, әдәби тәнкыйть өлкәсенә кулымнан тотып диярлек алып керүчем Гали абый Халитов булды», дип яза Рифат ага китабында. Аның җитәкчелегендә ул «Фатих Хөсни һәм аның прозадагы осталыгы» дигән темага кандидатлык диссертациясе язып яклый. Аспирантураны тәмамлап, институтка эшкә урнашкач, Гали Халитов кул астында аның белән бер бүлмәдә утырып эшләү, институтта Мөхәммәт Гайнуллин, Хәсән Хәйри, Хатыйп Госман, Якуб Агишев, Ибраһим Нуруллин, Хәмит Ярмиләр белән бергә аралашулар аңа акрынлап фән дөньясына тирәнрәк керергә, галим буларак үсәргә ярдәм итә. «Җитәкчем мине фәнни эшнең тәртибенә, вакытның кадерен белергә, рациональ, логик фикерләүнең нәрсә икәнлегенә төшендерде», – ди Рифат ага. Остазының ярдәме белән ул әдәбият-сәнгатьтә нәрсәнең әһәмиятле, кирәкле, ә нәрсәләрнең чүп-чар икәнен танырга өйрәнә. «Моны аңламаганнарның әдәби тәнкыйтьтә сүз алып сөйләргә бөтенләй хаклары юк», дип яза ул хатта.

Фатих Хөсни иҗатын тирәнтен өйрәнгән, кандидатлык диссертациясен дә аның иҗатына багышлаган Р.Сверигин 1968 елда «Фатих Хөсни» дип аталган беренче китабын да бастырып чыгара. 1965 елда Мәскәүдә «Фән» нәшриятында чыккан «История татарской литературы», аннан соң нәшер ителгән «История литературы СССР», алтмышынчы-җитмешенче елларда Казанда басылган алты томлык «Татар әдәбияты тарихы»нда Рифат Сверигинның Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев турында мәкаләләре урын ала.

Институтта фәнни эшчәнлеген Рифат агага җәмәгатьчелек эше белән бәйләп алып барырга туры килә. Аны институт партия оешмасы секретаре итеп сайлап куялар.

Шулай ТӘҺТИдә эшләп йөргән көннәренең берсендә, көзгә керәбез дип торганда, аның бүлмәсенә ул Уфада эшли дип уйлаган сабакташы Фәрит Хатыйпов килеп керә. Исәнләшеп, хәл-әхвәлләрне белешкәндә Рифат, дустыннан:

– Уфада ни хәлләр анда? – дип сорый.

– Мин Уфада түгел хәзер, Казанда. Педагогия институтында кафедра мөдире. Әйдә, кил миңа, бергәләп эшләрбез, – ди Ф.Хатыйпов.

– Ничек алай?

– Ничек булсын, иртәгә пединститутка киләсең дә, эшкә керешәсең.

– Сез нәрсә?! Минем бит студентлар укытканым юк.

– Ә алты ел мәктәп стажы нәрсәгә? Укыту, аудитория белән эшләү кайда да бер инде ул.

Менә шулай итеп Рифат ага педагогия институтында студентларга, булачак укытучыларга татар әдәбиятыннан белем бирә башлый һәм гомеренең кырык елын шушы игелекле эшкә багышлый.

Үзем педагогия институтында укымагач, Рифат аганы мин институт галиме, булачак педагоглар укытучысы буларак бик аз һәм начар белә идем. Шулай бервакыт мине балалар шагыйре һәм китап нәшрияты хезмәткәре буларак әлеге институтка студентлар белән очрашуга чакырдылар. Институтның Межлаук урамындагы төп бинасында зур гына аудитория студентлар белән шыгрым тулы иде. Артистлар булса, аншлаг, диярләр иде бу очрашу-чыгышны. Шунысына исем китте – аудиториядә нигездә кызлар гына иде, егетләр дигәнең – берничә генә бөртек. Рифат Сверигин дигән укытучы белән мин беренче мәртәбә менә шул очрашуда якыннан таныштым. Студентлар барысы да Рифат аганың шәкертләре булып чыкты. Һәм аның үз шәкертләрен бу очрашуга җитди әзерләгәнлеге күренде: алар миңа сораулар биреп кенә утырмадылар, шигырь укуымны, иҗатым хакында сөйләвемне, китап нәшрияты хезмәткәре буларак китап чыгару серләре турында чыгышымны тыңлаганнан соң, үзләре минем турында тәфсилле чыгышлар ясадылар. Минем гаҗәпләнеп: «Болар хакында каян беләсез?» – дип соравыма җавап итеп: «Рифат абый безгә бүгенге заман язучылары турында да лекцияләр укый бит», – диделәр. Шунда мин Рифат аганың татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган әдипләребез белән бергә бүгенге язучылар иҗатыннан да хәбәрдар булуын күрдем.

Фәнни-гыйльми эшчәнлеген Фатих Хөсни иҗатын өйрәнүгә багышлаган Р.Сверигин әдәбият белемен өйрәнүчеләр өчен абруйлы чыганак булып торган хезмәтләрендә Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Атилла Расих, Рафаил Төхфәтуллин, Аяз Гыйләҗев, Мәгъсум Хуҗин, Фәнис Яруллин, Айдар Хәлим, Әхәт Гаффар, Камил Кәримов һ.б.ларның әсәрләренең форма, стиль, әдәби осталык мәсьәләләрен яктырта. Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьченең газета-журналларда басылган мәкаләләре, төрле җыелышларда ясаган чыгыш-докладлары әдәби хәрәкәт проблемаларына, тенденцияләренә киң тукталган булуы белән аерылып тора. Язучыларыбыз Рифат аганың үз әсәрләре турында мәкалә, китапларына кереш сүз язуларын һәрчак көтеп алалар, чыккан китаплары турында мәкалә язуларын сорап мөрәҗәгать итәләр. Аның әтрафлы сүзе авторларны да, әдәбият сөючеләрне дә һәрчак кызыксындыра.

Ул язучыларыбызның әсәрләрен пропагандалау, яшь буынга илтеп җиткерү буенча «Хәтер» нәшрияты чыгарган хрестоматияләрне төзүче буларак та зур эш башкарды. Мирсәй Әмир, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури, Әхсән Баян, Әмирхан Еники, Кави Нәҗми, Мәгъсум Хуҗиннарның әсәрләрен туплаган хрестоматияләр бүген әдәбият укытучыларының өстәл китабы булып тора. Аның Тәлгат Галиуллин, Нурислам Хәсәнов иҗатларына багышланган саллы язмалары да әдәбият сөючеләр өчен бай мәгълүматлар бирүче хәзинә.

Р.Сверигинның шулай ук моннан берничә ел элек «Хәтер» нәшриятында язучыларыбызның Бөек Ватан сугышына багышланган әсәрләрен туплаган унбиш томлыгын редакцияләп, шуларның өч томын шәхсән үзе төзеп тапшыруын да күрсәтеп үтәргә кирәк.

Рифат ага белән без, якташым Солтан Шәмсинең аның кереш мәкаләсе белән ачылган «Юаныч» китабы дөньяга чыккач, якыннан аралаша башладык. Шунда мин, чама белән инде берничә ел элек вафат булган әтием белән бер тирәдәге, 90 яше якынлашып килүче бу агайның әле һаман да яшьләр кебек көр рухлы, зирәк зиһенле, физик яктан таза-нык, көчле булуын күреп сокландым. Аның шундый егетлеге гомере буе физкультура һәм спорт белән дус булуына бәйледер, дигән фикергә килдем. Чөнки Рифат ага яшьтән үк йөгерү белән шөгыльләнгән, футбол һәм волейбол уйнаган, уйнап кына калмыйча, төрле дәрәҗәдәге ярышларда катнашкан, шахмат белән мавыккан, зиһенен ныгыткан.

Гомерен татар әдәбиятын үстерүгә, язучыларыбызның әсәрләренә карата үзенең этрафлы бәяләмә-мәкаләләре белән хезмәт иткән, бер үк вакытта булачак педагоглар тәрбияләгән, алар арасында төрле елларда әдәбиятка килеп, аны җигелеп тартучы язучылар булуын да исәпкә алсак, Рифат ага Сверигинның халкыбызга, милләтебезгә күрсәткән хезмәтләрен бәһаләп бетерерлек түгел. Без аңа үзенең шәкертләрен, каләмдәшләрен шатландырып, әле тагын исән-сау, озын-озак гомер кичерүен телибез.

Кулымда әле типография буявының исе дә очып бетмәгән, «Һәр кошның үз куначасы» дигән өр-яңа китап. Аның титулына «Иронияле автобиографик элегия» дип язылган. Авторы Рифат Сверигин гомеренең тугыз дистәгә килеп җиткән өлешенә үзенчә әнә шулай шаяру катыш сүзләр белән беркадәр йомгак ясарга омтылган. Бу омтылыш барып чыккан да кебек. Ул 59 яшендә вафат булган әтисе Хәсәнгата абзыйның гомерен узып китеп, утыз бер ел артык яшәгән. Ләкин әле алда әтисе яшәми калган утыз бер ел гомере бардыр кебек. Шулай булсын иде. Исәнлек-саулык Сиңа, Рифат ага, Рифат картлач!

**Рафис КОРБАН**

# ТАТАР ФӘНЕ – КЫРГЫЗСТАНДА



Татарлар дөнья буйлап сибелеп яши дияргә күнеккәнбез. Халкыбызның мәркәзе Казандагы, Татарстандагы фән – читтәге күренекле ул-кызларын барлап, төрле кыйтгаларда яшәүче милләттәшләренең тарихын, мәдәниятен, яшәү рәвешен тергезергә омтыла. Әмма татарлар кебек зур-зур диаспоралар булып, яки гасырлар буе Татарстаннан читтә, әмма үз туган җирләрендә тупланып яшәгән халыкның язмышын-тормышын бер үзәктән торып өйрәнеп бетерергә мөмкинме соң?! Һич юк.

Шуңа күрә дә читтә яшәп, татар темасы белән шөгыльләнгән галимнәр аеруча кадерле. Шундыйлардан, бүгенге сүзебез Әнисә Риф кызы Бикбулатова турында булыр.

Татарларның читтә яшәп калуына сәбәпләр төрле. Әнисә Риф кызының яраткан әбисе Бикбулатова Гөлсем (кыз фамилиясе – Халикова) Башкортстан җирендә, Дәүләкәндә туа. 8 балалы зур гаиләне инкыйлаб алып килгән хәлләр илнең төрле почмакларына таратып ташлый, Гөлсем дә абый-апаларыннан аерыла. 20 елдан соң гына аңа бертуган апасы – Халикова Мәфтуха белән күрешү насыйп була. Әмма кызлар башка туганнарын эзләп таба алмыйлар.

Язмышның юллары сикәлтәле: Бөек Ватан сугышы елларында кыз комсомол линиясе буенча Чита шәһәренә килеп эләгә, Бикбулатов Галим исемле егеткә кияүгә чыга. Сугыш тәмамланган көннәрдә – 1945 елның 17 маенда дөньяга килгән Рифкә 9 яшь вакытта гаилә тагын күченә – Кыргызстанның Чуй үзәнендәге Кант районы Чон-Далы авылына барып чыга.

Шунда яшәп калалар. Риф Галимович үсеп, «Заветы Ильича» колхозында электрик, тракторчы, агроном булып хезмәт куя, шул ук авылдан Кочорова Төмбел исемле кызга өйләнә.

Менә шушы гаиләдә, 1969 елның 9 маенда дөньяга килә Әнисә. Аның артыннан тагын өч бала: Нурисә, Салават, Сафинә туа. 1986 елны Чон-Далы авылында К.Маликов исемендәге урта мәктәпне көмеш медальгә тәмамлап, Әнисә Риф кызы «СССРның 50 еллыгы» исемендәге Кыргыз дәүләт университетының тарих факультетына укырга керә. Керү имтиханнары биргәндә үк акыллы һәм үткен кызны күренекле галим, археология һәм этнология кафедрасы мөдире Асанканов Абылабек Асанканович күреп ала, үзенең кул астында курс эшләре язарга чакыра. Бүген 7 фән докторы, 30 фән кандидаты әзерләгән Кыргызстан Республикасы Милли фәннәр академиясенең академигы, Кыргызстанда этносоциология мәктәбе булдырган мәшһүр галим А.А.Асанкановның укучылары арасында Әнисә Риф кызы да бар.

1991 елны университетны кызыл диплом белән тәгәлләп, Әнисә Риф кызы археология һәм этнология кафедрасына стажёр-тикшеренүче булып килә. Кыргызстан Республикасы хөкүмәте каршындагы «Манас–1000» эпосын пропагандалау буенча Дәүләт дирекциясенең «Мурас» (Мирас) проектында эшли. 2004 елны этносоциологик материаллар нигезендә XX гасырның 80-90 елларында кыргыз хатын-кызларының

иҗтимагый-мәдәни хәл-халәтен тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертациясен яклый. Шул ук елны тарих факультетында укытырга керешә.

Язмыш кешенең нинди һөнәр сайлавына карап тормый – Әнисә Риф кызына да олы сынаулар аша узарга туры килә. 2003 елны табиблар аның яраткан ире, 34 яшьлек Таалайбек Тентимишевка «яман» чир дигән диагноз куялар. Ике елдан, хатыны кулында кечкенә кызы белән улын калдырып, ул бакыйлыкка күчә.

Әмма Әнисә Риф кызы сайлаган юлыннан тайпылмый, фәннән китми. Алай гына да түгел: университетта археология һәм этнология кафедрасын җитәкли башлый (2007-2016 еллар). Җиң сызганып, докторлык темасына алына.

Читтә яшәгән татар галимнәренең татар темасына килүе – үзе бер гаҗәеп күренеш. Кайберәүләр моны кан тарту яки җан авазы белән аңлата, кемдер – үз нәсел-нәсәбеңне белергә теләү белән бәйли... Ничек кенә булмасын, андый күренеш бар, күп кенә фикер ияләренең инде кандидатлык яклаганнан соң шушы темага кереп китүе күзәтелә. Бу очракта бер мизгелгә генә әлеге ситуациядә тукталсак, башка мәдәни тирәлектә яшәгән, карьера ясау юлларын яхшы күзаллаган кешегә бу мохит өчен чит, азчылык булган этнос темасын өйрәнүнең бер дә җиңел түгеллеген ассызыкларга кирәк. Бигрәк тә ул урын – төрки республика икән! Әмма әлеге юл – галим өчен фәндә иң кыска, иң турысы булмаса да, үз милләтеңә хезмәт итү юлы булганлыгы бәхәссез.

Әнисә Риф кызы өчен дә кандидатлык темасын дәвам итү күпкә җиңелрәк булыр иде. Тик тормыш кешене һәрчак тигез юлдан гына йөртми. Әбисе Гөлсем тәрбиясендә татар гаиләсендәге гореф-гадәтләрне белеп, татарлар белән аралашып үскән Әнисә Риф кызы да үзләренең башка гаиләләрдән аерылып торганлыгын кечкенәдән күрә. Бу аерма өй эченә аяк басуга күзгә ташлана: көзге өстендә – чигелгән сөлге, тәрәзәләргә матур итеп чигелгән пәрдәләр эленгән, этажеркада, магнитофон өстендә – чигүле салфеткалар; мендәрләр, караватт өслекләре челтәрләп каелган; диварда күкеле сәгать текелди. Чон-Далы авылында кыргызлар арасында 44 ел яшәсә дә, Гөлсем кыргыз телендә сөйләшми, соңгы көннәренә кадәр гаиләдә дә, урамда да бары тик татарча аралаша! Өйдә исә берсеннән-берсе тәмле милли ризыклар: өчпочмаклар, кыстыбыйлар, бәлешләр, коймак-беленнәр пешеп тора. Гөлсем әзерләгән телеңне йотарлык чәкчәкләрнең тәме бүген дә бу гаиләдә сагынып сөйләнә.

Совет заманында Кыргызстанда һәр дүшәмбе көнне кичке сигездә радиодан бер сәгать дәвамында татар җырларын тапшыралар. Бу вакытта Гөлсем, бөтен эшен ташлап, татар көйләрен тыңлый, сагынуын баса. Үз янына оныкларын да дәшә. Бәлки, әбисенең күз яшьләре аша җыр тыңлаган сурәте дә бу адымга өндәгәндер, бәлки, сынаулар-югалтулар аша кичеп, яшәү мәгънәсе, үзенең тормыштагы урыны-эзе хакындагы уйланулар, үз тамырларын-милли үзаңын ачыклау теләге шундый карарга китергәндер – Әнисә Риф кызы докторлык диссертациясе темасы итеп ата-бабалары тарихын, Кыргызстандагы татарлар тарихын өйрәнүне сайларга уйлый. Әлеге фикер белән фәнни җитәкчесе янына килә. Әмма тәҗрибәле җитәкче моны хупламый: өр-яңа темага керү өчен генә дә берничә ел кирәк булачак, дип, моңа кадәр эшләгән фәнни проблеманы дәвам итәргә киңәш бирә. Бары тик Әнисә Риф кызының үз фикерендә нык торуын күргәч кенә, докторлык темасын расларга рөхсәт бирә. Ничек кенә булмасын, татарларның чит җирләрдә яшәешен этносоциологик өйрәнү мәктәбе булдыруга юл ачкан Абылабек Асанканович Асанкановны рәхмәт һәм ихтирам белән телгә алырга кирәк.

Кыргызстанда яшәүче татарларның тарихын, мәдәниятен өйрәнү, чыннан да, зур тырышлык, вакыт, хезмәт сорый. Дин уртак, тарихи-мәдәни тамырлар уртак булса да, мәдәни аерымлыклар да зур. Әнисә Риф кызы бик күп кешеләр белән очраша башлый, архивларда эзләнә, һәм татарларның Кыргызстан Республикасы тарихына, бу җирләрнең икътисади һәм мәдәни үсешенә керткән өлешләре зур булуга төшенә. Әмма моны дәлиллисе, мисалларда сөйләп аңлатасы, яңгыратасы да бар бит әле! Моның өчен 15 ел кирәк булып чыга! Әнисә Риф кызы үзе шушы озак елларга сузылган

гыйльми тикшеренүләре – милли үзаңын үстерергә, үзтәңгәллеген билгеләргә, татар халкының аерылгысыз өлеше икәнен аңларга ярдәм итте дип саный.

Әлбәттә, чит илдә, республикада, субъектта яшәгән татарларның узганын һәм хәзергесен анализлау-бәяләү өчен, шунда яшәргә кирәк. Чөнки алар хакында мәгълүматлар – күп архивларда, төркемләнмичә-барланмыйча, уртак массив эчендә ята. Кечкенә генә фактның дөреслеген тикшерү яки яңа мәгълүмат табу өчен дә әллә кайларга бару, тау кадәр материал актару, озаклап утыру таләп ителә. Аннары, татар халкының вәкилләре Кыргызстан кебек төрки республикаларда укмашып түгел, сибелеп яшиләр. Еллар узган саен, йә татарлык үзаңын югалткан, яки үзләре озак вакытлар көн иткән урыннардан тулысынча күчеп киткән, каберташлар гына калдырган җирләр дә аз түгел. Бу җылылыгын җуйган эзләрне дә теркәп калдырырга, фәнни әйләнешкә кертергә кирәк. Әле болар – без күзаллаган һәм кычкырып әйтергә җөрьәт иткән кыенлыклар гына!

Әмма батыр йөрәкле, тырыш, үзенә һәм башкаларга чиктән тыш таләпчән Әнисә Риф кызы авырлыклар алдында туктап калмый. Кыргызстанда татарлар яшәгән барлык урыннарны йөреп чыга ул. Һәр урында татарлар белән аралаша, меңләгән кешеләрнең гайре табигый язмышлары белән таныша, зиратларны һәм татарларга куелган каберташларны карый, барысын да фотосурәткә ала... Акрынлап, болар – фәнни мәкаләләр, монографияләр булып дөньяга чыга торалар. Озак эшләп, эзләнеп, уйланып башкарган хезмәтнең ноктасы куела: 2020 елны Ә.Р. Бикбулатова «Кыргызстанда татарларның иҗтимагый-мәдәни үсеше (этносоциологик тикшеренүләр материаллары буенча)» дигән темага докторлык диссертациясен яклый.

Бер яктан, әлеге зур хезмәт моңа кадәр Кыргызстандагы татарлар тормышына кагылган барлык тикшеренүләрне, фикерләрне бергә тупларга мөмкинлек бирә. Галимә XIX гасырның икенче яртысыннан башлап, күпмедер күләмдә моңа кагылган, яки мондый эзләнүләрнең нигезен хасил иткән барлык фәнни материалны барлый. Историографик анализга Кыргызстан турындагы мәгълүматларны гына түгел, гомумән, читтә яшәгән татарларның милли үзаңы проблемасына караган хезмәтләрне тарта. Үз чиратында, Кыргызстанда яшәүче төрле этносларны өйрәнү мәсьәләсен дә читкә куймый. Бигрәк тә революциягә кадәрге чорга караган чыганаклар татарларның бу җирләргә күченү тарихын, аның сәбәпләрен, урнашу үзенчәлекләрен күрергә, күченүчеләрнең, сәүдәдән тыш, дини һәм мәгърифәтчелек эшчәнлеген алга куеп, монда юнәлүен, үз хисапларына мәчетләр һәм мәктәпләр төзүен, соңрак бу җирләргә Казанда һәм Уфада нәшер ителгән китаплар һәм вакытлы матбугатны күпләп алып килеп, мәдәни яңарыш хәрәкәтенә җирлек булдыруын бербөтен сурәт итеп тезәргә ярдәм итә.

Аерым алганда, фәндә бу җирләрнең татарлар тарафыннан үзләштерелүе Бөек Ефәк сәүдә юлына илтеп тоташтырыла. Алтын Урда һәм татар ханлыклары заманында сәүдәнең массачыл төс алуы күрсәтелә. Соңрак, XIX гасырда татарларның, тире, агач, металл һөнәрчелеген үстереп, үз авылларын булдыруы, шәһәрләргә күченү процессы, туган якларга язылган хатлары игътибар үзәгенә куела. Әмма бер нәтиҗә кызыклы: монда яшәүче татарлар бүген дә, нигездә, сәүдә һәм хезмәт күрсәтү эшчәнлегенә өстенлек бирә! Шул ук вакытта, бу җирләрдәге башка милләтләр белән чагыштырып, әле XIX гасырда ук татарларның өчтән бере белемле булу, бу яктан хатын-кызларның да ирләрдән калышмавы, совет чорында – татарларның балаларына югары белем бирергә омтылыш ягыннан аерылып торуы һ.б. бик күп мәгълүматлар, гомумән, татар холкы-характеры, этник менталитет турында да сөйлиләр.

Ә.Бикбулатова хезмәтләре халык санын алу материалларына (1897, 1905, 1926, 1939, 1959, 1979, 1989, 1999, 2009) таянып, татарларның тарихын, яшәү рәвешен, күченү хәрәкәтен, милли үзаңын шәрехләү-аңлатуларга бик бай. Болар бер гасырдан артык вакыт аралыгында татарларның кайларда, күпме, ничек яшәгәнлеге сурәтен тулысынча тергезәләр. Берничә дулкын актив күченүләр (революциягә кадәр, 1920–1940 елларда һ.б.) арасында, аеруча, 1946–1970 еллар аралыгындагысы күпсанлы булган. Кыргызстанда

татарларның саны 1993 елга кадәр үсеп бара икән. Монда яшәүче татарларның зур күпчелеге – 76,6 %ы – шәһәр кешеләре булу да аерым бер фикерләргә этәрә. Шул ук вакытта сораштырулар Кыргызстанда яшәүче татарлар арасында үзләрен Казан (34 %), Уфа (9 %) татарлары, мишәрләр (5 %), Кырым татарлары (4,2 %), Әстерхан татарлары (1,5 %), Себер татарлары (1,5 %) дип аеруларын, әмма бер этнос – татарлар дип санауларын күрсәтә.

Татарларның 70 %ка якыны – Кыргызстанның төньяк (Бишкәк, Чуй һәм Ыссык-Күл өлкәләре), 30 % көньяк төбәкнең 3 өлкәсендә туплануын, алар яшәгән шәһәрләрне һәм авылларны бик төгәл билгеләп, галимә тарафыннан этносоциологик сораштырулар уздырыла. Барлыгы 1640 кеше 85 сораудан торган анкета тутыра. Шулар нигезендә татарларның гаилә-көнкүреше, милли һәм конфессиональ үзенчәлекләре ачыклана. Минем үземә татар теленең кулланылышына караган күзәтүләр гаҗәеп тоелды. Әйтик, тикшеренүләрдә 24 % респондентларның үзләрен тел берләштерә дип санавы күренә. Еллар киселешендә татар телен җую (1926 елны – 94,3 %тан – 2009 елны – 66,5 % ка кадәр), рус телен туган тел дип санау (5 %тан – 28,6 %ка) билгеләнә. Шул ук вакытта «Татарлар кайсы телдә сөйләшәләр?» дигән сорауның өч варианттагы җавабы бик үзенчәлекле: җәмәгать урыннарында – 70 %, эштә – 65 %, өйдә – 35 %. Ягъни кыргызлар белән бер мәдәни тирәлектә яшәгән һәм эшләгән татарлар өчен туган тел – җәмгыятьтә аралашу чарасы. Шул ук вакытта алар гаиләләрендә рус теленә өстенлек бирәләр булып чыга!

Бүген татар укучысы Әнисә Риф кызы тикшеренүләренең бер өлеше белән танышу мөмкинлеге алды: аның «Татары Кыргызстана» дип исемләнгән монографиясе 2020 елны Казанда, Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. Эзләнүләрен дәвам итеп, ул хәзер архив материаллары нигезендә Кыргызстаннан Бөек Ватан сугышына киткән татарлар, аларның каһарманлыгы турында хезмәт әзерли. Шәхес культы корбаннары булган татарлар белән кызыксынып киткән. Кыргызстанда «1920–1953 елларда сәяси репрессияләр корбаннары» дигән 10 томлык хатирә китабы дөнья күргән була. Шуңа нигезләнеп, Әнисә Риф кызы 160 татар кешесен таба, аларның язмышларын ачыклау белән шөгыльләнә башлый, туганнары белән күрешә, Кыргызстан Республикасы Үзәк дәүләт иҗтимагый-сәяси документлар архивында (Бишкәк шәһәре) һәм Көньяк төбәкара дәүләт иҗтимагый-сәяси документлар архивында (Ош шәһәре) шәхси эшләрен, фотоларын эзли. 2022 елны «1920–1953 елларда сәяси репрессияләр корбаннары арасында Кыргызстан татарлары» дигән китап чыгарырга әзерли. Болардан тыш, Татарстанның фәнни оешмалары хезмәткәрләре белән бергәләп, архив материаллары нигезендә илдә мәгариф системасы оешуда татар мәгърифәтчеләренең роле турында һәм Кыргызстан Республикасы территориясендә эпиграфик һәйкәлләрне тасвирлаган китаплар нәшер итү планнары да бар. 2023 елны Ыссык-Күлдә «Үзәк Азиядә татарлар: тарих һәм бүгенге» дигән халыкара конференция уздыру турында уйлана.

Халкыбызга үз тарихын, үз шәхесләрен кайтаруга йөз тоткан игелекле мондый эшләр тормышка ашар, иншалла.

Бүген тарих фәннәре докторы, Ж.Баласагын исемендәге Кыргыз милли университетының тарих һәм төбәкне өйрәнү факультеты профессоры Әнисә Бикбулатова – 4 монография, 2 уку-укыту ярдәмлеге, 70тән артын фәнни хезмәт авторы. Кызы Галия һәм улы Данияр, югары белем алып, үз юлларын сайлаганнар. Әнисә ханымның 5 оныгы үсеп килә.

Әнисә Риф кызы «Манас» Кыргыз-төрек университетында Кыргызстан татарлары хакында фәнни эш башкаручы PHD докторантлар белән җитәкчелек итә. Бертуган сеңлесе – Бикбулатова Сафинә Риф кызы да Кыргызстанда авыл җирләрендә яшәүче татарларның тормышына багышланган диссертация әзерләү белән мәшгуль. Димәк, Бикбулатовалар династиясе Кыргызстанда татарларны өйрәнү мәктәбенең нигезләрен кора. Төпле итеп, ныклы итеп.


**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы.*

# БЕРДӘМЛЕКНЕ КӨЧ ИТҮЧЕ ХАНЫМ

*Яз-көз айларында кортларның чәчкәдән-чәчкәгә күчә-күчә бал җыйганнарын, иртә таңнан мәш килеп, эшкә керешкәннәрен, көн буе гөжләп торганнарын карарга яратам. Кечкенә дә төш кенә шул алар. Умартачы хатыны дәү әниемнең: «Бисмилла әйтеп кабыгыз, бер кашык татлы нигъмәт җыю өчен никадәр хезмәт кергәнен үсә төшкәч аңларсыз әле», – диюе әле дә истә.*

Бүгенге героебыз Рима Гомәр кызы Сафиуллованы да әлеге эшчән җан ияләренә тиңләргә мөмкин. Тик ул, соңгыларыннан аермалы буларак, ел әйләнәсе хезмәттә.

Республика күләмендә крестьян-фермер хуҗалыгы белән җитәкчелек итүче әлеге бердәнбер хатын-кызга сокланып һәм шаккатып карыйсың. Максатчанлык, үҗәтлек, тырышлык кебек сыйфатлар ана сөте белән кергән шул аңа. Тумышы белән Чүпрәле районыннан, умартачылар нәселеннән ул. Тугыз балалы ишле гаиләдә туып үскән Рима ханымда җаваплылык хисенең көчле булуы бик табигый. Кул арасына кергән балалар кечерәкләрен карый, әти-әнисенә йорт тирәсендә булыша.



*Рима ханымга кыр корабы да буйсына.*

– Умарталыктан тыш, йорт тулы терлек тоттык, әти-әни һәрберебезгә эшне бүлеп бирә иде, – дип искә ала ул үзенең балачагын. – Әни белән әти безнең өчен намус белән хезмәт итү үрнәге булып торды.

Шуңа күрә дә алынган һәр эшне җиренә җиткереп башкарырга кирәклеген яхшы аңлый, үзе шуңа омтыла, башкалардан да шуны таләп итә. Хәер, халыкның, хуҗасына охшамаган мал хәрәм була дигән мәкале бу очракта хезмәттәшләргә дә кагыладыр, мөгаен. «Бер максат белән янучы, бер тарафка юнәлгән фикердәшләр белән идарә итәргә дә кирәкми, – ди җитәкче. – Һәркем үз вазифасын яхшы белә. Шуңа күрә мин аларга юнәлеш кенә бирәм, тыныч күңел белән эшләсеннәр өчен хезмәт шартларын кайгырту белән шөгыльләнәм».

– Авыл халкы бердәмлеге белән көчле. Бердә чит кеше юк. Кайгыны да, шатлыкны да уртак итүенә, кирәк вакытта бер-берсенә тәмле сүзен, ярдәмен кызганмавына сокланам, – ди Рима ханым, елмаеп.

Ә бит моннан өч дистә еллап элек инде көйләнгән кала тормышын калдырып, салага кайтып төшәрмен дип күз алдына да китермәгән булгандыр. Тормыш иптәше Рәмис әфәндене Тәтеш районының бер хуҗалыгына рәис итеп билгеләгәч тә, Ульянда яшәп яткан Рима куркып кала. Тормышлары үз көенә ага, малайлары үсеп килә. Бер карасаң, бәхет өчен артык нәрсә кирәкми дә кебек. Әмма җир эшенә мөкиббән киткән, кырны икенче өедәй якын күргән иренә карый да тәвәккәлләргә була, шул ук хуҗалыкта иренең уң кулына әйләнә. Тырышлыклары бушка китми, чит илләр тәҗрибәсен туплап, районда гына түгел, республика күләмендә алдынгылар рәтенә чыккан хуҗалык җитәкчесен тагын да җаваплырак вазифага куялар. Моңа кадәр бухгалтер булып эшләгән Рима ханыма исә идарә дилбегәсен үз кулларына алырга туры килә.

– Бер эшне дә ялгыз гына җиңеп чыгу мөмкин түгел, бигрәк тә авыл хуҗалыгында. Чәчүгә төшәр алдыннан механизаторларны җыйдым да: «Егетләр, бөтен өмет сездә», – дидем. Бу эшнең нечкәлекләрен белми идем бит әле ул вакытта. Ходай рәхмәте, сүземне тыңладылар. Тукталып калмаска, сынауларны лаеклы узарга терәк булдылар, – ди бүген Рима ханым.

Кунак ашы – кара-каршы дигәндәй, хезмәттәшләренә рәхмәтен мулдан әйтә ул.

– Авыл – ул аерым бер мохит. Биредә яшәүчеләр авыр хезмәткә күнеккән, нинди генә авырлыклар килеп чыкса да, зарланмаска өйрәнгән. Мин исә, җитәкче буларак, алар алдында җаваплылык тоям. Эшләгәннең ашы булырга тиеш. Шуңа күрә дә төрле яклап ярдәм кулы сузарга, ял вакытларын күңелле итеп оештырырга, хезмәт шартларын уңайлы итәргә тырышам. Ашханә эшли, юыну, өс-баш алыштыру урыннарыбыз көйләнгән. Компьютерлар популярлашып киткән чорда бухгалтерларыбызны махсус курсларда укытып кайтардык, – ди җитәкче ханым.

Хезмәт алдынгыларына санаторийга юллама, зур-зур бүләкләр бирү, авырлыклар килгән чакта матди ярдәм күрсәтү дә матур гадәткә әйләнгән. Дистә еллар буе иңгә-иң куеп эшләгән, кирәк чакта уртак эш өчен вакытын да, көчен дә жәлләмәгән хезмәттәшләрен шатландыра алуны да бәхеткә саный Рима ханым.

– Тормышымны коллективымнан башка күз алдына да китерә алмыйм инде хәзер, алар миңа туганнарым кебек якын. Бергәләп, туган көннәрне, бәйрәмнәрне үткәрәбез, үзара ярдәмләшеп яшибез. Һәрберсенең эшкә теләп, ашкынып йөрүләре дә үзенә күрә бер күрсәткеч булып тора, минемчә. Уртак максатка ирешү өчен тырышканга күрә нәтиҗәләребез дә мулдан. Хезмәтенә күрә хөрмәте дигәндәй, хезмәт хакыбыз да күпләр сокланырлык. Шуңа күрә яшь кадрларны да җәлеп итә алабыз.

Кадрлар дигәннән, аларга кытлык юк, ди хуҗалык җитәкчесе. Шулай да якын-тирә авылларда яшәүчеләр белән эшләүне хубрак күрә ул. Гаиләсе янында булган, эш-тормыш шартлары җайга салынган хезмәткәр тырышыбрак эшли дигән фикердә тора.

Эшлекле ханымның иң зур хыялы исә – авылларны яшәтү, матурайту. Татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова тәкъдиме белән Тәтеш районындагы оешманы җитәкләргә алынуы да шул хыялын тормышка ашырырга омтылудан аның. Авыл хуҗалыгы тармагында берьюлы ике оешманы җитәкләгән кешенең эше болай да тавык чүпләп бетермәслек күп инде.

– Тукай да бит, «...эшкә бирсәң чын күңел...», дип язып калдырган. Иң мөһиме – теләк, – ди героебыз. – Вакытны дөрес бүлгән очракта алынган һәр эшең өлгереп була. Үзебез яшәгән җирләрне дә чит илләрдәге кебек чәчәккә күмәсем килә. Авылда да матур итеп яшәргә, эшләргә шартлар булганлыгын барысы да күреп торсын!

Бүгенге көндә райондагы үндүрт татар авылының һәрберсендә «Ак калфак» хәрәкәте эшләп килә. «Нәни энҗеләр», «Татар малае» бәйгесе үткәргәннәр. Шаккатырлык бит, руслар, мари-чувашлар күбрәк яшәгән Тәтеш татарча сөйләшә башлаган!

– Шактый тырышырга туры килде инде. Теләктәшләрем белән авылдан-авылга, өйдән-өйгә йөреп, киләчәгебезнең нинди булуы бездән торганны, ата-бабаларыбыздан калган рухи мирасны балаларыбызга, оныкларыбызга тапшыру зарурлыгын аңлатып



*Рима Сафиуллова (уңнан алтынчы) иҗтимагый эштә дә үзәктә.*

йөрүебез бушка китмәде. Зиратларны, чишмәләрне чистартуны элек оештырырга туры килсә, хәзер халык үзе хәбәрләшә дә өмәгә чыга, – ди җитәкче, горурланып.

Мондый үзгәрешләргә иң сөенгәне, әлбәттә, өлкәннәр. Әбиләрнең: «Рәхмәт, кызым!» – диюләре үк Рима ханымның иңенә канат куя, яңа эшләргә рухландыра.

– Шәһәрдән аермалы буларак, авылда бит теләгән һәр юнәлеш белән шөгыльләнергә секцияләр, түгәрәкләр оештырып бетереп булмый. Шулай да җаен табарга тырышабыз. Хатын-кызлар белән ансамбль оештырдык, костюмнар тектердек. Төрле бәйрәмнәрдә чыгыш ясыйбыз, яратып кабул итәләр. Инде башка районнарга да чакыралар. Моңа кадәр Казанга да барыр җае булмаган сәләтле бер терлек караучымны «Играй, гармонь» фестиваленә җибәрдек, дөнья күрергә мөмкинлек биргән өчен бүгенгә кадәр рәхмәт әйтә. Авылда да талантлы кешеләр күп. Аларны да барларга, бераз булса да ярдәм итәргә генә кирәк.


«Җилкәнеңне җилләр екса – йөрәгеңне җилкән итеп күтәр. Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән. Көчле рухлылар гына максатларына ирешә алалар. Түземнәр генә бәхеткә лаек...» Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» әсәреннән алынган әлеге юллар героебызның тормыш девизы булып тора. Бер тәвәккәлләп, аның турында китап язсаң, яратып, исләре китеп укырлар иде, мөгаен. Күпләргә үрнәк һәм терәк булган, үз тырышлыгы белән хезмәттәшләре арасында гына түгел, республика күләмендә абруй казанган Рима Гомәр кызының бәхете дә башкарган эше кебек бәрәкәтле, мулдан булсын.

**Ландыш НӘСЫЙХОВА**

# ХАТИРӘЛӘРНЕ БАРЛАГАНДА

***(Әдәбият галиме Хатыйп Миңнегуловның «Озын гомерем хатирәләре» (икенче кисәк) исемле китабы чыгуы уңаеннан )***

Әдәби процесста элек-электән, теге яки бу шәхес иҗатына якын килгәндә, аның мирасын барлаганда, әдәбият кануннары нигезендә бәя биргәндә, аның үзе турында үзе язганнары, документаль очерклары, автобиографик язмалары, хатлары, сәяхәтнамәләре, мөрәҗәгать-хәбәрләре игътибарга алына һәм акны ак, караны кара итеп фикерләргә омтылу, бәян итү, шуларга таянып хөкем чыгару рәвешенә өстенлекле караш яши. Әдәбият тарихында олуг шәхесләрнең иҗат мирасына мөрәҗәгать иткәндә, мондый алым элек-электән яши һәм, әйтергә кирәк, бүген дә лаеклы рәвештә дәвам иттерелә. Авторларның иҗат мирасында булган һәм сүз сәнгатенә караган барлык әдәби хәзинәләренә хәерхаһлы мөнәсәбәт – эшчәнлекнең чишмә башы булып тора. Язмаларының тел-өслүб үзенчәлекләрен ачыклау, әдәби телен, сүз сәнгатендәге урынын өйрәнү, матур әдәбият тарихына керткән өлешенә бәя бирү дә параллель рәвештә бара. Әдипнең биографиясенә, китапларының тематикасына, аның тәхәллүсләренә игътибар ителә. Дөрестән дә бу структура, теге яки бу әдипнең иҗат мирасын өйрәнүдәге әлеге калып, барлык шәхес иҗатын барлаганда, комплекслы өйрәнгәндә, туры килеп бетмәскә дә мөмкин.




Берәүләр үзләренең әсәрләренә тәхәллүс итеп, туган җирләренең, яшәгән карьяларының исемнәрен алалар, сирәк булса да, географик атамаларын алучылар да бар. Икенчеләр исә, әти-әнисенең, җиде буынгача булган әби-бабайларының исемнәрен алуны хуп күрәләр. Берәүләр автобиографик язмаларга өстенлек бирә, икенчеләре языласы сүзен, фикер байлыгын, реаль хакыйкатьне әйләнә-тирәлектән эзли. Ә кайберләре исә әдәби мирасларын автобиографик язмалар белән баета, тулыландыра, өченчеләре шигъри формадагы әсәрләренең кереш яки йомгак өлешенә үзе турында мәгълүмат өсти, фикерен әдәби әсәргә керешеп китәрлек итеп ялгап җибәрә. Андый мисаллар безнең татар әдәбиятында шактый. Мисал өчен Кол Галине алыйк. Аның тормышы хакында чыганаклар юк дәрәҗәсендә. Хәтта аның туган һәм үлгән еллары да билгесез. Әмма аерым мәгълүматлар шагыйрьнең тәрҗемәи хәле турында фараз кылырга мөмкинлек бирәләр.

Мәсәлән, борынгы әдәбиятта, бигрәк тә XVIII йөздә иҗат итүчеләрнең күпчелеге туган авылларының исемен үзләренә тәхәллүс итеп алалар. Габдерәхим Утыз Имәнинең (1754–1834) Чирмешән районы Яңа Кади (элеккеге Чистай өязе Утыз Имән) авылында туганын һәм әдәби

тәхәллүсе итеп, үз авылының исемен алуын беләбез. Шулай ук XVII йөздә иҗат иткән Мәүлә Колыйның да яшәгән еллары төгәл билгеле түгел, «Мәүлә Колый» – әдипнең тәхәллүсе. Бер кульъязмадагы шигырендә автор үзен «Меллагол» дип атый. Борынгы һәм урта гасырлар әдәбиятында мондый мисалларны шактый китерергә булыр иде. Димәк, бу әдәбият теориясендәге үзгә бер алымның отышлы, әйтергә кирәк, мөһим формасы. Соңгарак дәвердә исә автобиографик алым өстенлек ала бара. Бөек Тукаебызның «Исемдә калганнар»ына кадәр һәм аннан соң – бүгенге әдәби мәйдандагыларның да мондый алым кулланып, эш итүләрен күрергә була. Мондый алымны үз итеп, иҗат мирасларын тулыландыручы әдипләребез шактый безнең. Әйтик, язучы һәм драматург Афзал Таһировның «Мин ничек үстем» хикәясен, «Солдатлар» романын, Шәйхи Маннурның «Агымсуларга карап» романын, Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре»н, Мөхәммәт Мәһдиев, Тәлгат Галиуллин, Тәүфикъ Әйди, Миргазиян Юныс һәм башка бик күпләрнең әсәрләрен, Туфан Миңнуллин драмаларын мисал итеп китерергә булыр иде. Әдәбият галимәләре Гөлфия Гайнуллина Шәйхи Маннур иҗатын, ә филология фәннәре докторы Ләйлә Минһаҗева Ибраһим Салахов мирасына әнә шулай комплексны якын килеп өйрәнделәр, фәнгә дәлилле, саллы өлеш керттеләр. Димәк, бу инде фәнни яктан да өйрәнелгән һәм, әйтергә кирәк, шактый саллы күзәтүләр үткән өлкә диясе килә. Дөрес, әле кайбер күренекле шәхесләрнең әдәби тәхәллүсләре бүгенге көнгә кадәр ачыкланмаган, өйрәнелмәгән. Табылмаган авыл исемнәре яки башка бүтән төрле исемгә алыштырылган җирле төбәк атамалары хакыйкый чынбарлыкны ачарга комачаулый. Мәсәлән, туган илләреннән читләргә сибелгән татарның бер газиз баласы – язмышын Төркия мәмләкәтләре белән бәйләгән күренекле табиб, әдәби һәм гыйльми китаплар авторы Әхмәд Каранның (1878-1964) биографиясе, төгәлрәге, аның Татар Җөмһүриятендәге туган авылы, укыган, белем эстәгән урыннары бүгенге көнгә кадәр билгеле түгел. Үзенең әдәби кушаматын Каран дип атаса да, истәлекләрендә Казан арты төбәген искә алса да, бу якларда Каран исемле авылның юклыгы эзләнүләребезгә киртә булып тора. Минзәлә якларындагы Каран авылы белән әдип арасында бәйләнешләр дә юк диярлек. Бәлки, бу әдәби тәхәллүс, төбәк исеме түгел, әлеге нәселнең берәр төрле тәхәллүсе дә булырга мөмкин бит...

Шулай итеп, әдәби барыш авторның туган төбәген, язмышларын бәян иткән биографик чыгышлар аша анализлана, исбатлана, дәлилләнә, фәнни әйләнешкә кертелә. Мөһим детальләр аша ачыклана. Бу исә, әдипкә, аның иҗатына тулы бәя бирү өчен мөһим алшарт булып тора. Тикмәгә генә Мөхәммәт Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» әсәрен татар тормышын, татар авылының көнкүрешен, тарихын чагылдырган энциклопедик әсәр дип атамыйбыз. Мөхәммәт Мәһдиевнең якташы, филология фәннәре кандидаты Илһам Фәттахов та үзенең кандидатлык диссертациясендә боларга этрафлы бәя бирде. Әсәрләренең проблематикасын әдипнең биографиясе аша якын килеп тикшерде. Әле алга таба да Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләрендәге этнографик детальләргә мөрәҗәгать итеп, фәнни хезмәтләр язылыр, татар авыллары тарихына бай мәгълүмат өстәлер диясе килә.

Һәм менә киң җәмәгатьчелек өчен биниһая зур, мөһим яңалык. Әдәби сүз сәнгатенә, аның бай тарихына яңа сулыш өстәп, Хатыйп Миңнегуловның яңа китабы дөнья күрде. Галимне язучы буларак та ача торган, аның иҗатының тагын да зуррак мөмкинлекләрен күрсәтә торган «Озын гомерем хатирәләре» II кисәк. Университетта эшләү еллары (1967-2020). Сәфәр – сәяхәтнамәләр – Казан: «Ихлас» нәшрияты, 2020. – 408 б. китабы дөнья күрү бөтен татар дөньясының горурлыгы булды. Ихлас күңелдән һәм олы йөрәктән язылган бу мәҗмуга укучылар арасында киң хуплау тапты. Галимнең бөеклеген ачып, аңа ихтирам хисләре уятты. Дөрес, 2018 елда аның «Озын гомерем хатирәләре. I кисәк. Гомеремнең беренче чиреге» исемле китабы дөнья

күргән иде. (Казан: «Ихлас». – 112 б.). Бу китабы исә шуның бер дәвамы, чираттагысы булып тора. (Әле алга таба да әлеге китапның дәвамын күреп, бәяләмәләр язарга язсын). Беренче китапны укып чыкканнан соң, остазым Хатыйп Миңнегуловка: «Ник «Озын гомерем...» дип куйдыгыз? – дигәнем булды. – «Озын» сүзен төшереп калдырып кына булмадымы?» – дигәч, галим: «80 яшь – бик озын бит инде ул. Уртача яшь киртегеннән артып, озынаеп китә », – дигән иде, уйланып. Инде менә «Озын гомерем...» нең икенче кисәге дә язылып, киң катлам укучылар хозурына тапшырылды. Китап чыгару өлкәсендә тәҗрибәсе зур булган әдипнең әлеге казанышы, башкаларыннан күпкә аерылып, ничектер үзенә бер мөһим бер вакыйга итеп кабул ителде. «Хатирәләр»нең беренче кисәген яратып укып чыккан милли җанлы шәхес, Татарстанның Балтач районы Алан, Бөрбаш авыллары мәктәпләрендә директор һәм татар теле, әдәбияты укытучысы булып эшләгән Гүзәл Бариева миннән: «Хатыйп абый китабының беренче кисәген 96 яшьлек әни бөртекләп укып чыкты. Икенче кисәген (дәвамын) сорый. Шул чыккан булса, табып алып кайтып кына бирегез әле», – дигән иде. Сүземдә тордым, көн дә вакытлы матбугатны укып баручы, бөтен яңалыклардан хәбәрдар булган Нәзифә апага әлеге китапны алып кайттым.

Нәрсәсе белән гаҗәпләндерде соң бу хатирәләр? Беренчедән, Хатыйп Миңнегуловның теле гади, язу өслүбе «безнеңчә», бизәкләмичә, чуарламыйча, «мин-минлекләнмичә» яза алуда. Автографик истәлекләренең «җаны», «үзәге» булуда. Ул үткән гыйбрәтле юл үзенең бәгыре, йөрәге аша узгангамы, һәр язылган җөмлә, һәр куелган өтер, Хатыйп абыйның һәр фикере кәгазь битләренә бозылмыйча, үзгәртелмичә төшкән. Хатыйп ага боларны язганда, тыныч кына, күз яшьләрсез генә яза алдымы икән?!. Иҗат биографиясенә якты, җылы буяулар өстәүче истәлекләрдә кеше язмышларының ачы фаҗигаләрен күреп тетрәнәсең, сагышланасың. Тирән уйлар чолганышында яшисең һәм бераздан, Хатыйп Миңнегуловча, хәерле чишелешкә юлыгасың.

Китапның кереш өлешендә Хатыйп Миңнегулов әлеге эшкә тотынуының сәбәп-максатларына тукталып уза. 80 яшьлек кешенең хатирә-мемуарлар язарга алынуы табигый. Тик менә 80 яшенә кадәр Казан федераль университетында студентларга Борынгы һәм Урта гасырлар татар әдәбиятыннан белем биргән мөгаллимнең эштән китүе белән бәйле дисәң, анда үпкә-сагышның әсәре дә юк, инде көч-куәт барында үз фикерләрен үзе тәртипләп язып калдырыйм дисә, әле ашыгырга иртәрәк тә кебек, югыйсә үзенең фәнгә юл ачкан шәкертләре белән көн дә аралашып, сөйләшеп тора, моңа да сәбәп юк кебек. Автобиографик әсәренең эш процессында төшкән фотоларга гына түгел, гаилә архивы тарихындагы төсле фотоматериаллар белән дә үрелеп баруы галимнең яшәгән елларына билгеле бер нәтиҗәләр ясавы, тарихта бер нәрсәнең дә мәңгелек түгеллегенә ишарәме?! Ничек булса да, Хатыйп абыйның бу адымы хуплауга һәм мактауга лаек.

«Һич көтмәгәндә, бу китап шактый киң даирә укучыларның, аеруча таныш-белешләрнең, туган-тумачаларымның, элеккеге студентларымның игътибарын үзенә җәлеп итте», дип яза галим хатирәләренең кереш өлешендә. Дөрестән дә, әле яңарак кына дөнья күрүгә карамастан, бу китап материаллары мәктәпләрдә, уку йортларында, гыйльми язмаларда бик иркен файдаланыла. Хәтта өзекләре сәхнәләштерелә, чор белән әдип бәйләнешендә сценарийлар языла һәм киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителә.

2018 елда нәшер ителгән беренче «Хатирәләр...» дән соң икенче «Хатирәләр...» 2020 елда языла. Ул «Милләтемә берничә теләк» исемле мәкалә белән ачыла. Анда Хатыйп Миңнегуловның үтә дә тәэсирле җөмләләрен, иң якын кешесенә генә әйтеп була ала торган телдә җиткерелүен күрәсең. Ышанычлы итеп, тәвәккәллек белән сүз башлый ул: «Игелекле эш-гамәлләребез белән милләтебезне саклыйк, үстерик, башка кавемнәр арасында лаеклы урынны алу өчен фидакарьләрчә

көрәшик», дип ассызыклый автор, халкыбызга мөрәҗәгать итеп. Ә бит бу сүзләр үзеңнең шәхси халәтеңә туры килмәсә, болай итеп әйтеп булыр идеме икән?! Бу исә әдипнең әйтергә теләгәненең йөздән, меңнән бере генәдер әле. Аеруча җылылык белән әйтелгән бу сүзләрдән соң, китапның калган битләрен дә, ничектер галимгә хәерхаһлы мөнәсәбәттә дәвам итеп укыйсың.

Хатыйп Миңнегуловның «Озын гомерем хатирәләре» исемле китабы – әдипнең чираттагы ачышы дияр идем. Әдәби яктан теле йөгерек, бай эчтәлекле, җиңел укылуы белән характерлы бу китапны киң җәмәгатьчелек бик җылы кабул итте. Фән юлындагы шәкертләргә дә менә дигән күрсәтмә-әсбап буларак кыйммәтле хәзинә – юл яктыртучы, юнәлеш бирүче дәреслек.

Автобиографик мәҗмуганың төп өлешен профессорның гыйльми характердагы язмалары, очерклары, сәяхәтнамәләре, юбилей мөнәсәбәте белән язылган фәнни язмалары алып тора. Конференцияләрдә ясаган чыгышларына да киң урын бирелгән. Казакъстан, Финляндия, Төркия, Кытай, Кырым кебек ерактагы якын кардәшләр иҗатын өйрәнеп, Хатыйп ага бәяләп бетермәслек күп хезмәт язды. Беренчеләрдән булып, шушы кыйтгаларга сәяхәтләр кылды, анда яшәгән татарлар белән очрашып, андагы архивларга үтеп кереп, күләгәдә калган, моңарчы язган хезмәтләрен генә түгел, исемнәрен дә ишетергә мөмкин булмаган шәхесләрнең әдәби мирасларын ачыклады, аларның иҗатларын, язмаларын өйрәнеп, фәнни әйләнешкә кертте. Китапта аларга да тиешенчә урын бирелгән. Һәр бүлек өр-яңа теманы колачлый һәм биографик юнәлештә бәян ителә. Галимнең яшәү еллары хозурында булып узган вакыйгалар тирән яктыртыла, бәяләнә. Яшәү еллары нисбәтендә ачыклана.

Китабының беренче бүлегендә үк, Хатыйп Йосыф улының янә Казанга килүенең җан таләбе, күңел халәте чакыруы буенча икәнлеген чамалыйсың. Ул: «Җан үзенә ятышлы эш-гамәлләргә омтыла, күңелемә тәмам хуш килерлек шөгыльгә юксына, – ди, үзенең күңел халәтен чагылдырып. – Фәндә ныклап эшләргә җыенган яшь хезмәттәшләремә теләгем шул: бу өлкәгә мөмкин кадәр иртәрәк, бернинди тукталыш – интервалсыз керергә, аспирантурада укырга кирәк. Моны мин – күпләр докторлык диссертациясе яклаган вакытта гына фән кандидаты була алган кеше әйтә», ди ул, күңелендәгесен ихластан ачып салып. Әйе, Хатыйп абый – тормышта бернинди терәксез, үзенең тырышлыгы, максатчанлыгы, тәвәккәллеге аша гына зур уңышларга ирешкән шәхес ул. Дөрес, остазлары Хатыйп Госман, Нил Юзиевлар аңа һәрчак игътибарлы булалар. Аны Казанга чакырып китерәләр һәм булачак галимне гел рухландырып торалар: университетның әдәбият кафедрасына эшкә урнаштыралар, дәресләр бирәләр.

Хатыйп Миңнегуловның китабында, чын мәгънәсендә яшәү рәвеше, яшәү мәгънәсе чагыла. Әйе, ул аны үзе белән булган хәлләргә, вакыйгаларга бәйләп аңлата, йә инде теге яки бу күренешне тасвирлап, нәтиҗәләр ясарга һәркемнең үзенә калдыра.

«Хатирә»ләремнең әле тик кайберләрен генә үз эченә алган беренче кисәге дә, гәрчә кечерәк кенә булса да, бер китапны тәшкил итте. Ә бит ул гомеремнең, нигездә, беренче чирегенә генә үз эченә ала. Ә алда ярты гасырдан артык гомерне язу тора. Ул бит катлаулы, каршылыклы, вакыйга-хәлләргә шактый бай чор. Аны ничек, ни рәвешле бирергә? Бирелә тулылыкка, гомумилеккә дәгъва итү ахмаклык булыр иде. Шуңа күрә мин бу чордагы, яшәешемнең кайбер якларына, эпизод-күренешләренә, вакыйга-хәлләренә генә тукталырга уйлыйм. Хронологияне саклап булмас, мөгаен, вакыт яссылыклары, хронотоп үзгәреп тә торыр», дип искәртә автор.

Хатыйп Йосыф улының студенты, шәкерте, аспиранты, кандидатлык диссертациямнең җитәкчесе буларак, үзем дә өстәп, шуны әйтә алам. Ул бервакытта да, беркайчан да беркемгә дә тавышын күтәргән кеше түгел. Андагы зыялылык, олпатлык дәрәҗәсен күреп, исләрең китәр-

лек. Берәүне дә аерып алып хурламас, үзе югында кимчелекле якларын тикшермәс. Гәрчә үзенә төрле чорларда, төрле аудиторияләрдә, төрлечә кимсетеп, төрттереп алсалар да, берәүгә дә үч, ачу сакламас.

«Студентлар белән уртак тел табуның, уңышлы эшләүнең иң төп шартларыннан берсе – аларга хөрмәт белән карау, шәхесне түбәнсетмәү, үзара ихтирамлы мөнәсәбәт урнаштыру. Университетта ярты гасырдан артык хезмәт куюымның төп шарты, мөгаен, шулдыр да», – дип саный мөгаллим. Дөрестән дә, кайларга гына барып чыкса да, аны элеккеге студентлары уратып алыр. Укыган вакытларындагы кызыклы хәлләрне искә төшереп көлешеп алырлар, яки Хатыйп абыйның теге яки бу вакыттагы ярдәмен искә алып, аны олыларлар. Бу чыннан да шулай. Ә бит галим Хатыйп Йосыф углына да үз чорында бер дә җиңелләрдән булмаган. «Асыл максатым Алтын Урда әдәбиятын колачлап, комплекслы өйрәнү һәм аның нәтиҗәләрен 70 еллар ахырына докторлык диссертациясе рәвешендә яклауга кую иде. Әмма дөнья без теләгәнчә генә бармый шул. Баксаң, рәсми хакимияттә һәм җәмәгатьчелекнең аерым бер даирәләрендә Алтын Урдага тискәре, тенденциоз караш һаман да дәвам итә икән. Миңа «Алтын Урданы күтәрә, идеаллаштыра», – дип, урынлы-урынсыз бәйләнүләр китте. Хәтта махсус комиссия «Борынгы әдәбият» курсыннан минем дәрес-лекцияләрне, студентларның конспектларын тикшерә башлады. Югарырак оешмалардан бу елларда эшкә чакырулар да тукталды. Хатыйп Йосыф улы сәяси ышанычсызлар исемлегенә кереп алды бугай, – дип яза автор. – «Кыен чаклар бик күп булыр, түзәргә кирәк, балам» җырындагы кебек түздем, кешегә бик чыгармадым».

Х.Миңнегуловның эшчәнлеге, университетта укыту еллары – үзе бер кызыклы, маҗаралы, мавыктыргыч дөнья ул. Аның хатирәләрендәге һәр вакыйга табигатьтә алышынып торган ел фасыллары кебек гел үзгәреп, үз хозурлыгында, үз матурлыгы һәм җәлеп итәрлек хәлләре белән чиратлашып, гел алышынып тора. Менә ул фольклор экспедициясендә, бераздан профессор музейлар буйлап сәяхәткә кузгала, аннары аның Ленинградта, Мәскәүдә, Дүшәнбедә, Ташкентта һәм башка шәһәрләрдә стажировкалар узып йөрүен беләсең. Каян барысына да өлгерә, барысына да вакыт, мөмкинлек таба икән дип гаҗәпләнәсең?! Тик кайда гына, нинди генә илдә, нинди генә эштә булмасын, галим күргән-белгәннәрен, уй-фикерләрен, өйрәнүләрен «энәсеннән җебенә» кадәр үтә дә нечкәлек һәм төгәллек белән теркәп бара һәм китабында да шулай чагылдыра. Моның кадәр төгәллекне көндәлек алып бармаган кеше язу түгел, исендә дә калдыра алмый. Хатирәләрендәге һәрбер истәлек-вакыйгаларны шәхесләр белән үреп, тасвирлап бирүе галимнең бик отышлы һәм бик кулай алымы дияр идем. Шуңа күрә әлеге мәҗмуганы уку бер дә ялыктырмый, ә киресенчә, таныш исем-фамилияләрне танып уку кызыксынуларыбызны арттыра гына. Шунысын да әйтү урынлы булыр: биредә автор үзенең «кичәге» студентларын, шәкертләрен – «бүгенге» фән, мәгариф, мәдәният хезмәткәрләрен, галим-голәмәләрне, язучы, шагыйрь, журналистларны һәм башка бик күп тармакларда илгә-көнгә хезмәт итүчеләрне һәрберсенең исемнәре белән, бернинди үзгәртүләрсез һәм һәрберсенә җылы караш, ышаныч һәм ихтирам белән бәян итә.

Галим үзенең китабының «Мин ничек фән докторы булдым?» дип исемләнгән бүлегендә бәйнә-бәйнә үз башыннан узган гыйбрәтле дә, истәлекле дә булган кичерешләргә туктала, нәтиҗәләр ясый. Чөнки Хатыйп Йосыф улы бу процессны эченнән, үзәгендә кайнаган кеше буларак та, ачык белә. Чөнки ул, үзе кандидатлык һәм докторлык хезмәтләрен әзерләү һәм яклаудан тыш, дистә елдан артык Казан университеты каршындагы докторлык диссертацияләре яклау советының гыйльми секретаре, рәис урынбасары булып торды. Аның кулыннан йөздән артык диссертация узды, уңышлы якланды.

Галим эшчәнлегенең иң матур, иң киеренке, эшлекле чорында гаиләсенә көтелмәгән җирдән кара кайгы килә. Ленинградта институтны тәмамлап, шунда

ук калып, ансамбль-балетта эшләүче кызлары Гөлназ җиденче каттан егылып төшә. 1989 елда булган бу фаҗиганең эзе бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Сәламәтлеге нык какшаган Гөлназга әле бүген дә табиблар ярдәме еш кирәк. Әлеге аяктан егарлык хәлләргә түзә профессор, тешен кысып түзә. Фәннән дә читләшми ул. Һәм 1991 елда күптән көтелгән докторлык диссертациясен яклап, филология фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә алуга ирешә. «Әмма доктор булу җаваплылыкны тагын да көчәйтте, – ди галим. – Синең әйткән, язган сүзең рәсми дәрәҗәләргә лаеклы булсын. Фәндә, хезмәтеңдә син тырышлыкның, активлыкның үрнәге дә булырга тиеш», – дип, ул үз-үзенә таләпчәнлекне тагын да арттыра гына.

Хатыйп абыйның фәнни эшчәнлеге докторлык диссертациясе яклагач та, зур уңыш белән дәвам итә. Ел саен диярлек монографияләр бастырып чыгару, чит илләргә сәяхәтләр бер генә дә тукталып тормый. Элеккеге фәнни юнәлешләрен саклаган хәлдә соңгы дәвер, аеруча мөһаҗирлектәге татар әдәбияты һәм матбугаты, шул исәптән Гаяз Исхакый иҗаты белән дә ныклап шөгыльләнә башлый. Шуларның чыгармасы буларак, галимнең әлеге китабында төрки-татар сүз сәнгате, аның халыкара бәйләнешләре, Шәрык әдәбияты, халкыбыз тарихы турында да саллы гына язмалар бар.

Галимнең «Хатирәләре» үзенең жанр табигате белән, гәрчә фән белән билгеле бер бәйләнештә торса да, шактый дәрәҗәдә публицистикага, матур әдәбиятка тартым. Шуңа да әлеге язмаларда еш кына традицион хатирә жанрына хас булган тел-өслүб чараларының сакланмавын да әйтеп үтү кирәктер. Әдипнең гыйльми фикерләве, фәнни гыйбарәләре күбәеп, артып китә кебек. Шуңа да сүзләрдә, җөмлә төзелешләрендә фәннилек алгы планга чыга. «Урыны белән безнең сөйләм отчёт-хисап рәвешен дә ала, – дип искәртә автор үзе дә. – Ярар инде, үзем теләгәнчә, булдыра алганча яздым. Укучыдан минем хата-кимчелекләргә киң күңелле булуны сорыйм. Җитмәгән җирләрен үзе җиткереп, озыннарын үзе кыскартып укыр, дип ышанам», – ди автор, укучыга мөрәҗәгать итеп «Икенче кисәккә нокта кую алдыннан (йомгак урынына)» исемле бүлектә.

Моннан аңлашылганча, әле Хатыйп абыйның чынлап та әйтәсе сүзләре, җиткерәсе фикерләре калган икән. Боларын исә, алдагы «Хатирә»ләрдә көтәбез. Автор үзе дә: «Хатирә»ләремнең, Алла боерса, исән булсак, дәрт-дәрман, илһам килсә, бәлкем, өченче кисәге дә язылыр. Әгәр дә мондый мөмкинлек туа икән, ул өлешендә хезмәттәшләрем, студент, аспирантларым, нәсел-нәсәбем, туганнарым (бәлкем, әле мәхәббәтләрем, сөйгән ярларым турында да язылыр (монысын инде шаярыбрак та әйтәм)), иҗтимагый, гыйльми, мәдәни тормыштагы аерым хәл-вакыйгалар төп урынны алыр, дип уйлыйм. Шөкер, әле күңелдә, хәтердә бик күп истәлекләр саклана. Кузгатып җибәрергә генә кирәк». Насыйп булсын, Хатыйп абый, диясе генә кала. Сәламәт булыгыз да, халкыбызны мәгърифәтле, иманлы, динле, телле итүдәге эшчәнлегегездә илһам-ышаныч сүнмәсен генә иде.

**Рәҗәп БӘДРЕТДИНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты*

# УРМАНЧЕ ҺӘМ ТАКТАШ

## ИСТӘЛЕК

Бакый ага Урманче мин аны белгән дәвердә кунакка йөрергә, сәяхәт кылырга бик ашкынып тормый, ә үзе кунак кабул итәргә ярата иде. Күзне йомган килеш тә табып була торган китапларың, архив папкаларың, стеллажлардагы картиналарың янында булганда, теләсә кем белән теләсә нинди темага әңгәмә корырга җайлы бит! Кирәк булса, эшләнеп беткән, йә гипс, йә балчык хәлендәге скульптуралары да якында гына – шул ук өйдә, бер кат түбәндәрәк кенә... Бакый аганың Академик Королёв урамындагы кунакчыл өендә кемнәрне генә очратмадым мин?! Шуларның берсе – Рафаил Һади улы Такташ*, ягъни бөек шагыйребезнең өлкән улы.

1970 елның 23 августында булды бу очрашу. Мин ул вакытта «Яшь ленинчы» газетасында җаваплы секретарь булып эшли идем. Бакый ага мине иртәнге сәгать уннар тирәсенә өенә килергә, бер сәнгать белгеченең аның турында язган мәкаләсен укып фикер алышырга чакырган иде. Якшәмбе көн иде ул. Бакый аганың кунагы анда иде инде. Кояш нурларын шактый мул сеңдергән йөзле, чандыр, озын буйлы, ир уртасы кеше ачык көлсу төстәге затлы костюмнан.

– Шагыйрь Ренат Харисов, – дип, мине аңа тәкъдим итте Бакый ага. Рәссамның җыерчыксыз киң маңгае агарыбрак, ә йөзе кызарыбрак киткән кебек күренде. Әллә нинди очракларда да җан тынычлыгын сакларга күнеккән, хисләрен авызлыкта тота белгән, сабырлык үрнәге булырлык Бакый ага бераз дулкынлана иде.

– Рафаил Такташ, – дип, кискен генә кулын сузды миңа Бакый аганың кунагы, исеменең ахыргы авазларына басым ясап. (Соңыннан гына белдем: иҗатында гел яңалыкка омтылган Һади Такташ улына исем сайлаганда, Библия фәрештәсе Рафаилне дә, бөек итальян рәссамы Рафаэльне дә истә тотмаган, ә «Рабочий факультет имени Ленина» атамасының сүзләрен кыскартып ясаган икән. Шагыйрьнең хатыны Гөлчәһрә Хәмзина улы туганда, әнә шул факультетта укый торган була. Икенче улының исеме – Аван. Чуваш телендә ул «яхшы, әйбәт» мәгънәсен белдерә. Шуннан алынгандыр дисәм, ул да әүвәле Авангард булган икән. Күп еллардан соң миңа бүләк иткән үзенең шигырьләре һәм поэмалары китабының тышлыгында ул исемен Рафаил Такташ дип язган.)

Такташ исеме, минемчә, һәр татар кешесе өчен мәктәп дәресләкләреннән үк таныш, ниндидер магик көчкә ия, дулкынландыргыч сүз. Минем кебек яшь язучы өчен – бигрәк тә. Ул вакытта мин инде күренекле фотохудожник, шагыйрьнең кече улы Аван Такташ белән дә таныш идем, хезмәттәшлек мәйданында ара-тирә очрашканга, бу сүзгә күпмедер дәрәҗәдә күнеккән дә идем шикелле. Бакый аганың күзләрендә кояш нурлары эчеп аккан тыныч елга зәңгәрлеге булса, Рафаил абзыйныкында сикереп аккан салкын чишмә суы зәңгәрлеге иде.

Рафаил Такташ Бакый ага турында мәкалә түгел, ә монография язган булып чыкты. Монографияне Татарстан китап нәшриятына бирергә уйлый икән, ләкин анда тапшырыр алдыннан кулъязманы рәссамның үзе белән карап чыгарга булган. Мин килгәндә, алар эшне башлаганнар иде.

Бакый ага миңа урындык алып килде, үзе биек аркалы креслосына кыңгыраеп утырды, Рафаил Такташ, аңа каршы тәбәнәк креслога кунаклап, рус телендә язылган монографияне укуын дәвам итте. Биография өлешен алар үтеп бетә язганнар иде инде. Ул Бакый агада

* Такташ Рафаил Һади улы (1926 – 2008) – сынлы сәнгать белгече, рәссам, сәнгать фәннәре докторы, Үзбәкстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Үзбәкстан сынлы сәнгать академиясенең мактаулы академигы, 300дән артык фәнни хезмәт, берничә монография авторы.

әллә ни борчу тудырмады, зур креслосына чумып, тыныч кына тыңлый, башын ара-тирә кагып, хуплап куйгалый. Рәссамның конкрет әсәрләрен бәяләүгә килеп җиткәч, Бакый ага тураебрак утырды, тагы да җитдиләнә төшеп тыңлый башлады. Сәнгать белгече Бакый аганың мәшһүр скульптурасы «Сагыш»ка озаклап тукталды. Алар әстерхан чикләвеге агачы түмәрен кайдан, ничек алып кайту турында сөйләштеләр, аның кеше портретын ясау өчен иң яхшы материал булуын расладылар. Рафаил Һадиевич карт кеше сынының күзләрендәге төпсез тирәнлек, маңгаендагы сырларның хәрәкәтле булып күренүе, кулы аркасында бүртенгән кан тамырларында ярсу дулкыннар йөгерүе турында язган.

– Баки Идрисович! А почему эта работа по-татарски называется «Сагыш», а по-русски – «Раздумья»? – дип сорап куйды Такташ. – Сагыш же тоска, печаль... А раздумья – это совсем другое...

– Менә шунда инде бу эшнең хикмәте, Рафаилҗан... Татар килә дә: нилектән сагышлана, нәрсәне йә кемне сагына икән бу карт, дип уйлый... Башка милләт кешеләре килә дә: о чём же так крепко думает этот старик, диләр. И каждый фантазирует по-своему, – диде Бакый ага.

– И о чём же он думает, Баки Идрисович, если не секрет?

– Конечно, не о еде, и не о тряпках, и о женщинах печалиться ему уже бесполезно... – диде Бакый ага һәм, артистларча озак паузадан соң, серле генә итеп өстәп куйды: – Он думает о прошлом, сегодняшнем и будущем, а тоскует – в смысле сагына – по разрушенной мечте, Рафаилҗан...

– А конкретнее, Баки Идрисович!

– Ә бусы инде синең фантазияңә бәйле... – диде Бакый ага һәм эшне дәвам итәргә өндәде.

Рәссам монографиянең бу өлешен дә канәгатьлек хисе белән, хәтта кызыксынуын яшермичә тыңлады – ул Рафаил Такташның фикерләре белән килешә иде. Аның Дәрдемәнд сынын анализлавы миңа, бу шагыйрьне үзенең әдәби остазы дип санаган, аның иҗатын ныклап өйрәнгән, хәтта барлык шигырьләрен диярлек яттан белгән кешегә, аеруча нык тәэсир итте. Бакый ага да Дәрдемәндне иң зыялы һәм тирән татар шагыйре дип саный, аның шигырьләрен яттан сөйли иде. «Булат такмый кәмәрләгән конан бил...» шигырен ул ни өчендер «Фулад такмый кәмәрләгән конан бил...» дип укый иде. Ул миңа «Мөгезе бар куйның бары да кучкар түгел...» шигыренең Мәҗит Гафурига багышланган булуын әйтте – шагыйрьнең алтын приискаларында эшләп алган Гафури бераз аксак булган икән... Дәрдемәнднең «Тәнкәен ак, түшкәйләрен киң яраткан...», «Сөләйманны җиңә Бәлкыйс аягы...», «Кораб» шигырьләренә Бакый Урманченың иллюстрацияләре барыбызга билгеле... Рафаил Такташның минем яраткан шагыйремне «Дардманд» дип язуы һәм шулай тупас итеп укуы күңелемне кыерсытты. Мин, аны бүлдереп, Дәрдемәнд татарча менә шулай языла һәм укыла, ә русчасы болай дип язып һәм әйтеп күрсәтергә батырчылык иттем. Ләкин Рафаил абзый сүзләремне колагына кертмәде, тагын берничә мәртәбә Дардманд дип кабатлады. Мин Бакый аганың китап шкафыннан әле күптән түгел генә аңа үзем төзегән, үзем бүләк иткән, 1970 елның май аенда гына беренче тапкыр русча дөнья күргән «Дэрдменд» китабын алып бирергә мәҗбүр булдым. Рафаил абзый бу кечкенә китапны битараф кына алды, ачып, берничә шигырь укыды һәм кызыксынып китте. Бакый ага Дәрдемәнднең кайсыдыр шигырен (көндәлегемә анысын теркәмәгәнмен) татарча сөйләп күрсәтте һәм аны үзенчә аңлата башлады. Рафаил абзый татарча, бераз үзбәк акценты белән, шигырьне аңлаганлыгын әйтте, һәм ана теленең камил булмавы өчен гафу үтенде: «Сыну классика татарской литературы, конечно, это прискорбно, но, знаете, условия и обстоятельства были таковы», – дип уфтанды. Ул миннән Дәрдемәнднең татарча һәм русча чыккан китапларын табып бирүне үтенде. Мин русчасын табарга вәгъдә иттем, ә татарчасының 1959 елдан бирле нәшер ителмәве хакында әйттем. Рафаил абзый, бераз тын торганнан соң: «Да, он, видимо, всё ещё золотопромышленник!..» – дип куйды. Без яңадан монографиягә кайттык. Рафаил абзый инде «Дәрдемәнд» сүзен һәр очраган саен карандаш белән төзәтеп барды, төзәтеп укыды... Ул укыганда, мин аның кыяфәтендә

форосурәтләрдәге Һади Такташ чалымнарын эзләдем. Бераз таптым да, тапмадым да кебек. Һади Такташның чәче җил булмаганда да, аның барлыгын белгертеп торган давыл-чәч, ялкын-чәч булган. Ә Рафаил абзыйның чәче кара-көлсу, сыек, кыллы җептән бәйләнгән башлык кебек. Ә күзләрендә этисенең төсе бар кебек. Һади Такташның җете зәңгәр күзләре бик матур һәм сихерле булган, диләр. Мәскәүдә аның күзләрен күреп, француженкалар гашыйк булганнар дип тә сөйләгәнне ишеткәнем бар. Рафаил абзыйның зәңгәр күзләре гашыйк итә торган түгел, ә сискәндерә торган иде...

Бу җыйнак, минем өчен кызыклы һәм саллы булып тоелган монографияне без уңышлы гына ерып чыктык. Бакый аганың текстка вак-төяк төзәтмәләре генә булды. Ул, асылда, канәгать иде булса кирәк, ләкин аның күңелен нәрсәдер тырнавы сизелеп тора.

– Рафаилҗан! Ренатка кереш өлешен дә укытып карыйк әле, – диде ул. Рафаил абзый, бер сүз дә әйтмичә, миңа монографиянең шул битләрен аерып алып бирде. Алар чәй эчә-эчә нидер сөйләштеләр, ә мин текстка кереп чумдым. Кереш миңа ошамады. «Казан үзенең рәссамнары белән данлыклы» дип башланган керештә, башлыча, Н.Фешин, П.Беньков, П.Радимов, Л.Фәттахов, Х.Якупов һәм тагын берничә күренекле рәссам иҗатларына киң характеристикадан гыйбарәт иде. Бу төркемдә татар рәссамнарыннан иң беренче булып югары профессиональ белем алган, милли сынлы сәнгатебезнең барлык җанрларын да үстерүгә бәһаләп бетергесез өлеш керткән, казакъ, үзбәк сынлы сәнгатьләрен үстерешкән Бакый Урманче шул төркемнең гади бер әгъзасы гына булып калган. Андый шәхес аерым монографиягә лаеклы була аламы дигән табигый сорау туа. Күрәсең, Бакый аганы әнә шул борчыган, чөнки мондый сорау призмасы аша карагач, ягъни мондый керештән соң, аның иҗаты кечерәеп, икенчел булып кала. Мин үз фикеремне әйттем. Рафаил Һадиевич мине бүлдермичә, ләкин тырпаебрак тыңлады.

– Урынсыз була дип әйттем бит! – диде Бакый ага. Бу мизгелдә аның зәңгәр күзләрендә горурлык очкыннары уйный иде. – Әйттем бит, үгезнең мөгезеннән тотарга кирәк, дип.

Мин килгәнче алар нәкъ менә шушы хакта бәхәсләшкәннәр икән. Рафаил абзый миңа бераз сынабрак, өстәнрәк карап торды да сүзсез генә, тыныч кына шул абзацларны карандашы белән сызып куйды. Ул үзеннән бик күпкә яшьрәк кешенең тәнкыйтен матур күтәрде. Бакый ага фикеренә туры килгәнгә булса кирәк!..

Рафаил Һадиевич китәргә җыенгач, ишек катында тагын бер кызыклы, мине уйга салган вакыйга булды.

– Бакый Идрисович! Я же признаю и показываю Вас основоположником татарского профессионального изобразительного искусства цитатой из Наки Исанбета... Мало ли что не своими словами... Если был бы не согласен, то не взял бы эту цитату. Я всецело согласен... – диде Рафаил Һадиевич һәм татарча саубуллашып чыгып китте. Ул Бакый аганың телдән әйтелмәгән, әмма кәефендә чагылган фикерен, әлбәттә, чамалаган иде.

– Рафаилнең Казанга кайтып төпләнәсе, татарга хезмәт итәсе килә... Ул безнең җитәкчелек белән ачылышлы булудан курка бугай, – диде Бакый ага. – Мине дә бит монда коллегалар кочак җәеп каршы алмадылар...

**P. S.** Рафаил Такташның бөек рәссамыбыз Бакый Урманче турындагы монографиясенең язмышы миңа бүген дә билгесез. Мин аны эзләп карадым, ләкин әлегә таба алмадым. Ләкин андый фәнни хезмәт бар, һәм ул кайдадыр саклана. 2003 елда Казанда узган Беренче бөтендөнья татар галимнәре форумына үзе килә алмагач, Рафаил Һадиевич ниндидер материалларын Үзбәкстан делегациясе аша Казанга юллаган дигән хәбәр дә бар. Бәлки, шулар арасында теге кулъязма да булгандыр...

Кызганыч ки, Дәрдемәнд китабын аңа бүләк иткән-итмәгәнлегемне хәтерләмим. 1997 елда без Рафаил Һадиевич белән Казанда очраштык, сөйләшеп тә утырдык. Шул арада ул карандаш белән җәһәт кенә минем портретымны да ясады һәм бүләк итте, ләкин 27 ел элек булган вәгъдәм дә, монография язмышы да хәтеремә килмәде, ул да искә төшермәде.

**Ренат ХАРИС**

# XVI ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ – XVIII ЙӨЗНЕҢ УРТАСЫНДА ИДЕЛ-УРАЛ ТӨБӘГЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕ

## Казан алынганнан соң, Урта Идел төбәгендәге мөселманнарның тормышындагы үзгәрешләр

Казан ханлыгы җимерелү Урта Идел төбәгендә яшәгән барча халыкларны тирән социаль тетрәнүләргә китерә. Төбәктә хәрби – воевода җитәкчелегендәге – идарә системасы урнаша, ханлык җирләре, идарә итәргә җиңел булсын өчен – Казан һәм Зөя өязләренә бүленә. Җирле халык вәкилләре, шул исәптән татарлар да, тылмач итеп яки төбәк дәрәҗәсендәге идарә эшләренә генә билгеләнә ала.

1552 елны Казан дәүләте башкаласын саклаганда, барча ир-атлар да диярлек һәлак була. Фәкать бер төркем яугирләр, Казансу буе ягында шәһәрне камалышта тоткан дошман гаскәриләрен таптап үтеп, котылып кала. Әсир итеп, Казан ханы Ядегәр һәм кырымтатарлы бер аксөяк кенә алына. Мәетләрне урам читенә өеп куеп, 4 октябрьдә «чистартылган юлдан» шәһәр үзәгенә Тәре йөреше уза, Иван IV тантаналы рәвештә Хан сарае янәшәсендә хәзерге Благовещение соборы урынын билгели һәм ашык-пошык өлгерткән Газап чиккән изгеләр Киприян һәм Устина, шулай ук Спас чиркәүләрен ачуда катнаша. Шул рәвешле 1552 елның 4 октябреннән Казан каласы православие рус шәһәренә әвереләдерелә (*Загидуллин И.К. Празднование в России покорения Казани во второй половине XVI – начале XX веков // Казанское ханство: актуальные проблемы исследования. Казань: Институт истории АН РТ, 2002. С. 5–71.*).

Көз көне элекке күләмдә ясак һәм Казан кирмәне гарнизонына кышка азык-төлек җыярга дип, дәүләткә буйсындырылган ясаклы авылларга чыккан яңа хакимият вәкилләре кискен каршылыкка очрый һәм төбәктә сугыш кабынып китә. 1552 елның декабрендә Иделнең уң як ярында (Тау ягы) яшәгән марилар баш күтәрә. Казан тирәсендә Тугай җитәкчелегендә отрядлар оеша, биредә татарлар, марилар һәм удмуртлар бергә хәрәкәт итә. Безнең максат «Казан сугышы» барышын тасвирлау булмаса да, марилар 1554 елның җәендә башлаган хәрәкәткә каршы Мәскәүдән килгән берничә полкның, Мишә елгасы буенда баш күтәрүчеләр корган кирмәнне җимереп, көзен Чулман елгасы буенча Уфа ягына таба 250 чакрым, Иделдән Нократ елгасына кадәр 200 чакрым аралыкта урнашкан тирә-яктагы авылларны яндырып үтүен, партизан отрядларының гаскәриләр белән күп тапкырлар сугышканлыкларын әйтеп китү урынлы булыр. Бу масштаблы сугыш кампаниясе вакытында 6 мең ир-ат һәм 15 мең хатын-кыз, бала-чага әсирлеккә эләгә һәм кол итеп, Мәскәү ягына куыла. Бу айларда Арча ягы һәм Нократ төбәге дә зур тетрәнүләр кичерә. Сугыш хәрәкәтләре 1557 елның апреленә, баш күтәрүчеләр хәлсезләнеп, каршылык күрсәтүне туктатканчыга кадәр дәвам итә (*Алишев С.Х. Тернистый путь борьбы за свободу (Соц. и нац.-освободит. борьба татар. народа. II половина XVI-XIX вв.). Казань, 1999. С. 12–18)*.

Исән калган һәм яңа хакимияткә буйсынырга теләмәгәннәр башка ханлыкларга кача. Мәскәү хакимияте, йомышлы булып, үзенә хезмәткә кергәннәрнең туган-тумачалары һәм туган халкы белән аралашуын һәм элемтәләрен өзү өчен аларга яңа

җир биләмәләрен чит төбәкләрдән бүлеп бирә *(Фирсов Н. Положение инородцев северо-восточной России в Московском государстве. Казань: универ. Типогр., 1866. С. 191).*

Кирмәннәрнең – хәрби объект, ә яңа хакимиятнең төбәктә азчылыкны тәшкил итүе мөселманнарның шәһәрләрдән куылуына, авыл халкына әйләнүенә китерә. Нәтиҗәдә күпгасырлык шәһәр мәдәниятенең үсеше туктала.

Беренче вакытта төбәкләрдә хакимият күзәтүен оештыру яңа кирмәннәр төзү юлы белән тормышка ашырыла. Әйтик, Зөя кирмәне 1551 елда Казанны алу өчен корылса, калганнары, нигездә, баш күтәргән төбәкләрдә төзелә, Тәтеш 1571 елда Кырым ханының Мәскәүгә һөҗүменнән соң пәйда була. XVI гасырның икенче яртысында төзелгән калган барлык шәһәрләргә дә хәрби максатларда нигез салына. 1573-1574 елгы баш күтәрүне бастыргач, Кокшай кирмәне, 1581–1584 елгы баш күтәрүчеләрне тар-мар иткәч – Санчура, Чуел, Царевококшайск, Уржум һәм башка кирмәннәр корыла (*Пашина Е.В. Город Тетюши: военно-административный и социальный аспекты истории «малого города» Среднего Поволжья (последняя треть XVI – I четверть XVIII вв.): дис. канд. ист. наук. Казань, 2017. С. 48–55)*. Шуңа да аларда хезмәт иткән йомышлы хәрбиләрнең һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр белән алмашынуы XVII гасырның икенче яртысына туры килә.

Кирмәннәр кору алар тирәсендә куркынычсызлык зоналары булдыруны да аңлата: җирле халык чит төбәккә күчерелеп, кирмәннәр яны рус йомышлыларына бирелә һәм аларга рус крестьяннары урнаштырыла. Казан кирмәне тирәсендә шундый куркынычсызлык зонасы иң зурысы булып, аның радиусы 30 – 40 чакрым тәшкил итә. Бик мөһим транспорт һәм сәүдә юллары саналган Идел, Чулман елгалары, шулай ук Зөя ярлары буенда урнашкан чуваш һәм татар авыллары кешеләре дә читкә күчерелә.

Хакимиятне ныгыту максатында төбәктә төзелә башлаган саклау сызыкларын коруга ясаклы татарлар, чувашлар, марилар, удмуртлар күпләп җәлеп ителә. 1578 елда Тәтештән Алатырга, аннан Темников һәм Кадомга, 1652–1657 елларда Сембердән Минзәләгә хәтле – Кама аръягы, 1648–1654 елларда Идел ярыннан Корсунга һәм Саранскига кадәр саклану сызыгы корыла.

Башлап, саклау сызыкларына Мещера төбәгеннән йомышлы татарлар күчерелә, алар артыннан Урта Идел буеннан ясаклы игенчеләр хуҗалыкларын корып җибәрә. Әйтик, 1631-1632 елларны Уфада күпчелеген Урта Идел төбәгеннән күченгән татарлар тәшкил иткән 8355 типтәр һәм бобыль хуҗалыгы булуы билгеле (*Исхаков Д.М. Этнотерриториальные и этнокультурные группы татар и их взаимодействие // История татар с древнейших времен. В 7 т. Т.5. Казань 2014. С. 226*).

Хакимияткә мондый күченүләр, әлбәттә, ошамый: аларны тыярга тырышалар. 1688 елгы патша указында, мәсәлән, көньяк-көнчыгыш төбәкләргә качкан рус крестьяннарын, ясаклы татарларны һәм мукшыларны эзләп табып кайтарырга боерыла (*Ногманов А.И. Самодержавие и татары. Очерки истории законодательной политики второй половины XVI – XVIII веков. Казан, 2005. С. 196*).

Мәскәү дәүләтенең Рус православие чиркәве тарафыннан корылган рәсми идеологиясе өчен ислам дине дошмани элемент була. Хакимият тарафыннан мөселман дин әһелләре танылмый, хокуклары билгеләнми, аларны бары тик патшага тугры булырга ант иттергәндә генә файдаланалар (Коръән үптереп, ант иттергәннәр). Халык кузгалышлары вакытында хакимият халык белән сөйләшер һәм яңадан ант иттерер өчен абызларны, ахуннарны җибәргән (*Лебедев В.И. Башкирское восстание 1704–1711 гг. // Исторические записки. Т.1. М., 1937. С. 96, 98-99).*

Мәскәү дәүләтенең кануннар җыелмасы – 1649 елгы Собор уложениесы – ясаклы кешеләрнең гореф-гадәтләрен рәсми рәвештә таный, аларның үз дини кагыйдәләрен саклап яшәү хокукын терки, төгәлрәк әйтсәк, моңарчы урнашкан тәртипне раслап куя. Мөселманнарның гаилә мөнәсәбәтләре, милек, мирас бүлү, нигездә, руханилар кулында саклана; шулай ук авылларда урнашкан гадәт буенча да хәл ителә. Үз дини кагыйдәләре

буенча яшәргә рөхсәт мөселманнарга гыйбадәт кылуда һәм дини белем алуда, уку-укыту өлкәсендә дә ирек булганны аңлата. Хәзер дингә кагылышлы барлык мәсьәләләрне авыл җәмгыятьләре хәл итә, авылда яшәгән абыз да шул җәмгыятьнең әгъзасы санала. Бер үк вакытта дин әһелләре хакимияткә лояльлек сакларга тиеш була. Аларга русларны һәм яңа чукындырылганнарны вәгазьләү тыела, бу гамәл өчен үлем җәзасы карала *(История Татарии в материалах и документах. М., 1937. С. 151, гл. XXII. ст. 24).*

Хакимият русларның торак урынынннан башка кавемнәрне читкәрәк урнаштыру ягын карый. Әйтик, 1593 елны Казан янында урнашкан Татар бистәсендә төзелгән мәчетне җимерүнең сәбәбе рәсми кәгазьләрдә русларны чит дин йогынтысыннан саклау өчен кирәк дип аңлатыла. Ягъни канунда язылган тәртип, православие динендәгеләргә якын яшәсәң, үтәлми башлый.

XVI гасырның урталарында «Казан сугышы» вакытында әсирлеккә эләккән һәм үлемнән котылып калу өчен чукынган татарлар, хакимият күзәтүе йомшак булу сәбәпле, берникадәр вакыттан соң ачыктан-ачык мөселманча яши башлыйлар.

1593 елдан башлап, мөселманнар һәм мәҗүси туганнары белән бер авылларда яки хуҗалыкларда яшәгән яңа чукындырылганнар аерым салаларга туплана башлый. Бу аларны ислам дине йогынтысыннан аеру өчен эшләнә.

Элек-электән Россия, Австро-Венгрия, Госманлы империяләренең хакимиятләре аз санлы этник төркемнәргә автономия гарантияләгән, ләкин сәяси буйсыну таләп иткән. Әйтик, Госманлы дәүләтендә азчылыкны тәшкил иткән халыкларның традицияләрен саклау тәртибе милләтләр системасы дип аталган. Әлеге система җирле халыкларга үз диннәрен тоту, гражданлык хокукы өлкәсендә шәхси автономиягә ия булу мөмкинлеген, туган телдә башлангыч белем алуны гарантияләгән. Бу халыкларның элиталары, руханилары белән хезмәттәшлек дәүләткә чит җәмгыятьләр өстеннән контрольлек итәргә мөмкинлек биргән. Әлбәттә, бу модельнең һәр дәүләттә үзенчәлекләре күзәтелә.

Татар морзаларын Мәскәү дәүләтендәге югары катлам саналган йомышлылар категориясенә кабул итү дә рус хакимияте һәм мөселман элитасы вәкилләре арасындагы хезмәттәшлекнең мөһим элементы була. Шул рәвешле Мәскәү дәүләтендә морзалар югары дәрәҗәләрен саклап калганнар һәм тугры хезмәт иткәннәр. Хакимият мөселманнарның дини тормышларына кысылмаган. Чиркәү тарафыннан чукындыру, асылда, сирәк күренеш булган, ә Европа өчен мондый хәл сәер саналган: чөнки Көнбатыш дәүләтләре үз халыкларына белем бирергә, шул исәптән христианлаштырырга да омтылган.

Россиядә, бигрәк тә чукындыру яки урыслаштырырга омтылу кампанияләре вакытында, «милләт системасына» хилафлык килгән. Чукындыруда сизелерлек нәтиҗәгә ирешә алмагач, дәүләт кабат элекке модельгә кайткан. Шулай да уңышка ирешкән төбәкләр дә булган – беренче нәүбәттә, XVII гасырның икенче яртысында дәүләтнең үзәк районнарында яшәгән йомышлы татар катламына кергән нугайларны чукындырганнар *(Черновская В.В. Очерки по истории татар в Центральной России в XV – XVII вв. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2020. С. 193).*

Хакимиятнең мөселманнар белән хезмәттәшлеге XVIII гасыр башында өзелә. Пётр I тарафыннан Россиянең киләчәген Көнбатыш илләре үрнәгендә кора башлау, мөселманнарга карата прагматизмга нигезләнгән дини түземлелек сәясәте кискен үзгәрешләргә китерә. Татарларны, Көнбатыштагы кебек, социаль һәм дини планда унификацияләү башлана.

1713 һәм 1715 елгы Указлары белән Пётр I, христиан динендә булган крепостной крестьяннарны тартып алу белән куркытып, йомышлы татарларны һәм морзаларны чукындырырга тырыша. Максатка ирешә алмагач, ислам динен тотучы морзаларга 1718 елны кораблар төзү өчен урман кисүне дәүләт йөкләмәсе итеп беркетә; 1724 елны, дворян сословиесенә кертмичә, крестьяннар катламына язып, татар элитасын юкка чыгара, халыкны игенчеләргә әйләндерә.

1721 елда Изге Синод оешу һәм Рус православие чиркәвенең дәүләт оешмасына

әверелүе чукындыру сәясәтен үзәкләштерелгән самодержавие-чиркәү хакимияте тарафыннан яңача тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

Мөселман динендәге ясаклы кешеләрне чукындыру максатыннан, Пётр I чукынганнарга кайбер өстенлекләр кертә. 1720 елның 1 сентябрь указы буенча алар 3 елга салымнар түләүдән һәм кайбер йөкләмәләрдән азат ителгән. 1724 елның 2 ноябрь указы буенча чукынган мөселман рекрутлык бурычыннан котыла.

Императрица Анна Иоанновна (1730–1740) идарә иткән заманда 1731 елда Зөя каласында «Яңа чукындырылганнар эшләре комиссиясе», 1740 елдан исеме үзгәртелгән «Яңа чукындырылганнар эшләре конторасы» («Контора новокрещенских дел») мәҗүси чуваш, мари, удмурт халыкларын һәм мөселманнарны, акчалата һәм киемнәр белән кызыктырып, шулай ук көчләп чукындыру белән шөгыльләнә. Империя хакимияте 1746 ел 12 декабрь указы белән төбәк халыкларын чукындырганда, көчләү алымнарын тыюны таләп итә, шундый ук таләп Сенатның 1760 ел 15 сентябрендә Казан, Рязань, Тубыл, Түбән Новгород, Нократ, Тамбов һәм Әстерхан архиерейларына атап язган указында да кабатлана *(Загидуллин И.К. Исламские институты в Российской империи: Мечети в европейской части России и Сибири. Казань, 2007. С. 63)*. Бу указлар төбәк хакимиятләренең чукындыруда басым ясау һәм мәҗбүриләү алымнарын киң кулланганлыгын раслый.

1747 елның 11 март указы нигезендә яңа чукынганнарның 3 елга азат ителгән салымнарын һәм дәүләт йөкләмәләрен алар янәшәсендә яшәүче мөселманнардан һәм мәҗүси диннәр тотучылардан түләтү тәртибе кертелә. (*Ногманов А.И. Күрс. хезмәт. 206 б.*). Бу указ җирле халыкларның күпләп чукына башлауларына сәбәп була, чөнки үз диннәрен тоткан өчен өстәмә салым түләү һәм рекрут бирү игенчеләрне бөлгенлеккә төшерә. Фәкать Батырша җитәкчелегендәге 1755 елгы восстание тәэсирендә дәүләт бу указны юкка чыгара һәм үз диннәрендә калган игенчеләрнең җыелып килгән 250 мең сумлык бурычлары (ул вакыт өчен бик зур сумма) кичерелә (*Алишев С.Х. Күрс. хезмәт. С. 41–50).*

1743–1760 елларда Урта Идел буендагы һәм Себердәге төбәк халыклары арасыннан 400 меңнән артык кеше, шул исәптән 12 меңнән артык мөселман православие динен кабул итә *(Ислаев Ф.Г. Ислам и православие в Поволжье XVIII столетия: от конфронтации к терпимости. Казань: Изд-во Казан ун-та 2001. С. 176-177, 214).* Чукындыру кампаниясе халык күңелендә рус хакимиятенә ышанмау тудыра, аның һәр яңалыгын, реформасын мөселманнарга каршы юнәлтелгән, алдау юлы белән аларны чукындырырга омтылыш буларак бәяләнә. Көчләп чукындыру сәясәте, шулай ук, татарлар арасында рус-православие мәдәниятенә тискәре караш калыплашуда, шул ук вакытта исламлашуның көчәюендә чагылыш таба.

Миссионерлар мөселманнарның күршеләре булган яңа чукынганнарга һәм мәҗүсиләргә тәэсире зур булуын «ачыклый», чиркәү әһелләре үзләренең беренче вакытта уңышсызлыкларын мөселманнар йогынтысы белән аңлата. Мәчетләрне бетерү, беренче чиратта, яңа чукындырылганнарны башка диннәр йогынтысыннан саклау өчен кирәк була.

Хөкүмәтнең 1742 елның 19 ноябрь указы нигезендә яңа чукындырылганнар яшәгән Казан, Әстерхан, Себер һәм Воронеж губерналарында «тыючы указларга карамыйча төзелгән яңа мәчетләрне» бетерү, бары тик мөселманнар гына яшәгән авылларда исә кайсы мәчетне җимерергә, кайсысын калдырырга икәнен хәл итү өчен ревизия үткәрелә башлый. Шушы указ нигезендә Казан губернасының Казан өязендә һәрбер авылда диярлек эшләп торган 516 мәчетнең 418 е (81 %), Себер губернасында һәм Тубыл, Тара шәһәрләрендә – 133 нең 98е (73,7 %), Әстерхан губернасында 40 ның 29ы (72,5 %) җимерелә, соңгысында фәкать чит ил кешеләренең ислам гыйбадәтханәләре сакланып кала.

1742–1744 еллардагы вакыйгалар мөселманнарның күп гасырлык дини тормышын какшата, хакимиятнең башбаштаклыгына зарланып һәм җимерелгән мәчетләрне

яңадан торгызу яисә яңаларын ачуны таләп иткән күпсанлы гаризалар языла. Сенат һәм Синод вәкилләренең уртак утырышында мәчетләр салу «кагыйдәләрен» эшләү кирәк дип табыла. Аларның фикер сөреше игътибарга лаек: әгәр дә мөселманнарның барлык мәчетләрен җимерсәк, бу аларның диннәре өчен зур кимсетү булыр иде, бу хәбәр ислам илләренә барып ирешсә, аларда яшәгән христиан динендәге кешеләрнең дә чиркәүләрен җимерүләре бар; татарлар рус императорына тугрылык турындагы антны ислам кануннары буенча мәчетләрдә бирәләр.

1744 елның 22 июнендә чыккан яңа канун буенча 200–300 ир-ат мөселманга бер мәчет салу рөхсәт ителә. Әгәр дә авылда ир-ат саны кимрәк икән, мәхәллә составына күрше авыл кешеләрен дә кертергә мөмкин була. Шулай итеп, мәчет биналарының бер өлешен яңадан торгызу җае чыга. Бер үк вакытта хөкүмәт яңа шартлар да куя: моннан соң мөселман дин әһелләре русларны һәм яңа чукынганнарны, шулай ук мөселманнар хуҗалыгындагы башка дин тотучы хезмәтчеләрне исламга тартмаска, авылларына килгән миссионерларга карата түземле булырга, диндәшләрен чукындыруга каршылык күрсәтмәскә тиеш.

Ул вакытта авыллар кечкенә булганга, яңа норматив, татар авылларында уртача ир-ат санын исәпкә алсаң, 3-4 җәмгыятькә бер мәчет төзергә мөмкинлек биргән.

Мөселманнар һәм христианнар яшәгән авылларда дини тормышны көйләү мәсьәләсе дә көн тәртибенә баса. 1756 елны Казан губернасы мөселманнары исеменнән Якуб Бимәтов Сенатка татар авылларының барысында да, аларның зур яки кечкенә булуларына карамастан, мәчет төзергә рөхсәт сорап, гариза юллый. 1756 елның 23 август указы Казан, Воронеж, Түбән Новгород, Әстерхан һәм Себер губерналарындагы төрле дин тотучылар яшәгән авылларда яңа мәчетләр төзү кагыйдәләрен төгәлләштерә. Элекке кагыйдәләргә өстәп, әгәр дә авылда яшәүчеләрнең уннан бер өлешеннән кимрәген христианнар тәшкил итсә, хакимият аларны руслар яки яңа чукындырылганнар яшәгән урыннарга күчерергә тиеш була. Шул рәвешле, авылда православие дине вәкилләре һәм мөселманнар янәшә яшәгәндә, биредә мәчет төзү мөмкин булмавы әйтелә. 1764 елда Казан губернасының 56 авылында 4964 мөселман һәм 601 яңа керәшен бергә яшәгәнлеге билгеле *(Загидуллин И.К. Исламские институты в Российской империи: Мечети... С. 66).*

## Ислам институтлары

Казанны алу ислам институтларына зур зыян сала.

***1.Руханилар***

Казанны саклаганда, сәед Кол Шәриф җитәкчелегендә руханилар, суфилар һәм алар белән янәшә баскан мәдрәсә шәкертләре шәһид китә. 1552–1557 еллардагы «Казан сугышы» һәм руханиларның бер өлеше аксөякләргә ияреп, башка ханлыкларга качып китү төбәктә мөселман дин әһелләре санын киметә.

Яңа сәяси вазгыятьтә мөселманнарга ислам тәртипләренең йогынтысы кысыла һәм кими, алар гаилә эчендә һәм авыл җәмгыятьләрендә дини ритуаллар үтәүдә һәм тәрбия өлкәсендә генә сакланып кала.

Православие Мәскәү дәүләтендә мөселман руханилары өстенлекле катлам булудан туктый, ягъни хакимият вәкилләре һәм халык арасында дәрәҗәләре төшә. Алар ясаклы татарлар булып, күбесе игенчелек белән шөгыльләнә, чөнки ханлык заманында мәчет-мәдрәсәләргә һәм руханиларга бирелгән вакыф җирләре Мәскәү патшасы милкенә әверелә, ә дини ритуаллар үтәгән өчен ясаклы мөселманнар биргән сәдака крестьян хуҗалыгыннан башка яшәргә мөмкинлек бирми.

Дәүләт кайгыртуының һәм вакыфларның юкка чыгуыннан иң зур зыянны руханилар әзерләүче мәдрәсәләр күрә. Шәһәрләрдән куылу аларны бинасыз һәм китапханәләрсез дә калдыра.

Казан төбәгендә яңа чукынганнарның ислам диненә кайтулары мәгълүм булгач,

Казан епархиясе архиепископы Гермоген (1589–1606) бу конфессиональ төркем вәкилләрен шәһәргә җыеп, алар белән сөйләшеп, аралашып, православие диненнән китү сәбәпләрен ачыклап, шуларны патша Фёдор Ивановичка юллый. Шушы документта Казан алынганнан соң беренче тапкыр авылларда ураза тоту, мөселманча яшәү, руханиларның халыкны ислам әхлагы буенча тәрбияләве, никах уку турында хәбәр ителә (*История Татарии в материалах и документах. М.: Гос. соц.-эк. изд-во, 1937. С. 148*).

Тарихчыларга 1612 елда Казан өязе Җөри даругасы Төрек Тәмте авылында яшәүче абыз «ясаклы чуваш» Кучкәй Мәрәтказинга бирелгән җирне аның улы «йомышлы татар» «Дусмәмәткә» тапшыру турында патша указы билгеле. Кучкәй Мәрәтказинны «абыз» дип язу бу шәхеснең Төрек Тәмте авылында дини йолаларны үтәүче булуын раслап тора. *(Чернышев Е.И. Народы Поволжья в крестьянской войне под предводительством С.Разина (1670–1671 гг.) /сост., авт. предисл. и прим. А.И. Амерханова; под. ред. И.К.Загидуллина; авт. предисл. И.К.Загидуллин. Казань, 2020. С. 90).*

XVII йөздә «абызлар» дип, ислам дине ритуалларын үтәү тәртибен белгән һәм башкарган, кирәкле Коръән аятьләрен яттан укыган, дини йолаларны вакытында үтәп, авыл җәмгыятендә дини дәвамчанлыкны тәэмин итәргә тырышкан – нигездә, укый-яза белән кешеләрне атаганнар. Р.Фәхретдин фикеренчә, алар арасында укый-яза белмәгәннәре дә булган. Бу термин Коръәнне яттан белүче мөселманны аңлаткан «Коръән-хафиз» сүзенең кыскартылган варианты дип уйланыла. *(Хабутдинов А. Абызы // Альметьевская энциклопедия – Абызы (tatneft.ru). Карау датасы 5.04.2022).*

Көньяк Уралда, Казакъ даласы белән чик буенча урнашкан төбәктә, хөкүмәтнең дини вазгыяте Урта Идел буена караганда йомшак була. 1630 елларга кадәр, күчмәннәр киткәнче, бу төбәкнең шактый зур мәйдандагы сахралары Нугай Урдасы җәйләүләре санала (*Рахматуллин У.Х. Население Башкирии в XVII–XVIII вв. Вопросы формирования небашкирского населения. М., 1988. С. 98, 143)*. Уфа өязендә яшәгән башкортлар күчмә яки ярымкүчмә тормыш алып бара, Урта Идел төбәгендәге ясаклы татарлардан аермалы буларак, күпкә аз ясак түли. XVII–XVIII гасыр башында Көньяк Урал төбәгенә күченгән татарлар руханилар җитәкчелегендә дини тормышларын тәртипкә салып, муллалар үзләре арасыннан ахуннар (1734 елда алар 10 ахун булып, барысы да Казан ягыннан килгән руханилар) сайлап, аларга рухани булырга теләгән кешеләрдән имтихан алу, мәчет төзергә рөхсәт бирү, мәхәлләләргә имам билгеләү, бәхәсле эшләрдә шәригать буенча телдән мәхкәмә карарлары чыгару вәкаләтләрен тапшырганнар. Ягъни хакимият күзәтүе йомшак булуыннан файдаланып, дини үзидарә булдырылган.

Руханилар баш күтәрүчеләрнең әйдаманы сыйфатында 1662–1664 елгы башкорт восстаниесендә күренеп китә. Җитәкче итеп чыңгызлыларны чакыру өчен Кырым ханы янына Кара-Дуваный Бакакый абыз китә. Актай Дусмөхәммәтов абыз исә рус гаскәриләре белән сөйләшүләр алып баруда катнаша. *(Франк Аллен Дж. Исламская историография и «Булгарская» идентичность татар и башкир в России /Пер. с английского. Казань, 2008. С.40).*

Степан Разин җитәкчелегендәге восстание вакытында Казан артында яшәгән халыкка Каратай авылыннан Иштирәк абыз хат яза һәм Иделнең ике як яры буйларында яшәгән морзаларны, татарларны һәм чувашларны баш күтәрүгә кушылырга чакыра. Бер үк вакытта С.Разин Семберне камаганда, Казаннан бер яхшы киенгән татар килеп, аны гаскәре белән Казанга килергә өндәп китә. С.Разин үзе 1670 елда Урта Идел төбәге татарларына мөрәҗәгатендә Казанның Татар бистәсендә яшәүчеләргә, мәчетләр «тотучы» барлык абызларга һәм мөселманнарга, Ишкәй һәм Мамай исемле муллаларга, Ханыш һәм Москов исемле морзаларга мөрәҗәгать итә, үзенең алар мәнфәгатьләрен яклавы хакында яза *(История Татарии в документах и материалах. С. 378).*

1681–1684 еллардагы мөселманнарның баш күтәрүе хөкүмәтнең Урал һәм Идел буенда мәҗбүри чукындыру турында патша Федор Алексеевичның 1681 ел 16 май указына каршы юнәлтелгән булып, динне саклау өчен «изге сугыш» рәвешен ала

(*Очерки по истории Башкирской АССР. Т.1. Ч.1. С. 118)*. Суфи Сәед Җәгъфәр җитәкчелегендә баш күтәргән халык, кирмәннәргә һөҗүм итеп, хөкүмәт гаскәрләрен җиңә. Хөкүмәт чукындыру турындагы указын юкка чыгарырга һәм Урал төбәгендә яңа епархия төзүдән баш тартырга мәҗбүр була. Руханилар, идеологлар буларак, авылдан авылга йөреп, халыкны куәтләп тора. Шундыйларның берсен хакимият 1682 елда Каракүл авылында кулга ала (*Франк Ален Дж. Күрс. хезмәт. Б. 40-41*).

1681 елда йомышлы һәм ясаклы православие динендә булмаган этник төркемнәрне берьюлы чукындырырга омтылу уңышсыз төгәлләнгәч, хакимият тиешле нәтиҗәләр ясый. Пётр I, беренче чиратта, морзаларны чукындыруга алына. Бу сәясәт фәкать яңа чукынган йомышлыларга гына өстенлекле катлам – дворян булып язылу хокукы бирүдә чагылыш таба. 1724 елда татар морзалары дәүләттәге түбән катлам – дәүләт крестьяннары итеп язылгач, моңарчы ясаклы кешеләрдән генә торган мөселман руханилары төркеменә дини гыйлем алуны һәм вәгазьләүне үзләренә һөнәр итеп сайлаган йомышлы татарлар да кушыла.

Даими үсеп баручы хәрби чыгымнарны каплау өчен Пётр I яңа салымнар кертә. Урал төбәгендә 1704 елда башкорт җәмгыятьләренең хосусый милке булып саналган иң зур күлләрне дәүләт файдасына тартып алу һәм халыктан 72 төрле яңа салымнар, шул исәптән, авылда мәчет булган өчен һәр мулладан бишәр сум, мәчеткә җәмәгать намазына килүче һәрбер мөселманнан – берәр алтын (3-6 тиен) күләмендә җыю турында игълан ителә.

Чиновникларның кызларыгызның никахы вакытында татар абызы янәшәсендә поп булырга тиеш, вафат булганнарны мәчет янына күмәргә кирәк дигән таләпләре дини хисләрне мыскыллау дип кабул ителә *(Материалы по истории Башкирской АССР. Ч.1. М., Л.: издательство Академии наук СССР, 1936. С. 110).*

Мөселманнар яңа салымнар түләүдән баш тарталар: 1704–1711 еллардагы *Тубылдан – Иделгә, Җаектан Чулманга кадәр төбәкләрне биләп алган* восстание башлана. Бу вакыйгаларда руханилар баш күтәрүчеләр ягында чыгыш ясый, кайберләре кулга алына. (*Франк Ален Дж. Күрс. хезмәт. С.43; Лебедев В.И. Күрс. хезмәт. С. 86–89).*

Көньяк Уралда Оренбург экспедициясе (1734 – 1737) оешкач, аның җитәкчесе Сенатның обер-секретаре И.К. Кириллов Урал буен колонияләштерү проектын эшли. Аның нигезендә көньяк-көнчыгыш саклану чиген төзү, регионны үзләштерү өчен үзәктән игенчелек һәм сәүдә-сәнәгать белән шөгыльләнүче халыкны тарту, башкорт сословиесен чик буйларын саклауда куллану каралган була.

И.К. Кириллов Россия империясендә татар руханилары белән хезмәттәшлек итүгә нигез сала. 1734 елда башкорт авылларында яшәгән берничә рухани аңа гаризалар белән мөрәҗәгать итә. Аларда сүз Зөя һәм Казан өязләреннән күченеп килгән һәм үзләре тарафыннан сайланган өч ахунны раслау, шулай ук шәригать буенча эшли торган мәхкәмә карарларын тану, ягъни Россиядә рәсми рәвештә шәригать мәхкәмәсен рәсмиләштерү, шулай ук ахунга Уфада урнашып һәм мәчет төзеп, үз эшләре белән шөгыльләнергә рөхсәт бирү турында бара *(Франк Аллен Дж. Күрс. хезмәт. С. 44-45).*

Кирилловка руханиларның халык арасында йогынтылы көч булуы ошамый. Ул мөселманнар санын арттырмасыннар өчен руханилардан гаепләр табып, аларны кырыс җәзага тартырга һәм Уфадан, Казаннан, янәшәдәге өязләрдән читкә сөрергә тәкъдим итә, мәктәпләрдән һәм мәчетләрдән, халыктан аерып, гарәп һәм фарсы телләре тәрҗемәчеләре итеп файдаланырга кирәк, дип яза (*Ислаев Ф.Г. Ислам и православие в Поволжье XVIII столетия: от конфронтации к терпимости. Казань: изд-во Казан. ун-та, 2001. С. 102*).

Оренбург экспедициясе оештырылуга бер ел да үтми, 1736 ел 11 февраль указы нигезендә яңа мәчет-мәктәпләрне фәкать хакимият рөхсәте белән төзү тәртибе кертелә. Шул ук указ белән Уфа өязендәге ахуннарның санын дүрткә калдырып, ант иттереп, һәрбер даругага берәү беркетелә, аларга башка конфессиональ төркемнәрне вәгазьләү катгый тыела. (Ләкин 1735–1740 еллардагы феодаль һәм милли изү көчәюгә җавап буларак, башкорт һәм татар баш күтәрүләре бу указны тормышка ашыруны беркадәр тоткарлый).

Шулай итеп, 1736 елдан башлап, Көньяк Уралда хакимият мөселман руханиларын рәсми рәвештә таный башлый. 1771 елда, мөселманнар мөрәҗәгатен исәпкә алып, Исет провинциясендә ахун вазифасы кертелә, бу вазифага 1767-1768 елларда Уложенная комиссия депутаты булган Габдулла морза Мөслимев билгеләнә *(Витевский Н.Р. И.И.Неплюев и Оренбургский край в прежнем его составе до 1758 г. Т. 1. Казань, 1897. С. 203).* Хакимият тарафыннан ахуннар билгеләнүгә мисал буларак, халык арасында «Батча ахун» исеме белән танылган Оренбург шәһәре имамы Ибраһим бине Мөхәммәд Түләк, Бохара казыйлары һәм мөфтиләренекенә охшатып, документларга кул куяр өчен зур мөһер файдалануы, анда имамның титуллары арасында «мөфти» дип язылганы да булуы күрсәтелә ала *(Мәрҗани Ш. Мөстафад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 237 б.).*

1735–1740 еллардагы баш күтәрү Тубылдан – Чулманга, Җаекның *урта агымыннан Көнгергә кадәр җирләрне биләп ала. Хәрәкәттә төп көч булып, гади башкортлар, татарлар торса да, чувашлар, марилар һәм удмуртлар да кушылган. Башкорт старшиналарының, тарханнарның һәм мещерякларның күбесе баш күтәрүне бастыруда катнаша. Моның өчен аларга җир биләмәләре белән акчалата бүләкләр һәм кайбер өстенлекләр бирелә.*

Баш күтәрүнең *беренче этабы (1735-1736 еллар)* Оренбург экспедициясенең Ор елгасы буенда кирмән төзү ниятенә нисбәтле башлана. Башлангычында Бәнәпи абыз һәм Елдаш мулла баш идеологлар һәм аны оештыручылар булып таныла.

Восстаниене бастыру барышында, 1738–1740 елларда, 10 мең башкорт көчләп чукындырыла, аларны үзләрен чукындыручыларга крепостной крестьяннар итеп бирәләр. Әмма хәрәкәт бастырылганнан соң, төбәк хакимияте «Новокрещенская контора»ның миссионерлык эшчәнлеген Уфа өязенә җәелдерүгә каршы чыга *(Франк Аллен Дж. Күрс. хезмәт. 46-47 б.).*

Хакимиятнең максатчан эшчәнлеге нәтиҗәсендә, 1730 еллар ахырыннан 1740 елларга кадәр Көньяк Уралда хәрби ныгытмаларның 41 кирмән, 39 форпост һәм редутлардан торган тармаклы челтәре төзелә. 1744 елда үзәге Уфа шәһәре булган Оренбург губернасы оеша. Оренбург экспедициясенең исеме үзгәртелеп, Оренбург комиссиясе дип атала башлый (1737–1744). Шуның җитәкчесе В.Н. Татищев сорауларына капитан Стрижевский биргән җавапларда татар һәм башкорт авылларындагы дини-мәдәни торышның уртак һәм аерымлы якларын күрергә мөмкин. Ул башкорт авылларында – ахун, мулла, абыз, ә мәчет булган торак пунктларында мөәзин һәм мәчет каравылчысы кебек дин әһелләре бар, ләкин мәчетләр сирәк күренеш, әмма барлык гыйбадәтханәләре дә җәмигъ; башка өязләрдәге татар авылларының һәммәсендә диярлек мәчет бар, анда җомга намазлары укыла; ахуннар руханиларны билгеләп куялар, дип хәбәр итә *(Ответы капитана Стрижевского (о башкирах) на программу В.Н.Татищева // Известия общества археологии, этнографии и истории. Т.XXV. Вып.6. С.166).*

Уралда заводлар, чик буйларында кирмәннәр төзү башкортларның вотчина җирләре кыскаруга китерә. Чиновникларның, үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, закон бозулары халыкта ризасызлык тудыра. Тиз хәл ителә торган административ һәм мәхкәмә эшләре берничә айлар каралмыйча, кешеләр ерак аралардан үз эшләренең торышын белү өчен берничәшәр тапкыр шәһәргә килергә мәҗбүр була, күп чыгымнар һәм вакыт сарыф ителә. Җирле хакимият вәкилләренең җинаятьләре, хәтта кеше үтерүләре турындагы шикаятьләр губерна администрациясендә исәпкә алынмый. 1736 елда Урал буенда мәчетләр төзүгә хөкүмәт контролен булдыру халык тарафыннан мөселман җәмгыятьләренең эчке эшләренә тыкшыну дип кабул ителә, ә Урта Идел буенда дәвам иткән көчләп чукындыру мөселманнарның Россиядә киләчәк язмышлары турында хәвефле уйларын көчәйтә.

Баш күтәрүнең төп идеологы һәм оештыручысы рухани, Себер даругасының ахуны итеп расланган Габдулла Галиев (Батырша) була. Ул дин әһеле (абыз) гаиләсендә

дөньяга килә, 1731–1744 елларда Тайсуган авылында, соңыннан Казан өязенең Ташкичү мәдрәсәләрендә суфи мулла Габдессәлам бине Урайда белем ала. 1744-1745 елларда Уфа өязе Гайнә волосте Илшә авылы мәдрәсәсендә укыта, 1746–1749 елларда – Оренбург губернасы Мөслим авылында, 1749–1755 елларда Себер даругасы Карыш авылында мулла булып тора, мәдрәсә тота.

1755 елның март аеннан башлап, Батырша восстаниегә әзерлек эшләре алып бара, эшне 1755 елның 3 июлендә башларга ният кыла. Әмма 15 майда Бөрҗән волосте башкортларының, башкаладан килгән файдалы казылмалар эзләү экспедициясе җитәкчесенең һәм аның хезмәткәрләренең рәнҗетүләренә түзә алмыйча, аларны үтерүләре хөкүмәт гаскәрләрен хәрәкәткә китерә: кулга алулар уздырыла.

Батырша «өндәмәсе» йогынтысында кабынган баш күтәрүнең чит төбәкләргә таралуыннан курыккан Оренбург генерал-губернаторы И.И. Неплюев 1755 елның сентябрендә Урал буена гаскәрләр чакырта, тиз арада фетнәне бастыруга, бер елдан качып йөрүче Батыршаны кулга алуга ирешә[1].

Килеп туган куркынычны тирәнтен аңлап, хөкүмәт тиз арада, 1755 елның 3-4 сентябрьләрендә татарларга һәм башкортларга карата милли һәм социаль изүне киметү турында ике канун кабул итә. Беренчесе буенча йомышлы татарлар һәм морзалар Казан губернасы администрациясеннән алынып, Казан адмиралтействосы конторасы карамагына күчерелә. Шулай ук кораблар төзергә урман кискән өчен түләү кертелә. Бу сумма хәзер аларның җан башыннан салынган салымын түләүгә китә башлый. Икенче Указ нигезендә яңа чукындырылганнар белән бергә яшәүче мөселманнарны чит урыннарга күчереп утырту туктатыла, мөселманнар белән бергә яшәүче яңа чукындырылганнардан килгән шикаятьләрне карау православие руханилары кулыннан алынып, дөньяви хакимият карамагына тапшырыла. 1755 елның 28 сентябрь Указы буенча мөселманнардан яңа чукындырылганнар өчен (алар 3 елга барлык дәүләт йөкләмәләреннән азат ителгәннәр) салымнар җыю һәм рекрутлар алу туктатыла. Яңа чукындырылганнар өчен түләнми калган салым бурычлары юкка чыгарыла. 1755 елга дәүләт крестьяннары, хәтта, бер елга җан башына салына торган салымнан азат ителә (*Алишев С.Х. Күрс. хезмәт. С.41–50).*

Оренбург губернасы чиновнигы П.И. Рычков 1760 еллар ахырында күпчелек татар авылларында үзе күзәткән бала тәрбияләү үзенчәлекләрен язып калдырган. Сәяхәтче татарлар балаларын кече яшьтән үк ислам дине кануннары нигезендә тәрбия кылганнарына игътибар иткән. Һәрбер авылда диярлек мәчет һәм мәктәп бар, мулла мәктәптә малайларны укырга, язарга һәм дин нигезләренә өйрәтә, кыз балалар да дини тәрбиядән читтә калмый дип мактап куйган *(Рычков П.И. Журнал или дневные записки путешествия капитана Рычкова по разным провинциям Российского государства 1769 и 1770 году. СПб., 1770. С.5).*

Рус галиме И.И. Лепехин 1770нче еллар башында Себер юлы белән сәяхәт иткәндә, Якуб авылында тукталгач, биредә зур бинада төрле төбәкләрдән җыелган балаларның дәрес укып утыруларына шаһит булган. Күпсанлы балаларның төрле авыллардан укырга килүләрен галим бу авылда яшәгән абызның гыйлемле кеше булуы һәм аңа укырга килгән яшүсмерләрнең максаты киләчәктә рухани булырга теләү, дип аңлаткан *(Гвоздикова И.М. Күрс. хезмәт. 187 б.)*.


*(Дәвамы бар.)*

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы*

[1] Батырша көчле сак астында Мәскәүгә, аннан соң Санкт-Петербургка озатыла. Аннан восстаниенең сәбәпләре турында язмача мәгълүмат бирүне таләп итәләр. Шул рәвешчә, аның 1756 елның 4–21 ноябрендә императрица Елизавета Петровнага аталган «хаты» языла. Тикшерү тәмамланганнан соң, Батырша Шлиссельбург кирмәне төрмәсенә ябыла. Ул 1762 елның 24 июлендә төрмә сакчылары белән бәрелеш вакытында һәлак була. Аның хатыны, бер һәм өч яшьлек кызлары 1755 елның декабрендә Санкт-Петербургка Яшерен комиссиягә китерелә. Биредә Батырша гаиләсе – хатыны Зөлхәбирә, кызлары Зөләйха һәм Салиха – чукындырыла, Батыршаның кызлары 1763 елда монастырьга җибәрелә *(Исլаев Ф.Г. Күрс. хезмәт.).*

*Рөстәм Мингалимнең тууына – 85 ел*

# «КАЙДА СЕЗ, ИРЛӘР?» ДИГӘН ИДЕ...



Татарстанның халык шагыйре, драматург, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рөстәм Гали улы Мингалимнең (1937–2014) тууына 85 ел тулу уңаеннан Татарстан радиосы, әдипнең якты рухын искә алып, тулы бер тапшырулар тезмәсе әзерләде. Август ае дәвамында эфирга чыга торган бу тапшыруларда әдипнең күпкырлы иҗатын чагылдыру максат итеп куелды. Иң әүвәлдә ул «Сердәшханә» һәм «Язучылар – балаларга» тапшыруларында балалар язучысы буларак күрсәтелде; аның «Ә сәгать келт-келт итә», «Уйланырга кирәк», «Төнге әкият», «Бәхетле исем», «Галстуклы кәҗә», «Их, Самара яклары» кебек җыентыкларындагы әсәрләре балалар укуында яңгырады.

Юбилей уңаеннан Рөстәм Мингалим шигырьләренә иҗат ителгән җырлар да концертларыбыз программасында үзәк урынга чыкты. Үз заманында халык тарафыннан яратып кабул ителеп, әле дә популярлыгын югалтмаган «Нәрсәне төшенмисең?» (Рәшит Кәлимуллин музыкасы), «Уйнык әле дулкыннардай», «Юл җыры» (Фасил Әхмәтов), «Күрмәдегез генә» (Ренат Еникиев) кебек җырлары танылган җырчылар һәм балалар коллективлары башкаруында әледән-әле эфирда яңгырап тора.

Әлбәттә инде, әдипнең юбилее уңаеннан әзерләнгән тапшырулар арасында сәхнә әсәрләре иң зур урынны алып тора. Чөнки беләбез, алар тыңлаучылар тарафыннан һәрвакыт күтәп алына, безнең эфирга популярлык бирә. Әлеге шәлкемдә иң беренче булып Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының «Кайда сез, ирләр?» спектакленең радиоварианты (режиссёры – Празат Исәнбәт, музыкаль бизәлеш авторы – Фуат Әбүбәкеров) тәкъдим ителә. Шулай ук Әлмәт Татар дәүләт драма театрының 1986 елда язып алынган «Кунак кызы гел килмәс» (режиссёры – Празат Исәнбәт, музыкаль бизәлеш авторы – Марс Макаров), Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының «Мин сине шундый сагындым» (режиссёры – Рабит Батулла) спектакльләре эфирга әзерләнә. Режиссёр Фәрит Җәләй тарафыннан әдипнең шигырьләренә нигезләнеп эшләнгән «Соңгы чиктә» дип исемләнгән шигъри драма да тыңлаучыларыбызны битараф калдырмас, дип өметләнәбез.

Хәер, үзен татар дип хис иткән кешегә бу әсәрләрне тыңлаганда, битараф калу мөмкин дә түгел, чөнки Рөстәм Мингалимнең фикере әле бүген дә өр-яңа, каһарманнары исән – безнең арада.

Журнал укучыларына тәкъдим ителә торган аудиоязмада без Рөстәм Мингалим шигырьләрен урнаштырдык. Аның беренче өлешендә шагыйрьнең үз тавышын ишетербез, аннары тагын берничә шигырь Тәлгать Хаматшин укуында яңгырый. Күңелләребезгә якты бирреп киткән игелекле каләм иясен искә алып тыңлыйк.

# ОЛПАТ МӨХӘРРИРЛӘР ЗАТЫННАН



Шагыйрь һәм әдәби тәнкыйтьче Наис Гамбәрнең тууына 75 ел тулды. Ул 1947 елның 25 августында Мөслим районының Бүләк авылында дөньяга килә. Үз авылларында – башлангыч, күрше Үрәзмәт авылында урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1966 елдан Мөслим районының «Авыл утлары» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли башлый. Газетада өч елга якын эшләү яшь журналистның каләмен чарлый: ул авыл кешеләре тормышы һәм хезмәте турында әдәби язмаларын, очеркларын, мәкаләләрен бастыра. Мәктәпнең югары сыйныфларында ук Казаннан килеп, бер ел үзләренә әдәбият укыткан яшь романтик шагыйрь Рәдиф Гатауллиннан (Гаташтан) «шигырь җене» кагылып калган Наис бу елларда да үзенең шигъри каләм тибрәтүен дәвам иттерә.

Әдәбиятка мәхәббәт 1969 елда Наисне Казанга, университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә алып килә. Университетны уңышлы тәмамлаганнан соң, яшь белгечнең матбугат өлкәсендәге дәвамлы һәм бәрәкәтле хезмәт юлы башлана. 1974–1978 елларда ул Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә мөхәррир булып эшли. Аның мөхәррирлегендә «Татар халык иҗаты» күптомлыгының беренче дүрт китабы, Таҗи Гыйззәт әсәрләренең өч томлыгы, Мөхәммәт Гайнуллинның XIX йөз татар язучыларына багышланган тарихи-публицистик китабы кебек җитди эчтәлекле, катлаулы басмалар дөнья күрә. Алга таба мөхәррирлек эше көндәлек матбугатның башка төрләре кысасында барса да, Н.Гамбәр китапчылык эшен гомеренең соңгы көннәренә кадәр дәвам иттерә килә: килешү тәртибендә шул ук Татарстан китап нәшрияты һәм «Рухият», «Милли китап» кебек хосусый нәшриятлар белән хезмәттәшлек итеп, алар чыгарасы күптомлыкларның, шигырь һәм проза җыентыкларының текстларын редакцияләү, басмаларын югары сыйфатлы итү юнәлешендә зур иҗади ярдәм күрсәтә. Наис Гамбәр үзе редакцияләгән басмаларга еш кына кыскача кереш сүз яки китап авторының тулаем иҗатын анализлаган тәфсилле кереш мәкаләләр дә яза.

Узган гасырның туксанынчы еллары башында «Татарстан» журналы редакциясендә җаваплы секретарь булып эшләп алганнан соң, Н.Гамбәр 1993 елда «Казан утлары» журналына эшкә күчә. Ул анда әүвәл җаваплы секретарь вазифаларын башкара, аннары гомеренең соңгы көннәренә кадәр редакциянең фән һәм сәнгать бүлеген җитәкли.

Наис Гамбәр күпмедер дәрәҗәдә остазлары Дәрдемәнд, Хәсән Туфаннарның шигъри традицияләре кысасында иҗат итүче дип әйтергә була.

Иҗатта һәм мөхәррирлек хезмәтендә ирешкән уңышлары өчен Наис Гамбәр 2000 елда «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек була.

Ул 2005 елның 4 маенда Казанда кинәт вафат була һәм туган авылы Бүләк зиратында җирләнә.

Әдипнең якты рухын искә алып, журнал укучылары игътибарына аның шигырьләре күренекле нәфис сүз остасы Айрат Арсланов язмасында тәкъдим ителә.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

Печән базары

*Сатирик әсәрләр*

# САЙЛАУ

ЮМОРИСТИК ХИКӘЯ

Совет заманында булган хәл бу. Чираттагы сайлау вакыты. Ул елларда райком тарафыннан 100 процент сайлауга килеп тавыш бирү һәм шул тавышның 99,99 проценты партия кушкан кандидатураны хуплау булырга тиеш чаклар. Булмаса – партбилет белән хушлаш, эш урыныңны бушат. Сайлау иртәнге алтыда башлана, төнге 12дә сайлау әрҗәләре ачыла иде. Галләметдин кичтән алашасына печән салып керде дә, карчыгы Мөхлисә каршысына утырып, тәмләп чәй эчәргә әзерләнде. Анысы чите китек чынаякка самавыр таҗыннан төшкән чәйнектән салам төсен генә хәтерләткән такта чәй агызып, өстенә сөт салып, карт алдына этеп куйды.

– Саранланмый гына һинд чәе салсаң да, яраган булыр иде, – диде карт, ризасызлык белдереп: – Бу чәйнең тәме тел төбендә дә калмый, эчтең ни дә, юк ни, – дип сукранып алды ул.

– Бик салыр идем дә, каян алыйм, юк, дифицит! Яңа елга дип тоткан бер әчмүхә чәемне теге атнада «очлап» куйдык.

Карчык үзе дә такта чәйне өнәп бетерми, төсе дә сөт салу белән соры-зәңгәр төскә керә, тәме дә тирес тәме гел, җанга ятмый, һинд чәе бөтенләй икенче! Чәйнектән ак төпле чынаякка куян каны кебек каракучкыл, куе сыекча башларны әйләндереп җибәрерлек хуш ис таратып агып төшә, аның өстенә «Карагатның» иртәнге куе сөте агач кашык белән пыяла банкыдан мул итеп чумырып алып, шуның өстенә салына, җәелә, чыжлап торган самавырдан кайнап торган су гөбердәп агып, шул сөтне чәйнең куе кызыл төсе белән кушып-кочаклап, әүмәкләтеп җибәрсә, менә кайда авызга эләгәчәк ләззәт тәме! Менә кайда дөнья рәхәте! Ә бүген!.. Кәеф киткән иде.

– Кая, карчык, чыгар әле теге көннән калганны, берәрне кагып куйсам, буыннарның сызлавы басылган кебек була, тизрәк йоклап китәрмен, – диде карт, карчыгына борылыбрак утырып.

– Кит әле, килешмәгәнне, сиңа әйтәм, иртәгә сайлау, исе килер комиссиягә.

– Китер, китер, иртәгәгә чаклы бетә ул, эшкә барасы юк. Эш беткән, көлтә бәйлисе генә калган, – диде Галләметдин, көрсенеп.

Шәп чаклары бар иде Галләметдиннең дә. Матур яшәделәр алар Мөхлисәсе белән. Эше шәп иде. Фермада малчы булып эшләү – дәрәҗәле хезмәт, акчасы күп булмаса да, арт сан астында атка җигелгән арба бар. Кирәк чакта кешегә ялынасы юк: утын-печән кайта, язлы-көзле бакча сөрелә, күрше-күләннең дә ялынычы-йомышы төшеп тора – дәрәҗә зур. Көзен иң беренчеләрдән булып «быт-быт» килеп торган иске «Беларусь» белән үрге оч Әсгать малае Өлфәт капка төбенә килеп туктый да: «Галләметдин абзый, Мөхлисә җиңги, пырнимай тауар», – дип, трактор әрҗәсеннән җиде-сигез капчык арыш, биш-алты капчык бодайны җилтерәтеп алып, капка төбендә калдыруы күңелдә тыеп торгысыз горурлык, шуның белән беррәттән үзеңнең кирәкле кеше икәнеңне, сине хөрмәт итүләрен тоюдан туган канәгатьлек хисе дә мин-минлекне үстереп җибәрә иде.

Ә Мөхлисәсе соң – Мөхлисәсе, яшь киленмени, өйдән очып дигәндәй чыгып, ашъяулыкларын, чыбылдык-чаршауларын, сугылган паласларын, җәймәләрен ихатадагы яшел үләнгә түшәп тә өлгергән, «озак бозауларга вакыт юк» – ашлык чилепешле, көннәр эссе торганда җилләтеп, киптереп алырга кирәк. Галләметдин эшне алдан күреп, печән беткәч тә, агач тырмаларын чормага менгерергә ашыкмаган иде әле – ашлык болгатырга кулай алар. Бу хәтле байлыкның берьюлы өйгә кергәненә сөенүеннән, аннан да бигрәк иренең булдыклылыгыннан горурлыгы ташкан Мөхлисәнең яшь чактагы кебек бит очлары алсуланган, яулык читеннән чыккан чәч бөдрәләре тирле маңгаена ябышкан, күзләрендә элекке кебек нур уйнап тора. «Мунча ягыла икән бүген кичкә», – дигән азгын уй да чагылып китте Галләметдиндә күңелен рәхәт кытыклап, ә аннан соң майлы коймакны һинд чәе белән «сыпыртып» куярбыз, Алла теләсә. Тик шунысы эчне пошыра: җитми генә бит шул чәй, кибеткә кайтса халык талаша-бәхәсләшә алып та бетерә, бер кулга ике әчмүхә – тышына төшерелгән филе зур да, савыты бәләкәй шул! Әйе, тырышып эшләде ул фермада, дүрт бала үстерделәр алар: ике кызы шәһәрдә ГПТУ бетереп, берсе – тегүче, берсе маляр булып эшли, кияүләре дә тырыш кына – шофёр хезмәтендә, һәрберсе бала-чага үстерү белән мәшгуль, бер малайлары армиядә калды, Монголиядә, марҗага өйләнде, кече малае – җан ярасы – егет булып җиткәч, суга батып үлде. Сирәк кайталар балалар да... Һәркемнең үз дөньясы, үз мәшәкатьләре.

– Ярый, түлке – бер кырлы, бүтән сорама, иртәгә сайлауга барасы, – дип, Мөхлисә сандык артына яшереп куелган башланган шешәдән кырлы рюмкага аракы койды. Галләметдин савытны түңкәреп куйды, ипи кисәген иснәп, артыннан чәен уртлады.

– Д-а-а, карчык, бар иде яшь чаклар, кесә тулы борчаклар!.. Исеңдәме, колхозның мине ял йортына озатканы?

– Истә булмыймы соң?! Ничә көн үгетләде профсоюз Әнисә: «Барып кайт, Галләметдин абзый, ял ит, туйганчы йокла, тәннәрең дәва алыр, дөньяны, кешеләрне күрерсең, бушка бит», – дип ялынды.

– Ялынды инде, путёвкасы янгач.

Мөхлисәсе дә: «Бар, булмаса, иртән шыгырдый-шыгырдый торасың, сөякләреңә дәва табарсың бәлки» – дигәч, кузгалды.

Башта берничә көн кызык булды аңа: зур ялгашка да салып «җебеттеләр», кулларына балчык та сыладылар, физкультура да уйнаттылар, ашаулары да тәмле, чәе дә һиндныкы иде, тик бик тиз ялыкты ул бу игътибардан, сый-хөрмәттән. Үз ягын, авылын, Мөхлисәсен сагынды. Аннан да бигрәк җигеп йөргән атын – кашка айгырын сагынды. Яшь килеш өйрәтте ул аны, дөресен генә әйткәндә – җигеләсе айгыр түгел иде ул, холыксыз булганга, тәртәгә кертү өчен генә бирде атны аңа персидәтел, аннан нигәдер айгырга кул селтәделәр, Галләмгә калды мал.

Ялның дүртенче көнендә төш күрде ул: мал врачы Нурлыгаян урак тотып, айгырын печәргә йөри Галләмнең, үзе сөйләнә: «Ат та юк, эш тә юк сиңа», – ди, имеш. Кара тиргә батып уянды ул. Иртәнге ашны да ашап тормыйча, районга бара торган автобуста кайтыр якка элдерде. Кайтуына айгырын печкәннәр иде инде. Мантый алмый озак йөрде Галләметдин.

– Сал тагын берәрне!

– Җитте, дидем, мин сиңа! Иртәгә сайлау!

– Булса соң, әйткәндәй, беренче мин барам сайлауга, беренче сайлаучыга бүләк тә әзерлиләр имеш: 10 әчмүхә һинд чәе, диләр, сал тагын берне, чәй – безнеке, төн йокламасам, йокламам, тик беренче – мин сайлаячакмын! Тиздән Яңа ел, бәйрәмчә булсын әле быел!

Икенче көнне сәгать биштә Галләметдин сайлау участогы урнашкан бинаның ишеген тартып караган иде инде. Ишек эчке яктан бикле. Ул ишекне кагып карады, дәшүче булмады, тәрәзәнең сүрән яктысында, эчтә кешеләрнең тегендә-монда

мәшәкатьле йөренүләре күренеп-күренеп киткәли иде. Төн шундый матур, чалт аяз күктә йолдызлар җемелди, аяк астында кар шыгырдый, клуб янында үскән агачтан тәңкә-тәңкә кар коела. Иртәнге зәһәр салкын куенга да үтә башлады.

Ул тагын ишек шакыды: «Кызлар, Галләметдин бабагыз бу, ачыгыз, салкын, сәгать тулганчы читтә генә торып торырмын, өшетә!

– Ярамый, әле унбиш минут вакыт бар, суык булса кайтып тор, бабай!

Юк инде, күбен көткәнне, әзенә чыдарбыз, әнә этләр өрә башлады, авыл уяна булыр. Ул арада үрге очтан резина итекләре белән туң карда тая-тая, көлешә-көлешә иртәнге савымга баручы дояркалар якынлашты. Алар туп-туры клуб күтәрмәсенә күтәрелде, шул минутта ук ишек ачылды, шаулаша-шаулаша төркем эчкә үтте, Галләметдин карт та аларга иярде, тик сайлау комиссиясенең әзмәвер кебек әгъзасы – физкультура укытучысы Сәлим, карт алдыннан үрелеп, ишек яңагын кулы белән киртәләде. Ул арада сыер савучылар бюллетеньнарын алып, әрҗәләргә төшерделәр, бүләккә дип әзерләнгән фил төшкән һинд чәйләрен алып, көлешә-көлешә чыгып та киттеләр.

Сәгать кичке алтыга тавыш бирү тәмамланып килә иде инде. Күрсәткечләр 99 процентка җиткән иде. Тик 100 процент түгел иде әле бу. Бүтән авыл советларында эш төгәлләнгән дияргә була, барысы да «ал да гөл», отчёт белән район сайлау комиссиясенә юлга чыгу өчен закон буенча сайлау әрҗәләрен ачарга төнге 12 сәгатьне генә көтәсе калган иде.

Сайлау комиссиясе өчен калхоз тарафыннан махсус суелган симез сарык итеннән пешерелгән ашын ашаганнан соң, авыл советы рәисе Казыйхан Нурлыгаяновичның кендек өстендә калган кеп-кечкенә бер бушлыгы бу хәлдән аңлатып бетерәлмәс бер аяусыз хәвефле борчылу белән тулды. Ничек кенә исемлекне чутлап карамасыннар, әрҗә янында дәфтәргә билге куеп утырган кызның тамгалары арасында аерма чыга иде: дебет-кредит тап килми: исемлектә барысы да исәптә кебек, тик бер бюллетень артып калган, кем алмаган? Киттеләр һәркемне барлап: кем килгән, кем килмәгән?

– Санияттәй килдеме, урын-җирдә диләр иде?

– Килде, үзем күрдем, кызы үзе бюллетенен төшерде.

– Мансур бабай аяксыз иде...

– Малае аның өчен сайлады!

– Фәтхиянең кич лавкадан кызыл аракы алып чыгып барганын күрдем.

– Сайлады, сайлады да туры магазинга кереп китте.

– Туктап торыгыз әле, Галләметдин бабай күренмәде...

– Килде ул, килде, иртән иртүк...

Тикшеренү китте һәм ачыкланды: бабай сайламаган! Өенә чаптылар. Урамда төн иде инде, Мөхлисә әби сукрана-сукрана: «Йөрисең диваналанып карт сантый, син хәзер кемгә кирәк, ят, йокла, дидем мин сиңа, вакытың үткән, эзләмә дөреслекне, яшьләрнеке замана, такта чәй дә ризык, син һаман: «Чәйдә түгел мәсьәлә, имеш. Кер, ят!» – дия-дия, ишек каләсен күтәрде. Хәлне аңлагач, куркып китте.

– Ике сәгать тирәсе элек Кәҗә урамыннан Хәбир кайнешенә барып кайтам дип, алашасын җигеп, төбендә калган шешәсен күтәреп чыгып киткән иде, – диде тегеләргә.

Авыл советы персидәтеле Казыйхан белән сайлау комиссиясе әгъзасы Сәлим Хәбир кайнеш йортына юнәлделәр. Сәгать кичке тугыз иде. Кичтән ялкау гына, нәзакәтле генә яуган кар, иреннән көнләшкән ярсу хатын шикелле чыгырыннан чыгып, котырып буранлый башлады. Башы брезент белән капланган, өч-дүрт хәрби хуҗасын, соңыннан әллә кемнәрен алыштырган «Уазик» буксовать итә-итә урыныннан кузгалды. Сайлау әрҗәләрен ачарга өч кенә сәгать вакыт калып бара иде. Хәбир кайнеш аларны мунчадан яңа чыгып килер-килешкә үгез муенына парлары бөркелеп торган сөлге ураган килеш каршы алды.

– Килде ул монда, булды, нигәдер бик тынгысыз, ачулы күренде, бераз төшереп алган иде бугай. Кемнедер тиргәде, кемнедер күз буяуда, икейөзлелектә, булдыксызлыкта,

эш бармауда, нәтиҗәдә һаман да Американы куып тота алмауда гаепләде, тик кемне гаепләгәнен аңлап бетереп булмады, чөнки теге шешә төбендәге аракыны, мин эчүдән баш тарткач, үзе «төпләп» куйды.

Кая киткәнен төгәл генә әйтмәде, күрше авыл «кореш»ларга дип мари авылы ягына юырттырды, – диде. Бу инде бик җитди хәл иде. Мари авылы 7 чакрым, тик нишләмәк кирәк: «Ятып калганчы – атып кал»: чаптылар күрше мари авылына. Урам буйлап Галләметдиннең корешын эзләп, тагын хәтсез вакыт үтте. Ярый әле авыл советында алар кебек сайлау үткәреп, әрҗәләрне ачу вакытын көтеп утыручы комиссиядән сорашырга башларына килде. Тегеләре уйлау, фараз итү, гөманлау юлы белән Галләметдиннең һәм күпер буе Әсхәпнең бергә флотта хезмәт иткән булырга тиешлеген фаразладылар, клуб идәнен юучы Памачны юл күрсәтү максатында аларга беркетеп, Әсхәпләргә җибәрделәр. Тик, иртә уңмаган, кич тә уңмас, кич уңмаган һич тә уңмас, дигәндәй, Галләметдиннең Әсхәп өеннән чыгып китүенә ярты сәгатьләп вакыт үткән иде инде.

Шактый кызып алган Әсхәп: «Ул – мировой мужик, гаделлек өчен көрәшә, ул күрше район корешларының хәлләрен белешергә китте, «Яшәсен социализм, долой капитализм!» – диде. Бу инде ахырзаман иде. Персидәтел Казыйханның күз алдыннан бер мизгелгә авыл хуҗалыгы техникумында мал врачына укучы улы Әнвәрнең әтисенең булдыксызлыгы өчен техникумнан «очып» чыгуы да, хатыны Нәсимәнең: «Җебегән!» – дип «ысылдап» ябышуы да, аннан да бигрәк авылга иреннән аерылып, яңа гына эшкә килгән фельдшер Машаның алсу ирен читеннән кинаяле елмаеп, күзен читкә яшерүен күз алдына китерү белән йөрәгенә пычак кадалган кебегрәк хис биләп алды. Машина күрше район чикләренә чапты. Буран кызганнан-кыза барды. Тирә-як гел ак өермәдән тора иде.

«Бетте, барысы да җимерелде», дигән уйлар өермәсендә иде Казыйхан-рәис. Кинәт каршыга буран белән бергә әкият албастысы шикелле зур иләмсез агач ташучы машина тулы йөк белән пәйда булып, «Уазик»ка терәлеп диярлек үтеп китте. «Уазик» калтыранып юл читенә очты.

Кабинадан чыккан юлчылар ушка киләлмичә бер тын сүзсез катып тордылар. Ә агач ташучы «тягач» туктау түгел, аларны күрмәде дә.

– Бетте, булды! – диде шофёр. – Казыйхан абый, машинаны чыгарып булырлык түгел.

– Кунабыз, эшне тапшырырга иртәгә районга барырга туры килә.

Юлчылар сүзсез генә җилдән качып, машина эченә елыштылар. Авыр тынлык урнашты.

– Тпру, Кашка, кемнәр монда? Казыйхан энекәш, син түгелме бу? – Машинаның көзгесенә дилбегәсен элеп, Галләметдин ишекне ачты. – Ни булды, Казыйхан энекәш?

– Булды инде, Галләметдин абзый. Тизрәк авылга кайтырга кирәк иде, үзең беләсең, сайлау тәмамлана...

– Мин дә шуңа ашыга идем дә, кореш белән морфлотта хезмәт иткән чакларны сөйләшеп утырып, соңга кала язганмын, әле вакыты узмадымы?

– Кырык биш минут вакыт бар.

– Күчегез Кашкага!

Юлчылар карга кереп баткан машинадан күчеп, чанага төялеште. Кышкы юл буйлап, дөньяның үткәне дә, бүгенгесе дә киләчәккә – алга җилдерә иде.

**Халисә МӨДӘРРИСОВА**

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## САХА (ЯКУТИЯ) РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КӨННӘРЕ

Хәбәр иткәнебезчә, Саха (Якутия) Республикасында Татарстан Республикасы көннәре булып узды. Шул уңайдан Якутскига ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә хөкүмәт, Дәүләт Советы вәкилләреннән, әдәбият-сәнгать әһелләреннән, эшмәкәрләрдән торган зур делегация килде.

«Үткән ел ТАССРның 100 еллыгы уңаеннан Татарстанда Саха (Яутия) көннәре узган иде. Бүген безнең җавап визиты. Без республикабызны лаеклы күрсәтергә телибез», – диде Рөстәм Миңнеханов Д.К.Сивцев-Суорун Омоллоон исемендәге Опера һәм балет театрында узган Татарстан сәнгать осталары концертында. Якутия халкын һәм кунакларны җөмһүриятебез белән таныштыру өчен киң программа тәкъдим ителде. ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Саха (Якутия) Республикасы башлыгы Айсен Николаев белән очрашты. Очрашуда сүз киләчәктә үзара хезмәттәшлекне тагын да үстерү турында барды. Рөстәм Миңнеханов Айсен Николаевка татар җәмгыяте (бүген монда 8 меңнән артык татар яши) эшчәнлегенә ярдәм итүләре өчен рәхмәт әйтте. Очрашу кысаларында А.Николаев Р.Миңнехановка Якутия АССР төзелүнең 100 еллыгы уңаеннан беренче медальне тапшырды. Бу көнне җитәкчеләр якут совет язучысы, галим Платон Ойунский һәйкәленә чәчәклар салдылар. Эш сәфәре кысаларында Р.Миңнеханов Якутскида Россия Инновация төбәкләре ассоциациясе утырышын уздырды, Саха (Якутия) Республикасының татар иҗтимагый оешмалары вәкилләре белән очрашты, Татарстаннан килгән халык һөнәрчелеге, «Татарларда кунакта» күргәзмәләре белән танышты, «Казан» скверын ачуда катнашты.

Саха (Якутия) Республикасының Меңге-Хангалас районы Мэлдьэхси авылы янында саха халкының милли каһарманы, 1920 – 30 елларда азатлык өчен көрәш әйдаманнарының берсе, милләт тарихында таш күтәрү һәм хапсагай көрәшендә тиңдәшсез батыр Боссоойкога истәлек тактасын ачу булды. Боссоойконың (1883 – 1930) чын исеме – Гыйззәтулла Рәхмәтуллин. Татар кешесе! Аның әтисе Гафиятулла бу якларга сөргенгә сөрелгән була. Аны бик хөрмәт итәләр, «Тулла татар» дип йөртәләр. Улы Гыйззәтулланы исә, ике метр озынлыктагы буе һәм көчле булганы өчен «Боссоойко» (зур) дип атаганнар. Язучы, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин әлеге шәхес турында «Боссоойко» дигән хикәя язды. Ул татар, якут, рус телләрендә басылып чыкты. Истәлек тактасын ачу тантанасында киләчәктә Боссоойкога һәйкәл кую һәм аның музеен төзү турында эшлекле сөйләшү булды. Чарада Рөстәм Галиуллин һәм Татарстан китап нәшрияты директоры урынбасары Илдар Хөснетдинов катнашты.

Саха (Якутия) Республикасында Татарстан Республикасы көннәре Ысыах милли бәйрәме белән тәмамланды. Аның кысаларында Сабантуй да булды.

Саха (Якутия) Республикасына язучылар Ркаил Зәйдулла, Факил Сафин, Фирүзә Җамалетдинова, Хәбир Ибраһим, Равил Сабыр, Илсөяр Иксанова, Рүзәл Мөхәммәтшин, Лилия Гыйбадуллина, Ленар Шәех та бардылар.

## ДЕРЖАВИННЫҢ ТУГАН КӨНЕНДӘ

Җәмәгатьчелек шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе Гавриил Державинның туган көнен билгеләп үтте. Аның Казандагы Лядской бакчасындагы һәйкәле янында тантаналы митинг булды. Анда ТР юстиция министрының беренче урынбасары Айнур Галимов, ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Россия Язучылар берлеге идарәсе рәисе Николай Иванов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова һ.б. чыгыш ясадылар. Соңыннан алар, шулай ук милли-мәдәни берләшмәләр вәкилләре, галимнәр, педагоглар, мәдәният әһелләре Державинның һәйкәленә чәчәкләр салдылар. Аннары бәйрәм рухы Державинның туган ягы Лаешка күчте. Район үзәгендәге мәйданда булып узган тантанада юриспруденция өлкәсендә Державин исемендәге премиянең быелгы лауреаты игълан ителде. Ул – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты кафедрасы җитәкчесе Елизавета

Демидова-Петрова. Аны ТР юстиция министры Рөстәм Заһидуллин белән Лаеш районы башлыгы Илдус Зарипов котладылар.

### «ТАТМЕДИА» АҖ САБАН ТУЕ

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең 15 еллыгы уңаеннан Саба районында Сабантуй үткәрелде. «ТАТМЕДИА» 2007 елның 1 октябрендә ТРның беренче Президенты Минтимер Шәймиев Указы белән оештырыла. Ул бүген 98 район, шәһәр һәм республика газетасын, 17 журнал, 19 телеканал, 14 радиоканал, интернетта 79 сайт, социаль челтәрләрдә 350дән артык профильне берләштерә.

ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов Сабантуйда массакүләм мәгълүмат чаралары баш мөхәррирләре белән очрашты. Ул тынгысыз булу, туктаусыз эзләнү, яңа проектларны гамәлгә ашыру зарурлыгын, укучыларны югалтмас өчен алар белән бергә булырга кирәклеген искәртте. «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков республикадагы гаммәви мәгълүмат чаралары редакцияләренә бирелгән грантларның файдалы проектларны гамәлгә ашыруда журналистларга зур ярдәм булуын ассызыклады.

Марат Әхмәтов журналистларны Сабантуй белән котлады. «ТАТМЕДИА»ның 65 филиалыннан килгән каләм ияләрен Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев та сәламләде. Ул көнне Сабаның Сабантуй мәйданын журналистлар кыздырды, төрле ярышларда катнашып, үзара көч сынашты. Катнашучыларның күплеге белән игътибар үзәгендә булган волейбол ярышларында «Казан утлары» белән «Ялкын» журналлары редакцияләренең берләштерелгән командасы – чемпион! Хезмәттәшләребезне котлыйбыз! Җиңүчеләргә акчалата бүләк бирелде. Сабантуйның төп бүләге – тәкәгә милли көрәштә абсолют батыр, «Шәһри Казан» газетасының баш мөхәррир урынбасары Фәрит Салихов ия булды.

### КИТАП ТӘКЪДИМ ИТҮ

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең конференцияләр залында язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе Ринат Мөхәммәдиевнең «Кыргый атауга сәяхәт» китабын тәкъдим итү булып узды. Бу – «ТАТМЕДИА» ярдәме белән «Казан утлары» журналы китапханәсе» сериясеннән басылып чыккан унөченче басма. Китап бәйрәмендә «ТАТМЕДИА» АҖнең генераль директоры Шамил Садыйков, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров, Татарстанның халык язучысы Нәбирә Гыйматдинова, Казан шәһәре эчке эшләр идарәсенең элекке җитәкчесе Нургаян Әкбәров, автор үзе һ.б. чыгыш ясады. Чараны әдәбият галиме Әлфәт Закирҗанов алып барды.

### СӘФӘРЛӘР

Быел язучы, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон Хаҗда булып кайтты.

* * *

Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев тагын таулы Алтайга сәфәр кылды. Ул мәңге кар түбәле Курай тауларын, Караташ кыясын, Алтын күлне, алардагы хозурлыкларны рәсемгә алган. М.Галиев сәяхәт вакытында төшергән манзара-күренешләрдән күргәзмә ачарга җыена.

* * *

«Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре – баш мөхәррир Рөстәм Галиуллин белән бүлек мөхәррире Рафис Корбан – Марий Эл Республикасының Бәрәңге районында әдәбият сөючеләр белән очрашуда булып кайтты. Казан кунакларын Бәрәңге муниципаль районы башлыгы Әлфит Ибраев каршы алды, Бәрәңге шәһәр тибындагы бистә китапханәсендә, Мазарбашы һәм Куян авылларында очрашулар узды.

### ХАЛЫКАРА БӘЙГЕ

IX Халыкара «Глаголица» бәйгесендә катнашу өчен әдәби эшләр 19 сентябрьгә кадәр кабул ителә. Әлеге иҗади конкурс нәтиҗәсендә Казанда иң яхшы яшь язучыларны ачыклаячаклар.

Бәйгедә татар һәм рус телләрендә язучы 10 – 17 яшьлек яшь иҗатчылар катнаша ала. 19 сентябрьгә кадәр бәйгенең сайтында теркәлергә, анкета тутырырга, конкурсның нигезләмәсен өйрәнергә кирәк.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман З.ХАКИМА «Сколько мгновений в часе?», повесть А.ЮНУСОВОЙ «Цветок мака», рассказ С.ШАМСИ «У деда Ашрафа»; поэма Г.БАТТАЛОВОЙ, стихи Р.НИЗАМИ, С.ЯКУПОВОЙ, А.СИТДИКОВОЙ.*
*«Новые имена»: рассказы И.ХАФИЗОВА.*
*Литературный конкурс «Майдан - для батыров»:*
*рассказ Г.ГИЛЬМАНОВА «Под батыром»*
*«Литература родственных народов»: стихи А.АКБАЕВА (в переводе З.ХАКИМА).*
*«Юбилеи»: интервью Л.АБУДАРОВОЙ с хазратом Х.САЛИХЗЯНОВЫМ.*
*статья Р.КУРБАНА к 90-летию Р.СВЕРИГИНА.*
*«Соплеменники»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«Соотечественник» : статья Л.НАСЫЙХОВОЙ.*
*«Книжный обзор»: статья Р.БАДРЕТДИНОВА.*
*«Память»: статья Р.ХАРИСА.*
*«1100 лет со дня принятия Ислама в Поволжье»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Бесценные голоса»: статья к 85-летию поэта Р.МИНГАЛИМА и к 75-летию Н.ГАМБАРА. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*«Сенной базар»: юмористический рассказ Х. МУДАРИСОВОЙ «Выборы».*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках:*
*Памятник Ш.Марджани на берегу озера Кабан. Скульптуру изготовил художник Рамин Нафиков по проекту Б.Урманче. Фото И.АБРАМОВОЙ; поэтесса, главный редактор газеты «Ватаным Татарстан» Гульнара САБИРОВА.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by Z.KHAKIM «How many moments in an hour?», story by A.YUNUSOVA «Poppy Flower», story by S.SHAMSI «At Grandfather Ashraf»; poem by G.BATTALOVA, poems by R.NIZAMI, S.YAKUPOVA, A.SITDIKOVA.*
*«New names»: stories by I.KHAFIZOV.*
*Literary contest «Maidan is for batyrs»:*
*story by G.GILMANOV «Under batyr»*
*«Literature of related peoples»: poems by A.AKBAEV.*
*«Anniversaries»: interview by L.ABUDAROVA with hazrat H.SALIKHZYANOV.*
*article by R.KURBAN on the 90th anniversary of R.SVERIGIN*
*«Tribesmen»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*«Compatriot»: article by L.NASIKHOVA.*
*«Book review»: article by R.BADRETDINOV.*
*«Memory»: article by R.HARIS.*
*«1100 years since the adoption of Islam in the Volga region»: article by I.ZAGIDULLIN.*
*«Priceless voices»: article dedicated to the 85th anniversary of the poet R.Mingalim and to the 75th anniversary of N.Gambar.*
*The column is led by N.AKMAL.*
*«Haymarket»: humorous story by H.MUDARRISOVA «Elections».*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers:*
*Monument to Sh.Marjani on the shore of Kaban Lake. The sculpture was made by the artist Ramin Nafikov according to the project of B.Urmanche. Photo by I.ABRAMOVA; poet, editor-in-chief of the newspaper «Vatanym Tatarstan» Gulnara SABIROVA.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Кабан күле ярында Ш.Мәрҗани һәйкәле. Скульптураны Б.Урманченың билгеле проекты буенча Р.Нәфыйков эшләгән. *И.Абрамова фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә, «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире Гөлнара Сабирова.